ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# Казан утлары

3.2010





**Мөхәммәт Мәһдиев**
**(1930—1995)**

**Казан утлары**

**Qazan utları**

2010

# 3

**(1049)**

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

**НАШИРЕ:**
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*
*Казан, Академия ур.; 2*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru
✆: **Факс**—(843) 562-11-28.
💻: **E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Мәдинә МАЛИКОВА. Юкә чәчәк аткан чак иде. *Роман.* ........ 5
Әхсән БАЯН. Гөмбәзеннән төшми сөю-ай. *Шигырьләр.* ........ 31
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Җәяүле сәйран. *Роман.* ........ 35
Сания ӘХМӘТҖАНОВА. Сафлану. *Шигырьләр.* ........ 84
Рифә РАХМАН. *Хикәяләр.* ........ 88
Әлфия СИТДЫЙКОВА. Иңнәремдә өмет-канат. *Шигырьләр.* ........ 100
МИҢНЕРУЙ. Гөмбәз бишегендә. *Шигырьләр.* ........ 102
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Исемнәре Искәндәр... *Хикәя.* ........ 104

**БӨЕК ҖИҢҮГӘ 65 ЕЛ**

Бөек Ватан сугышында катнашкан татар әдипләре. ........ 25

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Алисә ЗАРИПОВА. Күбәләккә тимәгез сез... *Шигырьләр.* ........ 113

**ҖАНИСӘП—2010**

Без—татарлар! *Фәнис ФӘТХИнең Илдар ГАБДРАФЫЙКОВ белән әңгәмәсе.* ........ 115

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Римзил ВӘЛИ. Батыр йөрәк шигърияте. ........ 120
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Илһам учагың сүрелмәсен. ........ 131
Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Татар трагедиясе. ........ 138

**МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

Әдипләребез фикерләре. ........ 145

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ........ 148

**ХӘТЕР**

Марсель ГАЛИЕВ. Ике урман чигендә. ........ 151

**СӘНГАТЬ**

Рифкать ВАХИТОВ. Әниләр-апалар турында. ........ 159

**ТАРИХ**

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Халкыбызның зыялы улы. ........ 164

**АК ЖИЛКӘН**

Илдус ХУҖИН. Яңа робинзоннар. ........ 169

**ГОМЕР ИТМЕШ, ДӨНЬЯ КӨТМЕШ...**

Тәлгат НӘҖМИЕВ. Парчалар. ........ 180

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 186

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: романы М. МАЛИКОВОЙ «И сад был в цвету», Р. МИР-ХАЙДАРОВА «Пешие прогулки», рассказы Р. РАХМАН, Ф. ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ; стихи А. БАЯНА, С. АХМЕТЗЯНОВОЙ, А. СИТДИКОВОЙ, МИННЕРУЙ.
«К 65 летию Победы»: «Татарские писатели—участники войны».
«Творчество молодых»: стихи А. ЗАРИПОВОЙ.
«Перепись—2010»: «Мы—татары!» Беседа Ф. ФАТХИ с И. ГАБДРАФИКОВЫМ.
«Литературная критика»: Римзил ВАЛИ. «Поэзия отважного сердца»; статья Т. ГАЛИУЛЛИНА к 60 летию Р. Низами; А. ЗАКИРЗЯНОВ. «Татарская трагедия».
«К 80-летию М. Магдеева»: Татарские писатели о творчестве М. Магдеева.
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
«Память»: статья М. ГАЛЕЕВА к 80 летию Х. Сарьяна.
«Искусство»: статья Р. ВАХИТОВА о художнице У. Ардашировой.
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«История»: статья Х. МИННЕГУЛОВА к 140 летию Ф. Карими.
«Белый парус»: И. ХУЗИН. «Новые робинзоны».
«Жить-поживать»: Рассказики Т. НАЗМИЕВА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина Л. ФАТТАХОВА и Х. ЯКУПОВА «Подписание декрета об образовании Татарской АССР» (1950), писатель Камил ТАНГАЛЫЧЕВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry: novels by M. MALIKOVA «And garden was in bloom», R. MIR-HAYDAROV «Hiking», stories by R. RAHMAN, F. ZAMALETDINOVA; poems by A. BAYAN, S. AHMETZYANOVA, A. SITDIKOVA, MINNERUY.
«To 65th anniversary of Victory»: «Tatar writers are participants in war».
«Creativity of youth»: poetry by A. ZARIPOVA.
«Census-2010» «Interview F. FATHI with I. GABDRAFIKOV.
«Literary criticism»: Rimzil VALI. «Poetry of brave heart», article by T. GALIULLIN to 60 th anniversary of R. Nizami, A. ZAKIRZYANOV. «Tatar tragedy.»
«To 80th anniversary of M. Magdeev: Tatar writers about creativity by M. Magdeev.
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages».
«Memory»: article by M. GALEEV to 80th anniversary of H. Saryan.
«Art»: article by R. VAHITOV about artist U. Ardashirova.
From pages of Tatar Encyclopaedia.
«History»: article by H. MINNEGULOV 140th anniversary of F. Karimi.
«White Sail»: I. HUZIN. «New Robinsons».
«To live happily»: short stories by T. NAZMIEV.
Diary of social-cultural life.
On our covers: painting by L. FATTAHOV and H. YAKUPOV «Signing of decree on formation of Tatar Autonomous Soviet Socialist Republic» (1950); writer Kamil TANGALYCHEV.

---

★ **Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.**
★ **Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
★ **Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.**

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 1.03.2010, график буенча 1.03.2010.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О–214. Тираж 5278.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

**«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.**
**Казан, Декабристлар урамы, 2**

**© «Казан утлары», 2010 ел.**



Мәдинә
Маликова

# ЮКӘ ЧӘЧӘК АТКАН ЧАК ИДЕ

**(НУРЗИФА)**

РОМАН

**Ант**

Дөнья шулай корылган инде ул: уены-чыны бергә. Ә уеннан уймак чыга...

Бу очракта да бөтенесе яшьлек шуклыгыннан башланды.

Сәнгать училищесының соңгы курс студентлары укуларын тәмамлап, шаулап-гөрләп, жырлап-биеп, чыгарылыш кичәсен үткәргәннәр иде инде. Дипломнар кулга керде, котлау һәм саубуллашу сүзләре әйтелде. Мона кадәр һәммәсе бергә атлап килгән киң юл серле сукмакларга таралды. Киләчәк ымсындыра да, бераз өркетә дә. Күңел каядыр ашкына, очына. Шул ук вакытта күнегелгән класслардан, остазлардан, аннан да бигрәк дуслардан, хәтта дошманнардан да аерыласы килми. Дүрт ел эчендә аның дошман дигәне дә күңелнең күләгәле бер почмагына кереп урнашкан була бит. Ансыз дөнья кызыксыз, аш та борыч сипкәч кенә тәмләнә.

Июль кичендә шундый алгысак күңелле ике егет остаханәдә дуслары белән очрашып, сөйләшеп утырдылар.

Шәһәрнең өске ягында, күбрәк фән-сәнгать әһелләре яши торган урамда, биш катлы йортның чормасындагы зур бүлмә иде бу. Остаханәнең төп хуҗасы, училищеның укытучысы, танылган рәссам Әгъләм Талипов җәйгә туган авылындагы йортына күчкән, ягъни натурадан табигать күренешләрен ясарга киткән иде. Биредә аның ике шәкерте, Мозаффар белән Хәнәфи калды, бу егетләрне рәссам күптәннән үз канаты астына сыйдырган иде инде.

Беренче булып Мозаффар килде. Аның култык астына калын коңгырт кәгазьгә төрелгән, бер метрга ярты метр чамасы зурлыктагы рам кыстырылган иде. Ул, ачык тышкы ишектән кереп өскә күтәрелде, бишенче катны узгач идәннән түшәмгә кадәр корылган калын тимер рәшәткә каршында тукталып калды. Рамын кырыйга куеп, джинсы чалбар кесәсеннән ачкыч алды да

Мәдинә МАЛИКОВА – *язучы; «Кар сулары», «Шәфкать», «Алтын ятьмә», «Өермә» һ.б. китаплар авторы. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

рәшәткә ишегенең зур эчке йозагын шыгырдатып ачты. Ул кергәч, ишек үзеннән-үзе ябылып, йозак челт итеп бикләнеп калды.

Чормада өч ишек булып, ян-яктагылары ике остаханәгә, каршыдагысы уртак коридорга ачыла иде. Төнгә остаханәләрнең хуҗалары гадәттә өенә кайтып китә, бинаның бу каты бөтенләй буш кала. Шуна күрә ана йортсыз-җирсез сәрхүшләр ияләнеп киткән иде: йозакны ватып керәләр, куналар, чәйнек, чынаяк, мендәр-юрган ише кирәк-яракны, кайчакта хәтта күз кунарлык дип тапкан картиналарны да үзләре белән алып китәләр.

Милициягә барып зарлануның да нәтиҗәсе сәер генә булды. Бер кичне, йөргән кызы Азалияне озатып кайтып барганда, тәрәзәдә ут күреп, Мозаффар анда кереп чыгасы итте. Ишек ачык иде. Ә эчтә, түр почмактагы карават янындагы тәбәнәк өстәл тирәли милиция киемендәге өч кеше утыра. Алларында бер шешә һәм хуҗаның чәй янына куя торган тәм-томы: чикләвек төше, өрек, йөзем... Сукбайларны куып чыгарганнар да, җылы урында үзләре бераз сусыннарын басып, хәл алырга булганнар икән...

Шулай әйле-шәйле болгана торгач, ахыр чиктә ун яктагы остаханәдә ут чыгарып, Карнаков дигән рәссамның күп еллык иҗат җимешләрен төтен иттеләр. Ярый әле, тиз арада янгын сүндерүчеләр килеп җитте, ут каршы якка күчеп өлгермәде, югыйсә танылган рәссам Талиповның шактый картиналары да, Мозаффар белән Хәнәфинең өйрәнчек эшләре дә юкка чыгачак иде.

Аптырагач-йөдәгәч, рәссамнар чормага менә торган баскычка аркылы менә шушындый, милиция «обезьяннигы»ндагы кебек рәшәткә корып куярга мәҗбүр булдылар да инде.

Мозаффар өскә ук менде дә, сул ишекнең йозагын ачты.

Эчтә остаханәләрдә генә була торган иркенлек, шул ук вакытта тәртипсезлек хөкем сөрә иде. Өч метрдан артык биеклектәге түшәм уртасында тузан сарган биш лампочкалы, арзанлы яктырткыч эленеп тора. Сул яктан, ике метр биеклектә тоташ уелган тәрәзәләрдән сибелгән яктылык стенага терәп куелган биек өстәлне, андагы кәгазь, каләм, буяуларны, озынча алюмин кюветны, диварларга өсле-өсле сөялгән рамнарны, түр почмактагы ятакны, аның янындагы тәбәнәк өстәлне һәм эскәмияне яктырта иде.

Мозаффар кулындагы рамны ураган нечкә бауны чишеп, кәгазен шытырдатып сүтте, аның эченнән буялмаган агач рамлы картинаны чыгарды да ишек янындагы диварга, тырпаеп торган кадакка элде. Аннары идәндәге рамнар арасыннан берсен алып, янәшә урнаштырды. Арткарак чигенеп, картиналарның әле берсенә, әле икенчесенә карап торды.

Астан шакылдау ишетелде, кемдер тимер рәшәткәне йодрыгы белән төя иде булса кирәк. Анда кыңгырау төймәсе дә бар-барын, әмма шактыйдан бирле эшләми, егетләрнең исә аны рәтләп куярга һаман кулы җитми иде.

Мозаффар җәлт кенә ишекнең икенче ягына элеп куелган кечкенә көзге каршына таба авышып, күпереп торган куе кара чәчен төкереге белән сыпыргалады. Ул, әлбәттә, кем килгәнен чамалый, һәм бик тә матур күренергә тели иде. Көзгедә исә кояшта янган түгәрәк чырай, чем-кара чәч белән яртылаш капланган киң маңгай, аңа бер бизәк өстәгәндәй борын өстеннән сызылган ике сыр, куе кара кашлар, шаян кысылган коңгырт күзләр, чиста кырынган булса да, каралып торган тыгыз яңаклар, кинчә борын, нык муен, көчле иңбашлар чагылды. Аның кыяфәтеннән рәссам икәнен чамалау кыен, ул яшьтән җирдә эшләп үсеп, балачактан үз ишләре белән сабан туе мәйданнарында көрәшергә өйрәнгән, озакламый механизатор яки агроном булып җитлегәчәк авыл егетенә охшаган иде. Килмәгән җире юк-югын, алай да шәһәр кызларын бер күрүдә кызыктыра торганнардан түгел. Ә аның исә кызыктырасы килә. Барысын да түгел, билгеле, арадан берсен. Һәм, аның уенча, нәкъ шул берәү бу минутта тимер рәшәткәне дыңгырдата иде булса

кирәк. Ачкычын оныткандыр. Андый галәте бар аның... Шулай уйлап, Мозаффар елмаеп ишекне ачты. Әмма рәшәткә артында ул көткән кеше түгел, өч егет басып тора иде. Озын буйлы, колак астына төшеп торган куе сары чәчле, Аполлон кебек камил гәүдәле җырчы Ансар Гыймадиев, буйга аннан бераз кайтышрак, сынга сыеграк җирәнсу бөдрәле шагыйрь Зөфәр Назиров һәм алар янында бөтенләй кечерәеп калудан курыккандай, башын югары чөйгән, кыска киселгән көлсу чәчен өскә тырпайтып лак белән катырган Хәнәфи. Кулында зур, калын кара портфель.

—Сәлам! Сәлам!

—Вәгаләйкем әссаләм!

— Рәссамнар кунакларны шушылай каршы аламыни?—диде җирәнсу бөдрә башын чөеп Зөфәр Назиров.

—Кунак көткән кеше юк әле монда!

—Ач тизрәк, мин чакырдым аларны,—диде Хәнәфи.

—Үз ачкычың кая соң?

—Кичә Зифа монда калган иде, ачкычымны онытып чыгып киткәнмен. Бүген җидедә киләм дигән иде. Мондадыр бит?

—Юк әле, килеп җитмәде,—дип йозакны ачты Мозаффар. Аның маңгаендагы ике сыр ихтыярсыздан тирәнәеп киткәндәй булды—Хәнәфинең сүзләре анда ризасызлык тудырган иде. Тегесе исә моны сизмәде кебек:

—Боларның мәнә синең диплом эшеңне күрәселәре килә, тәкатьләре корыган, —дип, шаян елмаеп, юлдашларына карап куйды.

—Сәлам! Шәп портрет ясагансың диләр, күргәннәр мактап туя алмый,—дип сөйләнде Зөфәр баскычтан менгәндә.—Ник аны бездән яшереп тотасың? Узган юлы да бер портретыңны безгә күрсәтеп тормыйча гына чит ил кешесенә сатып җибәргән идең. Чын дус шулай итәмени?

—Ничек итә?

—Соң бит бу—иң якын кешеләреңне зур сәнгать әсәренә карап ләззәтләнүдән мәхрүм итү, дигән сүз. Әллә каян, Прагадан укмы, кунак чакырып китергәнсең, ә безне искә алу юк! Мәнә мин һәр яңа шигыремне иң элек якын дусларга укыйм!

—Чакырып китергән кунак түгел иде бит ул,—дип акланырга тырышты Мозаффар.—Ул кеше заманында Әгъләм абый белән бергә укыган. Хәзер Прагада музей директоры икән, Казанга тәҗрибә уртаклашырга килгән. Юл уңаеннан курсташының остаханәсенә дә кереп чыкты. Шунда Әгъләм абыйның ике картинасы белән бергә минем дә бер портретны аласы итте. Шул гына.

Ансар авыр көрсенгәндәй кыланып:

—Әйе-е... Кайда да әшнәлек шул...—дип куйды.

—Әшнә дип кенә чит ил кешесеннән акча алырсың, бар!—дип аңа каршы төште Зөфәр.—Бер дә башканыкына түгел, Мозаффарның картинасына күзе кызган бит әле. Синекен дә алдымы соң?—дип, Хәнәфигә борылды ул.

—Ну... Минекеләрнең иң яхшылары монда түгел иде,—диде Хәнәфи читкә карап.—Училищега илтеп куйган идем... Имтихан биргәндә кирәк булдылар да...

Зөфәр аны тыңлап бетермичә, Мозаффарга борылды:

—Әйтәм бит мин сиңа, гениальный рәссам булачаксың, дип! Кызганыч, без ул портретны күрми калдык!

Шулай сөйләшә-сөйләшә алар остаханәнең бусагасын атлап керделәр.

—Кая ул портрет?—дип сорады Зөфәр.

—Менә монда.

Мозаффар ишек ягындагы диварга ымлады.

Егетләр борылып тынып калдылар. Карашлар яктырагына, ачыграк төсләр белән ясалганына төбәлде.

Картинада кышкы аяз көн тасвирланган иде. Төнлә кар явып узган,

күрәсең, күперенке көртләр өстенә кер кунып өлгермәгән әле. Әмма кар чем-ак түгел, урыны-урыны белән ул алсу, алтынсу, зәнгәрсу, яшькелт төсләргә манылган—күк читендә көмеш бөжра белән уралган кояш шулай яктырткан, көрт киртләренә шундый сихри шәүләләр төшергән. Алгы пландагы биек чуен рәшәткә әле генә лаклангандай ялтырап тора. Үрмәле агач ботаклары рәвешендәге бу борынгы рәшәткә егетләргә таныш иде: Язучылар йортының ихатасын әйләндереп алган ул. Арттарак, әнә, бинаның шулай ук борынгы, затлы, ачык яшел төскә буялган почмагы да күренә.

Рәшәткә янында ак башлык, ак тун кигән яшь кыз басып тора. Алланган йөзен күтәреп, биек агачка—мөгаен, юкә тармагына кунган песнәккә төбәлгән. Керфекләрендә—бәс, иреннәрендә куанычлы елмаю...

—Шә-ә-п,—диде сузып Зөфәр.—Акчам булса, хәзер үк сатып алыр идем... Ошаттыгыз сез безнең бакчаны. Кайчан карама, училище студентлары шунда рәсем ясап утыра. Ә бу кыз кем?

Монысына көлемсерәп Хәнәфи җавап бирде.

—Анысын эзләп тә ерак китмәде Мозаффар,—диде.—Безнең җыештыручы апаның кызы. Кайчакта килеп, әнисенә ярдәм иткәли.

—Бу инде җыештыручы булып кала торган гына түгел!—дип куйды Ансар.

—Әйе-е!—дип хуплады аның сүзен янә Зөфәр.—Март башы бит бу. Кар астыннан бөреләрнең сулышы саркый кебек... Мин шулай аңлыйм. Бу кызыкайның да күңел бөреләре ачылырга әзерләнә...

—Ә песнәк... Песнәк сайрый бит, тирбәлә!—диде Ансар.

—Миңа калса, мондагы манзараны кояштан бигрәк, шушы кызның йөзеннән сибелгән нур яктырта, —диде Зөфәр һәм Мозаффарга таба борылды:

—Каян аласың син бу төсләрне, мондый балкышны?

—Менә шушыннан,—дип Мозаффар тәрәзә астындагы биек, озын өстәлдәге зур гына алюмин кюветны алып күрсәтте. Кювет буш түгел, сулы булып, аңа эреле-ваклы, төрле төсләргә манылган кылкаләмнәр батырылган иде. Зөфәр аларга, болганчык суга гаҗәпләнеп карады.

—Нәрсә аптырадың?—диде Мозаффар көлемсерәп.—Корыда тотсаң, пумаланың буявы кибеп ката, шуңа суда тотам. Фәкать шул гына.

Зөфәр алсу төскә манылган кечкенә пумалачык-кылкаләмне судан чыгарып, кулында бөтергәләде.

—Татлы мизгелләрне шушының белән мәңгеләштерәм, димәкче инде син, ә?..

—Син бигрәк инде... Мәңгелек дигән булып... арттырып җибәрмисеңме?..— дип, әкрен тавыш белән, үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды Хәнәфи. Тик аңа илтифат итүче булмады.

—Ах, нилектән бөтен җиһан якты нурга төренде, нилектән соң минем җаным татлы назга күмелде, син елмаясың икән бит, син елмаясың икән...—диде Зөфәр, янә дивардагы портретка төбәлеп.—Дөрес әйтмисең син, Мозаффар! Хикмәт пумалада түгел, хикмәт менә монда!

Ул бармакларын җәеп, Мозаффарның ак футболка белән капланган күкрәгенә каты гына сугып куйды.

—Синең хисләрең менә шушыннан түгелә. Сызыклар, төсләр булып! Шигырь дә бит каләм белән түгел, күңел түрендә җилпенгән былбылларның канат очы белән языла.

Аннары ул бер адым артка чигенде дә, бил тинентен бөгелеп башын иде.

—Мин синең әсирең!

—Әсир алырга җыенган кеше юк әле монда!

—Ә мин менә бирелəм... Чөнки мондый гүзәллекне болай камил итеп тасвирлый алмыйм! Гомумән, рәссамнар каршында бөтен шагыйрьләр

исеменнән баш иям! Сезнең кылкаләмегез—безнен каурый каләмнән көчлерәк!

—Кайсы яктан карыйсың бит!—дип куйды Ансар.—Мин, мәсәлән, Мозаффарның картинасын җырлый алмыйм... Ә синең шигырьләрне көйгә салып җырлап була. Әллә алар күңелләрне кимрәк кузгатамы?

Һәм сүзләрен раслап, җырлап җибәрде:

Син уемда—уйлар чакларымда,
Уйда—уйламастай чакта да,
Сылу сының һәрчак хәтеремдә:
Син биектә һаман, ак тауда...

Аның көчле, җанга ятышлы тенор тавышы иркен остаханәнең диварлары арасында бәргәләнде.

—Син кайсы кызга атап язган идең бу җырны?

Зөфәр тураеп аңа төбәлде.

—Чыннан да... Ул бик гүзәл иде...

—Менә күрдеңме,—дип, аның җилкәсеннән каккалады Ансар.—Мозаффарның үз гүзәле, синең үзеңнеке. Мондый җыр язган шагыйрь беркем каршында да башын иярга тиеш түгел!.. Ә бусы кем эше?—дип янәшәдәге портретка ишарә ясады ул.

Анда, борынгы рам эчендә, шулай ук борынгы буяулар белән хатын-кыз тасвирланган иде. Ул ике кулын баш астына салган да, йөзен тамашачыга борып, чалкан яткан, ефәк күлмәге нәфис тәненә сыланып тора.

—Монысы мировой шедевр,—дип сүзгә катнашты баядан бирле дәшми торган Хәнәфи.—Моннан ике гасыр элек яшәгән испан рәссамы Франсиско Гойяның картинасы.

—Сезгә каян килеп керде ул?..—диде шаккатып Ансар.

—Чынга охшаганмыни?—дип, астыртын көлемсерәп, сорауга сорау белән җавап бирде Хәнәфи.—Күчермә ул. Мозаффарның эше.

—Син аны кайда ясадың?

Егетләр Мозаффарга төбәлделәр.

—Альбомнарда фотосурәте бар бит. Астында бик тәфсилләп бирелгән аңлатмасы...—диде Мозаффар.—Безнең Әгъләм абый кулны күнектерү өчен классик әсәрләрнең күчермәсен ясарга куша. Мин менә шушыны сайладым.

—Плагиатлык булмыймы соң бу?—дип куйды Зөфәр.

—Астына «Күчермә» дип язып куелган ич.

—Безнең эше кешенең аны чынга алуы да ихтимал,—диде Ансар.

—Мондый әсәрләр гади бәндә кулына керми,—диде Хәнәфи.—Рәтен белгәннәр аңлый... Менә минем диплом эшенә мондагы комиссия дүртле генә куйды да бит, аңлаган кешеләр кадерен белде, сатып та алдылар.

Хәнәфи, Түбән Кама егете, патриот буларак, диплом эшенә тема итеп, сәнәгать күренешләрен сайлаган—завод торбалары фонында машина тәгәрмәче тоткан бер егетне тасвирлаган иде. Заводныкыларга бу бик ошады, картинаны андагы мәдәният сараеның алгы залына элеп куярга тәгаенләдылар. Хәер, елгыр егет бу хакта андагылар белән алдан ук сөйләшеп куйган иде, билгеле.

—Акча бирделәрме әллә? Каян алганнар? Шиннарын юл буена басу тутырып тезгәннәр, алучы юк икән бит!—диде Ансар. Ул районнарда концертлар куеп күп йөри, шунлыктан дөнья хәлен дусларыннан яхшырак белә иде.—Заводларда эш хөртиләнде бит хәзер!

Чыннан да СССР дигән империя таркалып, илдә хәлләр нык үзгәргән, завод-фабрикаларда эш тукталган, эш кешесенең хәле көннән-көн авырая барган чак иде бу.

—Әйе, болгаттылар дөньяны...—дип бөдрә башын кашып куйды Зөфәр.—

Беркемнең беркемгә кирәге калмады.

—Башың эшләсә җае табыла!—дип серле көлемсерәде Хәнәфи.—Мина менә «КамАЗ» шиннары белән түләделәр.

—Нишлисең алар белән?—диде гаҗәпләнеп Зөфәр.—«КамАЗ»ың бармы әллә?

—Нәрсәгә миңа «КамАЗ»? «КамАЗ»лы дуслар күп лә минем! Әйдәгез, шуларга рәхмәт әйтеп, уңышларны юыйк әле! Мин Мозаффар кебек саран түгел, ул, әнә, долларларын йома, безне сыйлап тормый. Аннан үрнәк алмагыз, минем кебек булыгыз!

— Сез ике дус, ике пумаладаш...—дип Ансар сүз башлаган иде, Зөфәр, кашын җыерып:

—Пумалабаш дисеңме?—дип аны бүлдерде.—Нишләп пумалабаш булсын? Буяудашлар алар, буядашлар! Чыннан да, рәссамнар шундый бер уртак атамасы булырга тиеш бит инде. Без—шагыйрьләр, әдипләр—бер-беребезне каләмдәш дибез, ә рәссамнар «буяудаш» булсын. Шәп бит! Берегезне алып, икенчегезне куя торган түгел, һәркайсыгызның үрнәк булырлык яклары җитәрлек!

Бераздан егетләр түрдә, тәбәнәк өстәл янында гәп сатып утыралар иде инде. Хәнәфи буаз портфеленнән зур-зур ике шешә сыра, җиде йөз илле граммлы бер шешә портвейн, бер шешә су чыгарды.

—Кайсыгыз ни эчә?

Зөфәр портвейнга карап, борынын җыерды.

—Шин исе килми микән моннан?

—Мин аны кибеттән акчага сатып алдым,—диде саргылт кашын җыерып Хәнәфи.—Акчаның исе юк, диләр!

—Дипломнарыгызны шушының белән генә юабызмыни?—диде Ансар.

—Яхшырагын Мозаффар куяр. Халыкара мәйданга ул чыкты бит. Минем районга киткән картина өчен монысы да бик җиткән.

Чынаякларны бушатып, капкалап алганда, сүз яшь рәссамнарның киләчәк язмышы турында барды, билгеле. Хәнәфине Түбән Камага чакыралар, яхшы гына эш хакы да вәгъдә итәләр. Хәзергә шиннар белән түләячәкләр икән, бу заманда анысы да ярап тора... Әмма ул әлегә ныклы бер карарга килмәгән иде әле. Казанны да ташлап китәсе килми, алга таба укысаң да яхшы булыр иде. Тик менә керә алуына ышанычы юк...

Мозаффарның исә һәммәсе хәл кылынган: ул Мәскәүгә китә—Суриков исемендәге училищега укырга керәчәк.

Шешәләрне бушатып, Әгъләм абыйның чәй янына куя торган чикләвек төше, печенье ише тәм-томы белән тамакны алдап, аны-моны сөйләшкәннән соң, кузгалыштылар һәм, ишеккә борылгач, янә теге ике портрет каршына килеп бастылар.

—Теләсә ни әйтсеннәр, минем карашка монысы шәбрәк,—диде Ансар, «Кыш ахыры»на ымлап.

—Шәп шул!—дип аның сүзен җөпләде Зөфәр.—Яшьлек бөресенең ачылырга омтылышы, хисләрнең уянырга әзерлеге. И-их, кызы ла кызы! Гомеренең җаендә нинди булыр икән? Мозаффар! Син бит монда сүнми-сүрелми торган хисләрнең яралуын тасвирлагансың! Баштанаяк гашыйк син бу гүзәлкәйгә! Аның утларында янып гомерең узачак, шуны бел! Идеалың, рухландыручың, Музаң ул синең!

Ансар мәгънәле көлемсерәп өстәп куйды:

—Натурщицасы ул аның...

—Дөрес!—дип аның сүзен җөпләде Зөфәр.—Син гомерең буе аны тасвирлаячаксың! Рембрандт Саскияне тасвирлаган шикелле! Ах, тәне тулышып тибрәнә башлагач, күнел кыллары сөю көен көйләгәндә ни төсле итеп тасвирларсың икән син аны?

—Әйе, чишендергәч нинди булыр икән?—дип, тагын үзенекен кыстырып куйды Ансар. —Рәссамнар ул яктан бәхетле бит алар. Безнең эше түгел. Мин гашыйк булсам, нишли алам? Каршысына басып, җырлап җибәрсәм генә инде. Ә син шигырь сөйлисеңдер. Беребез дә аңа тора салып кына, чишен, дип әйтә алмыйбыз. Ә рәссам чишендерми калмый... Менә бит!—дип почмактарак торган рамга бармагы белән төртеп күрсәтте ул. Анда күзне ерта торган кызыл тәнле, артык нечкә билле, таза арт санлы бер хатын бу якка аркасын куеп кырын яткан иде.—Монысы да синекеме әллә?..

Соңгы сорауда гаҗәпләнү чагылды.

—Анысы минеке,—диде Хәнәфи теш арасыннан. Егетләргә аның рәсеме ошамаганы сизелә, бу—аның күңелен тырный иде.

—Моны син шул кыздан ясадыңмы әллә?!

—Училищеның натурщицасыннан... Зифаны тиз генә чишендерә алмассың!

Хәнәфинең бит очлары кызарып чыккан, ирennәре кысылган, соры күзләре сәер ялтырый иде.

—Ах, Зифамыни! Исеме җисеменә мач килгән икән!—диде Ансар Мозаффарга таба борылып.

—Чын исеме Нурзифа аның,—диде Мозаффар. Аның да йөзе үзгәреп, ничектер җитдиләнеп китте, хәтта тавышы да калтыранып чыкты шикелле.

—Нурзифа-а-а,—дип сузды аңа текәлеп Зөфәр.—Моңарчы ишеткән юк иде. Ә нинди матур исем! Нурлы да, зифа да... Ә бәлки, ул чыннан да дөньяда бердер! Һәрхәлдә, Мозаффар дускай, синең өчен шулай... Күренеп тора: тозакка нык капкансың. Болай булгач аны ясап гомерең узачак инде. Син аны яшьлегендә Боттичеллиның «Яз»ы төсле итеп, аннары Рубенс манерасында... Аннары Рембранд стилендә... Яңа «Даная» иҗат итәчәксең!

—Һәм аны безнең милли музеебызга куярлар. Кеше күңеленә шундый көчле тәэсир итә торган булыр ул, күпләр аны карарга кат-кат килер...

—Һәм берәрсе, йөрәгенә чыдый алмыйча, кислота китереп сибәр. Хәнәфи, син ничек уйлыйсың?

Шагыйрь белән җырчы хихылдашып куйдылар. Нәкъ шул көннәрдә газитләр Рембрандтның Эрмитаждагы «Даная»сына кемнеңдер кислота сипкәне хакында язган иде.

—Бу муза синең яныңнан да узгалыйдыр, күрми үтәсеңдер,—диде Ансар Зөфәргә карап.

—Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе—ботак тишеге...

—Менә шул-шул. Күңел күзләрен киң итеп ача шул ул чын сәнгать әсәре.

—Әллә син моны чын сәнгать әсәре дип беләсеңме? Шедевр язу өчен безгә укырга да укырга, өйрәнергә дә өйрәнергә әле!—диде Хәнәфи.—Зәвык җитми шул сезгә, егетләр. Бөек әсәрне уртакулдан аермыйсыз. Беләсегез килсә, Гойяның картинасы миллионлаган доллар тора. Аңа да сатып алып булмый, чөнки Испания хөкүмәте аның әсәрләрен илдән чыгарырга рөхсәт итми. Ә үзенекен Мозаффар йөз долларга биреп җибәрде.

—Туктале, тукта,—диде төпченергә яратучы Ансар.—Миллионлаган доллар тора, дисең... Сатып җибәреп булмыймы соң моны?

—Эшләнеп бетмәгән әле ул,—диде Хәнәфи.

—Кай җире?

Хәнәфи аяк очларына басып картинаны алды да, рамын каергалады. Астан икенче рам килеп төште, аның киндеренә грунт кына салынган, рәсем ясалмаган иде.

—Бусы нәрсәгә тагын?—дип сорады Зөфәр гаҗәпләнеп.

—Гойяның картинасы ике катлы бит аның. Өстәгесендә күлмәк кигән

хатын, астагысында күлмәгән салгач...

—Нишләп анысын ясамадың?—дип Мозаффарга төбәлде Зөфәр.

—Җитешеп булмады әле.

—Җитеш син аңа тизрәк!

—Һәм сатып җибәр,—дип шагыйрьнең сүзен дәвам итте Ансар.—Хәер, күчермәнең бәясе ташка үлчимдер инде анын...

—Ә ник анын күчермә икәнен әйтеп торырга?—диде Хәнәфи. Анын соры күзләре майланган иде.—Экспертлар гына аера бит аны. Алар да алдана икән әле. Күптән түгел телевизордан сөйләделәр: бик күп музейларда оригинал урынына күчермәләр эленеп тора, ди. Байларның затлы сарайларындагыларын әйтәсе дә юк. Күчермәләрне чын дип сатып, череп баеган кешеләр бар. Бездә дә сәнәктән көрәк булып баеп китүчеләр ишәйде, шуларның берәрсенә сыларга булыр иде дә бит...

—Берәр җитмәгән җире бармы әллә?

—Моның әле киндере, буяулары үзебезнеке генә. Борынгыча ясалганнарын файдалансаң, Мозаффарның күчермәсен чынынннан экспертлар да аера алмас иде. Алай да моның белән бәйләнергә ярамастыр.—Хәнәфинең нык уйланганы йөзенә чыккан иде.—Бик мәгълүм әсәр. Югалган шедеврлар да күп бит, шуларны ясарга булыр иде...

—Югалган әйбердән күчермә ясап буламыни?

—Репродукцияләре бар бит аларның. Әнә, теге альбомда тулып ята,—дип ятактагы калын альбомга ымлады Хәнәфи.

—Акылдан шаштыгызмы әллә, җинаять ич бу!—диде кашын-күзен җыерып Мозаффар.

—Нинди җинаять булсын ул? Кешенең менә шушы сурәткә карыйсы килә икән, карасын! Диварына асып куясы килә икән, куйсын! Карап торышка аермасы булмагач, анын ни гаебе бар?

Сүз шунда өзелде, ишек уемында кыз сыны пәйда булды. Сирәк кенә эре кызыл чәчәкләр төшкән кофта, йомры тез башларыннан чак кына югары кин итәк кигән, коңгырт чәчләре аркасына сибелгән бу кыз, ят егетләрне күреп, кыенсынып елмайды, түгәрәк ак йөзе алланып чыкты. Бу хәлендә ул үзе дә рамга куелган картина кебек иде. Тере картина! Бер дивардагы сурәткә карады шагыйрь Зөфәр, икенче ишек уемындагы кызга...

—Бу—шушы түгелме соң?—диде исе китеп.

—Исәнме, Нурзифа! Кер әйдә, нишләп туктап калдың!—диде Мозаффар.

—Исәнмесез... Мин сезне мондадыр дип белмәгән идем... Җыештырырга соңга калдым бүген...

—Бүгенгә җыештырмасаң да ярар...

—Котлыйбыз, Зифуш!—диде Хәнәфи.

—Нәрсә белән?

—Син Мозаффар абыеңа бишле алып бирдең.

—Ничек?

—Башка берәүнең портретын ясаган булса, өчле тотып калган булыр иде. Ә сине күргәч, һәммәсенең күңеле йомшарды...

—Котлыйм...—кызның тавышы сузынкырак, ничектер йомшак иде.—Алайса мин Василий Дмитриевич ягын җыештырып чыгам. Әни әйтте, ул бик үтенеп сорады, диде.

—Ә мин?—диде Хәнәфи.—Мине тәбриклисең килмимени? Мин дә диплом якладым бит!

—Сезне дә котлыйм...

—Юк алай гына түгел. Син... Син безнең хөрмәткә бокал күтәрергә тиеш.

—Мин эчмим!

—Ә син су белән. Әмма исерткеч сүзенне әйтеп!

Нурзифа ярдәм сорагандай Мозаффарга күз салып алды. Тегесе дәшмәде, ике кулын джинсы чалбарынын кесәсенә тирән итеп батырып, куе чәчләре астыннан үчекләгәндәй елмаеп басып торуында булды.

—Дүрт егеткә бер-ике авыз сүзенне жәлләмәссең бит инде!—диде шунда Зөфәр.

—Поднимем бокалы, содвинем их разом!—дип кинәт сузып жырлап жибәрде Ансар.

Кыз ирексездән елмайды. Хәнәфи жәлт кенә чынаякларны тутырды.

—Бәхетегезне ижатта табыгыз,—диде Нурзифа Мозаффарга карап. Һәм стаканнан бер йотым су кабып куйды да, чыгып китте.

Егетләр сүзнең очын югалтып, бер мәлгә тынып калдылар. Һәммәсенең карашы янә дивардагы портретка төбәлде.

—Йа хода, була бит шуның матурлык!—дип, көрсенде Зөфәр.—Мин менә хәзер миллиардлаган христианнарның ни өчен хатын-кыз сурәтенә табынганын аңладым кебек...

Ул, урыныннан кузгалып, портретка таба атлады. Хыялый кыяфәткә кереп, шигырь укый башлады:

—Нинди гүзәл мизгел жан иңдерде,
Кем бәхетенә тудың бу жиргә?
Матурлыкны таный белгән һәркем
Хыялланыр сине күрергә.
Яшәешнең кырыс жирләрендә
Ямьсезлектән күңел арганда,
Эретергә бозлы күңелләрне
Әле дә син бар безнең арада.
Әле дә син бар—гомер сулмас чәчәк,
Мәхәббәттән туган гүзәллек,
Төшләренә кереп елатырлык,
Өннәрендә үзәк өзәрлек.

Аннары кискен хәрәкәт белән Мозаффарга таба борылды да:

—Кирәкми сиңа башкаларның күчермәсен ясарга!—диде.— Сары шайтанга хезмәт итә күрмә! Күпме талантлар дөнья куып юкка чыга... Ижат кешесе өчен икенең берсе: матурлыкка хезмәт итү яки үлем! Үз кыйбласына йөз тотып, үз юлың белән бар!

Аның нык дулкынланганын күреп, Ансар сүзне шаяруга борырга теләгәндәй, көлемсерәп:

—Сүз бирсен ул безгә, сәнгатькә ихлас хезмәт итәм, дип ант эчсен! —дип куйды.

Шагыйрь исә моны житди кабул итте.

—Чыннан да, сүз бир син безгә, Мозаффар!

—Ә ник ул гына? Матурлык яки үлем, дисеңме әле?—дип торып басты Ансар.—Мин дә аңа кушылам, ант итәм! Сәхнәдән аерылсам, барыбер яши алмаячакмын.

—Әйе, хыянәтче яшәмәсен! Аңа бирелгән сәләт, талант—халык байлыгы ул. Кадерен белсен! Белми икән, үлсен! Әйдәгез, өчәүләшеп ант итәбез!— диде Зөфәр канатланып.—Кил, Мозаффар! Бир кулыңны!

Моңарчы дәшми-тынмый утырган Мозаффар, торып, алар янына килде.

—Ә ничек ант итәбез? Борынгы гладиаторларча, кулны пычак белән сызып, бер-беребезнең канын ялашыпмы?

—Егетләр ич без, сүзебез дә житә,—диде Зөфәр.—Бер-беребезнең күзенә

туры карап, матурлык яки үлем, дип өч тапкыр кабатлыйк!

—Әгәр берәрегез сүзендә тора алмаса, нишләтерсез? Бәреп үтерерсезме әллә?

Өч егет, көтелмәгән бу сораудан сискәнеп, өстәл ягына борылды. Сүзгә мавыгып, алар дүртенче табындашны онытып җибәргәннәр икән бит. Әнә ул, карашын читкә төбәп утыра, янагы тимгелләнеп чыккан, кружка тоткан кулы дерелди. Берничә мизгелгә тынлык урнашты. Гадәттәгечә иң беренче булып Ансар телгә килде, хәлне җиңеләйтергә теләп, шаярткандай:

—Без—аны исәннәр исемлегеннән сызып ташлаячакбыз,—дип куйды.

Зөфәр исә диварга сөялгән рамдагы мул арт санлы хатын сурәтенә күз салып алды, сүрелгән йөзен Хәнәфигә борды:

—Әй син ник «берәрегез» дисең? «Без» дип сөйләш! Антка кушыласын килмимени?

—Мине бөтенләй чуттан төшермәкчеме әллә сез?..

Хәнәфи кружкасын куеп, салмак кына күтәрелде.

—Тик менә шунысы: сүздә ничек торганыбызны кайчан, ничек тикшерербез икән?

—Әйдәгез, ун елдан соң дип сөйләшик,—диде Зөфәр канатланып.— Шушында очрашабыз да, кемнең ни кылганын карыйбыз. Бирегез кулларыгызны!

Дүрт егет кулларын бер йомарламга укмаштырып, тирән сулыш алып:

—Матурлык яки үлем! Матурлык яки үлем! Матурлык яки үлем!—дип, өч тапкыр кабатладылар.

Алар, сүзгә мавыгып, ишекнең ачылганын сизми калганнар икән. Сәер дә, серле дә, хәтта бераз шомлы да гамәлнең шаһиты булып, ишек уемында Нурзифа басып тора иде.

—Бәрәкәт! Антыбызның шаһиты да бар икән бит безнең!—диде Ансар.

—Шаһитның да нинди генә әле!—диде Зөфәр.—Талант иясенең илһамчысы, музасы! Әй, кызыкай, онытма бу минутларны! Исеңдә тот: нәкъ ун елдан соң без шушында очрашып, кемнең шушы антка тугры калганын, кемнең хыянәт иткәнен белешербез. Синең каршыңда, синең күзләреңә карап! Кил монда, аер безнең кулларны!

Нурзифа дәшми генә алга атлады һәм егетләрнең бергә укмашкан йодрыкларына кулының кырые белән йомшак кына бәреп алды...

## Егет белми кыз хәлен...

Ах егетләр, егетләр, белсәгез иде сез бу илһамчыгызның, үзегез әйткәнчә, «муза»ның хәлләрен! Тышкы кыяфәтенә сокланып туя алмыйсыз, күкләргә күтәреп мактыйсыз, әмма эчендә ниләр барын белмисез, бәгыре ничек сызланганын сизмисез! Сукыр сез, сукыр! Арагызда иң сукыры—Мозаффар! Диплом яклаган көнне Нурзифаның йөрәгенә нинди яра салганын сизми калды, белми ул...

Ә бит ул көнне кыз бәйрәм кебек көтеп алган иде. Аны бөтен ваклыклары белән кат-кат күз алдына китергән иде... Мозаффарга, һичшиксез, «биш»ле куячаклар. Ул училище ишегеннән балкып килеп чыгар. Нурзифа аны баскыч төбендә каршы алыр, котлап, чәчкә бәйләме—кызыл розалар сузар. Ул минутта бит очыннан пәп итеп алу да урынлы булыр әле...

Монысын күз алдына китергәндә, Нурзифаның бөтен тәне кызышып китә, иреннәре тулышып, утта янгандай була иде.

Әмма аның хыяллары тормышка ашмады.

...Иртән базарга баргач, Нурзифаның күзе иң элек эре, җете кызыл розаларга төште, билгеле. Их, шуларның җидесен... яисә бишесен... һич

югында өчесен матур итеп төрдереп алырга иде... Әмма Голландиядә үскән ул купшы чәчәкләр кыйбат тора икән. Күзләрнең карашын алардан аерып, рәтләр буйлап китәргә туры килде. Ахыр чиктә, Нурзифа бер сабак ак хризантема гына ала алды. Кадерен белеп кабул иткән кешегә монысы да начар түгел, дип юатты ул үзен.

...Июнь иртәсе аяз, тыныч иде. Язучылар йорты каршындагы карт юкәләр шау чәчәктә, иртәнге җиләс һава бал исенә туенган. Урамнан машиналар сирәк үтә, тыныч, аулак. Нурзифа капка янына сәгать тугызда ук килеп басты. Иртәрәк икәнен белсә дә җаны түзмәде. Эре кызыл чәчкәләр төшерелгән ак кофта, кыска итәк кигән кызның нечкә сыны юкә агачының юан кәүсәсе артына ышыкланды.

Шактый озак—сәгатьләр буе басып торырга туры килде ана. Менә ниһаять ишектә таныш сын күренде. Нурзифа ана таба омтылды. Әмма шул мизгелдә:

—Мозаффа-а-ар!—дигән тавыш яңгырады. Урам чатында кара кофта, кара чалбар кигән, түшенә эре ак төймә таккан кара чәчле кыз күренде. Кулында озын сабаклы, эре-эре кызыл розалар бәйләме. Менә ул урам аша йөгерә. Лядской бакча ягыннан килгән ак «Жигули» астына керә язды. Мозаффар ашкынып ана таба атлады. Менә кыз, чәчкәләрне читкәрәк сузып, калку күкрәге белән егетнең түшенә ятты да иреннәренә беректе. Юкә кәүсәсе артына посып, бу тамашаны күзәтеп торган Нурзифа өчен кояш тотылгандай булды...

Өенә кайтканда, кызның бәгырен көнләшү ачысы талый иде. Ямансу чакларда ул юаныч эзләп кәгазь, буяулар, кылкаләм ала. Сәнгать мәктәбендә өйрәнгәннәрен эшкә җигеп, кичерешләрен рәсемгә сала...Бу юлы да шулай итте: өстәлгә кушбит зурлыгындагы ватман кәгазе җәеп куйды. Бераз уйланып утырганнан соң, кулына кылкаләм түгел, күмер таякчыгы алды.

Анын кулы астыннан ике кыз сурәте калкып чыкты: ак күлмәк кигәне—биегрәк урындыкта, кара киемлесе тәбәнәгрәктә утыра. Карашлары төрле тарафка төбәлгән, әмма һәр икесенең дикъкате бер-берсенә юнәлгәнлеге сизелеп тора. Бер-берсеннән читләшәләр, тик ерагая да алмыйлар. Менә күмер астыннан юан кара чылбыр сузыла башлады, ул ике сынны бер-берсенә беркетеп, кат-кат урап алды.

Нурзифа сурәтне диварга энәләр белән беркетеп куйды. Һәм артка чигенеп, башын кыңгыр салып, озаклап карап торды. Ак күлмәкле кыз анын үзенә охшаган иде. Ә карадан киенгәне... Анысы билгеле бит инде!

Иртәгесен төнге каравылдан кайткач, Нурзифаның әнисе Гәүһәр сурәткә сәерсенеп карап торды.

—Болар кемнәр инде?.. Берсе ак, берсе кара—яхшылык белән яманлыкмы әллә?

Бераз көтеп тә җавап булмагач:

—Син икесен дә матур итеп тасвирлагансың,—диде уйланып.—Чынлыкта алай түгел шул ул. Яманлык ул һәлакәт дигән сүз бит, фаҗига, үлем. Газраилне шуның төсле дип күз алдына китерәсеңме әллә син?

—Ә Одетта белән Одиллия?—дип Нурзифа күзләрен зур ачып.—Одиллия ямьсез түгел бит! Ул үзен яраттыра да белә...

—«Аккош күле» балетын әйтәсең инде. Ә ник соң агында үзеңне ясадың?.. Одиллиясе дә бардыр инде? Классташыңмы әллә?

Бу сорау да җавапсыз калды.

—Мозаффар абыеңа күрсәттеңме соң? Ни диде?

—Юк әле, күрсәтмәдем... —дип кызарынып башын иде Нурзифа.

Әнисе аны үзенчә аңлады:

—Нәрсә кыенсынып торырга... Күрсен, житмәгән җирләрен әйтсен. Аңлатсын, өйрәтсен. Иртәгә җыештырырга барганда моны да алып бар...

—Мин анда бармыйм,—диде Нурзифа иреннәрен тешләп, Һәм чылангаn

керфекләрен күрсәтмәс өчен башын иде.

—Нишләп? Үпкәләдеңме әллә?

—Барасым килми,—диде Нурзифа тавышын күтәрә төшеп.

—Үз теләгәнен генә эшли торганнар без түгел шул, кызым,—диде Гәүһәр авыр көрсенеп.—Минем дә менә кеше шакшысын һич җыеп йөрисем килми...Тамак тәмугка кертә, дигәннәр борынгылар. Элек тә зарлана идек, кибетләр буш, кирәкне табып булмый, фабрикада эш авыр сыман иде... Баксаң, бер дә зарланырлык булмаган икән. Фабрикабыз кире ачылса, йөгереп барыр идем. Ишеген ачуга бөркелгән баллы исен күкрәк тутырып сулау үзе генә дә ни тора!

Ул шулай сөйләнә-сөйләнә йокы бүлмәсенә керде дә, өстен алыштыргач, башын салындырып, караватка утырды. Күңеле бик тә төшенке иде аның. Кондитер фабрикасы ябылганга бер ел тулды, кайларга гына барып, кемнәргә генә сүз кушып карамады Гәүһәр, тик менә рәтле эш табылмады. Һөнәре бик сирәк җиргә ярый шул, конфет камыры—карамельдән чәчкәләр ясый ул. Эресен-вагын, бәйләм-бәйләм итеп тә, кечкенә кәрзингә куеп та... Уртасында аккошлар йөзгән зәңгәр күл тирәсенә тезеп тә... Кара, хозурлан, бер чәчкәсен яки кошын сындырып алып, кабып җибәр. Теленне генә йота күрмә!

Гәүһәр ясаган чәчкәле күл фабрика директорының өстәлендә тора, еракларлан килгән кешеләр аны күреп шаккката иде. «Туебызга ясап җибәрегез әле»,—дип, Мәскәү хәтле Мәскәүдән шылтыраталар иде. Әлбәттә инде, бу эшкә өйрәнергә теләүчеләр бар иде, әмма берсе дә Гәүһәр кебек остара алмады. «Илдә бер Гәүһәр»,—диләр иде шул аны!

Ул ясаган татлы гүзәллекнең беркемгә дә кирәге калмас, дигән уйның саташып төш күргәндә дә башына килгәне юк иде. Ябык еллар шушындый була—матурлыкның да, осталыкның да, кешенең үзенең дә кадерен бетерә икән.

...Йөри торгач, Язучылар йортына вахтер булып та ялланды Гәүһәр. Бер тәүлек эшлисең, ике тәүлек ял итәсең. Эш хакы ташка үлчим, алай да иш янына куш була... Кичә бик арган иде, төнлә каравыл будкасында утырган килеш йоклап киткән дә, тикшерүче килеп, тәрәзәнең юка пәрдәсе аша шуны күреп алган. Бүген аны бик каты кисәттеләр: тагын берәр тапкыр шундый хәл сизелсә, куып чыгарачаклар.

Ире исән чакта, болай каты бәрелә алмыйлар иде. Абруйлы кеше иде Вилдан, заводта тәэминат бүлеге җитәкчесе. Шәһәрнең яңа районыннан ике бүлмәле фатир алды, дөнья хәлен белеп булмый, дип, кассага шактый акча да салып куйган иде. Икесе дә дөбердәтеп эшлиләр, бердәнбер кызларын ике мәктәптә укыталар иде... Кинәт кенә бөтенесе берьюлы ишелде дә төште. Заводта эш тукталды, кассадагы акчалар янды. Әллә шул хәсрәттән, әллә гомере беткәнгә, Вилданның йөрәге кинәт туктады...

Менә бер ел инде тол хатын булып яши Гәүһәр. Бер тамакны туйдырырлык эш табуы кыен, ана исә кызын аякка бастырырга кирәк. Киләсе елдан сәнгать мәктәбендә уку түләүле булачак, дип кисәттеләр менә. Ә Нурзифаның тагын өч ел укыйсы бар әле. Ничек тә булса ташлатмаска иде.

Ананың тамагына ачы төен килеп тыгылды...

Нурзифа ачык ишек янына килгән иде, учлары белән битен каплаган әнисен күреп, сискәнеп китте. Гәүһәрнең ситсы халат астындагы иңбашлары калтырана, элек гел бөдрәләтеп йөри торган көлсу чәче башына сыланган, арада ак бөртекләр җемелди.

Нурзифа килеп, әнисен иңнәреннән кочып алды:

—Елама, әни! Бер остаханәнең идәнен себермәгәннән дөнья җимерелмәс лә!

—Инде син дә мине аңламагач, син дә хәлемә кермәгәч,—дип сулкылдады Гәүһәр.

—Аңлыйм, әни! Кая дисәң, шунда барам, ни әйтсәң, шуны эшлим! Елама гына!

Остаханәнең буш чагын туры китерергә дип чамалаган иде ул. Әмма дүрт егеткә тап булды. Аларның очынып-талпынып сөйләгәннәрен ишетте, алай гына түгел, намус белән иҗат итәргә дип биргән антларын үз кулы белән беркетте.

Бу күренеш Нурзифаның хәтеренә, талантлы рәссамның картинасы кебек, бөтен төсмерләре, хәтта тавыш аһәннәре белән унмас-җуелмас булып уелып калды.

Карадан киенгән кыз бу картинага сыймаган иде.

### Ун ел узгач

Дүрт егетнең яшьлек мавыгуы белән биргән анты вакыт узган саен хәтернең ерак почмагына чигенә барса һәм, ун ел үткәч җыелып, аның үтәлешен тикшереп тормасалар да гаҗәп булмас иде. Гомер иткәндә гамьнәр өсте-өстенә өелеп, искеләрен яналары онытгырып тора бит ул.

Бигрәк тә бу заманда, гасырлар алышынган чорда шулай булды: дөнья болганды, борчулар баштан ашты. Иҗат кешеләренә акча түләү бетте, совет чорында концертлар оештырып, җырчыларның, артистларның тамагын туйдырган филармония нык хәлсезләнде.

Элекке елларда музейларга да, клуб диварларын, олы җитәкчеләрнең кабинетларын бизәү, танылган кешеләрнең юбилейларында бүләк итү өчен дә күп кенә картиналар дәүләт акчасына сатып алына иде. Яна хакимиятне бүтән мәшәкатьләр күмеп китте. Халыкны тамак кайгысы басты. Нәтиҗәдә күп кенә рәссамнарны эш белән, хезмәт урыны белән тәэмин итеп килгән сәнгать фонды уннарча миллион бурычка батып, банкрот дип игълан ителде, Карл Маркс урамындагы күргәзмә заллары, остаханәләр урнашкан зур бинаны сатачаклар икән, дигән хәбәр таралды.

Бәхеткә, Мозаффар мондый зур ыгы-зыгылардан бераз читтәрәк калган иде. Ул Мәскәүдә Суриков исемендәге сәнгать училищесын тәмамлаганнан соң бер елга Италиядә барып, осталыгын арттырды, аннары Казанга кайтып, уңга-сулга карамыйча, иҗат эшенә чумды. Мона аның мөмкинлеге булды, чөнки хатыннан унды. Азалия затлы кешеләр арасында исеме танылган тегүче булып үсеп житкән иде. Ул үзенең танышлары аркылы, рәссам Юлдашевның исеменә таянып, яна йорттан фатир алуга да иреште.

Инде менә Мозаффарның үзенә дә язмыш йөз белән борыла башлаган кебек булды. Татарстан президентының тышкы элемтәләр буенча ярдәмчесе Тимур Акулов Чехиягә барган да, анда күргәзмә үткәрү турында килешүгә кул куеп кайткан икән. Чит илләрдә безнең белән кызыксыну көчле, чөнки СССР таркалып, чиктәге «тимер пәрдә» алып ташланганнан соң, алар өчен өр-яңа дөнья ачылгандай булды. Җае туры килгәндә, кайбер рәссамнарның, шул җөмләдән Юлдашевның да, картиналарын долларга сатып алгаладылар. Прагада да сатарга мөмкин булачак икән. Анда Талипов белән Юлдашевның яна әсәрләре белән аеруча кызыксынуларын белдергәннәр.

Акулов бу матур хәбәрне җитәкчеләргә җиткерүгә, мәдәният министры Илгизәр Фаязович Кәримов Рәссамнар берлегенең рәисе Хангилдинны һәм Талипов белән Юлдашевны махсус чакырып сөйләште. Әлбәттә инде, мәсьәләне югары кабинетларда гына хәл итү дөрес булмаячак, киң җәмәгатьчелекнең фикерен исәпкә алу тиеш иде. Ә моның өчен зур күргәзмә үткәрергә кирәк, дип табылды. Комиссия картиналарны шуннан сайлап алачак, аларның бәхетле авторларына да Чехиягә ике атналык командировка биреләчәк иде.

Моңарчы йокымсырап яткан рәссамнар берлеге бу хәбәрдән дәррәү җанланды, Карл Маркс урамындагы әлегә сатуга куелмаган бинаның

икенче катындагы зур залда күргәзмә ачылды. Табигый ки, Талипов белән Юлдашевка анда иң күп урын бирелгән, икесенен дә Чехиягә барачагы алдан ук билгеле иде.

Әмма мәшәкатьләрнең иң кызган көннәрендә, һич уйламаганда, Мозаффар юкка чыкты.

Анын, мавыгып, дөньясын онытып, остаханәсендә озаклап ятуына, кайчак кунып ук калуына күнеккән хатыны Азалия беренче кичне әлләни борчылмады борчылуын. Мәшәкате дә күп иде: алты яшьлек Сәйярны балалар бакчасыннан алып кайтып, ашатасы, киемнәрен юасы, туктаусыз лыкылдавына җаваплар бирәсе, иң соныннан, караватына яткырып, әтисенекенә охшаган, куе, кара, тынлаусыз чәчен сыйпый-сыйпый, әкиятләр сөйлисе...

Ниһаять, бала күзен йомып, өйдә тынлык урнашкач, Азалия шкаф өстендәге түгәрәк пыяла сәгатька карап алды. Ун тулып килә икән инде. «Шалтыратырга кирәк»,—дип уйлады ул.

Әмма остаханәдәге шәһәр телефоны озын-озын чинады, кесә телефонынннан исә ят тавыш: «Абонентка тоташып булмый»,—дип җавап бирде.

Беренче елларны мондый очракларда Азалия бик борчыла, чәүчәләкләнә иде. Төн уртасында бала күтәреп, остаханәгә барып кергән чаклары да булгалады. Әмма Мозаффарның анда, кылкаләм тотып, мольберты каршында басып торганын, яисә эше бармаудан гаҗизләнеп почмактагы ятагында аунап ятканын күргәч, аннан бигрәк үз-үзенә ачуы кабара иде.

Нишлисең, рәссамнар үзенчәлекле кавем шул—кулга ияләштереп, күз алдында гына тота торган түгел. Никадәр талантлырак булсалар, шулхәтле йөгәнсезләр.

Азалия эшеннән гадәттәгечә бик арып кайткан иде—ательеда көнозын аягөсте буласын, җитмәсә күп кеше белән аралашырга, һәркайсының җаена торырга туры килә. Бик йончыган иде, башы мендәргә тиюгә тынгысыз йокыга чумды.

Иртәгесен кичкә таба да Мозаффарның телефоннары җавап бирмәгәч ул, баланы бакчадан алганнан соң, остаханәгә кереп чыгарга булды.

Бишенче катка менеп, идәннән түшәмгәчә тоташ рәшәткә янындагы кыңгырауга күпме генә басса да, өстән ни зыңгылдау тавышы, ни башка берәр аваз ишетелмәде.

Бу юлы инде Азалияне чын-чынлап шом басты. Анын чалбар балагына чытырдап ябышкан кечкенә Сәйяр да, нидер сизенгәндәй, көйсезләнеп шыңшырга кереште.

Аннан соң берничә сәгать томан эчендә узгандай булды: уйлар буталды, куллар күнегелгән эшне башкарды: пешерде, юды, баланың башын сыйпады.

Ә бәгырьне һаман бер сорау тырный иде: Мозаффар кайда? Әллә сон әйтергә дә онытып, яңа картинасы өчен этюдлар ясарга китте микән? Моңарчы алай ук кыланганы юк иде дә бит, аның башына ни килмәс...

Ничек белергә? Кемнән сорарга?

Җавап булып күңелдә бер исем калыкты: Нурзифа! Утлы каләм белән сызылгандай йөрәкне өтте ул. Ничә еллар инде тыңгы юк бу кызыйдан!

...Ун ел элек Мозаффар аны үзенең картинасында язучылар йортының бакчасы янында кар өстенә бастырып ясаган иде. Дипломны ул шуның белән яклады.

Әйе, иң мөһим картинасында тасвирлау өчен йөргән кызы Азалияне түгел, ә менә шул кызны сайлаган иде ул.Бу нәрсә күңелне тырнамый калмады, әлбәттә.

Әмма Азалиянең акылы җитте—егеткә үпкә белдермәде, диплом яклап чыккан жиренә бер кочак роза алып килде. Нурзифа—мәктәп баласы,

Мозаффар Мәскәүгә китәчәк, ерагайган аралар хисләрне сүрелдерер, дигән ышаныч бар иде.

Әмма бу очракта алай булып чыкмады. Мозаффар каникуллар вакытында Казандагы остаханәсендә эшләде. Әледән-әле һаман шул Нурзифаның портретларын ясап торды. «Казан гүзәле», «Татар кызы» дигән мәгълүм картиналарында да шуның чалымнары ярылып ята. Ун ел эчендә кешеләр дә, яшәеш тә нык үзгәрде, тик рәссамның күнел күзендәге шушы кызга караган саен эленә торган алсу пыялалы күзлеге генә ватылмады, томанланмады.

Нәрсәсен таба торгандыр! Чибәр кызлары белән дан тоткан Казан каласында андыйлар адым саен очрап тора югыйсә... Әгәр дә Мозаффарның буяулары белән тасвирланса, һәркайсының сурәтен мадонна итеп, диварга элеп куярлык.

Рәтле булса кияүгә чыгар иде, яше егерме бишкә җиткән бит инде! Безнең әбиләр заманында андыйларны сазаган кызга санаганнар!..

Ә бәлки анын йөргән кешесе бардыр да инде? Азалия генә белми калгандыр? Дуамал сугыш чукмары булса, көнләшеп, Мозаффарны бер-бер хәл кылып ташлавы да ихтимал бит!

Азалия шомланудан тигезсез типкән йөрәген басарга тырышып, калтыранган куллары белән телефон янында яткан тар кенәгәне актарды. Менә ул—исеме астына кызыл каләм белән сызылган...

—Исәнмесез!

—Хәерле кич... Азалия апа, сезме?

Бу сорау болай да җәрәхәтле күңелне тырнап узды. Монарчы аларның телефоннан сөйләшкәне юк иде, каян таныды әле? Шалтыратканны көтеп утырганмы әллә? Өендә үзе, димәк, Мозаффар белән түгел...

—Әйе, мин бу,—диде Азалия бер мәл тынып торгач.

—Мин сезгә үзем дә шалтыратмакчы идем...

Кызның борчылганын сизеп, Азалия бөтенләй тынсыз калды. Нилер булган, ахры!

—Бүген Мозаффар абыйны күргәзмә залында көтәләр иде, телевидениегә төшерергә,—дип дәвам итте Нурзифа.—Алдан әйтеп куйган булганнар. Ә ул килмәде. Онытты микән әллә? Исенә төшерегез әле...

—Әйтер идем дә, өйдә юк шул!

—Остаханәдә бөтен әйберсе тарау килеш ята... . Кайда соң ул?

—Өченче көннән бирле күзгә күренгәне юк... Әллә син беләсенме, дигән идем...

—Чит илгә алып барасы картиналарын әзерли иде бит ул, каядыр барырга исәбе юк иде кебек...

Азалия трубканы куйды да, чуалган зиһенен тупларга тырышты. Уйлап карасаң, Мозаффарның нәкъ менә бу көннәрдә юкка чыгуын бәйсез холкы белән генә аңлату авыр иде. Прагага бару турында күпме хыялланды, күпме очынды, тырышты! Шундый җитди мәсьәлә хәл кылынганда качып йөрерлек үк башсыз түгел ләбаса ул...

...Кайтып килми микән?!

Азалия тәрәзәнең пәрдәсен ачып, тышка карады. Биек багана башыннан төшкән яктылыкта аермачык күренеп тора—Мозаффарның күксел сигезенче «Жигули»е үз урынында, карт каен төбендә. Шактыйдан инде рульгә утырганы юк: «Техосмотр үтәсе бар»,—дип сөйләнеп йөри, һаман шуны башкарып чыга алмый.

Иркен ишегалды каен, миләш, тирәкләр белән ышыкланган, уртасына балалар өчен атынгыч-шугычлар ясалган. Быел да язын аларны тозәттеләр, матур итеп буяп та куйдылар. Биек баганада көчле лампа яна, агач ябалдашларының челтәрле күләгәләрен җиргә бизәк итеп төшерә.

Бик тә ямьле бу күренеш бүген шомлы булып күренде. Ишегалларын,

урамнарны бизиләр-матурлыйлар, әмма шул тирәдә яшәгән кешеләрне афәтләрдән саклап бетерә алмыйлар. Әгәр берәрсе юкка чыкса, карурманда адашканнан хәтәррәк. Бик тырышсаң, урманда кеше эзенә төшеп буладыр, ә менә шәһәрдә эзләр калмый.

Алла сакласын, Мозаффар бер-бер бәхетсезлеккә юлыгып, һушсыз ятса, ә Азалия аны эзләтмәсә, нинди хатын була инде?

Ул трубканы кире күтәрде дә, «ашыгыч ярдәм» номерын җыйды. Теге баштагы хатын-кыз талчыккан тавыш белән җавап бирде: соңгы ике көн эчендә ярдәм күрсәтелгән һәм хастаханәләргә илтеп тапшырылган кешеләр исемлегенә Мозаффар Юлдашев теркәлмәгән икән... Билгесезләр дә юк...

Азалия, юаныч эзләгәндәй як-якка каранды да, бер як диварны биләп торган шкафның аскы киштәсендә күпереп яткан ак төргәкне алып, бүлмә уртасындагы өстәлгә таратып җибәрде. Торшердан төшкән яктылыкта ак ефәк елкылдады, затлы челтәрнең читләрендәге көмеш сәйләннәр җем-җем итте. Азалия туй күлмәкләре тегүче буларак шәһәрдә танылган оста. Ательеда төрлесен тегәргә туры килә, ә менә өендә ул затлы, бай кәләшләрне генә киендерә. Бу ефәк—яшь җырчы Ләйсән Вәлидинең туй күлмәге булачак. Бүгеннән тотынырга кирәк, вакыт аз калды.

Аһ нинди бәхетле, чибәр, талантлы кыз ул Ләйсән Вәлиди! Парлашып килгәннәр иде, кияве дә үзенә тиң икән: буй-сыны ипле, йөзе нурлы, теле тәмле. Исеме дә матур—Рашат.

—Минем кәләшнең күлмәге дөньяда бер булсын!—диде ул елмаеп.—Үзегезгә теккәндәй итегез!

Үзенә туй күлмәге теккәндә яшьрәк иде шул әле Азалия, болай ук оста түгел иде. Алай да тырышты, рәссам кияүнең күнеленә хуш килсен, диде. Кавышулары сокланырлык, тормышлары ямьле булырга тиеш иде, чөнки сәнгать таныштырган иде аларны.

Ул чакта Азалия техникумда кисүче-тегүче булырга укый иде. Яхшы тегүче, әлбәттә сәнгатьне аңларга, иҗатка сәләтле булырга тиеш, дип саный иде андагы остазлар. Шул максаттан алар шәкертләрен театрларга, музейларга еш йөртәләр иде.

...Җиңү көненә багышланган күргәзмәдә Азалия зур гына картина каршында тукталып, төркемнән аерылыбрак калды. Картина сугыш беткән чорга багышланган иде: басу юлыннан пилотка, гимнастерка, кирза итекләр кигән берничә ир-ат килә, авылдан аларга каршы бала-чага, хатын-кыз йөгерә. Ничектер күңелне кузгатты бу күренеш. Азалиянең дә бабасы сугышта булган. Исән кайткан, әмма озак яшәмәгән. Ул да шушы солдатлар төсле булгандыр...

—Монда иң яхшы әсәр шушы, әйе бит?—диде кемдер.

Кыз ямансу уйга чумып торганда, сизми калган: артына бер ят егет килеп баскан икән. Азалия кебек үк кара чәчле, түгәрәк йөзле. Тик буйга шактый калкурак, йөз сызыклары кискенрәк.

—Миңа да ошый...—диде Азалия.

—Ә беләсезме, хикмәт нәрсәдә?

Кызның аптырабрак калганын күреп, егет елмаеп сүзен дәвам итте:

—Хикмәт хәрәкәтне тасвирлый белүдә. Менә бер солдат честь биргән...

Шунда Азалиянең күз алдында могҗиза булды кебек—солдат кискен хәрәкәт белән кулын чигәсенә күтәрде һәм... төшерә дә башлады.

—Әйе... Күрәм...

Егет аның дулкынланганын сизеп, тагын да рухланып сөйләргә кереште:

—Кеше һәрвакыт хәрәкәттә бит ул. Хәтта беренче карашка тик торган төсле күренсә дә. Анда да сулыш алудан, йөрәге тибүдән бөтен тәне

тибрәнеп тора. Бер хәрәкәтне ясаганда ул инде икенчесенә әзер тора. Менә бу кул,—дип картинага ишарәләде ул.—Ул күтәрелгән генә, әмма төшәргә әзерләнгән инде. Рәссамның таланты менә шуны бирә белүдә. Безнен Әгъләм абый искиткеч талантлы шул ул!

—Туганыгызмы әллә?

Егет тигез, тыгыз тешләрен жемелдәтеп көлеп жибәрде.

—Әгъләм Талипов—минем укытучым. Таныш булыйк—мин Мозаффар, сәнгать училищесы студенты,—дип кулын сузды ул.

—Ә мин жинел промышленность техникумында укыйм,—дип, Азалия кулын аның учына салган иде, егет шундый итеп кысты, атсыз бармактагы нечкә алтын балдак тәнгә уелып керде. Кыз авыртудан күзләрен чытырдатып йомып алды, әмма Мозаффар моны сизмәде, картина турында сөйләвендә булды.

Ул арада Азалиянен төркемдәшләре залдан чыгып киткәннәр иде инде... Мозаффар аны озата китте...

Менә шуннан башланды аларның танышулары, йөрешүләре. Өч елдан соң алар Мәскәү загсында язылыштылар.

Нинди бәхетле чаклар бар иде! Алдагы көннәр якты булыр, гел куаныч кына алып килер кебек иде...

Кара көннен килүе шушы микән әллә? Бәла-казаны берәү дә сорап-көтеп алмый бит...

Телевизордан фажигаләрнең төрлесен сөйләп кенә торалар, юкка чыккан кешеләрнең сурәтләрен күрсәтәләр. Көн саен яналарын. Табылалар микән, шунысын гына әйтмиләр. Табылмаганнары да шактыйдыр, мөгаен. Кайберләре исән дә түгелдер, гәүдәләре кая да булса ятадыр... Үтерү очракларының һәммәсен дә ачыклый алмыйлар бит. Ачылмый калган жинаятьләр шактый, диләр.

Тик утырырга һич ярамый! Нидер эшләргә кирәк!

Азалия кулындагы ефәкне читкә атты да, янә телефонга ябышты. Бу юлы «02» не—милиция номерын жыйды.

## Нык тамырлы гөлләр матур була

Нәкъ шул сәгатьтә, Казансу артындагы бер урамда, тугыз катлы йортның тәрәзәсеннән икенче берәү карап тора иде. Нурзифа иде бу. Аның да йөрәк мае сыза, күнеле ниндидер бәхетсезлек булганын сизә... Монарчы берәр кая озакка киткәндә, Мозаффар мольбертын, буяу-кылкаләмнәрен үзеннән калдырмый иде. Ә бу юлы алмаган, һәммәсе үз урынында... Ятакта да, өстәлдә дә рамнар... Гүяки ул остаханәсеннән бер генә минутка дип чыккан... Тик нишләптер кире кермәгән. Кая киткән? Ник өенә кайтмаган?.. Хатыны да тәмам аптыраган, күрәсең, юкса Нурзифага шалтыратып тормас иде. Тавышыннан ук нык хафаланганы сизелде...

Кайда йөри икән соң ул?

Урман түгел, чүл түгел, шәһәр ләбаса бу! Әнә бит, төн уртасы булуга карамастан, тар урамнан, утларын елкылдатып, машиналар узгалый, үтеп-сүтеп йөрүчеләр күренгәли. Мозаффарны да кем дә булса күргәндер, кайдалыгын беләдер. Тик кем?

...Әллә соң Рашат белән кинәшергәме?

Тик бу сәгатьтә ана шылтырату әдәп кысасына сыяр микән? Иң беренче булып бүтәннәр түгел, ул искә төште, йөзе балкып күз алдына килде килүен дә, төн уртасында борчуынны ничек кабул итәр бит!

...Азалиянең теләге ниһаять тормышка ашыр кебек—Нурзифа үзенең күңеленә хуш килердәй берәү белән танышкан иде. Дөрес, Рашатны аның йөргән егете дип авыз тутырып әйтеп булмый әле. Танышканнарына ике генә ай. Очрашканда сүзләр дә эш янсә сәнгатьтән ары китми, йөрәк

тирәсенә барып житми.

Ачылып китүдән икесен дә нәрсәдер тыя. Рашатның үткәнендәниләр булганын, күңел түрендә нинди серләр ятканын белеп булмый, ә менә Нурзифаны нәрсә тыйганы, дөресрәге кем тыйганы ап-ачык—ул Мозаффар. Рәссам аны гүяки күзгә күренмәс нурланыш киртәсе белән әйләндереп алган да, һичкемне якын китерми кебек.

...Сүз дә юк, ярата Нурзифа Мозаффарны. Тик менә йөрәк хисләренең төсмерләре бик күп бит аның. Әйтик, кайсыбер үсмер кызлар укытучысына гашыйк була. Олылый, соклана, аны гына уйлый, гел аның янында булырга омтыла. Әмма кочагына керү турында хыялланырга да батырчылык итми. Нурзифаның Мозаффарга гыйшкы да шундый булып кабынды. Вакытлар узу белән кызның хисләре яңа төсмерләргә байый барыр иде, мөгаен... Әгәр арага башта Азалия, аннары аның белән янәшә кечкенә Сәйяр кереп басмаса...

Кемнендер ирен, баланың атасын тартып алырга, ике кешене бәхетсез итәргәме?! Нурзифа уенча бу—кеше өенә ут төртү кебек җинаять иде.

Аның өчен Мозаффар яраткан укытучысы кебек булып калырга, гомер юлын парлап үтәрдәй башка берәү очрарга тиеш иде. Тик ел артыннан ел узды, рәссамны алыштырырлык егет табылмады...

Мозаффар кебекләр адым саен очрап тормый шул!..

Менә, ниһаять, ул килде шикелле... Мозаффарга бөтенләй охшамаган охшавын, әмма беренче күрүгә үк бөтен кыяфәте, үз-үзен тотышы белән дикъкатьне җәлеп итеп, күңелне кузгатты.

...Нурзифа кухня җиһазлары ясап сата торган фирмада эшли. Гомуми мәктәп белән бергә сәнгать мәктәбен дә тәмамлаганнан соң, мәдәният институтына читтән торып укырга керде ул. Көндезгесенә дә үткән булыр иде, әнисен кызганды. Ул тапкан акчага ике җанны асрау җиңел түгел, ә кайсы яшь кешенең тиен санап яшисе килсен!

Шуны уйлап, кыз ярты ел дизайнерлыкка укыды да эшкә урнашты.

Фирма ышанычлы булып чыкты, чөнки авыр елларда да өй җиһазларына ихтыяҗ бар иде. Сәвит заманында халык андый әйберләргә зур кытлык кичергән иде шул.

...Май уртасының кояшлы көнендә Нурзифа Әмирхан урамындагы яңа ачылган бүлектә утыра иде. Өстәле бүлмәнең түрендә, челтәрле рәшәткә куелган зур тәрәзәгә каршы аның. Ә урамда ике якка машиналар агыла, тротуардан бертуктаусыз халык үтеп тора.

Бер мәлне ул күзен компьютердан аерган иде, тротуар эргәсенә килеп елышкан ак «Лада»ны күреп алды. Әле генә заводтан чыкканмыни, бик тә чиста, пөхтә машина иде бу. Бөтен җире елкылдап тора. Менә аннан шундый ук пөхтә егет килеп чыкты: ак чалбар, ак күлмәк, житез-төгәл хәрәкәтләр. Буе шактый озын, гәүдәсе ыспай. Тураеп басканда алтын рамлы күзлек пыялалары елкылдап алды. Төшенә тузга язмаган сурәтләр ясалган футболкалар кигән джинсы чалбарлы халык арасында чәүкә төркемендәге ак күгәрчен кебек күренде бу егет. Менә ул җиңел адымнар белән тротуар аша үтте һәм ишекне ачты. Буяу, лак, химикатлар исенә туенган бина эченә, егеткә ияреп, болын җиләслеге килеп кергәндәй булды. Бу—аннан аңкыган затлы дезодорантның хуш исе иде.

—Исәнмесез!

—Саумысез! Хуш киләсез!

—Миңа кухня шкафлары кирәк иде...

Ул шунда сүзен өзеп, Нурзифаның йөзенә төбәлде. Күзгә-күз карашып, дәшми-тынмый озак басып торып булмый бит инде, кыз дивар буйларында тезелеп торган шкаф-өстәлләргә ишарә ясады:

—Менә үрнәкләре. Барысы да түгел, билгеле. Калганнарын моннан карый аласыз.

Һәм өстәлендәге калын журналны кырыйгарак шудырды.

—Монда аерым детальләр күрсәтелгән. Без аларны, заказчикларның теләген искә алып, җыеп-туплап илтеп урнаштырабыз. Болары да ошап бетмәсә, өр-яңа төрлесен ясап бирәбез.

Нурзифа егетнең үткен карашыннан кыенсынып, керфекләрен күтәрмичә генә гадәттә сөйли торган сүзләрен тәкърарлый иде.

—Кем эшли? Сез үзегезме әллә?—дип ниһаять телгә килде егет.

—Безнең дизайнерлар бернечә... Кайсын телисез.

—Ләкин сез... Сез ничек бирелә?!

Нурзифа аптырап керфекләрен күтәрде.

—Минем махсус белемем бар. Теләсәгез, дипломымны күрсәтә алам. Тәҗрибәм дә җитәрлек.

Ә егет ишетми дә кебек, бөтенләй башканы уйлый иде.

—Сезне мондый җирдә очратырмын дип башыма да китермәгән идем,—диде ул ниһаять.

—Мине кем беләндер бутыйсыз, ахры. Безнең очрашканыбыз юк бит.

Егет елмаеп, башын чайкап куйды.

—Сезне башка берәү белән бутап булмый...—диде.—Онытыла торганнардан түгел. Сәнгать музеенда портретыгыз эленеп торамы? Рәссамын да хәтерлим: Юлдашев.

Егетнең йөз чалымнары көнчыгыш кешесенә тартым иде: күзләре кысыграк уелган, янаклары чыгынкы. Елмайганда, бит очында чокырчыклар хасил булып, уң якта ул чокырчык шактый тирән уелса, сулында чак кына сизелә. Бу исә аның йөзен тагын да сөйкемлеләндереп җибәрә. Ләкин иң мөһиме, аның эчтән ягтыруы иде. Йөзен боза торганнардан түгел, җыерчыклар да тиз генә чыкмастыр, мөгаен. Сүзләрне бераз ашыгыбрак, «р»ны йотыбрак әйтә.

—Хәтерем ялгышмаса, портрет «Казан гүзәле» дип атала. Исемегез Гүзәлдер инде?

—Ул бит картинаның исеме, минеке түгел. Сез дә рәссаммы әллә?..

—Кызганычка каршы, рәссам ук булалмадым. Әмма сәнгать белән кызыксынам, музейларда еш булам. Рашат!—дип кулын өстәл аша сузды ул аннары.

—Нурзифа.

—Шулаймыни-и? Нурзифа—Гүзәлдән шәбрәк бит. Матурлык өстенә нурлы да дигән сүз! Юлдашевның портретында сез бик оста тасвирланган.

Кыз бит очлары алланып чыкканын тоеп, башын читкә борды да егетнең дикъкатен читкә юнәлтергә теләп:

—Кухнягызның үлчәмнәрен алып килдегезме?—дип сорады.

—Юк әле. Иртәгә китерермен. Ничәгә кадәр эшлисез?

—Җидегәчә.

...Иртәгесен кичке җиде тулыр-тулмас ак «Лада» ишек каршына килеп туктаган иде инде. Рашат кухня бүлмәсенең үлчәүләрен китергән икән. Шкафларга карап, ниндиен кая куярга икәнен тиз генә әйтте дә:

—Эш сәгатегез беткәндер бит инде?—диде.—Кая кайтасыз? Әйдәгез, илтеп куям.

—Мәшәкатьләнмәсәгез дә була. Мин Ямашев урамының аргы башында гына торам.

—Алай булгач, илтәм дә илтәм инде!

Шундый итеп әйтте—каршы торып булмады.

Шул көннән соң аларга очрашырга сәбәп тә юк иде шикелле: заказ алынган, әзер шкафларны фирма эшчеләре илтеп бирәчәк. Әмма егет тагын, тагын килде. Тегесен үзгәртәсе, монысын төзәтәсе килгән, имеш... Бикләрен, тоткаларын сайлана...

Гел эш сәгате беткән чакны туры китерә үзе, Нурзифаны машинасына утыртып озатып куя. Ерак ара түгел, өч кенә тукталыш барасы. Әмма халыкның эштән кайткан вакыты, урамда машиналар тыгылып, «бөке»ләр ясалып кына тора. Тик мона егетнен эче пошмый шикелле. Янәшәсендә утырган Нурзифа белән сөйләшү рәхәт кебек ана.

Беренче карашка алар яшькә бер чамарак тоелса да, егет утызга житкән икән инде.

—Малайлыктан чыгасы килми,—диде ул шаярып.—Аннары нәсел шундый минем, тиз картаймый торган.

Ул Әлмәттә туып-үскән, әтисе зур бер нефть оешмасында баш бухгалтер, әнисе—мәдәният сараенын директоры икән. Мәгълүм булганча, нефть өлкәсендә эшләүчеләр, иң авыр елларда да егылып ятмады. Рәшат музыка мәктәбен тәмамлаган, тик төп һөнәре итеп музыканы сайламаган, университетнын юридик факультетына укырга кергән. Соңгы елларда илләр арасында студентлар алмашу ешаеп китте бит—ул да ике ел Германиядә укып кайткан икән. Диплом алгач, Казанда калган, аспирантура тәмамлап, диссертация яклаган. Хәзерге вакытта институтта лекцияләр укый, кичләрен мәдәният сараенда музыка житәкчесе булып эшли.

—Сәнгатькә тарта күңел,—диде ул.—Зур күргәзмәләрне калдырмаска тырышам. Җанга да мунча кирәк бит! Тукайның «тәнгә—мунча, җанга—юк» дигәнен хәтерлисезме? Дөрес әйтмәгән бит. Җанга да мунча бар! Сезнең портретка карагач, мәсәлән, минем күңелдә бер кер табы да калмады...

Аннары, Нурзифанын бу сүзләрне төче мактауга санап, кашларын җыерганын күреп, мәгънәле көлемсерәде дә:

—Ә хәзер үзегезне күргәч...—дип тукталып калды.

—Күңелегезгә кер табы төшердемме әллә?

Башка берәү булса: «Юк-юк, һич тә алай түгел, сез ул портреттан чибәррәк!»—дияр иде. Әмма Рәшатның җавабы көтелмәгәнчә булды:

—Ә беләсезме, Юлдашев сезнең асылыгызны ачып бетерә алмаган бит. Андый ук беркатлы түгел сез.

—Менә күрдегезме? Портретта мин түгел, рәссамның хыялы!

—Гөлнең чәчәген балкыткан ул, ә тамырын ачмаган. Ә сезнең тамырлар нык. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела.

Нурзифа моңа каршы сүз тапмады. Егетнең беркавым тынып торганнан соң әйткәне генә күңелгә нык сеңеп калды:

—Тамырын киң җәйгән гөлләр матуррак чәчәк ата.

Алар Нурзифаның өе янына кайтып җиткәннәр иде инде. Рәшат машинадан төшеп тормады, башын сузып кына саубуллашты.

Артык ачылып китәсе килмәгәне шуннан да сизелде. Нәрсә тыя иде аны? Ул, мөгаен, буйдактыр—хатынлы ир кухняны үзе генә юнәтеп йөрмәс иде. Аерылганмы, әллә йөргән кешесе бармы?

Нурзифаның моны беләсе килә, әмма турыдан сорарга кыймый иде. Әлегә ярамый да.

Чөнки Рәшат белән ачылып сөйләшкәнче ул бик тә мөһим, четерекле, күптән уйлап йөреп тә моңа кадәр тәвәккәлли алмаган бер эшне башкарырга тиеш иде. Мозаффарның зур бер гозерен үтәргә кирәк иде аңа...

Ниһаять, моннан бер атна элек Нурзифа, бөтен кыюлыгын, батырлыгын җыеп, тәвәккәлләде: рәссамның күптәнге теләген үтәргә һәм шуннан соң араны өзәргә, дигән катгый карарга килде.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА КАТНАШКАН ТАТАР ӘДИПЛӘРЕ

## Аитзәк Аитов (1908–1941)



1908 елның декабрендә хәзерге Саратов өлкәсенең Дергач районы Алтата авылында туа. Шигырьләр, очерклар, мәкаләләр яза. Аларның күбесе 1930-1937 елларда Донбасста (ул чакта—Сталино шәһәрендә) татар шахтерлары өчен чыгып килгән «Пролетар» газетасында дөнья күргән.

Сугышның беренче көннәреннән үк Аитзәк Аитов фронтның алгы сызыгында. 1941 елның 23 октябрендә Смоленск өлкәсендәге Демидов шәһәре өчен барган бәрелешләрнең берсендә ул дошман пулясыннан һәлак була.

## Әсгать Айдар (1906–1959)



1906 елның 6 июнендә элекке Самара губернасының Иски Сорочи дигән татар авылында туа. Шигырьләр, хикәяләр, повестьлар яза. Сугышка кадәр «Кызыл Үзбәкстан» (Ташкент), «Кызыл Татарстан» (Казан) һәм «Коммунист» (Мәскәү) газеталарында әдәби хезмәткәр, аннары Казанда Татарстан дәүләт нәшриятында мөхәррир һәм Татарстан радиокомитетында әдәби хезмәткәр вазифаларын башкара.

Сугышның башыннан ахырынача Әсгать Айдар хәрәкәттәге армиянең алгы сызыгында була, солдат-разведчик һәм гвардияче старшина сыйфатында бик күп канлы бәрелешләрдә катнаша, берничә тапкыр авыр яралана, сугышчан батырлыклары өчен орден, медальләр белән бүләкләнә.

## Абдулла Алиш (1908–1944)



1908 елның 15 сентябрендә элекке Казан губернасының Спас өязе Көек авылында туа.

Сугышка кадәр татарча чыга торган «Техника» журналында, «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналында эшли, аннары Татарстан радиокомитетында әдәби мөхәррир вазифасын башкара.

Утызынчы еллар—Абдулла Алишның әдип буларак иң күп язган, әкиятләре, шигырьләре, хикәяләре һәм пьесалары белән үзен яшь укучыларга таныткан чор.

Ул 1941 елның июль аенда армиягә алынып, фронтка озатыла һәм солдат-радист сыйфатында Орел өлкәсендә барган оборона сугышларында катнаша.

Шул елның 12 октябрендә Брянск шәһәре тирәсендәге канлы бәрелешләр вакытында чолганышта калып, ул дошман кулына эләгә. Хәрби әсирләр лагерендә чагында татар әсирләреннән төзелгән «Идел-Урал легионы»ның антифашистик яшерен оешмасында катнаша. 1943 елның августында яшерен оешманың эше ачылып, Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре кулга алына. 1944 елның 25 августында алар җәзалап үтерелә.

## Нури Арсланов (1912–1991)



1912 елның 19 сентябрендә Казакъстанның Кызылъяр каласында туа.

Сугышка кадәр «Пионер» журналы һәм «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында рәссам булып эшли.

1941 елның август аенда армиягә алына. Рота командиры сыйфатында Төньяк-Көнбатыш фронтның Ржев шәһәре юнәлешендәге канлы сугыш хәрәкәтләрендә катнашып, авыр яралана. Фронттагы сугышчан хезмәтләре өчен совет хөкүмәте аны «Кызыл йолдыз» ордены һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкли.

Нури Арсланов әдәбиятка сугыш тәэсирләреннән туган «Мәхәббәт» (1942) һәм «Рус кызы» (1943) исемле поэмалары белән килеп керә, тора-бара күренекле шагыйрьгә әверелә.

## Мөхәммәт Әблиев (1900–1941)



1900 елның 15 июлендә Татарстанның Кама Тамагы районы Даныш авылында туа.

Каләм иясе буларак ул егерменче елларда танылa башлый. Повестьлар яза, драматургия өлкәсендә каләмен сыный, 1937 елда үзенең атаклы «Шәмсекамәр» драмасын яза.

Мөхәммәт Әблиев сугышның беренче көннәреннән үк укчы дивизиянең сәяси бүлеге комиссары сыйфатында фронтның алгы сызыгында сугыша һәм, күп тә үтми, дошман пулясыннан һәлак була.

## Әхтәм Әминев (1918–1942)



1918 елда Башкортстанның Илеш районы Әнәс (Әнәч) авылында туа. Үсмер чагында Свердловск өлкәсендә татар телендә чыгып килгән «Социализм юлы» газетасында шигырьләрен бастыра башлый. Аннары Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кереп, сугыш башланган елны институтны тәмамлый. Шул ук елның декабрендә ул фронтка китә һәм берничә айдан, 1942 елның апрелендә, Калуга өлкәсендә барган бәрелешләрнең берсендә каты яраланып, аңына килә алмыйча вафат була.

## Юныс Әминев (1921–1982)



1921 елның 1 декабрендә Татарстанның хәзерге Әгерҗе районы Салагыш авылында туа.

Ул, 1940 елның ноябрендә гаскәри хезмәткә алынып, 1942 елның мартына кадәр хәрби мәктәптә укый, аннары взвод командиры сыйфатында Дон фронтына җибәрелә. 1943 елның 6 мартында яралы һәм контузияле хәлендә дошман кулына әсир төшә һәм 1944 елның августында совет гаскәрләре азат иткәнгә кадәр Румыниядәге хәрби әсирләр лагеренда тоткынлыкта яши. Сталино (хәзерге Донецк) шәһәрендәге 240нчы совет лагеренда әсир төшү сәбәпләрен ачыклау буенча махсус хәрби тикшерүне

үткәннән соң, 1945 елның гыйнварында янәдән фронтка җибәрелә, сугыш беткәнче алгы сызыкта була, Будапештны штурмлауда, Братиславаны азат итү сугышларында катнаша, тагын яралана. Сугышны ул Прага шәһәрендә тәмамлый.

Юныс Әминев сугыштан соңгы елларда чын-чынлап торып әдәби иҗат эшенә керешә һәм, тора-бара, күренекле драматургка әверелә.

## Габдрахман Әпсәләмов (1911–1979)



1911 елның 28 декабрендә хәзерге Мордва республикасының Рыбкин районы Иске Аллагол авылында туа.

Әдәби иҗат белән яшьтән үк кызыксына, шигырьләр, хикәяләр яза, мәсәлән, «Маһинур» исемле хикәясе «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында 1937 елда дөнья күрә. 1940 елда ул читтән торып М. Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый.

1941 елның августында Габдрахман Әпсәләмов сугышка китә. Әүвәл Карелия фронтының диңгез бригадасы составында миномет расчеты командиры, аннары 1943 елның җәеннән 1945 елның маена кадәр шул ук фронтта чыккан «Ватан өчен сугышка» дигән татарча газетаның җаваплы сәркәтибе була.

Сугыштан соң Габдрахман Әпсәләмов, җиң сызганып, әдәби иҗат эшенә чума, күп санлы романнар иҗат итеп, күренекле язучыга әверелә.

## Абдулла Әхмәт (1905–1976)



1905 елның 25 мартында хәзерге Курган өлкәсенең Притобольный районы Звериный дигән татар авылында туа. Утызынчы елларда хикәяче буларак таныла, «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналында әдәби хезмәткәр булып та эшли.

Абдулла Әхмәт сугышның беренче көннәрендә үк фронтка китә, алгы сызыкта гади солдат була, яралана, госпитальдән соң—янәдән алгы сызыкта. 1943 елдан башлап сугыш беткәнчегә кадәр ул «Алга, дошман өстенә!» исемле татарча фронт газетасында хәрби мөхбир булып хезмәт итә.

Сугыштан соң Абдулла Әхмәт проза һәм драматургия жанрларының һәр икесендә дә нәтиҗәле эшли.

## Мөхәммәт Әхмәтгалиев (1920–1943)



1920 елның 21 февралендә Казан шәһәрендә туа. Беренче шигырьләре 1935 елда «Мехчы», «Яшь ленинчы» газеталарында, «Пионер» журналында, күмәк җыентыкларда һәм альманахларда дөнья күрә.

Мөхәммәт Әхмәтгалиев 1942 елның 22 маенда фронтка җибәрелә һәм 1943 елның 27 августында Смоленск шәһәре тирәсендә барган авыр сугышлар вакытында дошман пулясыннан һәлак була.

## Госман Бакиров (1896–1982)



1896 елның 12 мартында хәзерге Татарстанның Арча районы Югары Курса авылында туа.

Ул беренче бөтендөнья сугышында катнаша, 1916 елда дошман кулына әсирлеккә эләгә, аннан котылгач, туган якка кайтып, укытучылык итә. Егерменче елларда «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасын оештыру эшләрендә якыннан катнаша, үзе дә биредә беренче хикәяләрен, очеркларын бастыра. Утызынчы елларда балалар язучысы булып таныла.

Госман Бакиров 1942 елда үзе теләп фронтка китә, башта орудие командиры сыйфатында, аннары «Ватан намусы өчен» исемле татарча фронт газетасының хәбәрчесе буларак, сугышның ахырынача алгы сызыкта була. Ул үз гомерендә икенче тапкыр (Беренче бөтендөнья сугышы вакытында һәм хәзер бу сугышта) Украинаның Тернополь шәһәрен азат итүдә катнашкан зат.

## Кәшфи Басыйров (1906–1943)



1906 елның 17 апрелендә хәзерге Башкортстанның Бәләбәй районы Мәтәүбаш авылында туа.

Беренче хикәяләре 1925 елда дөнья күрә башлый. 1934 елның көзеннән 1942 елга кадәр ул Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә корректор, техник редактор һәм тәрҗемәче булып эшли.

1942 елның гыйнварында Кәшфи Басыйров армиягә алына һәм 1943 елның 16 гыйнварында фашистларга каршы сугышта батырларча һәлак була.

Кәшфи Басыйров әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә шактый нәтиҗәле эшләп калырга өлгерә. Ю. Лебединскийның «Неделя» («Бер атна» 1936), М. Лермонтовның атаклы «Герой нашего времени» («Безнең заман герое» 1937), Н. Гогольнең мәшһүр «Мертвые души» («Үле җаннар», 1947) романнары, В. Короленко, А. Чехов һ. б. рус язучыларының әсәрләре татар укучысына аның тәрҗемәсендә барып ирешә.

## Салих Баттал (1905–1995)



1905 елның 5 августында Татарстанның хәзерге Алексеевск районы Зур Тигәнәле авылында туа.

Шагыйрь, прозаик һәм драматург буларак ул сугышка кадәрле үк таныла башлый.

Ватан сугышы чорында Салих Баттал Хәрби һава көчләренен Тын океан флотында хәрби очучы булып хезмәт итә (1941-1945), япон империалистларына каршы сугышларда катнаша, шәхси батырлыклары өчен сугышчан медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң Салих Баттал күләмле поэмалары, шигъри романнары белән кинкүләм танылу алды.

## Нур Баян (1905–1945)



1905 елның 15 маенда Татарстанның Актаныш районы Әнәк авылында туа.

Ул егерменче елларда, Казандагы татар-башкорт хәрби мәктәбендә укыганда ук әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый, шигырь һәм поэмалардан торган берничә китап бастырып чыгара. 1932-1938 елларда Татарстан дәүләт нәшриятында мөхәррир һәм матур әдәбият бүлегенең мөдире вазифаларын башкара. Чын мәгънәсендә шагыйрь булып танылa.

Нур Баян сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китә, әүвәл полк партия оешмасы сәркатибе, аннары дивизия газетасы редакторы һәм, ниһаять, полк командирының сәяси эшләр буенча урынбасары сыйфатында фронтның алгы сызыгында хезмәт итә. Җиңү көненә нибары унбиш көн кала, 1945 елның 23 апрелендә, Австрияне азат итү өчен барган соңгы сугышларның берсендә подполковник, шагыйрь Нур Баян дошман пулясыннан һәлак була.

## Ислам Беляев (1926–1986)



1926 елнын 14 мартында Татарстаннын Тәтеш кантоны Уразлы авылында туа. Мәктәпне тәмамлагач та, ул армиягә алына, Бөек Ватан сугышында катнаша.

1954 елдан «яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасында эшли башлый, аннары исә Татарстан китап нәшриятында өлкән редактор, редакция мөдире вазифаларын башкара. Укучыларга шигырьләре һәм повестьлары белән таныла. Ул—«Габдулла Тукай» исемле документаль фильмнын (1966) сценарий авторы.

## Касыйм Вахит (1916–1942)



1916 елнын 16 мартында хәзерге Башкортстаннын Әлшәй районы Нигъмәтулла авылында туа.

Беренче шигырьләре 1932-1933 елларда Уфадагы «Коммуна» (хәзерге «Кызыл Тан») газетасында басыла башлый. Ул поэзиянен төрле жанрларында каләмен сынап карый. Татарстандагы көндәлек матбугатта «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан» газетасында, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары»), «Чаян», «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналларында әсәрләрен еш бастыра.

Сугыш башлануга, әле яна гына Казан педагогия институтынын татар филологиясе бүлеген тәмамлаган Касыйм Вахит үзе теләп фронтка китә һәм сугышнын беренче көннәреннән үк алгы сызыкта булып, 1942 елнын 4 октябрендә Сталинград өчен барган канлы бәрелешләрнен берсендә дошман пулясыннан һәлак була.

Сугышчан иптәшләре аны Шелемка дигән авыл янындагы туганнар каберлегенә жирлиләр.

## Хәй Вахит (1918–1978)



1918 елнын 20 декабрендә Татарстаннын хәзерге Биектау районы Мәмдәл авылында туа.

Казан музыка училищесын тәмамлаганнан сон, ул армиягә алына, хәрби жыр-бию ансамблендә жырчы булып хезмәт итә, соңыннан, сугыш башлангач, разведчик-артиллерист сыйфатында Беренче Белоруссия фронтында барган каты сугышларда катнаша, Польшага кадәр сугышчан юл уза.

Гәрчә сугышка кадәр үк яза башласа да, Хәй Вахит күренекле драматург дәрәҗәсенә сугыштан сон ирешә. Ул татар драматургиясен һәм татар театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертә.

## Әзһәр Габиди (1926–2001)



1926 елнын 25 сентябрендә Татарстаннын Сарман районы Чукмарлы авылында туа. Сарман урта мәктәбен тәмамлагач, 1943 елны фронтка китә. Яраланып яу кырыннан кайткач, 1950 елда Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый. Утыз ел буена урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта.

Әзһәр Габиди балалар өчен язган шигырьләре белән танылды.

## Ибраһим Гази (1907–1971)



1907 елның 4 февралендә Татарстанның хәзерге Кама Тамагы районы Иске (Олы) Карамалы авылында туа.

Ул утызынчы елларда әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый, Казанда чыга торган «Авыл яшьләре» журналында һәм «Кызыл яшьләр» газетасында мөхәррирлек вазифаларын башкара.

1943 елдан башлап җину көннәренә кадәр Ибраһим Гази хәрәкәттәге армия сафында фронтта татар телендә чыга торган «Сталин байрагы», «Кызыл Армия» газеталарында хәрби корреспондент булып хезмәт итә.

Сугыштан соң язган роман-повестьлары белән Ибраһим Гази күренекле әдипләр сафына басты.

## Нур Гайсин (1914–1995)



1914 елның 2 ноябрендә Башкортстанның хәзерге Чакмагыш районы Әхмәт авылында туа.

Утызынчы елларда ук аның беренче шигъри мәҗмугалары дөнья күрә.

Сугыш башлангач, ул армиягә алына, әүвәл зенитчы артиллеристлар әзерли торган хәрби курсларда укый, ә 1942 елның апреленнән сугыш беткәнчегә кадәр һава оборонасы гаскәрләрендә взвод һәм зенит батареясы командиры була. Балалар шагыйре һәм прозаик буларак сугыштан соң таныла.

## Әнәс Галиев (1920–1996)



1920 елның 3 апрелендә Татарстанның Арча районы Кушлавыч авылында туа.

1940 елда солдатка алына һәм сугышның беренче көннәреннән үк фронтның алгы сызыгында була. 1942 елның сентябрендә, Майкоп шәһәре тирәсендә барган канлы бәрелешләр вакытында, артиллерист Ә. Галиев чолганышта калып, контузияле хәлдә дошманга әсир төшә һәм 1945 елның апрелендә союздаш гаскәрләр тарафыннан азат ителә.

Әнәс Галиевнең беренче шигырьләре 1937 елда «Кызыл яшьләр» газетасында басыла, аннары исә ике шигырь китабы дөнья күрә (1938, 1940).

Сугыштан соң ул, нигездә, прозаик буларак танылу алды.

## Габдулла Галиев (1920–1941)



1920 елның 20 июнендә Татарстанның Теләче районы Шәдке авылында туа.

Утызынчы елларда аның әдәби эшчәнлеге башлана. Бер-бер артлы яшь шагыйрьнең Татарстан дәүләт нәшриятында ике китабы—«Яшел бөреләр» (1939), «Үсәбез» (1940) дөнья күрә.

Габдулла Галиев, 1939 елда гаскәри хезмәткә алынып, Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтның алгы сызыгында була. 1941 елның сентябрь аенда Украинадагы Каменец-Подольский шәһәрен саклау өчен барган бәрелешләрнең берсендә ул дошман пулясыннан һәлак була.

*Дәвамы киләсе саннарда*



Әхсән
Баян

# ГӨМБӘЗЕННӘН ТӨШМИ СӨЮ-АЙ

## Якты Март

**Килә дә җитә матур Март
Ерак вакытлар урап.
Килүен ел да көтәбез,
Ак бәхетләргә юрап.**

**Зәңгәр вәгъдәләргә юмарт—
Килсә дә җилләп, бурап...
Шатлыклар сибә дөньяга
«Нечкә билле җилле» Март.**

**Аяклары тими җиргә—
Елмаеп, балкып килә.
Кыш суынган күңелләргә
Бәйрәмнәр алып килә.**

**Шаян җилләр белән уйнап,
Бик мавыкма, иркә Март,
Яшь килендәй уз түрләргә,
Бәйрәмнәрне матурлап.
Бик чибәрсең, күз тимәсен,
Хуш киләсең, бик чибәрсең,
Хуш киләсең, якты Март!
Якты Март!**

## Урман кызы

**Урман кызы, күкләр аллангач,
Су буена килде ялангач.
Күрделәр дә: «Ah!»—дип шул чакта,
Таң калдылар таллар як-якта.**

Әхсән БАЯН (1927) – *Татарстанның халык шагыйре, әдип-прозаик, драматург, публицист; күпсанлы китаплар (шул исәптән 5 томлы «Сайланма әсәрләр») авторы. Казанда яши.*

Кыз сөйләде серен талларга:
Сөю—сагыш икән аңарга.
Мәхәббәтен чибәр—шуңарга
Агызмакчы икән суларда.

Шул уй белән йөзде, коенды,
Ярга чыккач, бәйрәм тоелды,
Кызны күргәннән дип бел моны:
Чәчәк күмгән бөтен болынны.

Ә чәчәкләр шундый асыллар,
Зәңгәр, көрән, сары, алсулар.
Кочагында көннең эрегәч таң,
Гүя төсләр иңгән кояштан.

Һәм соклангач чишмә, челтердәп,
Кыз да көлде чишмә төслерәк.
Аны сөеп, урман сөенде;
Ул бакчага хәзер тиң инде.

Кыз киенде, яшел күлмәге,—
Зифа каен!—җилдә тибрәлде.
Кыз—яктыга өстәп татлы моң,
Кушты җырга сөю шатлыгын...

Урман-судан яңа көй алып,
Ул авылга керде елмаеп.
Урман кызы булган яшь җырчы
Күрше кызы иде ахрысы...

## Шомыртлар

Бакча янындагы саз буенда
Чәчәкләргә күмелә шомыртлар.
Чәчәк аткан чакта өсләренә
Төшә томан, төшә болытлар.

Утырткандыр нигә саз буена?—
Белгән эткәм, бары ул белгән.
Сак, дип, әйләндергәч киртә белән,
Күпсенгәннәр—киртә җимерелгән.

Кызгану юк!—чәчәк-ботакларны
Сындырганнар кочак-кочаклап.
Бүләк иткән кемдер сөйгәненә,
Кем ак иткән көнен, туй ясап.

Сындырганнар кызык өчен кайчак,
Шук малайлар, егет-җилкенчәк...
Битләр буялганчы шомырт ашап,
Узды кайсы, безне үчекләп.

«Ул—сезнеке түгел!»—диде кайсы,
Җавап әзер: «Булсын сезнеке!».
Әйтмәгәнбез: «Бүлешегез күкне,
Җил кемнеке, һава кемнеке?»

Әле дә исән шомырт куаклары,
Гасыр хәтле вакыт үтсә дә,
Иренмәгән һәркем авыл күркен
Кочакларга төяп китсә дә...

Рәнҗи белми шомырт куаклары,
Сөенеп чәчәк ата шомыртлар...
Яннарында куна ак томаннар,
Онытмыйча төшә болытлар.

## Көзге

Күрәм, чибәр, аласың да
Син кулыңа тулы ай,
Үз йөзеңә, күк йөзенә,
Сөрмә сөртәсең бугай.

Кемдер бәхет күрер синдә
Очрашу кичләрендә.
Кичләреңдә син мине дә
Ал, дустым, исләреңә.

Болыт төсле чәчләреңнән
Җил сыйпый, сөя назлап.
Көзгеңнән сибелгән ак нур
Миңа да төшсен азрак.

Миңа диген саф төсләрне
Чит-ятларга күчермә.
Талмасын кулың, көзгеңне
Җиргә ялгыш төшермә.

Ак бәхетең калсын бөтен,
Ташлама ташлы ярга:
Язмасын безгә көзгеңнең
Ярчыкларын җыярга—
Төнге караңгыларда...

## Бәйләнчек фикер

Хушлашканда мәхәббәтем
Яшь коймады кайгырып,
Үзенә тиеш җәзаны
Китте миңа калдырып...

Әйләнеп йөри хатирә
Гүяки әрсез черки.
Һич чара юк котылырга,
Черки түгел ул чөнки.

Килми һич тә калдырасы
Тынычлыкта, тынлыкта,
«Сөям!»— диеп, чәнчә килеп,
Булмый үзен куып та.

Сөюнең кабат кайтуы
Шулдыр төсле күренә.
Үзе—чәнчә-чага торган
Бәйләнчек фикер генә.

Хыянәт калган җәзасыз,
Гөнаһсыз гамәл кебек...
Күрсәткәч былтыр көчсезлек,
Йөрим быел үкенеп.

Алдым киңәш, белмим кемнән:
—Хыянәт аша килгән
Бәйләнчек уйдан, фикердән
Ерак булырга өйрән...

## Кояш балкышында

Якты көнгә карый оялгандай
Гөмбәзеннән төшми калган ай—
Үзеннән зур улын кочакларга
Кыенсынып торган анадай.

***

Яшь чибәрләр, шигъри юлларымны
Исәлеккә күчереп язгансыз.
Рәхмәт, сезгә телим узмас бәхет,
Чын мәхәббәт—чиксез, ялгансыз.

**Моңардан зур бүләк бар дисәләр,**
**Андый сүзгә һич тә кушылмам.**
**Гомер юлларыгыз киләчәктә**
**Шигырьдән дә матур булсыннар.**

**Сүз куешкан бәя куючылар**
**Узсын, әйдә, безне гел урап.**
**Иң чын терәк сез бит, сез барында,**
**Җир ныклырак, күкләр—яктырак.**

***

**Кабатлап җырлый гашыйклар,**
**Кабатлый кошлар тагы:**
**«Мәхәбәт—ачы, сагышлы,**
**Сөю—шатлыклы кайгы.»**

**Сизми калдым мәхәббәтнең**
**Шатлыклары беткәнен.**
**Шау чәчәкләр аткан чакта,**
**Карлы җилләр искәнен.**

**Җырлар, никтер, әйтмәделәр**
**Алда ниләр көткәнен,**
**Мәхәбәтсез яшәүләрнең**
**Газап кына икәнен...**

**Тормыш сездән кызганмасын**
**Гомерләрнең татлысын.**
**Сез күрмәгез, сез белмәгез**
**Ярсыз калу ачысын.**

## Мәхәббәтнең соңгы төне

*(эстрада җыры)*

**Сәгатьләрдән төгәл күңел**
**Әйтеп бирде дөресен,**
**Сәгать сукты, инде бүген—**
**Мәхәббәттә соңгы төн.**

**Яңа җырлар ялган түгел—**
**Бүтән булмас мондый төн.**
**Секундларын саклыйм истә,**
**Сәгатьләрен оныттым.**

**Бөтен дөнья белсен, күрсен—**
**Мәхәббәткә бетте көн.**
**Чәчте очкын, сипте төтен**
**Соңгы кабат соңгы төн...**

**Килер әле диеп көттем**
**Ике ай да ике көн.**
**Юраганым ашты чынга:**
**Килде гүзәл соңгы төн,**
**Со-о-оң-гы-ы-ы тө-ө-ө-ө-н!**

*2005—09*

Рауль
Мирхәйдәров

# ҖӘЯҮЛЕ СӘЙРАН

РОМАН

## АЛТЫНЧЫ БҮЛЕК

### Япон

1

Туйдан шома гына китә алдылар. Прокурор Шубаринның кешекарага сиздерми төркем эчендә эреп югала алу сәләтенә игътибар итте. Һәм шушы уен икесенең дә кәефен күтәреп җибәрде.

—Сезнең белән разведкага барырлык икән,—диде канәгать калган Шубарин, әмма прокурорның сүзне дәвам итәсе килмәде. Ул Шубаринны үзенә кирәк сөйләшүгә борырга теләп:

—Ә сезгә нәрсәгә икенче юрист һәм нәкъ менә прокурор?—дип сорады.

Артур Александрович аңлап җиткермәде:

—Нинди юрист, нинди прокурор турында әйтәсез?

Прокурор Шубаринның ихласлыгын сизеп, исенә төшерде:

—Сез Халитовка да эш тәкъдим иттегез, мин үзем генә башкарып чыга алмам дип уйлыйсызмы?

—Ә-ә, хәзер төшендем. Чын, Халитовка ясаган тәкъдимем баштан чыккан.—Артур Александрович елмайды.—Яшермичә әйтүем өчен, зинһар, кичерегез, сездә белем, акыл, прокурорлык колачы белән балаларга хас беркатлылык гел янәшә кебек. Юк, Халитов мина юрист буларак кирәк түгел, юридик мәсьәләләрдә төп таянычым сез булачаксыз һәм көчегез җитәсенә ышанам.

—Ул очракта Халитов нигә кирәк булды соң?—Прокурор сүзен бирмәде.

—Ә мина үз өлкәгездә хуҗа булырга омтылышыгыз ошый, бу яктан без пар килгәнбез: мин дә бар нәрсәне күз уңында тотарга яратам. Фәйзиев синдикатта үзен икенче кеше дип санаса да барлык эшләрдән хәбәрдар түгел, бигрәк тә алда торганнарыннан. Ул миңа җирле җәмәгатьчелек белән бәйләнештә тору өчен кирәк, дип әйтимме. Мине бик теләп юлларыннан алып ташларлар иде дә, кадрлары тиешле югарылыкка үсеп җитмәгән,

*Ахыры. Башы узган елның 12 санында.*

шул тотып тора. Халитовка килгәндә, аның хәзерлеге ягыннан шигем бар: миңа ярым-йорты белемлеләр кирәкми. Безнен якларда белемне ничек алганнарын үземнән чыгып чамалыйм: Ташкентта политехник институтта ике ел укыдым, аннары Мәскәүдәге Бауман институтына беренче курска барып кердем. Чагыштырырга мисаллар җитәрлек... Кызганыч, менә шушы ярыминженер, ярымтабиб, ярымжурналист, ярымбелгечләр, аларны әзерләп чыгарган ярымпрофессорлар, ярымдоцентлар кайчан да булса крайны тупикка китереп терияЧәк, тик берәүнең дә анда эше юк: җирлеләр, үзләренекеләр, янәсе...—Ул башын чайкап куйды.—Халитов үзе түгел, миңа аның элемтәләре кирәк. Ә аның элемтәләре, ай-яй-яй, күптәннән прокурор бит. Менә без Көнбатыш сәясәтчеләре хезмәт урынын калдыруга, аларны зур-зур компанияләр үзләренә ала дибез. Макнамара, Хейг, Киссинджерларны хәтерлисездер. Бездә дә шулайрак... дөрес, киңлек һәм мөмкинлекләр башка булса да, асылы шул. Тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: үзем дә «элеккегеләр»не шактый җыйдым һәм алар минем ышанычымны акладылар. Чынын әйтим, күбесе вакыт сынауларына түзә алмадылар: әзрәк аякларына басуга, элекке гадәтләрен куып, миңа нәрсә эшләргә кирәгеннән көчләп такмакчы булдылар. Ә бит хуҗалык эшләрендә мин-минлек, шапырыну белән бернигә ирешеп булмый, анда икътисади исәп-хисап, тизлек кирәк, шуңа мин андыйлар белән араны шартлатып өзәм. Сезгә төрттерүем дип уйламагыз, сез бөтенләй башка, дан-шөһрәткә исегез китми—ә бу иң мөһиме. Халитовка сезнен мөмкинлекләрегез турында әйткәндә мин шаяртмадым. Бездә чыннан да югары урыннар алу өчен бернинди киртәләр дә юк, бары тик вакыт кына кирәк. Кайбер икътисадчылар әйткәнчә, «күләгәдәге» икътисад белән җитәкчелек итү өчен сәясәтне, кадрлар мәсьәләсен бик нечкә тоемларга кирәк. Тәҗрибәмнән чыгып тагын шуны әйтә алам: югары урыннарда һаман бер үк кешеләр, шуңа мин аларга «күз салам». Шәрык халкы—бик сак халык бит ул, кичәге хуҗаны кире какмый, чөнки «элекке» иртәгесен кабат үз урынын алырга мөмкинлеген аңлый, димәк, ул чагында мин ике тапкыр отам булып чыга. «Элекке»ләр монда элемтәләрен һәм йогынтыларын озак вакытка саклый. Халитовны үз ягыма тарта алсам, ул мине партия һәм совет аппаратындагы төрле дәрәҗәдәге түрәләргә сәфәрләрдән котылдырыр иде. Миңа зур кыенлыклар аша ачыла торган ишекләрдән ул җиңел генә үтеп керә ала. Мин үз дошманнарымның тәҗрибәсен өйрәнеп кенә калмыйм, кулланам да. Дөньяда бар да сонга калып булса да кабатлана. Менә, мәсәлән, студент елларыгызда сезне кока-кола һәм жвачка буржуаз тормыш атрибутлары дип куркытканнардыр, ә хәзер шуларның лицензияләре белән үзебез үк шундый заводлар төзедек. Мин кызык өчен генә тән сакчысы тотмыйм...—Шеф, елмаеп, караңгы юлга йотылган Ашотның җилкәсеннән каккалап алды.

Шубаринның сөйләшергә теле кычытуын чамалаган прокурор моментны ычкындырмаска булды.

—Сез кайтканда Халитов турында сөйләмәкче идегез.

Шубарин, үтәли җилдән куркыпмы, ян тәрәзәнең пыяласын яба төште.

—Халитов турында? Мәгълүматым җитәрлек булса да, әлегә бер сүз дә әйтә алмыйм. Ә менә ни өчен очрашырга теләвем турында сөйли алам. Күләгәдәге икътисад дип әйтик, чөнки, «идән асты» безгә туры килми, без рәсми оешма, законлы рәвештә эш йөртәбез, тик безнең өчен җитештерүгә караганда әзер продукцияне сату күпкә мөһимрәк. Ил икътисады белән таныш кешегә, билгеле, сәер тоелыр, әмма бездә кая карама—дефицит. Менә шуңа мине товарны реализацияләү күбрәк борчый. Даими үсеп барган капитал иясе буларак, мин җитештерүгә йогынты ясый алам. Тик

монда товар чыгару базарлары мәсьәләсе килеп туа. Без үз республикабыз эчендә генә кайный алабыз. Аннан читкә чыгу—көтелмәгән нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Анда кануннар катгыйрак дип уйлый күрмәгез, юк, без анда бары читләр генә, яклаучыларыбыз булмаганга, безгә чын-чынлап канун көчен күрсәтергә мөмкиннәр. Әле үз республикабызда да гади генә түгел: һәр өлкәнең үз хуҗасы дигәндәй, аяк чалырга җай эзләп кенә торалар, менә шуңа күрә мин арага күпер салу өчен «лоббистлар» тотам да инде. Халитов прокурор булган өлкәдә без берни эшләп чыгармыйбыз, бары әзерне сатабыз гына. Тик шунысын да әйтим, бу—безнең иң төп базарлардан берсе, чөнки республикадагы туристлык маршрутларының яртысы шушы өлкә аша уза. Уйлап карагыз, һәр көнне кесәләре акча белән тулы йөзләгән сатып алучылар...Тик бу базар өчен көрәшергә туры килә. Дөресен генә әйткәндә, Россия өлкәләрендәге экскурсия бюролары белән килешү төзү өчен шактый тырышырга туры килде, нәтиҗәдә һәр җомгада хезмәт хаклары югары саналган Кемероводан, Донецк, Төмән, Хабаровскидан йөзләгән туристлар өч көнлек путевка белән килеп төшәләр. Алар килешкә без җанфәрманга кайры туннар тегеп өлгертәбез, кунакханәдәге безнең кибетләр соңгы сатып алучыны озатканчы—төн уртасына кадәр эшли, мондый хәлне тагын кайда күргәнегез бар? Шунда, киоскта ук, заказлар китабы бар: кемгә җитмәгән, йә үлчәме туры килмәгән—рәхим итеп авансын калдыра да алдагы җомгада сатып ала.

Сез безнең хуҗалык белән танышырсыз әле, анда халыктан тиреләр җыюдан башлап әзер әйберләрне сатуга кадәр эшләр гөрләп бара. Мин кайры туннарны иң кыйбатлы һәм табыш күп китергәнгә генә мисалга китердем, бездә продукциянең ассортименты йөздән арта, бар да табыш бирә торган. Тик шунысы бар: үзебез булдырган базардан вакыт-вакыт каршылыклар туа. Өлкәдә халыкны эш белән тәэмин итү авыррак, шуңа Халитов предприятиеләремнең бер өлешен монда күчерергә куша. Тик моның мәгънәсе юк дип саныйм. Ни өчен?—анысын соңрак үзегез аңларсыз. Өлкәдә әзер әйберләрне сату белән Алла тарафыннан сәүдәгәр итеп яратылган Әхрәров шөгыльләнә, ә прокурор, урамда сатарга ярамый дип, аның биш киоскын яптырды. Безнең эш хакы исә продукцияне күпме сатуыбызга бәйле. Җиһазларыбыз да кыйбатлы, тулы көчкә эшләгәндә генә үз-үзен аклый ала. Халитов бугазга пычак терәгән күк булды, әмма без аның белән ничек тә уртак фикергә килергә тиешбез. Бюджетка шактый акча күчергәнгә генә безгә карата түзеп торалар. Кемнең тиктомалга килеп кергәнне югалтасы килсен? Әле җитмәсә, өстәгеләр вазифаларына карап, төрлечә «сава». Ритмнан язганга караганда, безгә түләү отышлырак. Халитов Әхрәровтан күптәннән үзенә тиешлесен каерып алып бара, ә хәзер... безнең аяк-кулны бәйләп, җитештерүгә дә үз сәясәтен үткәрмәкче була.

Шубаринны бик бирелеп тыңлаган прокурор үз авызыннан :

—Монда эшче куллар белән җиңел булгач, өстәвенә урындагы хакимиятләр дә кызыксынгач, нигә предприятиеләрегезне, һич югында филиалларны, цехларны ачарга уйламыйсыз соң?—дигән сорау чыкканын абайламый да калды.

—Менә-менә, сез дә алар җырын җырлыйсыз. Ни өчен дисезме, җавап бирәм—миңа теләсә нинди хезмәт ресурслары кирәк түгел. Гади генә мисал китерим... Кайдадыр туксан процент хатын-кыз өйләрендә утыра, шундый куәтле көчне эшкә җигәргә кирәк, дип шау-шу куптаралар. Ә бит аларның берсе дә хатын-кызларның санын, яшьләрен, гаилә хәлләрен, нәрсә белән шөгыльләнергә теләүләрен, нәрсәгә сәләтле, хәзерге заман җитештерү ритмнарына әзерме-юкмы икәнлекләрен рәтләп белми дә...

Әйтик, үзәктән читтә хатын-кызлар өчен келәм фабрикасы төзеп

куйдылар, ди. Төгәл нәрсә белән шөгыльләнәсен белмәгән тирә-яктагы бар хатын-кыз ябырылачак, сүз дә юк. Ябырыла, чөнки балалары авырып киткән очракта больничный лист биреләсен белә, шулай ук декрет ялы, бала туганнан соң яшь ярымга кадәрле бирелә торган ял, балаларга өстәмә түләү, гомумән, эшләүче хатын-кызларның өстенлекле хәленнән хәбәрдар—аның аңына әгәр предприятие эшчесе саналса, хезмәт хакы эшләгәнгә генә түгел, теләсә кайсы очракта да түләнергә тиеш дигән нәрсә кереп урнашкан. Ә аннары башлана инде тәртипсезлек... Цехтагыларның көн саен өчтән бере эшкә чыкмый башласа, директорга нәрсә эшләргә кушасыз, әле аларның һәрберсендә өч-дүрт бала йә аннан да күбрәк, өстәвенә әле тудыруларын дәвам итәләр, ә бит балалар бик еш авырыйлар. Шулай итеп, елдагы ике йөз житмеш эш көне тоташ больничный листтан торырга мөмкин булып чыга түгелме соң? Әле шуңа декрет яллары өстәлсә, кайбер хатын-кызлар эш урыннарында елга биш кенә күренеп ала. Ел арты ел шулай дәвам итә. Алардан нинди эшчеләр чыксын инде? Хәзерге заман предприятиесе күнекмәләр, югары дәрәҗәдә һөнәри осталык, тәртип таләп итә. Әле андый эшчеләрне эштән азат итәргә дә ярамый. Ахыр чиктә фабрика янәшәсенә ашыгыч кына тулай торак төзеп куялар да, унайлыклар вәгъдә итеп, төрле яклардан яшь кызлар жыеп китерәләр. Шуннан нинди табыш, продукциянең нинди үзкыйммәте турында сүз булырга мөмкин, йә? Бу очракта келәмнәргә бәяне коточкыч күтәрсән генә инде...

Менә хәзер аңладыгызмы инде мине ни көткәнен? Безгә банкротлыкка чыкмас өчен, даими ихтыяж-сорау, базарны өйрәнергә, ассортиментны яңартып, яхшыртып торырга кирәк. Тагын да шәбрәге—тиз арада яңа төр әйберләр чыгара башлауны көйләү, аз сандагы, әмма югары квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр хисабына жиһазларны бар көченә эшләтеп үзкыйммәтне киметү. Сыйфат турында әйтеп тә торасы юк... Кадрларны мин үзем сайлап алам. Аларны тәкъдимнамәләр буенча эзләп табабыз, кирәк булса, укытабыз, өйрәтәбез. Менә шуңа мин Хаитовның тәкъдимен кабул итә алмыйм.

—Минем анлавымча, өлкәдә предприятиеләр ачарга теләмәвегез кадрлар аркасында гына түгел бугай, шулаймы?

Шубарин ихластан көлеп жибәрде дә кабат сүзсез генә юлга текәлгән шоферның аркасыннан каккалап алды.

—Күрдеңме, Ашот, безнең белән бу машинада нинди генә зур кешеләр юл кичмәде, тик берсе дә яңа юристыбыз кебек авыздан чыкканны эләктереп ала белмәде. Мондый сыйфатыгыз белән кайчан да булса жирле сәнәгать министры булмагаегыз. Әйе, сез хаклы, кадрлар мәсьәләсе медальнең бер ягы гына. Яшермим, кадрлар никадәр генә кыйммәтле булмасын, безнең өчен иң мөһиме, әлбәттә, югары житештерүчән жиһазлар һәм чимал булып кала. Үзебез түләгән хезмәт хакына без өйрәнергә һәм унбишәр сәгать эшләргә әзер кешеләрне, дөресен әйтим, матди яктан риза булмаган белемле инженерлар мохитеннән һәрвакыт таба алабыз. Тормыш тарафыннан жәберләнгән бу югары белемлеләр бик тиз арада хезмәт күнекмәләре алып, соң чиккәчә тырышып эшли башлыйлар. Бездә тик торуның, йә булмаса авыртуның файдага түгел икәнен һәркем белә, аңлый. Бераүгә дә чималны, энергияне янга калдыру кирәклеген кабатлап торасы юк, чөнки хезмәт хакының шуңа бәйле икәнен төшенәләр. Һәртөрле яңалыклар,сакчыллык, идеяләр бүләкләнә. Менә шундый хезмәткәрләр. Әмма алар арасында да алыштыргысызлары була әле. Мисал өчен, сарык тиресе иләү—тун тегү житештерүен торгызганда, тире иләүче-мехчыны Белоруссиядән чакырып китердек. Аның белеменнән, тырышлыгыннан, оештыру сәләтеннән башка без бу табышлы эшне аякка бастыра алмаган булыр идек, ә менә аның хезмәт

хакы теләсә кайсы фининспекторның чәчләрен үрә торгызырлык. Осталар турында сүз чыккан икән инде, мактана алам—крайнын, хәтта аннан читтәге осталарнын күпчелеге бездә: калыпчылар, лекальчы, технолог, рәссам, станок һәм жиһазларны көйләүчеләр, конструктор, уйлап табучылар... Үзебезнең финанс мөмкинлекләреннән чыгып, үзгәртеп, теге яки бу житештерүне жайга салу бик жинел, безнең эштә ин мөһим отыш—вакыт бит. Кем әйтмешли, һәрнәрсә үз вакытында кадерле!

Жиһазларга әйләнеп кайтыйк әле... Безнеке сериялэп чыгарылган түгел, ә осталар тарафыннан үзгәртелгәннәр, йә жирле заводлардагы уйлап табучылардан аларны бернichә данәдә эшләтеп алабыз. Чит ил жиһазлары да бар, дөрес, аларны табуы кыенрак. Бездәге житәкчеләрнен күбесе техник белемле, үзем турында әйттем инде, шуна без машина төзү заводларында барган эшләрдән, аларның мөмкинлекләреннән яхшы хәбәрдар. Сүз дә юк, чит илдәге яналыклар белән дә танышып барабыз, житештерү һәм сыйфатка караган технологияләрне күз унында тотабыз. Күпчелек станок, машина, жиһазларнын шәхси хужалары бар, әйе-әйе, гажәпләнмәгез, шәхси хужалары һәм мин аларга шактый акча түләргә мәжбүрмен, кая барасын—бик сирәк станоклар алар.

Мисалга, бер ел элек минем янга Одесса кешесе килеп чыкты. Ул кайчандыр коры әйберләр төяп ташый торган суднода механик булып эшләгән, менә диген инженер, көндез чыра яндырып эзләсән дә андыйны таба алмыйсың. Менә шул кеше бер чит портта ремонтта торганда яныбызга килде, чүпрәк-чапрак, джинсы һәм аппаратураларга күз дә салмый, техниканы караштыра. Хәзер инде ничек булганын төгәл генә әйтә алмыйм—ул безгә бакыр фурнитура кулланып пластмассадан «хрусталь» люстралар штамплаучы ике ярымавтомат итальян станогы китерде. Ике станок та өчәр төрлене чыгара—барысы алты типта. Гажәеп инде менә, сатуга чыгарып өлгертә алмыйбыз, шунда ук алып та бетерәләр. Бәясе дә «тешләрлек түгел»: утыз—илле тирәсе. Үзебез дә шундый жайланманы корып карадык, эшли, әмма сыйфат ягыннан калыша. Бу механик белән килешү төзедек: жайланмаларны файдаланган өчен һәрберсенә ике ел дәвамында ай саен икешәр мең түләп барырга, ә аннары ярымавтоматлар безнең милеккә күчә. Үзе гаиләсе белән өчәр смена эшләсә дә, базарда ихтыяж бетмәде. Ике ел эчендә шунын кадәрле акча эшләп алдылар, мөгаен, анын кадәрлене гомерләре буена да таба алмаслар иде. Нәрсә әйтәсем килә: без генә түгел, осталар, уйлап табучылар, талантлы инженерлар үзләре дә безне эзләп килделәр.

Кайчакларда кирәкле жиһазларны акча күчерү юлы белән ала алмаган очраклар була, ул чагында зур акчалар эшкә жигелә. Бик күпләр андый сумма алдында калтырап төшәләр. Ә бу акчалар—пайчыларныкы, бәлки берзаман сез дә шуларнын берсе булырсыз әле, бездә аны икенче төрле өлешкә керү дип атыйлар. Жиһазларның яртысы аларныкы санала, безнең бурыч—таш яуса да пайчыларнын кертемнәрен кире кайтару, ә аннары табылган акчадан процентлар түли башлыйбыз. Бу беренче карашка гына катлаулы тоела. Хисапчыларыбыз, шөкер, акыллы, өстәвенә пайчыларыбызның һәрберсендә ялгышу белмәс «Кассио» хисаплау машиналары. Менә шуннан үзегез анлагыз инде, мин Халитов кушты дип жиһазларны теләсә кая урнаштыра аламмы? Житмәсә, бу мәсьәләне үзем генә хәл итмим, жиһаз хужалары һәм пайчылар белән берлектә карыйбыз. Ә беләсезме, өлешкә керүчеләр арасында кемнәр дә булырга мөмкин? Прокурор, ОБХСС начальнигы, партия житәкчесе, хәтта завод директоры белән министрга кадәр.

Сүзсез генә тынлап барган прокурорнын хәтерендә Халитовнын сүзләре калыкты: «...барысын сатып алды, барысын үз эшенә тартып кертте, бар

да аның тирәсендә бөтереләләр...», «...сезнең дус-белешләрегез, дөресрәге, әрәмтамакларыгыз мине тәмам китереп кыстылар...»

«Барысы да исәпләнгән: акчасын керткән кеше аның үсеше өчен жанфарманга тырышмый кая барсын,—дип уйлап куйды Азлархaнов.—Нәкъ менә яшерен синдикат инде...»

Ул шефына күз салды: үз-үзенә ышанган, тыныч, теләсә нинди очракта да үзен кулда тота белә. Дөресен әйтергә кирәк, прокурор каршында утырган кеше—искиткеч талантлы һәм... куркыныч. Кайбер очракларда, мөгаен, аның сүзе финанс министры белән республиканың Дәүләт банкы рәисенекенә караганда да үтемлерәктер, чөнки кирәк икән—зур күләмдәге «тере» кыштырдап торганнарны чыгарып салу аның өчен ике тиен бер акча. Әле тагын, һәрбер хуҗалык житәкчесе кебек, казна ярдәменнән дә баш тартмый: исәп-хисап чуты, кредит, ссудалар... Хокук белгече буларак, Азлархановка монда уйланыр нәрсәләр күп күренә.

Билгеле, Шубаринның «хуҗалыгында» кайнау өчен прокурорга әле күп тырышасы: тиз арада икътисад, хуҗалык, банк эшләре буенча белем эстәргә кирәк булачак, әле аннан соң да барлык финанс махинацияләренә, ай-һай, төшенә алуы икеле: Шубаринның үткенлеге, сизгерлегенә тан калырлык.

Азлархaнов:

—Сез ничек уйлыйсыз, бу яшерен икътисадның барлыкка килүенә һәм чәчәк атуына сәбәп ни?—дип сорау бирде.

—Әһә, нәкъ прокурорларча бу,—шеф шаяртуга бормакчы булды.—Соравыгызга җавап табу өчен мин әүвәл җиһазлар турында фикеремне дәвам итим әле.

Безнең аеруча табышлы төп хуҗалык көчләре Бохарада урнашкан. Мин беренче тапкыр шунда чирканчык алдым, шунда житлектем, таяныр кешеләр таптым, ә иң мөһиме «лоббистлар» аша өлкә хуҗасына чыктым. Ә хәзер без аның белән бергә бәйләнгән, аның янына теләсә кайсы вакытта кереп йөри алам. Ә ул үз чиратында республикадагы «Беренче»нең яраткан, үз кешесе. Хәер, сез аны миңа караганда да яхшырак беләсездер? Прокурор булып эшләгәндә бер генә очрашмагансыздыр, аның хакимлек итәргә яратуын беләсездер дип уйлыйм. Шуңа минем алда бернинди каршылыклар да юк. Сүз уңаенда, нигә әле сезгә мөмкинлек чыгу белән жирле сәнагать министры булмаска ди? Республикадагы кадрлар мәсьәләсе тулысынча аның кулында бит.

Бервакыт шулай дефицит чимал өчен Мәскәү фондларын кулга төшерү җае чыкты, бик тиз арада илле мең кирәк. Шуннан тегенең янына киттем, бер елдан икеләтә кайтарырга вәгъдә бирдем. Ә ул, беләсезме, кабинетындагы сейфыннан биш төргәк алды да кулыма тоттырды. Хәтта нәрсәгә кирәк булуы белән дә кызыксынып тормады. Билгеле, мин дә әйткән көнемдә ун төргәкне илтеп бирдем. Шунда ул миңа, шаярткан булып: »Аларны әйләнешкә кертеп җибәрү мөмкинлеге юкмы?»—дигән булды. Капиталының тагын икеләтә үсүен тели иде—мин моны сиздем. Ул чакта бернинди планым булмаса да: «Әгәр сезнең тарафтан әз-мәз терәк булса—баш өсте»,—дип җавап кайтардым. Менә шулай һич көтмәгәндә, кем әйтмешли, карт-бланш алдым. Шундый пайчыларның өлешләре булганда, эшкә иң сак кешеләрне дә тарта алдым һәм бернинди куркусыз дефицит, югары житештерүчән җиһазлар алып, алга карап, озак вакытлы программа белән эшләү мөмкинлегенә ирештем. Кырык урында ясалма мехтан ир-атлар, хатын-кызлар, балалар туннары тегү цехлары ачтым. Иң оста кием кисүчеләрне бер урынга тупладык, алар өчәр сменага бүленеп, көне-төне эшләделәр, өстәвенә модадан да калышмадылар, ассортиментны да гел яңартып тордылар. Шунлыктан базарларда туннарны кулдан тартып алып

бетерә бардылар. Озын сүзнен кыскасы, озакламый турыдан-туры тәэмин итеп торучыларга чыктым һәм, «тере» акчалар түләп, өчтән бер бәясенә вагон-вагон чималлар алып, Бохарага озаттым.

Бохарада һәм өлкәдә куркыр сәбәп булмаганга, мин предприятиеләрне жиһазлар белән тутырдым—эшлә дә эшлә генә. Шулай да, үзегез күреп торасыз, предприятиеләрнең үзәге барыбер монда, сезнең белән очраштырган «Лас-Вегас»ка күчте. Менә монда ачу—мина калса, ин унышлысы.

Әле рудник эшләп торган вакытта, үз эшләрем белән монда килеп чыгарга туры килде. Төрле божралар, прокладкалар, сальниклар, дефицитның-дефициты—пляж өчен модалы аяк киемнәре житештерү цехы ачарга иде исәбем. Бер-ике көн предприятие буйлап карангалап, кайбер житәкчеләр белән сүз алышкалап йөргәннән соң, руда комбинатының көннәре санаулы калганын аңладым. Ин аз дигәндә бер елдан аны таркатачаклар, ә көчле, заманча житештерү базасы һәм мәйданнары калачак, гадәттә аларны булдыру өчен еллар һәм акча, бик күп акчалар китә бит.

Туры килүен кара: жирле хакимиятләр башларын кашып торганда, мин килеп чыгам да халык кулланылышы товарлары житештерә торган үзебезнең цехларны ачарга тәкъдим итәм. Әлбәттә, житештерүнең чын масштаблары турында ләм-мим—авыз биктә.

Ә инде юраганнар юш килгәч, шәһәр хакимиятләренә сүзләре кайда да үтә торган пайчыларым белән төзегән программамны бернинди каршылыксыз кабул итәсе генә калды..

Минем монарчы шул тикле колач җәеп, янып эшләгәнем юк иде әле... Шәһәр хакимиятенең каушап калуыннан, көчсезлегеннән файдаланып, пиратларча кыландым—ничек телим, шулай эшләдем, ә жирле администрация миңа һәрьяклап ярдәм күрсәтте.

—Халитов сезне гангстер дип атагач, үпкәләгән булдыгыз тагын,—дип төрттерде прокурор.

Шубарин моны шаярту дип кабул итте һәм, көлемсерәп, бүленгән фикерен ялгап китте:

—Андагылар өчен минем эшем кара урман иде, мин, әлбәттә инде, аларга аңлатып торуны кирәк санамадым. Тау ведомствосы кушуы буенча күп нәрсә сүтелергә һәм чыгарылырга тиеш булса да, күзебез нәрсәгә төште—барысын да үзебезгә калдыра алдык. Буталчыклык, хуҗасызлык, җавапсызлык аркасында жиһазларның күпчелеге әлегә кадәр безнең тарафтан баланска алынмыйча каядыр һавада эленеп тора бирә—исән-акылын китәрлек!

Ышанасызмы-юкмы, термик мичләрдән файдалансак та, әлегә кадәр ни электр энергиясе, ни су, ни газ өчен бер тиен түләгәнебез юк. Ә безнең цехлар шундый зур көчәнеш белән эшлиләр ки, жиһазларның смена коэффициентының ил күләмендә иң югарысы бездәдер, мөгаен. Тау ведомствосының башсызлыгына диимме, ваемсызлыгынамы—кыскасы, юмартлыгына шаклар катарлык.

Менә сез, мәсәлән, икътисадчы булмасагыз да, бездә әйберләрнең үзкыйммәте нинди түбән булуын чамалыйсыз, чөнки фондлардан тыш без чималны акчалата йә ярты бәясенә, йә чирек, ә кайчакларда хәтта бушка диярлек алабыз.

Артур Александрович, сөйләвеннән туктап, артына борылып карады, сүзләренең прокурорга ничек тәэсир итүен йөзеннән укырга теләде, ахры.

Прокурорның игътибары анарда иде. «Кызык,—дип уйлады ул, мондый лекциягә Шубаринны кайсысы этәрде икән: уңышлы майтарылган эшме, әллә бераз «төшергән» булуымы? Әллә ул, чыннан да, беркемнән дә курыкмыймы? Һәрхәлдә, миннән шүрләми—монысы көн кебек ачык...»

—Бервакыт, ун еллап элек, «Известия»дә Әрмәнстандагы кайсыдыр авторемонт заводы турында бер мәкалә укыган идем, күрсәтелгән адрес буенча барсаң, анда заводның исе дә юк—бушлык икән. Әмма предприятие республикада алдынгылардан, табышлылардан санала, күп тапкырлар бүләкләнгән, макталган, аның турында матбугатта мәкаләләр дә күренгәләп торган. Барлык исәп-хисап эшләрен бердәнбер кеше, минем карашымча, финанс даһие алып барган, ә предприятиене кәгазьдә генә яшәгән хуҗалык механизмын биш бармаклары кебек шәп белүче берничә аферист төзегән икән.

Менә шул вакытта үз-үземә нәтиҗә ясадым: кайчан да булса предприятиегә нигез сала калсам, ул чын, үсә торган, рәсми, алдынгы булачак, тик... айсберг принцибында төзеләчәк, ягъни күзгә күренми торган өлеше витрина һәм отчет өчен билгеләнгән өстәгесеннән өч мәртәбә артыграк булачак. Ә моның өчен Әрмәнстанныкыннан ким булмаган бухгалтер, икътисадчылар кирәк; тора-бара мин андыйларны таптым, үзем дә икътисад һәм планлаштыру буенча белем тупладым. Шунсыз яшерен икътисадта син—нуль, анда башларыннан тыш, капиталы һәм ышанычлы иминиятләштерелгән аслар, китлар гына исән кала ала.

«Икеләтә бухгалтерия», «өч катлы» кебек теләсә нинди әйтем безгә туры килми. Ул югары математика төшенчәсе белән, мәсәлән, бишүлчәм белән билгеләнергә тиеш. Әгәр шундый үлчәү мөмкинлеге булса, әлбәттә. Безнең предприятиеләр ин табышлысы, ин механикалаштырылганы, бездә иң югары хезмәт күрсәткечләре, иң түбән үзкыйммәт, ин яхшы файдалы эш коэффициенты, менә дигән эш шартлары, хезмәт хаклары турында әйтеп тә тормыйм. Барлык күрсәткечләр буенча иң алда барабыз, сезгә, бәлки, сәер тоелыр,—нәкъ менә социалистик предприятие үрнәге диярсең. Безнең белән тирә-яктагы гына түгел, республика күләмендә бер генә тармак та ярыша алмый—без иң беренчеләр. Нинди генә байракларыбыз юк: союзныкы, республика, өлкә, шәһәр, тармакныкы дисеңме, ВЦСПС, министрлар Советы, комсомолның ҮКы байракларымы, күчмәсеме яки бөтенләйгә бирелгәнеме—бар да махсус залга куелган. Сүз җаенда мактанып алыйм әле: мин—Хезмәт Кызыл Байрагы ордены иясе, «Лас-Вегас»та шәһәр советы депутаты.

Прокурор кинәт алгы тәрәзә өстенә беркетелгән көзгедә Ашотның йөзен күреп алды: ул салмыш шефының шапырынуын ошатып бетермәде бугай, бәлки хуҗасының ачылып китүе аның өчен дә яңалык булгандыр. Тик шефы белән нинди генә мөнәсәбәттә булса да, Ашот прокурорны өнәп җиткермәде шикелле. Җинаять кодексы белән таныш егет өчен прокурор элеккеме йә хәзергеме—барыбер «мент» булып кала, күрәсең. Рәшәткә артында аны беркайчан да аларга ышанырга ярамый дип өйрәткәннәр, ахры. Юк, ул моны тышкы яктан сиздермәскә тырыша, ә менә көзгедә тотып алган карашыннан прокурор Ашотка карата сак булырга кирәклегенә төшенде.

Юл кырыйларында артка шуышып калган кышлак утларына караганда, алар шәһәргә якынлашалар иде. Гостиницага кайтып җитәргә чама белән кырык минутлап калгандыр, димәк, әле ул сүзгә юмартланып киткән шефына тагын берничә сорау бирә ала иде.

—Эшнең шулай куелышына сезнең эшчеләрегез ничек карый соң? Һәм тагын бер сорау: сезнең айсберг яклаучыларыгызга ни дәрәҗәдә бәйле?

Артур Александрович уйланып торганда, Ашотның тавышы ишетелде:

—Менә прокурорлар шундый инде алар, бар нәрсәне берьюлы чыгар да сал...—һәм үз-үзеннән канәгать калып, көлеп куйды.

Прокурор, бәлки, бу сүзләрне шаярту буларак та кабул иткән булыр иде, мәгәр Ашотның әлеге дә баягы көзгедә чагылган салкын күз карашы моның киресен раслый иде.

—Сораулар кискен, дөрес, әмма эшкә керәп киткәндә мин дә нәкъ шулай ачык, анык белергә теләгән булыр идем.—Хуҗасы Ашотның аркасыннан кагып куйды: шаяртуын ошаттымы, әллә синең эшең түгел, дип кисәтүе булдымы.—Аннары дәвам итте:—Эшчеләргә килгәндә... Сез юкка гына аларның социаль активлыкларын купайтасыз. Алар өчен иң мөһиме—хезмәт хакы, әйбәт эш шартлары һәм гадел мөнәсәбәт. Мин үзем менә шушылардан башка уңышка ирешеп булмый дип саныйм. Алда әйтеп киттем инде: без кешеләрне бик сайлап кына алабыз. Аннары, алар нәрсә белергә мөмкин? Алар түгел, хәтта инженерлар да бөтенесен аңлап бетермәслек итеп төзелгән безнең структура. Ышаныгыз, яшерү максаты белән түгел, ә яңгырашлылык өчен шулай оештырылган: мисал өчен, берничә урында кисәләр, башка уннарча урында тегәләр, халык яши торган йөзләгән пунктларда сатабыз.

Әгәр нәрсәдәндер канәгать түгелләр икән—кая барсыннар? Сайланырлыкмыни? Сез эшләгән кирпеч заводына барсыннармы? Ни хезмәт хакы, ни тәртип юк! Мин үстергән җимешләр түгел: кешеләрне дәшмәскә, кирәкмәгән җиргә борын тыкмаска өйрәткәннәр, янәсе, әнә җитәкчегез бар—уйласын. Һәм безнең эшчеләребез канәгать, тик ниндидер килешмәүчәнлек килеп чыга икән, шунда ук бетерергә тырышабыз, килешү юлын һәрвакыт табып була дип саныйм.

Һәр елны бер яки ике группа эшчеләребез юлламалар белән чит илләргә, социалистик илләргә баралар. Тәҗрибә уртаклашып кайтырлык итеп, илләрне мин үзем сайлыйм.

Мәсәлән, тире иләүчеләр Югославиягә, аяк киемнәре тегүчеләр—Чехословакиягә, кием тегүчеләр һәм трикотажчылар—Венгрия белән Польшага барып кайттылар, һәрберсендә алдан килешү буенча үзебезне кызыксындырган предприятиеләрдә булдылар. Чит илдән дистәләгән тәкъдимнәр белән кайталар һәм без аларны шунда ук житештерүдә кулланышка кертеп җибәрәбез. Әле тагын шундый очраклар да була: мәсәлән, безнең истә-оста да булмаган өр-яңа тегү машинасы сатып алалар, ә ул процессны ун мәртәбә тизләтә һәм яхшырта торган булып чыга. Йә булмаса чемодан тутырып үзебездә көндез чыра яндырып эзләсәң дә табылмый торган чыдам жепләр алалар, дистәләгән тартма «зингер» инәләре, өем-өем запчастьлар һәм тартма-тартма пистоннар, каптырмалар—болар бар да продукцияне яхшыртуга китерә. Без, билгеле, чыгымнарга акча кызганмыйбыз, аларның эшкә карата шундый мөнәсәбәтләрен хуплыйбыз. Кайберләре ял итү һәм күңел ачулар урынына берничә көннәр цехларда югалып яталар, үзләре өчен таныш булмаган кисү йә башка төрле технологик процессларны үзләштерәләр, чөнки беләләр: без аларга соңгы нәтиҗә өчен түлибез.

Сүз дә юк, эшчеләр белән капма-каршылыклар килеп чыккалый, тик сез уйлаган җирлектә түгел. Гадәттә өстәгеләр пайчылар белән нидер бүлешә алмый, тик һәрвакыт килешү ягын карыйбыз. Кемдер уеннан чыгарга тели икән—рәхим итсен, без аны тоткарламыйбыз, пай акчасын кулына тоттырабыз да саубуллашабыз, өлешкә керәм дип торучылар муеннан, тик теләсә кемне аласы килми, чөнки хәзер безне акча кызыксындырмый. Әгәр инде ызгыш-талашлар тирәнгәрәк китеп, безнең күзәтүдән ычкынса, ул очракта эшкә зыян килмәсен өчен барысын да эшләргә туры килә. Ахыр чиктә Ашот белән аның дусларына мөрәҗәгать итәм,—дип тәмамлады сүзен Шубарин.

—Ярдәм итәме?—дип кызыксынды прокурор.

—Без бит алдан сүз куешмыйбыз,—диде Ашот, ачулы көлемсерәп.

—Тик бу—иң соңгы чара,—дип сүзгә кушылды Шубарин, ашыга-ашыга. Ул Ашот кирәкмәгәнне сөйләп ташлар дип курыкты, ахрысы.—Ә

икенче соравыгызга килгәндә, нәрсәдер табу, оештыру, житештерү, сатып зур табыш алу—миңа калса, вак махинаторның талантын күрсәтә, аның максаты, әйтик, йөз, ике йөз мең эшләп алу, ул шуннан артыгын булдыра алмый. Кайчандыр мин япон суднотөзелеше турында бик кызыклы бер мәкалә укыган идем. Бу борынгы һәм шул ук вакытта хәзерге заман тармакларының берсе. Хәзер анда фән һәм техниканың бар казанышлары тупланган. Японнар гадәттә батмый торган суднолар төзиләр. Элегрәк корабль төпкә китсен өчен тишекләр дә житә иде. Хәзергеләр исә бик сирәк очракта гына бирешә, анда да зыян күрмәгән бүлекләре судноны батудан саклый, алай гына түгел, шуннан торып аварияләрне бетерергә була. Менә мин дә айсбергның батмый торган шундый моделен төзедем дияргә мөмкин. Тулысы белән миннән башка тагын ике кеше генә—баш бухгалтер белән баш икътисадчы кына хәбәрдар, кем әйтмешли, без өчәүләп көн дими, төн дими вахтада торабыз. Тик барысы да, хәтта пайчылар да бөтен нәрсә минем кулда дип беләләр, хәер, кайберләре Икрам Мәхмүтовичны катнаштырып сөйлиләр бугай.

Теге ике кешегә үземә ышангандай ышанам. Юк, минем аларны куркытканым да, үземә ни беләндер бәйләп куйганым да булмады... Бары тик алар бик башлы һәм айсбергның батмасын яхшы беләләр. Уңышсызлыкка очрый-нитә калсак, янгын вакытындагы кебек, уттан чигенү вариантлары эшләнгән. Япон корабләндәге шикелле, янгынны сүндерешергә күрше бүлекләр дә кушыла, алайса үз байлыклары да юкка чыга бит. Җавабым шул: мин пайчы-яклаучыларга караганда үз моделемә күбрәк ышанам. Дөрес, аларның ярдәмнәрен дә инкарь итеп булмый. Бигрәк тә аякка басып килгәндә миңа акча, бик күп акча кирәк булды, ә хәзер тәгәрмәч әйләнә башлагач, акчага мохтажлыгым юк, чималны да залогка биреп торалар. Хәзер безгә шундый акча салучылар кирәк: беренчеләре—дефицит чимал һәм жиһаз табучылар, икенчеләре—табыш алуны гарантияләүчеләр, өченчеләре исә—«янгын сүндерүче» ролендәгеләр. Файда, табышның төмен бер татыганнар үзләре минем белән очрашу эзли. Туйдагы хикмәтләрне күрдегез бит! Бар да хөрмәт күрсәтергә, күзгә чалынып калырга тырыша. Артур Александрович тукталып, гүя тагын сорау көткәндәй, прокурорга борылып карады. Ә тегесе шул моменттан файдаланып калырга ашыкты:

—Шулай да, сез теге кешедән бурычка алып торган илле мең белән генә җәелеп китә алмагансыздыр? Тиз күтәрелүегезнең объектив сәбәпләре дә булгандыр? Минем аңлавымча, сез капиталны гына түгел, житештерү көчен дә икеләтә, өчләтә арттыргансыз булып чыга, әйеме?

Артур Александровичның кәефе күтәренке иде:

—Әгәр сезнең турыда мәгълүмат тупламаган булсам, үзегезнең өлкәдә артельчыларда—сезнең халыкта шулай диләр бугай—өлештә торган дип уйлаган булыр идем. Минемчә, сез бар сорауларга да җавапларны беләсез шикелле. Шаяртам, билгеле, чамалау бер нәрсә, ә менә икенче бер компетентлы кешедән раслату—икенче нәрсә, шулай бит?

—Әлбәттә,—дип килеште прокурор.—Әңгәмәбездән кирәкле мәгълүматлар алып калыйм дим, кәгазьләр белән булаша башлагач, сезне азрак борчырмын. Нигездә мин үземнән нәрсә таләп ителгәнен төшендем кебек.—Һәм, чират синдә дигәндәй, башын урындык аркасына салды.

—Әйе, сез хаклы, акча һәм ирек безнең эштә бар нәрсәне хәл итә алмый, объектив икътисадый күзаллаулар булырга тиеш. Билгеле, акча алып торып, үземне сәүдәдә иркенрәк хис иттем. Әгәр базарлар товар белән шыплап тулган булса, әллә ни отып булмас иде. Әле менә шул турыда баш ватам: ни өчен базарларга елдан-ел товарлар аз китерелә, ә?

Беләсезме, Икрам фәлсәфәгә бирелеп тормый, нәрсә ди: янәсе, синнән-

миннән башлыраклар чемодан-сумкалар тутырып Госпланга, Госснабка, Внешторг, Минторгка акчалар ташыйлар һәм: монысын сатып алмаска, монысын житештермәскә, тегесе белән сату итмәскә диләр,—шулай итеп, дефицит барлыкка китерәләр, ә бушлыкны, янәсе, синең белән мин тутырабыз,ди.

Мин ана болай дип жавап бирәм: менә бөтен хикмәт шунда, беркем беркая һичнәрсә илтми, берәү дә басым ясамый, артларында дуслары белән Ашот тормый, ә алар барыбер елдан-ел дефицит арттыралар дим. Шул арада Икрамның икенче мисалы дә әзер, ул гомумән бик кызу кеше, күз унында тотыгыз дип әйтүем.

Ул әйтә: алмыйлар икән, димәк, югарыда йә шыр тилеләр, йә дошманнар утыра, ди. Менә аның логикасы шундый. Дөресен әйтим, мин аның бер уе белән дә килешмим.

Менә безнең күтәрелешнең беренче сәбәбе, димәк,—күп төрле товарларга дефицит. Ә икенчесе дип дәүләт сәүдәсендә куелган бәяләр дип әйтер идем.

Ясалма куннән тегелгән итекләр йөз сумнан да ким тормый. Чит илдән кертелгән кайры туннар менгә тарта, ә бездә тегелгәннәре алты йөз тирәсе, аларына сорау зур. Бер каеш кисәге белән ике шнурдан торган босоножкалар—илле тәңкә... Кайсы якка күз салма, шундый бәяләр. Ир-ат күлмәкләре егермегә менде, ә ясалма мехтан тегелгән бүрекләр алтмышынчы еллардагы ондатра бүрекләр белән бер бәядә, әйе-әйе, башымны кисәргә бирим, тиенгә тиен туры килә. Ясалма мехтан туннар өч уртача хезмәт хакына тарта, ә ирләр күн пиджаклары, алары лайкадан йә кәжә тиресеннән, тагы да югарырак—биш тирәсе.

Димәк, бәя куйганда безгә юнәлеш бар. Без дәүләтнекеннән өскә дә сикермибез, оттырмыйбыз да. Югарыдагылар теләгебезне аңлагандай гел бәя күтәрәләр, бер махсус кешебез моны гел күзәтеп тора. Дөресен әйткәндә, менә шушы бәяләр айсберг төзергә этәрде дә инде мине.

Шушындый кызыктыргыч перспективалар ачылмаган булса, мин берәр житештерүдә утырган булыр идем, тик айга үземнең ике-өч меңемне барыбер алыр идем, чөнки башы эшләгән кеше юлын таба ул.

Үзегез уйлап карагыз, күн итекләр алтмыш-алтмыш биш, босоножкалар—егерме биш-утыз тора. Аяк киемнәре эше ачуның мәгънәсе булыр идеме? Хәер, бу берәүнең дә башына килмәс иде, биш тиенлек куян, ун тиенлек зыян диләрме әле?

Иләнгән сарык тиресе кыйммәт йөри бит. Без итчегә бер тире өчен биш сум бирәбез—бу дәүләт бәясеннән ике тапкыр югары. Ә ул безнең таләпләргә туры килерлек итеп эшкәртеп бирә. Бер кайры тунга сигез-ун тирәсе тире китә, ә без аны биш йөздән сатабыз.

«Лектор» бераз тын алды. Прокурор дәшмәде, монологның дәвамын көтте.

—Тагын бер сорауны ачыклап китим әле. Дөрес, тактлы кеше буларак, сез аны бирмәдегез, әмма кызыксынуыгызны күреп торам.

Бүген сез минем турында ни әйткәннәрен ишеттегез: гангстер, акула, сигезаяк. Сезгә, озак еллар хокук сагында торган кешегә, мөгаен, без икътисадны артка сөйрәүчеләр, халыкны талаучылар, урындагыларны сатып алучылар булып күренәбездер. Беренче карашка гадел тоелган гаепләүдән котылу жинел түгел, тик эш шунда: безнең эшчәнлек өчен алшартлар өлгергәннән соң, чын-чынлап аякка басуыбызга әле жиде-сигез еллап кына. Без аның кайбер сәбәпләре турында сөйләштек, кайберләренә әйләнеп кайтырбыз әле.

Әйдәгез, мәсьәләгә икенче яктан килеп карыйк. Халык хужалыгына зыян

салабызмы без? Мона ничек карыйсың бит. Эшне башлаган чагында теге яки бу предприятиенең фондларына кул сузганда намусым борчыган чаклар еш булды, чөнки фабрикаларның планнары өзеләсен, эшләре аксыйсын аңлый идем. Тик аларны бәладә калдырмасларын, эшчеләргә барыбер хезмәт хакларын бирәчәкләрен дә белә идем. Минем эшчеләрем генә эш хаксыз калырга мөмкин, безнең зыянны каплаучы, дотация, субсидия бирүчеләр юк.

Ә инде депутат булып, план-бюджет комиссиясендә эшли башлагач шаккаттым: дефицит дип саналган товарлар белән өлкәдәге складлар шыплап тулган һәм аларны саклау миллион сумнарга төшә икән. Ел саен гамәлдән чыгару комиссиясендә эшләп, үз күзләрем белән ун меңләгән пар аяк киеме, кием-салым, гомумән, меңләгән исемдәге әйберләрне учакка салуларын күрдем. Ә хәзер башкача уйлыйм, кызганыч, чит фондларны тагын да күбрәк файдалана алмыйм—барыбер күпчелек әйберләрен йә утка, йә чүплеккә озаталар. Чималны бүлгән вакытта иң беренче миңа бирәләр икән, басым ясый дип уйламагыз, барысы да беләләр: мин алдыммы, димәк, ул эшкә җибәрелә һәм казнага акча керә... Сездә, мөгаен, тагын бер сорау тугандыр: без рәсми экономикага альтернатива була алабызмы?

Прокурор җанланып китте:

—Әйе, әйе, нәкъ шул турыда сорамакчы идем.

—Җавап бирәм—юк һәм тагын бер кат юк. Сездән яшермим, безнең продукция кишердән татлыракны татып карамаганнар өчен. Үзем дә, пайчылар да артель житештергән әйберләрне алмыйбыз. Хәер, кайры туным—үзебезнең фирманыкы. Тик андыйлары бездә бик аз тегелә, уртача житмеш-сиксәнгә бер, ул—минем шәхси фондым һәм мин аны үзем бүләм. Аннары һәр ел сентябрь аенда цех начальнигы Яков Наумович Гольдберг Мәскәүгә барып безгә турыдан-туры ярдәмнәре тигән кешеләр һәм аларның гаилә әгъзаларының үлчәмнәрен алып кайта. Әзерләрен йә Фәйзиев, йә үзем илтеп бирәм. Карале, кыш житәргә күп калмады, сезнең дә үлчәмегезне алырга кушармын.

Безнең товарлар дәүләт сәүдәсенекеннән әллә ни аерылмый: шул ук сыйфат, шул ук модельләр, ничек әле, ит юкта үпкә тансык диләрме? Гажәпкә, безнең сатып алучыларыбыз остарып, шомарганнар түгел, аларны иң беренче чиратта әйбернең тышкы кыяфәте кызыксындыра, ә без исә, фирманың авторлык хокукы булуга карамастан, нинди дә булса импортныкына охшатып ясарга тырышабыз. Менә шундый «Карден»нан күлмәкләр һәм «Саламандра» итекләрен кулга да тими алып бетерәләр.

Туристик юллама белән Франция һәм Германиягә җыенгач, дуслар: «Адидас» йә «Карден»га шылтыратып, үзеннең булыр-булмас әйберләреңә алар фирмаларының атамаларын үзләштереп ятуыңны хәбәр итәбез, дип төрттерәләр. Тик ни генә димәсеннәр, табышымның яртысы «Адидас» белән бәйле, аның серле тамгаларын кая гына чәпемибез. Без, билгеле, халыкны киендерәбез дип мактана алабыз, тик бер нәрсәдән качып булмый—болай да юка акча янчыкларын чистартабыз. Бу—шәхсән минем үз фикерем.

Рәсми икътисадта радикаль үзгәрешләр булуга, сүз дә юк, без ничек барлыкка килсәк, шулай тиз арада юкка да чыгачакбыз. Әлегә рәхәтләнеп җәелергә мөмкинчелек барында ник файдаланып калмаска, ди? Менә рәхим итегез, бер прокурор безнең пайчыбыз, икенче берсе нишләргә белми: артыбызга тибәргәме, әллә Әхрәровны әкрен-әкрен йолыккалауны дәвам итәргәме, ә өченчесе, ачыктан-ачык әйтүем өчен кичерегез, сезнең кебеге тирә-юнендә нәрсә майтарылганын да сизенмичә бөтенләй икенче дөньяда яшәп ята. Өлкәдә безгә аркылы төшкән бер генә житәкчене дә белмим мин. Хәтта Ашот та кулга әзер килеш килеп эләкте. Сөйләсән-сөйләмәсән,

мин чәчүче түгел, ә әзерне уручы гына. Бер нәрсә дә буш урында барлыкка килми, явызлыктан явызлык туа, һәм менә хәзер үземне, мәнфәгатьләремне яклар өчен тән сакчылары һәм юрист ярдәменә мөрәҗәгать итми булмый... Менә шушы өчлек: дефицит, кыйммәтчелек һәм бар нәрсә рөхсәт ителә торган хәлнең тууы, минем уйлавымча, яшерен икътисадны барлыкка китерде дә инде.

—Сез лекция укучы академик кебек, вакытка сыештыгыз,—дип, нәтиҗә чыгарды прокурор, чөнки машина кунакханә ишеге төбенә килеп туктады.

Озак кына сүзсез торганнан соң, Ашот:

—Мин кирәк булырмынмы?—дип сорады хуҗасыннан.

—Мөгаен, юктыр, кирәк булсаң—шылтыратырмын. Гадәттәгечә, иртән очрашырбыз.

## 2

Инде төн уртасы авышкан, шау-гөр килеп торган «Лидо» да тынып калган, дүрт катлы кунакханә дә, берән-сәрән якты тәрәзәләрен исәпләмәгәндә, татлы йокыга чумган. Төнге швейцар, күрәсең, зур кешеләрнең соңга калуына күнегеп беткән, тавыш-тынсыз гына ишек ачты.

—Сезнең, бәлки, капкалап аласы киләдер, туй пылавын көтеп тормадык бит?—дип сорады Шубарин.—Суыткачта нәрсә дә булса бардыр, Адик өстәп тора.

Юл бик ялыктыргыч булып, туй шаукымы башына капса да, прокурорның унайлы мәлне ычкындырасы килмәде, аның бирәсе сораулары калган иде әле.

—Тамагым ач түгел-түгелен, әмма чәйдән баш тартмас идем. Ләкин унайсыз, Адик да йокларга яткандыр.

—Бернинди мәшәкате юк, хәзер хәстәрлибез.

Аларның аяк тавышына диваннан сикереп торган кизүгә:

—Галочка, кыенсынмасаң, безгә самовар гына кертче,—диде дә, җавабын да көтмәстән, прокурорны үзенә әйдәде.

Шубаринның суыткычы бай иде. Ул житез генә кыланып өстәл хәзерләде.

Прокурор исә кәнәфигә утырып, оеган аякларын сузып җибәрде һәм машинада башланган әңгәмәне дәвам итәргә теләп:

—Әйе, дөресен әйтим, бүген күп нәрсәгә күзем ачылды. Нинди лекция! Сезгә Халык хуҗалыгы академиясенең кафедрасы да җәл түгел,—диде.

Тик Шубаринның сөйләшүне дәвам итәргә теләге юк иде, ул:

—Юк, мин сәгатьләп түләүгә риза түгел,—дигән булды.

Ул арада ишек шакыдылар—кизү Галочка самовар китергән икән. Хуҗа чәй пешерде. Чәй янында прокурор янә үзен кызыксындырган темага әйләнеп кайтмакчы булды:

—Эшегезнең ничек барлыкка килүен аңладым, тик шуны беләсем килә: сезне эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә ни этәрде, акчага хирыслыкмы?

Шубаринның йөзенә күләгә йөгергәндәй булды, әмма ул үзен бик тиз кулга алды. Сүзен ерактан уратып башлады:

—Кеше эшмәкәрлеккә сәләтле икән, нишләргә кушар идегез? Безнең җәмгыятьтә андый эшләр белән шөгыльләнү намуслы кешегә хас түгел дигән фикер туган. Шуңа без ни тиешле дәрәҗәдә житештерә, ни сата алмыйбыз һәм кеше ни гомерен чиратларда үткәрергә мәҗбүр. Ә бит карасаң, сәүдә, уйлап табу өлкәсендә талантлылар иҗади яктан сәләтлеләргә караганда күпкә ким. Әнә, иҗат берлегендә торган язучыларның саны ун меңгә житә дип сөйлиләр, әле, мөгаен, керергә чиратта торучылары йөз меңләгәндер.

Рәссамнар, композиторлар, артистлар, җырчылар, музыкантлар, режисссерлар, журналистлар күпме? Бездә бит алар буа буарлык.

Ә илгә бары бер генә эшлекле авыл хуҗалыгы министры, энергетика, машина төзелеше, элемтә министры—җәмгысы йөз талантлы эшмәкәр кирәк һәм вәссәлам: без бөтенләй янача яши башлыйбыз. Шәп язучыларны искә алабыз, рәссам-композиторларны—шулай ук, хәтта футболчыларны беләбез генә түгел, йөзгә таныйбыз, ә безгә җылы һәм яктылык биргән берәр техник белгечне хәтерлибезме, йә?

Прокурор аның дулкынлануын сизде, гадәттә тыныч, салкын канлы Шубарин кызып ук китте:

—Ярар, минем очракта, мөгаен, азмы-күпме аныктыр, хәзер, Аллага шөкер, генетиканы берәү дә кире какмый. Миндә бозык, әшәке кан уйнагандыр дип саныйк. Бу край белән азмы-күпме таныш кешеләр беләләрдер: Шубариннар монда күп нәрсәгә ия булганнар: ремонт мастерскойлары, Әндиҗанда сөт-май комбинаты, табышлы йортлар. Бабай, аның абыйсы тимер юл инженерлары булганнар, Петербургта белем алганнар. Әтием дә инженер булган, башкалардан аерылып торган, минем кебек үк Бауман институтын тәмамлаган. Менә бер мисал... Алтмышынчы еллар башында көнкүрешкә шариклы ручкалар үтеп керде. Әтием өч көн эчендә конструкциясен төзеп атна дигәндә ярымавтомат эшләгән, ә аннан тәүлек буе өзлексез ручканың әзер өч детале чыгып торган. Ул чакларда, хәтерлим әле, ручка житмеш тиен тора иде һәм бик озак еллар дефицит саналды. Әти, шаяртып, акча суга торган автомат уйлап таптым, ди иде—һәм бу чынлыкта да шулай булып чыкты. Әтинең башы түгәрәк иде, ул жирле картон фабрикасына йөз шариклы ручка сыярлык тартмаларга заказ бирде—бу исә безне санап утыру мәшәкатеннән коткарды. Безгә бу тартмаларны тутырып өлгертәсе генә калды. Безнең гаражда шундый өч ярымавтомат бар иде, ялгышмасам, аларның һәрберсе көнгә мең данә житештерде. Чимал белән дә кытлык тумады: ул елларда берничә көнкүреш химиясе комбинатлары эшли һәм бу предприятиеләрнең калдыгы—пластмассаны салырга яраткан шоферлар чүплеккә илтәсе урынга безгә китерәләр иде. Урнаштыру белән дә мәшәкать килеп чыкмады, ул елларда әле жирле сәнәгать системасына кергән артельләр, промкомбинатлар бар. Һәр ручка әтигә кырык тиен табыш китерде дип хәтерлим, димәк, һәр көн мең сумнан артык акча кереп барган дигән сүз. Әти—нәрсәнең нәрсә икәнен тиз чамалап, тагын шундый утызлап ярымавтомат ясап республика өлкәләре буйлап таратты. Аның өлеше күпме булгандыр, анысын белмим, әмма һәр айның соңгы атнасында әти «Волга»сына Ашот шикелле ике егетне утыртып, үз биләмәләрен әйләнеп кайта иде. Ул уйлап тапкан әйберләрен беркайчан да сатмады, бары тик йә арендага бирде, йә өлешкә керде. Бервакыт ул миңа бер корылма күрсәтте, аны ун меңгә сораганнар. Бик зур акчалар инде, югыйсә, юк, әти аны бары тик арендага гына бирде. Ул жайланма нәкъ биш ел эшләде һәм йөз мең табыш китерде—бу әтинең миңа сәүдә эшләре буенча биргән беренче күрсәтмә сабагы булды, шуңа күрә мин дә үз корылмаларымны сатканым юк. Без Бохараның бер борынгы үзбәк мәхәлләсендә зур таш йорт торгыздык. Ни өчен андамы? Беренчедән, аралашу кыенлыгы тумады, безнең гаиләдәгеләр барысы да җирле сөйләшне яхшы беләләр иде, икенчедән, мәхәлләдә тормыш бөтенләй башка: күрше күршегә тыкшынмый, әмма кирәк чакта яклый да алалар. Аннары андагы халык житеш яши, затлы нәселдән һәм без дә алардан әллә ни аерылып тормый идек. Өстәвенә әти дә юмарт кыланды: мәхәллә комитетына шактый биреп барды, төрле чараларга һәм кирәк-яракларга зур-зур суммаларны кызганмады, бирәдә бердәнбер урыс гаиләсе булсак та, шуна үзебезне чит-ят сизмәдек.

Йортка килгәндә, әти анда станоклар һәм эретеп ябыштыру җиһазлары

булган менә дигән мастерской ясады. Әле дә шаккатам: ишегалдыннан чыкмыйча, ул үзе нәрсә конструкцияләсә, шуны ясый торган булды. Мин шушы мастерскойда үстем дисәм дә була, һәрбер станокны энәсеннән җебенә кадәр белә идем. Күрдегезме, мина инженер булыр өчен кирәкле барлык алшартлар тудырылган булган.

—Ул үз эшен нәсел буенча сезгә тапшырган булып чыга инде, шулаймы?—дип ачыклык кертте прокурор.

—Юк, алай димәс идем. Киресенчә, әти беркайчан да үз эшләренә тартмады һәм читтәрәк булуымны хуплады—мине чын инженер итеп күрәсе килде аның. Шуна күрә институтны да алыштырдым.

Шубариннар инкыйлабны ничек исән-имин, югалтуларсыз кичерделәр, анысын төгәл генә әйтә алмыйм. Дөрес, хосусый милекне дәүләтнекенә әйләндерделәр, әмма байлыкнын зур өлешен саклап кала алдык, хәер, андыйлар бер без генә түгел идек.

Безнең гаилә иркен яшәде, тик тирә-юньдәгеләрдә көнләшү, күралмау уятыр дәрәҗәдә үк кыланмады. Әти туплаган байлык, урынлы файдаланганда, абый белән икебезне озак еллар муллыкта яшәтерлек иде.

Абыем—фән кешесе, танылган галим-физик, Мәскәүдә яши. Әти-әни акчасы анын тормышында төп роль уйнады дисәң дә була, чөнки бернинди борчу-мәшәкатьсез жаны теләгән эш белән шөгыльләнде, егерме ел тырыша торгач, фәнни ачыш ясады. Минемчә, ул тормышыннан бик канәгать.

Ә мин, институтны тәмамлагач, туган якларга кайттым, әйбәт кенә урнаштым, хезмәтемдә дә әкренләп күтәрелеш башланды. Тик озак та үтмәде, үзем теләгән биеклеккә күтәрмәсләрен төшенеп алдым. Бу—урыннар нәсел-нәсәбә буенча өләшенә торган еллар иде. Ә мин, исәр, үземчә заводнын баш инженеры лаеклы ялга киткәч, шунын урынын көтеп йөрдем. Чөнки мин—баш технолог, күпләрнең уйлавынча, ул урынга лаеклы бердәндер кандидат идем. Тик... Баш инженер итеп чираттагы райком секретаренын үзебезнең институтта читтән торып укып йөргән киявен куйдылар. Кызганыч, әтием бакыйлыкка күчкән иде инде, югыйсә ул мина булышкан булыр иде, чөнки урын бүлешкән даирә кешеләре арасында ул үз кеше булды. Минем тырышуларымны, киләчәккә планнарымны белә иде—нишлисең, барып чыкмады...

Кем әйтмешли, ярык тагарак янында калгач, минем иннәрем салынды, эштән күңел бизде...Ә бит баштарак эчтән генә: киләчәктә зур бер заводнын директоры булу, хәтта бераз тәҗрибә туплагач, тармак белән идарә итү турында хыяллана идем...

Әңгәмә барышында хужа кунакны кыстарга да онытмады, чынаягына чәй агызды, печенье ише тәм-томны ана табарак этәрде. Тик прокурорнын инде сусыны басылган, Шубариннын истәлекләре дөньясын тәмам оныттырган иде.

—...Билгеле, безнең шәһәрчектә бернинди яшерен сер юк, бар да күз алдында, шуна минем белән булган хәл барысына да мәгълүм булды. Әти мондагыларнын күбесенә күтәрелергә ярдәм иткән кеше булганга, хәлемә керергә тырыштылар. Тик минем генә бар нәрсәдән күңелем суынды. Әти эшнең шундый юнәлеш аласын алдан ук сизенгәндер, ахрысы, үләр алдыннан, үз эшләре белән таныштырды. Һәр айны үз өлешемә тигән табышны ала бардым, шул өлешнең берсе генә дә мин өметләнгән баш инженернын хезмәт хакыннан шактыйга артык иде.

Әти вафатыннан соң, анын элеккеге компаньоннары киңәшләшергә минем янымa килә башладылар.

Бервакыт аларнын проектлары өстендә бер ай утырдым—һәм баштанаяк сүтеп корырга туры килде. Алар эшем өчен акча тәкъдим иттеләр, тик

мин дә, әтием шикелле үк, эксплуатациядән килгән табышның яртысын таләп иттем, тегеләр тешләрен кысып булса да ризалаштылар, хәер, кая барсыннар—миннән башка алар металлдан тиешле нәтиҗәләр ала алмасын яхшы беләләр иде. Өч ай дигәндә, заказларын башкарып чыктым. Аннары завод белән хушлаштым да җирле сәнәгать фабрикаларының берсенә туксан сумлык хезмәт хакына механик булып урнаштым. Эшсезлектән җанны кая куярга белми йөргән көннәрнең берендә, әтинең пайлары булган кечкенә цех һәм предприятиеләрне яңартырга тотындым. Мине колач җәеп дигәндәй каршы алдылар, чөнки кулым тигәннән соң, җитештерү вакыты кыскару белән бергә әйберләрнең сыйфаты да күзгә күренеп яхшырды. Инженерлык шаукымым тынычлык бирмәде—баш-аягым белән эшкә чумдым һәм нәтиҗәсе дә, әйткәнемчә, озак көттермәде.

Мине җирле сәнәгать идарәсендә күреп алдылар һәм шәрыкка хас кәвеш, хатын-кыз, ирләр туфлиләре җитештерә торган аяк киемнәре фабрикасын үзгәртеп кору белән җитәкчелек итәргә тәкъдим ясадылар. Реконструкциядән соң бик тиз арада ассортимент яңартылды: без платформалы аяк киемнәре чыгара башладык, бәлки хәтерегездәдер, бик модалы саналды ул. Яшьләргә махсус җитештерергә тотындык, гомумән, фабриканың эшләре гөрләп барды.

Фабрикада көн-төн яттым—ә ул Бохарадан алтмыш чакрым ераклыктагы район үзәгендә урнашкан, шунда тормышта үз урынымны табуымны аңладым.

Уңышка ирешүемдә инженерлыгымнан тыш, исәпсез-хисапсыз җирле сәнәгать препприятиеләренең яшертен эшләрен белүем, һәр станокның, һәр цехның мөмкинлекләре белән таныш булуым да ярдәм иткәндер. Озакламый барысын да үз кул астыма тупладым. Берәү дә миннән мондый елгырлыкны көтмәгәндер, ул чакта утыз да тулмаган иде бит әле. Шулай да акча мине ул кадәр кызыксындырмады. Фәйзиев әйтмешли, үз империямне төзү белән мәшгуль булдым. Иҗат ирегеннән, мөстәкыйль рәвештә карарлар кабул итә алуымнан башым әйләнде һәм беләсезме, берничә мәртәбә бар нәрсәмнән колак кага яздым. Моның өчен гадәти предприятие җитәкчесен иң начары—урыныннан алып ташларга мөмкиннәр, ә минә дистәләгән еллар бернинди кайгы-хәсрәтсез яшисе үз акчаларынны югалтсанмы... Минә шундый тәвәккәллеккә барганда гына чын хуҗа булып, җаваплылык дигән нәрсәнең ни икәнен аңлыйсың, бу очракта отыш та икенче инде—икеләтә, өчләтә...

Шубаринның янәдән сүзгә мавыгуын чамалап, прокурор әйтеп куйды:

—Димәк, бабагыз шикелле сезгә дә миллионер булу өчен ярты гасыр кирәк булды? Мөгаен, андый максатны да күз уңында тоткансыздыр?

—Юк, бабам да, аның абыйсы да миллионерлар түгел иде. Мин алардан сакланып калган кәгазьләрне яхшылап өйрәндем. Дөрес, алардан күп нәрсәләр калды һәм алар хәзер дә халыкка хезмәт итәләр. Мисалга Әндиҗандагы шул ук сөт-май комбинатын, борынгы архитектура истәлеге булып дәүләт карамагына күчкән йортларны китерә алам. Ташкенттагы ремонт остаханәләре базасында заводлар калкып чыкты.

Яшермим, миллионнарым бар, бәлки, өч-дүрттер. Тик алардан ни мәгънә, йә әйтегез?

Көтмәгәндә Шубаринның сөйләмендә чагылып киткән ачыну-әрнү прокурорны гаҗәпкә калдырды. Әлегә кадәр әңгәмәдәше аңарга аерата эшлекле кеше булып тоелган иде. Ә хәзер менә сиңа мә!..

Шубарин, прокурорның күңелендәген укыгандай:

—Әйе-әйе, аптырамагыз...—диде.—Мин тормышта бик тыйнак: тартмыйм, кирәк чакта гына, анда да чамасын белеп кенә эчәм, корсак колы

түгелмен, кәрт уйнамыйм.Үз тирәмдәгеләрнен кайбер әхлак принципларын ошатып бетермим. Икрам Мәхмүтовичның, мисалга, ике хатыны бар. Мин андыйларны бусагам аша да атлатмас идем, тик эш аркасында түзәргә туры килә. Үземнең берниндн ачыктан-ачык йә булмаса яшерен теләкләрем юк, дөрес, картиналар тупларга яратам.—Шубарин ниндидер кадерле нәрсәгә юлыккандай җанланып китте.—Сугыш вакытында, ә бәлки тагын да элегрәк—инкыйлабка кадәрдер—качаклар алып килгән Сальвадор Розеның ике картинасы, Николай Генның биш полотносы бар, калганнары—билгесез осталарныкы. Бик рәхәтләнеп белгечләрне чакыртып, күп нәрсәләргә ачыклык кертер идем дә—ярамый. Каракмыни, биктә яшертен тотарга туры килә. Мин матди ярдәм күрсәтеп, әйтик, балалар йортына зур суммадагы акча да күчерә алмыйм бит, ачыктан-ачык васыять та итеп булмый, ә яшертен рәвештә калдырырга йөрәгем кушмый, бер нәрсә дә җинел генә табылмады. Ә сез: акчага хирыс, дисез. Байлыкка исем китми минем. Эшлим, ә акча үзеннән-үзе арта бара, тик, сихерләнгән кебек, эшемне калдыра да алмыйм: ул да мине ычкындырмый.

Илдә үзгәрешләр була калса, күкрәгемә мылтык тереселәрен дә беләм, маддәсе дә таныш: «Аеруча зур күләмдә урлашу».

Мактанып әйтүем түгел, әмма мин җаваплылыктан курыкмыйм, моны үземнең иҗади мөмкинлекләремне тормышка ашырган өчен түләү дип кабул итәчәкмен.

Гаҗәп: прокурор аның бу сүзләрендә ясалмалык сизмәде. Шубарин дәвам итте:

—Шунысы сөендерә: тормышта ватмадым-җимермәдем, бары тик җитештердем, туры мәгънәсендә яхшылык эшләдем.

Ә бит башка мисаллар да җитәрлек. Теге яки бу колхозны, совхоз, завод, фабрика, комбинат, институт, газета, тармакны таркатучыларны исемләп санап була. Җирләрне, елга-күлләрне корытучылар, урманнарны кисеп, юкка чыгаручылар күпме... Өйләрдә, кунакханәләрдә чыккан янгыннарны тикшерә башласаң, күп очракта телевизорлар сәбәпче була—ә моңа берәүнең дә исе китми.

Сез, бәлки, ышанмассыз да, хәер, анысы сезнең эш, акчадан битәр инженерлык сәләтем белән эшмәкәрлек талантымны эшкә җигә алуымнан канәгать калдым мин. Моның өчен күләгәдәге икътисадка бурычлымын.—Ул бераз әйтергәме-юкмы дигәндәй уйланып торды да дәвам итте:—Икрам биюченең тагын да зуррак акчага өметләнеп янында бөтерелгәнен яратса, мин янымда «биегән» сатлык җитәкчеләрнең кыланмышларыннан канәгатьләнү кичерәм. Рәсми рәвештә инженер буларак мөмкинлекләремне файдалана алмавым өчен мин алардан менә шулай итеп үч алам. Шушы адәмнәрнең күбесе кадрлар һәм икътисад белән идарә итә бит әле. Беренчедән кала—анысы бик текә, хан диярсең—барысына да йә пай, йә ришвәт сонмый калмадым. Мин аларны кызык итәм: әҗер биргәндә хокук сагында торучы белән берәр эре түрәне икесен бергә чакырам. Югыйсә, икесе дә нәрсәгә килгәнен беләләр, әмма өреп кабартылган әңгәмәләр корып маташалар, мәсәлән, чираттагы идеологик пленум турында—исең китәр... Әле шундый хәлләр дә була: конверт инде берсенең кесәсенә кереп урнашкан—купюраларның махсус вакларын бирәм—нишләсен, утыра теге тырпайган кесәләре белән, ә үзе күзен дә йоммыйча намус, әхлак турында гәп куертып маташа. Әгәр кайчан да булса мине күләгәдәге икътисадны оештыруда гаепләп чыксалар, мин, мөгаен, ул сазлыкка бу адәмнәрне дә өстерәрмен. Крайның икътисады гына түгел, кешеләре дә нинди хамелеоннар кул астында булуын белеп торсыннар...

Кунак Шубаринның үзеннән шикләнмәвен, хәтта бөтенләй санга

сукмавын күреп бөрешеп калды. Артур Александрович шулай да үзе турында артык ачылып бетмәде. Элеккеге прокурор гадәттә сабыр, тыныч тотарга өйрәнгән номер хуҗасын бөтенләй икенче яктан күрде: салкын акыл белән эш йөрткән бу кешенең тормышка карата үз карашы бар, янәсе аның төп принцибы—килешү, ә үзен кимсетелгән саный, уныш елмаймый торган кеше, янәсе,—баш инженер була алмый калган. Прокурорның хәтеренә кылт итеп Бикхуҗаевларның төнге илчесе килеп төште: болар арасында ниндидер охшашлык күрде. Тик хәзергә хәтер казанында актарынасы килмәде, тик шунысы бәхәссез: Шубарин да шундый ук куркыныч адәмнәрдән иде.

Йөрәге үзен сиздергәләп алса да, Азлархановның әңгәмәне өзәсе килмәде.

—Шулай да эшегездә кайсысы мөһимрәк: инженер талантымы әллә эшмәкәрлекме?

Сүзгә мавыгып кайнап чыккан самовар турында да онытканнар икән. Хуҗа, сорауга җавап эзләр өчен вакыт отарга теләгәндәй, ашыкмый гына чәй пешерде.

—Ничек кенә сәер тоелмасын, хәзер предприятиеләр тизлек һәм куәт җыйган заманда инженерлык таланты белән эшкуарлык колачыннан күп нәрсә тора.

Әңгәмәдәшенең гаҗәпләнүдән авызы ачылуын күреп, Шубарин көлеп җибәрде.

—Әйе,әйе, шаккатмагыз... Булганнарны саклау, зарар-зыянсыз җитештерү, иң әһәмиятлесе—сату, менә шул талант инде.

—Кемнән сакларга?—дип кызыксынды элекке прокурор.

Хуҗа кеше кабат көлүен яшереп кала алмады.

—Иң беренче чиратта гаҗәеп театрымдагы «актерлар»дан. Роль эләктерә алмый калганнарыннан бигрәк тә—минеке камера театры бит һәм составына караганда халыкныкы булырына бөтенләй дә өмет-ышаныч күренми.

—Беркайчан булмавы да ихтимал,—дип әйтүдән үзен тыеп кала алмавына кунак соңыннан үкенде, билгеле.

Шубарин зәһәр генә:

—Шулай дип уйлыйсызмы?—дип чәнчеп алды.—Ярар, шулай да булсын, ди... Ә сез бюрократик аппаратта түрәләр саны арткannan-арта барганын беләсезме? Мин ашау продуктлары җитештермәсәм дә, янгын инспекторыннан башлап санитар табибка кадәр—барысын да туендырырга мәҗбүрмен. Югыйсә, аларның бит минем предприятиеләремнән башка да көчләрен куяр урыннары буа буарлык. Әйтик, нигә әле шәһәрдә агуланудан курыкмыйча тукланып чыгарлык ашханә ачып җибәрмәскә, ди, йә булмаса, гафу үтенәм, бер бәдрәф булдырмаска, ә? Хәер, миңа калса, күпне таләп итәм шикелле... Җыеп әйткәндә, мин берәүдән дә ярдәм өмет итмим, ә менә аяк чалучылар, каршы килеп маташучылар муеннан ашкан—барысына да «бир» дә «бир». Иң яхшы токымлы сыерны да көнгә ике генә савалар, югыйсә, аяк сузарга мөмкин, шулай бит?

Өстәвенә җинаятьчелек белән наркоманиянең җәелгәннән-җәелә баруы күнелгә шом сала. Прокурор буларак, сез дә хәбәрдардыр: безнең якларда мамыкчы, алтын табучы, каракуль-тирече миллионерлар саны арту белән, илнең һәр төбәгеннән җинаятьчеләр дә агыла башлады. Бу уен-муен эш түгел. Һәм минем бурычым—үземнең генә түгел, ә бергә эшләүчеләрем, аларның гаиләләренең дә иминлеген тәэмин итү.

Айсбергны кору өчен элегрәк хокук һәм икътисадны өйрәнгән булсам, соңгы елларда җинаятьчелекне дә күз уңыннан ычкындырырга ярамаганын тәгаен беләм. Бу төбәктә үземне республика прокуроры, хәтта эчке эшләр министрына караганда да мәгълүматлырак дип санарга батырчылыгым

житә. Мисалга, узган ел Ашот кешеләре махсус минем компаньоннарымның башын ашарга килгән Ростов бандасын зыян салмаслык иттеләр. Егетләр эләктергәч, алар белән мин дә очраштым. Ай-яй, чиркангыч бәндәләр! Көч куллanудан башканы башларына да китерә алмаучы вәхшиләр. Ай да үтми, мине, хезмәттәшләремне йә булмаса аларның гаилә әгъзаларын коткы ярдәмендә башларын бутарга омтылган тагын берәрсе килеп табыла. Андыйлары белән дә «аңлашырга» туры килә.

Прокурор, елмаюын көч-хәл белән яшереп:

—Сез, алайсам, дон Корлеоне, Крестный ата кебек инде?—диде.

—Шулай булып чыга.—Артур Александрович көлемсерәп куйды.—Хәзер үзем дә буталып беттем инде: тормышта нинди-кайсы талант мөһимрәктер—аңламыйм. Тик Халитовның миннән шүрләвенә сөенә алмыйм, чөнки беләм: ул куркаклардан түгел.

Әңгәмәдә киеренкелекнең арта баруын чамалап, кунак шул урында туктарга кирәклегенә төшенде: артык кызыксынуының ахыры ни белән бетәсен әйтеп булмый. Болай да никадәр мәгълүмат алды, аларны тагын бер кат баш казанында кайнатып чыгарасы бар.

—Кичерегез, сезне сорауларым белән йөдәтеп бетердем бугай. Кунакчыл булуыгыздан файдаланып күпме вакытыгызны әрәм иттем... Иртәгә, дөресрәге бүген көн киеренке булачак—мина эшкә чыгасы. Шушындый матур кич өчен рәхмәт, инде китәргә рөхсәт итегез...

Яшерен синдикат хуҗасы сәгатенә карап алды һәм гаҗәпләнүдән күзе мангаена менде:

—Утырып та караганбыз, озакламый таң ата,—диде ул үкенеч белән, аның кунагы белән аерыласы килмәве йөзенә чыккан, күрәсең житкерәсе хәбәрләре калган иде әле.

Прокурор башында: «Нәрсәне аңлата бу?—дигән сорау чагылып алды.—Бер генә минутка йомшарып алумы? Исәп-хисапмы? Әллә акчага исе китмәгән кешене эшендә ышанычлы таянычы итү теләгеме? Әллә тормышта үзгәреш җилләре исүен искәреп, «театр»ына «ут төртмәкче» һәм ахырдан шапылдатып ишегән ябып куймакчымы?» Әйе, уйланырлык бар монда.

—Ходай хакы өчен, үзегез кичерә күрегез, тоткарладым. Югыйсә, аерым тәртип белән яшәвегезне белә идем бит. Бүген сезне йокыдан гына түгел, сәйраныгыздан да коры калдырдым. Сәламәтлегегезне саклрбыз дип сүз бирдем, үзем үтәмим булып чыга. Әмма мин бик шат. Гомеремдә моның кадәр ачылганым юк иде, кем әйтмешли, күңел савыты тулган булган...

Ул янә сәгатенә күз ташлады:

—Сез хәзер ял итегез, аннары гадәттәгечә Адикта төшке аш, соныннан эштәгеләр белән таныштырырмын. Анарчы кабинетыгызны хәзерләп куярлар...

### 3

Төшкә кадәр уянмыйча йоклау үзенекен итте—Азларханов тәненә көч кайтканын сизде. Душта коенып чыкканнан соң, шефының төгәллеген хәтерләп, билгеләнгән вакытта аска төште. Тегесе инде өстәл артында утыра һәм йокысыз төннән соң изелгән-ватылган Икрамның бокалына «Боржоми» салып маташа иде. Шефы белән ике-өч авыз сүз алышканнан соң, Фәйзиев төшке аштан баш тартып, ял итәргә китте.

Шубарин турында йокысыз төн үткәргән дип әйтмәссең дә, инде ул өч җирдә киңәшмә уздырган, ике ремонт заводында булган һәм шәһәр башкарма комитетын урарга өлгергән.

Теге вакыттагы кебек ашыкмыйча гына тәгам җыйдылар. Өстәл артыннан кузгалганда гына прокурор Ашотны күреп алды, ул, гадәтенчә, ялгызы гына

тамак ялгый иде. Күрәсең, Артур Александрович көче житкәнчә барысын да билгеле бер системага салган.

—Әйдәгез, кичә кысырга калган сәйранны бүген үткәрик әле,—дип, Шубарин жәяүләп кенә барырга тәкъдим итте һәм машинада үзләрен көтеп утырган Ашотка ишарә ясады. «Волга» шунда ук кузгалып китеп тә барды.—Ерак барасы түгел, монда гына.

Озак та үтмәде, алар элеккеге руда идарәсе бинасына килеп тә життеләр. Мәрмәр баскычтан өскә күтәрелгәндә, прокурорның күзе гранитка алтын белән язылган «Жирле сәнәгать идарәсе» дигән язуга төште.

Икенче катка менеп иркен кабул итү бүлмәсенә уздылар. Унга да, сулга да кабинетлар тезелеп киткән. Агач остасы имән ишекләрнең берсенә «Азлархanов Ә.Д.» дигән бронза табличка беркетеп маташа иде. Ә каршы ишектә «Шубарин А.А.» дигән язу чекрәеп тора. Хужа кеше үзенең яна юристын шунда өндәде.

Купшы кабинетның бусагасын атлауга, профессорның миен: «Монда безнең «хужа» үзе чәчмәгәнне ура икән» дигән уй телеп үтте.

Тик шефның эш вакыты минутлап бүленгән, ахры, артыгын жәелергә ирек бирмәде. Селектор аша:

—Татьяна Сергеевна, ундүрт тә егермегә чакырылганнарны дәшегез әле, зинһар,—диде дә прокурорга борылып:—Хәзер баш белгечләр белән таныштырам, алар сезгә эш рәтенә төшенергә ярдәм итәрләр,—диде.— Берничә кичектергесез эшне караганнан соң, идарә белән дә, документлар белән дә танышырга вакытыгыз иркен кала әле. Нидер анлашылмый икән, бу иптәшләр булышырлар.

Ул арада бусагада икәү күренде. Аларның алдан кергәне Александр Николаевич Ким, икенчесе Христос Янович Георгади. Икесенең дә кулларында саллы-саллы өч-дүрт папка.

Баш бухгалтер да, баш икътисадчы да инде өлкән яшьтәгеләр икән— прокурор моны көтмәгән иде, сәерсенде.

Әмирхан Даутович тагын бер кат Шубаринның айсбергы акыл белән төзелгәненә, аны батыруы жинелләрдән булмасына инанды. Мондыйларны ялан кул белән генә эләктереп булмый.

Прокурорны идарәнең югары советына тәкъдир итү ун минуттан артмады. Эштә ярдәм кулы сузарга әзер икәнлекләрен белдереп, документлар белән танышып чыгу өчен папкаларны яна юристка сонып, картлар мыштым гына чыгып югалдылар.

—Күрәм, сезнең монда интернациональ коллектив икән,—дип сүз башлады прокурор, кореялы Ким белән грек Георгадины күздә тотып. Ул кабинет хужасының алар турында тагын ни дә булса өстәсенә өмет итте.

Тик Шубарин эш вакытында артык жәелеп китүчеләрдән түгел иде, ахрысы, сүзен кыска тотты:

—Беләсезме, кадрлар сайлауда минем үз карашым. Урыннарны элемтәләргә карап өләшмим, анкетадагы бишенче пункт, ягъни милләтенең кем булуы мине бөтенләй кызыксындырмый. Бары эшлекле, булдыклы булсыннар—миңа шул житә. Бухгалтерга сиксән яшь, булсын—әмма мин аны ике кырык яшьлеккә дә алмаштырырга жыенмыйм. Көн саен эшкә чыкмавына да, ике-өч сәгать кенә эшләвенә дә каршы килмим.

Прокурорның аптырап калуын күреп:

—Берни сорашмауларына гажәпләнмәгез, алар досьегыз белән таныш. Бу урынга сезне алуны мин үзем генә хәл итмәдем. Сездән нәрсә таләп ителгәнен анлыйлар. Ә хәзер, әйдәгез, кабинетыгызны күрсәтим дә, Аллага тапшырып, башларсыз...

Кабул итү бүлмәсенә чыгуга, күзе иң беренче ишеккә беркетелгән

табличкага төште. Нык беркетелгән, дүрт бакыр шөреп белән. Тик озаккамы? Шубарин белән шаярып булмый.

Ә тегесе ишекне киң итеп ачты да:

—Рәхим итегез,—дип, юристны алдан үткәрде.

Кабинет шефыныкыннан әллә ни аерылмый диярлек. Тик тегесендә хуҗа кулы сизелеп тора: кырыс, рәсми.

Прокурор папкаларны ике тумбалы, өстенә яшел сукно ябылган өстәлгә куйды да тирә-якны күзәтә башлады. Күзе шунда ук ян стенадагы плакатка төште. Лариса күргәзмәсендәге бу реклама плакаты элек аның прокуратурадагы бүлмәсендә дә бар иде. Үзе дә сизмәстән, аяклары шунда тартты. Ул сүзсез генә ишәккә атланып, базардан зәңгәр ләгән алып кайтучы картның хәйләкәр йөзенә карап торды.

—Игътибарлы икәнсез, рәхмәт,—диде. Өстәл янына килгәч, сорап куйды:—Кызык, мина кадәр бу кабинетның хуҗасы кем булды икән?

Шубарин биек тәрәзәләргә ямь өстәп торган бөрүле пәрдәләрне төзәтәрәтли җавап бирде:

—Икрам.—Аннары аңлатуны кирәк тапты, ахры:—Юк, сез борчылмагыз. Ул шулай килеп чыгуына сөенде генә. Минем белән күрше булуыннан кыенсына иде бугай. Аның теләге—үз кабул итү бүлмәсен, үз сәркатибен булдыру иде. Шау-шулы, аралашучан булганга, аның яныннан кеше өзелмәде, моның исә мина ошап бетмәвен сизенә иде. Аннары үзе янына кемнең килгәнен, кемнең киткәнен дә белгертәсе килмәдеме? Кайвакыт мина атналар буена югалып торырга туры килә, ә Татьяна Сергеевна һәрвакыт үз урынында, димәк, барыбер үзбуйлы кылана алмый. Билгеле, аркама ышыкланыпниләр майтарып йөрүеннән хәбәрдармын.

—Мәсәлән, әгәр сер булмаса?—дип кызыксынды прокурор.

—Рәхим итегез... Мисал өчен, ул үзенең шәхси таксопаркын булдырып, ун «Жигули» сатып алды, хәзер егетләре көн-төн акча сугалар. Куркасы юк—олы абыйсы өлкәнең ГАИ башлыгы.

—Үз башына мәшәкать алып, нәрсәсе кызык инде?

—Һәрберсе көн саен илле сум биреп барырга тиеш. Исәпләгез, елга өч йөз эш көне хисабыннан. Эшләдеме ул бүген, юкмы—анысы кызыксындырмый. Һәм өч ел дәвамында шулай, аннары машина таксистның шәхси милкенә әйләнә. Ремонт, резина, бензин мәшәкатьләре ана кагылмый, авария йә низаг була калса гына катнаша.

—Һәм шоферлар шуңа ризамы?

—Ничек кенә әле! Шартлар ике як өчен дә файдалы бит. Теләүчеләр күпме диген! Машина беренче елны ук хакын чыгара һәм биш мен сум табыш китерә, ә аннан соңгы ике елда чистасы китә, көненә биш йөз сум.

Прокурор ирексездән:

—Менә бу колачлау!—дип куйды.

—Мин алай димәс идем,—диде шеф.—Дөрес, ул үзенчә эшлекле, энергияле, чит идеяне тормышка ашырырга сәләтле. Тик безне бит идеяләр туендыра. Ул өченче катка күчүенә канәгать, мина буйсынмыйча үзе теләгәнчә яшисе килә икән—рәхим итсен: монда барыбызга да урын җитәрлек. Аннары ул бүгенге көндә сезнең абруйны күтәрергә кирәклеген дә яхшы аңлый.

Урнашыгыз, әгәр нәрсәне булса да үзгәртергә телисез икән—хуҗалык мөдире сезнең карамакта. Идарәдә үзегезне хуҗа кебек сизегез. Сезгә комачауларга теләмим, хәзер китәм. Онытмагансыздыр, мине тагы озын юл көтә, бүген прокурор Халитов белән очрашабыз. Тик кызганыч, юлда янәшәмдә сез генә булмыйсыз, сөйләшер сүз табылыр иде,—дип ишеккә

таба атлады. Тоткадан кулын алмаган килеш, бераз уйланып торды да кабат өстәл янына әйләнеп килде.

—Күпме генә гәп куертсак та, мин сезгә иң мөһимен әйтеп бетермәдем. Сезне эшкә тартуымның төп сәбәбе...—Ул туктап калды.

—Мин сезне игътибар белән тынлыйм, әйтеп бетерегез. Шулай да, рөхсәт итсәгез, башта утырыр идем...

—Әлбәттә, әлбәттә.—Шеф аңышып алды.—Рәхим итегез.. Беләсезме, эш менә нәрсәдә... Без бик тиз үсеш алдык, әмма эш-гамәлләребезнең күпчелеге норматив актлар, боерыклар белән беркетелми калынган. Бердән, ашыксак-кабалансак, белеп җиткермәсәк, икенчедән, үзебез буйсынган берләшмә һәм ведомстволар гаебе аркасында. Мин бер көн белән яши торганнардан түгел, бүген кайсыдыр документ җитешми икән—аны җайга салып була: Фәйзиевлар кланы—кул астында. Тик алда ниләр булмас. Сез мине аңладыгызмы?

Прокурор башын селкеде.

—Минем уйлавымча, һәркем үзе өчен җавап бирергә тиеш. Шуңа күрә юридик документларның, билгеле, соңга калып булса да, үзебезгә генә түгел, бездән өстә торганнарга кагылышлысы да төзелүен телим. Менә шул документларны хәзерли алсагыз, аларны шунда ук тормышка ашырыр идем.

Шубарин, аңлата алдым микән дигәндәй, прокурорның күзләренә карады.

—Минем кешедә эшем юк. Закон алдында кайбер гөнаһларым бар икән, алар өчен кырыс, авыр җәзага тартуларын теләмим. Сезнең белем, тәҗрибә, абруй миңа шуның өчен кирәк,—дип тәмамлады ул сүзен һәм ишеккә атлады...

Прокурор сизде: юк, бу кеше курка торганнардан түгел. Ул үзенә ни кирәген белә.

Ялгызы калгач, юристконсультант яңа кабинетын өйрәнүне дәвам итте: буш сейфка күз салды, бигенең катлаулы системага корылганын чамалады, аннары тәрәзә янына килде. Тәрәзәләр мәйданга карый икән; аста, подъезд каршында торган Ашотның машинасы китеп тә өлгергән.

Прокурор өстәл өстендә яткан сигез папканың кайсыннан башларга дигәндәй, бераз уйланып торды. Алдагы атнага бирәр документны эшләп тапшырырга кирәклеген бик яхшы аңлый һәм ул кәгазьләрнең аны Шубарин алдында, алай гына да түгел, үз араларына юристны чакыруга бераз шикләнебрәк караган ике баш икътисадчы алдында да абруен күтәрәчәген белә. Тик Шубаринның соңгы монологы аның роле нидән гыйбарәт икәнен ахыргача ачып салды. Билгеле, компаньоннарына юристның төп бурычын, һәрхәлдә, болай ук аңлатмагандыр.

Ул тагын бер кат Шубаринның алдан күрүчәнлеге хакында уйланды: айсбергны төзергә булышып, әле дә икътисад буенча төп кинәшчеләре саналган ике картны җаваплылыкка тартулары икеле, бар удар аның җилкәсенә төшәчәк, ә ул моны бер дә теләми иде.

Кулына эләккән беренче папканы ачып, прокурор документлар өйрәнергә тотынды. Боз кузгалды дигәндәй, Христос Янович, Фәйзиев, Шубаринның үзе белән бергәләп ачыклыйсы сораулар язылган битләр саны арта барды. Игътибарын читкә юнәлтеп, әледән-әле телефон шылтырады, чытлык яшь хатын-кыз тавышлары Икрам белән кызыксынды. Көн ахырына бу шылтыратулар өзлексезгә әйләнгәч, прокурор, телефонны өзеп куярга мәҗбүр булды.

Татьяна Сергеевна чәй кертте һәм юристның эштә тоткарланасын белгәч, кабул итү бүлмәсенең ачкычын калдырды һәм аны вахтада калдырмыйча, үзе белән алуын үтенде.

Баш-аягы белән эшкә чумган прокурор вакытның узганын сизмәде дә. Башын күтәреп караганда, урамда карангылык җәелгән иде инде. Ә ул нибары өч папканы карап чыгарга өлгерде, әле аларына да кабат-кабат кайтасы бар. Аның тизрәк эшнең асылына төшенәсе килә, чөнки үз ролен күпме уйнаячагын, Шубаринны күпме алдап йөри алачагын анык кына күз алдына китерә алмый. Шуңа күрә тагын бер папка белән танышып, кунакханәгә җәяү генә кайтырга исәпләде. Мөгаен, анарчы шефы да номерында булыр, анарга тәгаенләнгән сорауларга бүген үк җаваплар алыр. Ә дүртенче папка исә тагын да мавыктыргычрак булып чыкты, инде шактый нәрсәгә төшенеп өлгергән прокурор үзе дә сизмәстән чираттагы папкага үрелде.

Көтмәгәндә баскыч буйлап ашыгыч күтәрелгән аяк тавышлары ишетелде, кабул итү бүлмәсендә кемнәрдер шаулашып алдылар да ишек ачылып китте. Кабинетка сулышы капкан Ашот килеп керде, аның артыннан Икрам белән дулкынланудан йөзе агарган Шубарин күренде.

—Әйттем бит, исән-сау, эшләп утыра!—дип тезде әсәрләнгән Ашот, мылтыктан аткандай. Юлда килгәндә арт сабагын укытканнармы, шатлыгыннан ул прокурорны кочып алырга әзер иде.

Барысы берьюлы карашларын шефка текәделәр. Артур Александрович кинәт хәлсезләнеп калган гәүдәсен кәнәфигә батырды. Берни аңламый торган прокурорга:

—Алла хакы өчен кичерегез, ятышсыз килеп чыкты. Кайтып төштем, Халитов белән эшләрне көйләүне әйтеп шатландырыйм, бер унайдан рәхмәтемне дә белдерим дип бүлмәгезгә күтәреләм—ә сез юк. Кизүдән сорыйм: «Күренмәде»,—ди. Адикка төштем, кичке ашка килмәде, ди. Шылтыратам—трубканы алучы юк... Бер-бер хәл булган ахры дип, барысын да аякка бастырдым. Сәгатегезгә күз салыгыз—төн уртасы житкән бит. Машинага төялдек тә монда очтык. Йоклаган вахтерны уятып керсәк, анысы: «Бернинди юристны да белмим, бар да кайтып беттеләр»,—дип тора.

Прокурор, ниһаять, төшенеп көлеп җибәрде...

—Ә телефоныгыз ник эшләми?—дип сорады Ашот.

—Әй, Икрамның таныш хатын-кызлары тынгы бирмәгәч, өзеп куйган идем.

—Бар да яхшы, әгәр ул яхшы тәмамланса,—дип нәтиҗә ясады шефлары,—тик иртәгә үк телефон мәсьәләсен хәл итегез, эшләгән кешегә комачауламасыннар.—Аннары шоферына борылып:—Ә син, Ашот, Коста белән мәсьәләне хәл ит: йә иртәгә үзе килсен, йә башка кеше тап—болай дәвам итә алмый, бүгенге хәл барыбыз өчен дә сабак булсын. Мин төп мәсьәләне хәл итәргә өлгермәгән кешенең гомерен куркыныч астына куя алмыйм.

Ике сәгатьләр үттеме икән, хезмәттәшләре белән соңга калган кичке аштан прокурор бүлмәсенә кайтып керде. «Чыннан да, тыштан ниндидер куркыныч янадымы икән? Әллә Шубаринны документларны алып качты дигән уй тәшвишкә төшергәнме? Шуның кадәрле мәгълүмат белән йомгакны тәгәрәтеп җибәрергә мөмкинлекне бик яхшы белә бит»,—дип фикер йөртте ул. Әйе, әйе, курыкты—моны прокурор Шубаринның гадәттәге тыныч йөзе дулкынланып китүеннән сизде. Урынында күргәч, шатлануы да ясалма килеп чыкты.

Тик шунысы аңлашылмый: монда нәрсә яшеренгән, чит уенда ул нинди роль уйный, ни өчен аны шулкадәр саклыйлар? Ә шефы авызыннан ишетелгән «төп мәсьәлә» дигәне нәрсәгә ишарәли? Бикхуҗаевлар, үч алу—болары нәрсә? Аның шәхси тормышында аларның ни эше бар, нигә

шулкадәр кайгырту, игътибарлылык? Тик бу сорауларның берсенә дә әлегә җавап юк—көтәргә кирәк. Дөрес, бер нәрсәгә төшенде: моннан соң аңа күз-колак булачакларына иманы камил. Аннары шефы да яңадан соңгы көннәрдәге кебек ачылып бетәрме? Тик монысына борчыласы юк: әгәр прокурор тиз арада документларны әзерләп бирсә, тегеләр алдында югалта язган ышанычын кире кайтара алачак.

Тынычланып, ул йокларга ятты...

## 4

Иртән, машина белән барудан баш тартып, эшенә җәяүләп кенә юнәлде. Ул бүген кәгазьләрдә казынуны читкә куеп, бухгалтериядән арбитражга тапшырыласы штраф санкцияләренә бәйле документларны соратып алды. Соңгы вакытта өч урында юристконсультант булып эшләгәнгә, болары таныш иде. Ул тагын эшкә чумып, төшке аш вакытын үткәзеп җибәрде. Шубаринның шылтыратуы бу дөньяга кайтарды:

—Әмирхан Даутович, бездә дә тәртип башка предприятиеләрдәге кебек, хезмәтне саклау бар, төшке ялны да бетергәнебез юк. Аннары эшчәнлегегезне вакытка карап түгел, нәтиҗәгә карап бәялибез. Шулай булгач, кәгазьләрегезне ташлагыз да чыга торыгыз, хәзер машина килеп җитә. Без дә Адикка төшәбез. Төшке аш—изге эш...

Ул залга кергәндә, хезмәттәшләре җыелган иде инде. Шубарин белән янәшә яшь кенә купшы киемле егет утырган, аның соргылт пыялалы күзлеге нык иякле йөзенә килешеп тора.

—Таныш булыгыз, озак көткән кунагыбыз шушы инде,—диде шеф.

Прокурор өстәл аша кулын сузып исемен әйтте. Кунак аз гына калка төшеп, әллә ничек сәер генә:

—Ә мин Коста,—диде. Әмирхан Даутовичка аның тавышы таныш, үзен күргәне бар сыман тоелды. Тик аның йөзе, бигрәк тә күзләре ярты битен каплап торган зур күзлек артына яшеренгәнгә, исенә төшерә алмады. Прокурорга нигәдер барысы да аның: «Безнен кайдадыр очрашканыбыз бар кебек»,—дигән сүзләрен көткәндәй сизелде.

Гадәттә салкын канлы шефы түзмәде, гаҗәпләнеп сорады:

—Әллә Костаны танымадыгыз инде?

Кунак ашыкмый гына күзлеген салды да өстәлгә куйды. Әйе, бу ул—Бикхуҗаевлардан килгән төнге илче иде.

Компания көткән эффектны боза алганга кәефе килеп, прокурор:

—Без, чынлап та, Коста... белән таныш түгел,—диде.

Кунак һичбер тартынусыз шаркылдады:

—Әйе шул, теге вакытта исемемне әйтергә оныткანмын.

Бар да аның көлүенә кушылды.

Соңга калып булса да прокурор Костаның фамилиясен исенә төшерде—Джиоев, чыгышы белән төньяк Кавказдан. Тәҗрибәле җинаятьче, канундагы карак, үтерүдә гаепләнүче.

—Минем белүемчә, теге вакытта ул сезне коткарып калган, ә хәзер гомерегезне сакларга бурычлы. Дуслашырсыз дип ышанам—Коста сездән мөкиббән. Дөрес, әлегә кадәр «дипломат»тан баш тартуыгызны кичерә алмый бугай.—Күренеп тора: шефның кәефе шәп иде.

—Ул очракта Коста егерме менсез кала иде бит. Бикхуҗаевлар, шәт, сүзләрендә торганнардыр?—Прокурор үзен дорфарак тотарга тырышса да, күнеле сизде: аны кабат сыныйлар иде.

—Бирми генә карасыннар, мин шаярганнарын яратмыйм,—дип җавап бирде Коста эчкерсез генә. Дөрестән дә, аның күзләрендә иман әсәре күренмәде. Төшке аштан соң прокурор белән Шубарин идарәгә кайттылар,

ә Фәйзиев белән Коста кунакханәдә калдылар. Джиоев прокурордан стена аша урнашырга теләгәнгә, күрше бүлмәдәгене күчерергә туры килде.

Кабул итү бүлмәсендә шефны берничә кеше көтеп торганга, арбитражга җибәрәсе кәгазьләргә имза куйдыруны сонгарак калдырып, прокурор үз кабинетына үтте. Ике сәгатьләрдән соң, Шубарин үзе юрист янына керде.

—Кичәге ыгы-зыгыда юньләп рәхмәт тә әйтә алмадым, сезнең аркада Халитов белән килешә алдык. Ул башкача безгә комачау ясамас, алай гына түгел, үзәк универмаг каршында сату итәргә рөхсәт тә бирде. Халитовка чыгаручы кешегә шактый гына күләмдә гонорар вәгъдә иткән идем, әмма сездән башка бирәү дә аның белән очрашу оештыра алмады. Менә бу сезгә хезмәтегез өчен...—Һәм ул прокурор каршына бер төргәк йөзлек куйды.

—Ничек, шаһитларсыз гынамыни?—Юрист шаяртуга борып, акчаны алды да игътибарсыз гына өстәлнең буш тартмасына ыргытты.

—Үпкәләтәсез, без бит дуслар, шулай түгелмени? Кичә үзегез өчен шундый борчылдым.

—Рәхмәт. Акчалар өчен дә. Мебельләр алырга нәкъ шуның кадәрлене сорап тормакчы идем. Коста өчен дә рәхмәт. Тик кыйммәткәрәк төшмәс микән—андыйлар азга риза булмыйлардыр?—диде прокурор, әңгәмәне кирәкле юнәлешкә бормакчы булып.

Тик тегесе вак-төяккә тукталып торасы итмәде:

—Хак, Коста кебекләрнең эше югары бәяләнә, әмма сезнең гомерегез кыйммәтрәк. Бу вакытлыча гына, ярты елдан аның кирәге булмаячак. Әмма хәзергә сезне куркыныч астына куярга теләмим: безнең алда торган эшләрне сез күз алдына да китерә алмыйсыз.—Сөйләшүнең тәмамланганын аңлатып, Шубарин урыныннан торды.

Костаның килеп чыгуы прокурорның тормышын катлауландырып җибәрде,—юк, ирегә чикләнгән йә Джиоевның үкчәсенә басып йөрүеннән түгел; тыштан караганда бар да гадәттәгечә шикелле, тик ул үзен күзәтү астында кебек тойды. Костага карата тактиканы ачыкларга кирәк иде. Билгеле, кичке җәяүле сәйраннар турында сүз булырга мөмкин түгел, хәтта аның белән бер өстәл артында булу теләге дә юк. Хәер, тән сакчысының әлегә андый мөгамәләдә булганы юк. Мисалы әллә ни ерак йөрми: әнә, шеф Ашот белән төчеләнеп тормый—һәрберсе үз урынын белә.

Коста белән сирәк-мирәк кул бирешкәндә дә прокурор үзен көчкә тотып тора. Арттырып җибәрергә ярамый: Коста Ашот кына түгел, хәер, анысы да машинада барганда прокурорга ышанмавын ачыктын-ачык сиздерде түгелме? Ә монысы «әх!» дигәнче чиста суга чыгарыр, нәрсә, башка эше юк, артыннан һәр адымын күзәтергә вакыты баштан ашкан.

Прокурор баш-аягы белән эшкә күмелде: көннәр буе тау кадәр өелгән кәгазьләр арасында казынды. Беренчедән, ул аларның тизрәк очына чыгарга тырышса, икенчедән, магнит кебек артына тагылган Коста белән аралашмас өчен шулай кыланды. Тик дөресен әйтергә кирәк, тегесе үзен тиешле дәрәҗәдә тотты, бирәү дә аның ни белән шөгыльләнгәнен хәтта күз алдына да китерә алмас иде. Илтифатлы, аралашучан, юмарт күренгән Коста тиз арада бар җирдә—идарәдә, кунакханәдә, ресторанда дуслар, танышлар булдырды. Ул оста итеп азга да канәгать булган чырай чыгара, әмма шул ук вакытта бер генә нәрсә дә аның күз очыннан ычкынмый. Прокурор күзәтү алымнарын белә, ике мәртәбә сак кына тикшереп карады һәм Коста белән шаярырга ярамый дигән нәтиҗәгә килде.

Берничә уңышлы тәкъдименнән соң, ул шефының уяулыгын сизелерлек киметә алды. Беренчесе—республика Госснабы, министрлар Советы һәм Җирле сәнәгать министрлыгы аша үткәрелгәне—идарәгә мөстәкыйль

рәвештә республика чикләренә чыгып, сатылып бетмәгән йә планнан тыш житештерелгән продукцияне алу хокукы бирде. Бу документ Шубаринның әллә нихәтле «сул» актларын канунлаштырырга ярдәм итте. Чөнки ана монарчы һәрвакыт нәрсә алган, кайдан, күпме алганын исбатларга туры килгән. Мисалга, рәсми рәвештә мең метр тукыма алды, ди, ә чынлыкта үзе кебек бирәр «өлгер»дән ун, йөз мең метр ала. Бу кәгазь аны бик күп бәлаләрдән йолып калачак иде.

Прокурор берсе артыннан берсе яна документлар әзерләде, алар барысы да Шубарин тарафыннан хуплап каршы алынды. Хәтта монарчы ана карата көнчел караштa булган Фәйзиевнын да әкренләп күнеле эреде, тик моны нигәдер шефыннан яшерергә тырышты.

Ике атналап уйланып йөргәч, прокурорның башына сукты: тукта, Фәйзиевлар кланы унайлы очрак чыгуга Артур Александровичны юлдан алып ташларга җыена түгелме? Клан, мөгаен, Шубарин тарафыннан җибәрелгән машина аннан башка да эшли алыр дип саный, ахры. Һәм, аларның уйлавынча, бу урынга юрист менә дигән кандидат.

Тик бу ачышы прокурорга сөенеч өстәмәде—ике тегермән ташы арасында каласы килмәде, анын үз уены—соңгы көннәрдә берсе артыннан берсе уен кәртләре чыгып тора: кулында өлкә һәм республикада ин югары урыннарда утырган һәм Шубарин «кашыгыннан» ашаган түрәләрнең яртылаш исемлеге бар. Мәскәүнекеләргә чыгу гына катлаулырак—бераз көтәргә туры киләчәк. Әмма тагын бер кыенлык килеп туды: Шубарин яклы кыланганда, Фәйзиевлар кланыннан ни көтәсен чамалады. Бер генә чара бар: сак кына маташырга да, житәрлек мәгълүмат туплауга, унайлы очрак табып юкка чыгарга.

Фатирында ремонт эшләре бетү алдында, яна паркет идәннәрне лаклыйсы гына калды, ә аннары өй туе үткәрәсе булыр. Югыйсә, кайчан күчәсен инде дип, тәмам башын катырдылар. Бу яна оясында берничә ай яшәп кала аламы—билгесез, әмма аңа озакка төпләнә дип уйлаулары кирәк.

Шубарин биргән бер төргәк акча өстәл тартмасында ята бирә, хәтта сейфка салып куюю теләге дә юк, хәер, ул аларны акчага санамый да. Фатиры да шулай ук... Ялган—рәшә сыман.

Кинәт башына акыллы фикер килде: бу акчалар Костадан бер-ике атнага котылып торырга ярдәм итәләр түгелме соң?

—Коста, минем сезгә шәхси үтенечем бар,—дип башлады ул сүзен.—Беренчедән, зәвыгыгызга ышанам, икенчедән, һич вакытым юк, документлар шәхси эшләремә караганда йөз тапкыр мөһимрәк—мине кайгырткан кешеләрнең ышанычларын тизрәк аклыйсым килә. Көн-төн кәгазь актаруымның сәбәбе—мин инде өлкән яшьтә, кредитлар хисабына яши алмыйм, шуңа шактый гына күләмдә аванс алдым, ә үтенечемә килгәндә... Бер-ике атнадан Красиндагы фатирым әзер була, беләсездер. Мебельләр аласы иде. Менә сезгә акчалар, якында гына бик шәп кибет, чит ил гарнитурлары да бар. Зинһар, бүлмәләрнең үлчәмнәрен алыгыз да җиһазлар сатып алыгызчы. Беррәттән савыт-сабалар да карарсыз.—Ул Костага акча төргәге сузды.

Тегесе, гадәтенчә, алдау юк микән дип, төргәкне таратып карады, аннары кем белән эш иткәнен исенә төшереп, көлемсерәп куйды...

Прокурор да анын халәтен анлады: көтмәгәндә ясалган бу тәкъдим, никадәр яшерергә тырышса да, Костаны каушатып җибәрде.

Джиоевнын башына килгән беренче фикер шул булды: прокурор, янәсе, акча төртә дә анын югалуына өметләнә, тик бу уен шунда ук башыннан куды, Коста өчен бер төргәк акча—юк акча икәнен прокурор төшенә ләбаса.

Опекуны күзеннән югалуга, ул ничектер авыраеп калды, кулыннан эш төште, әгәр кабинетында диван булса ике дә уйламас барып авар иде. Кичке сәйранын кабат башлап җибәрсә дә, йөрәге һаман үзен сиздереп тора. Монарчы Шубарин табып биргән чит илнен дефицит төймәләре коткарып килә, нитроглицерины да һәрвакыт кул астында. Хәлиткеч адым ясарга әле иртә, Ким белән Георгади анарга нәрсәнедер әйтеп бетермиләр, димәк, айсбергка ачкыч табу өчен башта шулары белән ышанычка керергә кирәк.

Өлкән яшьтә булуларына карамастан, бу агайлар «Лидо»ны бик ошаталар. Бер-ике яхшы коньяктан да баш тартмыйлар, андый көннәрдә кухняда алар өчен махсус кабымлыклар әзерләнә. Прокурорга да телиме-юкмы «Лидо»га килергә, тормышыннан, хәзерге урыныннан канәгать икәнлеген күрсәтергә туры килә. Шәп утыралар, алар өстәленә тагын кемнәрдер, бигрәк тә Икрам Мәхмүтовичнын әшнәләре елыша, өстәвенә тәмәке төтене исе үзәгенә үтә, әмма прокурор тешен кысып түзәргә тырыша.

Коста чыгып китүгә, шефны кисәтмәве исенә төште: тагын бер атнадан Ларисаның үлеменә биш ел тула, зиратка барып кайту өчен машина һәм озатучы кирәклеген искәртергә кирәк. Кичекмәс эшләр килеп чыгар дип, ул бу сөйләшүне азакка калдырмаска булды. Сонгы вакытларда бер генә чара да аның катнашыннан башка йә аның белән килешенмичә узмый, Шубарин булмаганда кинәш-табыш итешергә аның янына киләләр.

Бухгалтерия кәгазьләренә имза сырлап утырган Шубарин юристны күрүгә, аларны читкәрәк этәрде. Прокурор үтенечен житкерүгә, Шубарин ничектер сагаеп калды, тик гадәтенчә, үзен бик тиз кулга алды. Урыныннан кузгалып, бүлмә буйлап арлы-бирле йөренә башлады, гадәттә бик нык дулкынланганда йә кемнедер әрләгәндә ул шулай итә.

—Авыр хәлгә куйдыгыз. Шулай да мин кисәтергә телим, телисез икән боерык дип анлагыз: ул шәһәрдә ярты еллап күренмәвегез хәерле, нигә икәнен сорамагыз—хәзергә әйтә алмыйм. Ышаныгыз, бу сезнен файдага. Ә датага килгәндә—исемдә, бу хакта инде әмер бирелгән. Хатыныгызның якты истәлеген без бергәләп—яна дусларыгыз, хезмәттәшләрегез искә алырбыз. Бераз гына сабыр итегез, ни өчен барырга ярамавын ике атнадан, бәлки бераз алданрак та анлата алырмын дип уйлыйм. Каберенә килгәндә, бар да тәртиптә. Таш куйган Григоряннар—безнен Ашотнын ерак туганнары. Каберне шулар карый, күнелегез тыныч булсын, шундый көндә кабер чәчәксез калмас.

Күнеле төшкән прокурор кабинетына әйләнеп кайтты. Эшкә тотынырга кулы бармады, кинәт кенә саулыгы да какшагандай булды. Нәрсәне яшерәләр? Шубарин кулында ул нинди корал? Нигә ана озак еллар эшләгән шәһәрендә күренергә ярамый, тагынниләр маташтыра икән? Тик берсенә дә анык кына җавап табылмады.

Хәзер аның шиге юк: чыннан да, узган атнада Шубарин Ларисаның каберендә булгандыр, эшлекле кеше буларак, чистарту һәм тәртиптә тоту өчен кем беләндер килешеп, акча калдыргандыр. Чәчәкләрнен дә иң кәттәләрен куярга сөйләшкәндер. Нигәдер башына, әгәр хәзер йөрәк өянәгеннән үлеп китсә, Шубарин белән Фәйзиев аны зурлап хатыны белән янәшә күмәрләр, хәтта Григоряннардан таш куйдырырлар, эшләре никадәр тыгыз булмасын, вакытларын да, акчаларын да кызганмаслар кебек тоелды. Өстәвенә, искә алу мәҗлесен дә җиренә җиткерерләр, матур сүзләрен дә кызганмаслар, хәтта онытканда бер каберенә дә килерләр.

## ҖИДЕНЧЕ БҮЛЕК

### Уеннан чыгу

#### 1

Киеренке узган бу атна анын сәламәтлегенә китереп сукты. Төн уртасында ике мәртәбә «Ашыгыч ярдәм» чакыртырга туры килде. Моның өчен Костага рәхмәтле, беренчесендә ул, хәле китүгә, әкрен генә стенага суккалады—алар шулай килешкәннәр иде. Күз ачып йомганчы, Коста кереп тә җитте. Соныннан табиблар вакытында чакырып өлгергәнсез диделәр. Таң атканчы Коста анын янынннан китмәде. Атна ахырында хәле җинеләйгән прокурор эшкә чыкты. Тик күнелендәге юшкын таралмады: хатынының каберенә бара алмавын бик авыр кичерде. Шубарин бу турыда башка сүз кузгатып тормады, үзе дә артыгын төпченмәде, килер вакыт—әйтерләр, дип уйлады.

Җомга көнне—Лариса үлгән көн—«Лидо»да төшке аш вакытында Артур Александрович аңа «Поляроид» белән ясалган төсле фотография сузды.

—Ярты сәгатьләр чамасы элек китерделәр. Бүген сәгать тугызда төшерелгән.

Кабер өсте чәчәккә күмелгән. Алгы планда—ак һәм кызыл розалардан купшы веноклар; ә уртада ап-ак розалардан торган зур бәйләмдәге муар тасмага «Җирле сәнәгать идарәсеннән» дип язылган. Икенчесендә исә кыска гына—«Иреннән» диелгән.

Прокурорның ирексездән күзләренә яшь тулды.

—Рәхмәт,—диде ул.—Шулкадәр кайгыртуыгыз, игътибарыгыздан мина бик уңайсыз.

—Кыенсынмагыз. Мин бит кулымнан килгәнен генә эшлим. Без бит хәзер бер җептә, максатыбыз уртак, тормышымның ипле булуына өлешчә сез дә җаваплы, шулай түгелмени?—Шубарин күнелен күтәрергә тырышып, юристның кулына кагылды.—Хәер, ашыкмыйк. Кичен монда—ябык банкет залына җыелабыз. Сезнең исемнән иң якын кешеләр генә чакырулы. Төшке аштан соң ял итегез, ә кичен сәгать сигезләрдә бергәләп кунаклар янына төшәрбез; соңга калучылар булмас дип ышанам.—Шулай итеп, алар кичкә кадәр саубуллаштылар.

Бүлмәсенә менгәч, прокурор үз уйларына чумды, кабат теге август көнендә район милициясе бинасында капитан Чураевтан хәбәр көтеп утыруы исенә төште.

Биш ел үткән! Хатынын югалтканнан соң, тормышын болай күз алдына китергән идемени ул? Гаҗәп, хатыны үлгәнчегә кадәргесе томан кебек, хәтта вакыт-вакыт анын башына: андый бәхетле көннәр чыннан да булды микәнни? дигән уйлар да килеп киткәли.

Ә хәзер томышының яңа этабы башланды, күпмегә сузылыр—билгесез, берничә айгамы, елгамы? Ул үзе ярты елдан артыгына өмет итми; шома, сизгер Шубарин һәм анын компаньоннарына каршы торыр өчен көчләр тигез түгел. Ярымсерле синдикатка кодаларга килгән кичтән башына сенгән уен тормышка ашыра калса, алданиләр көтә? Хакимияткә тапшырганнарын—кем-кем, прокуратурада эшләгәч, ул андагы тизлек һәм алымнарны бик яхшы белә—әйләндереп чыгару елларга сузылачак, ә анын йөрәге моңа чыдармы, көтеп җиткерә алырмы бу көнне? Хәтта монда, һәрнәрсәгә көче җитә торган кайгыртучан Артур Александрович янында, теләсә кайсы моментта башкаладагы профессор белән бәйләнешкә кереп киңәшләр, кирәк булса үзен дә чакыртырга мөмкинлек булганда—дару төймәләре турында әйтеп тә торасы юк—«Ашыгыч ярдәм»сез котылып булмады.

Тик аның алда ниләр күрәсен уйлап, баш ватасы килмәде...Утыз ел элек эсминецның калтырап торган палубасында сайлап алган юлын гомер азагында тиешенчә яшәп, алдына куйган бурычын үтәп йомгакларга язсын иде.

Сигез туларга биш минут кала ишек шакыдылар, бусагада Шубарин күренде. Ул инде банкет залында булып, соңгы күрсәтмәләрен биргәндер—профессорның менә иманы камил—аннары гына күтәрелгәндер. Никадәр генә йөрәге сызланмасын, юрист аның күзләрендә бу искә алуның синдикат өчен нииндидер әһәмияткә ия икәнен сизми калмады. Бәлки, сирәк очраша торган кешеләрен бер табын артына җыясы килгәндер? Ә бәлки тагын бер тапкыр кемгәдер бергә булуларын күрсәтергә теләгәндер? Хәер, Шубаринны аңламассың...

Соңгы атналарда «Лидо»да еш булса да, прокурорның банкет залына күз салганы юк иде. Ресторан ишек төбендә аларны бәйрәмчә киенгән Адик каршы алып, залга озатып куйды. Яп-якты бүлмәгә керүгә, барысы да сүз берләшкәндәй аягүрә бастылар. Өстәл артында Ким белән Георгадидан тыш Гадел Шәрипович, Григоряннарны күреп, аның күзе маңгаена менде. Ашот белән Коста, тагын таныш булмаган берничә кунак—барысы да ир-атлар.

Ашот күрсәткән урынга атлаганда, Әмирхан Даутович стенада Ларисаның елмаеп төшкән зур төсле фотографиясен күреп алды. Фотографиянең кырыйлары 1940—1978 даталары куелган кара муар тасма белән уратып алынган. Биек бәллүр вазалар—вакытлыча кибеттән алып торганнардыр инде—тулы ап-ак розалар, чәчәк савытларына да кайгы тасмалары беркетелгән. Керү юлында идәндә торган вазадагы розаларны рәтләштереп арттарак калган Шубарин түргә—прокурор белән Икрам уртасына урнашты. Бераздан прокурор табынга иялэшә төште, әмма өстәлнең купшы, мул булуы аның исен китәрде. Күренеп тора: Фәйзиев махсус базаларның астын өскә китергән; пычак-чәнечке-бокаллар казнаныкына охшамаган, урынбасар тырышкан: өеннән китерткәнме, әллә өлкә комитетының дачасы йә резиденциясеннән алып торганмы? Кайчандыр бер төшке аш вакытында Георгади, Европа тәрбиясе алган кеше буларак, көмеш кашыклар белән авыр зәңгәрсу бәллүрне үз итүе турында сөйләнгән иде—бәлки аның байлыгыдыр? Һәм болар барысы да Ларисаны искә алу өчен хәзерләнгәнме? Мондый купшылык аңарга ошаган булыр иде микән соң?..

Прокурор шефына нииндидер һавалылык хас булуын күптәннән сизенә, менә хәзер дә аның бу сыйфаты табынга күчте—биниһая зур өстәл артына зур кабул итүләрдәге кебек таралып утырдылар, шунадыр мәҗлестә рәсмилек, кырыслык хөкем сөргән кебек. Нәселеннән килә микән, әллә урыс гадәтеме, Шубарин кунаклар кабул итүгә, сыйлауга мөкиббән иде.

Адикка бүген ике официант ярдәмгә килгән, хуҗаның ымлавы булды—алар шунда ук чәркәләргә аракы, коньяк койдылар, күрәсең, кемнең кайсы эчемлекне хуп күрүе аларга алдан хәбәр ителгәндер.

Шубарин урыныннан торды һәм: «Вакытсыз арадан киткән Лариса Павловнаның якты истәлеген бер минутлык тынлык белән искә алыйк»,—диде. Аннары таныш булмаган ир-атлар өчендер, прокурорның хатыны белән таныштырды. Озак сөйләде, ул, чынлап та, Лариса турында аз белми икән... Хәтта прокурор онытырга өлгергән кайбер вакыйгаларны да искә алды. Үзе дә сизмәстән аны уйлары еракка—артта калган бәхетле көннәргә алып китте, хуҗаның сүзләре әкренләп тоныклана барды да бөтенләй ишетелмәс булды. Әмирхан Даутович күзләрен Костаның баш очына туры килгән портреттан аера алмады... Башыннан яшен тизлегендә: «Бу бит беренче тапкыр кешеләр катнашында искә алынган мәҗлес»,—дигән уй чагылып узды. Еллары нинди туры килде бит, берсеннән икенчесе

көенечлерәк, әмма күнелен бер нәрсә тынычландырды: каберенә таш куйдыра, чардуган кордыра алды.

Прокурор ихтирам белән Григоряннарга күз салды, тегеләре исә игътибар белән дулкынландыргыч нотыкны тынлыйлар иде. Башкалар белән бергә прокурор да коньягын эчеп куйды. Аннары Халитов сүз алды, ул Лариса белән булган фаҗигане тагын бер кат күңелләрдә янартты, дустының кайгыны ирләрчә ныклык белән кичерүе турында искәртте. Урынын белеп әйткән сүзнең тылсымлы көченә прокурор менә шунда, чакырылган кунакларның чыгышларын тынлаганда инанды... Әгәр шул мәлдә Шубарин Бикхуҗаевлар белән кул сугышына барыйк дисә, берәрсе каршы килер иде микән? Табын янында бердәмлек, үз-үзенне аямау рухы хөкем сөрә иде! Һәм бу мохитне тудыручы кеше—Шубарин. Искә алу мәҗлесенә җыенганда, прокурор мондый дәрәҗәдә кайгы уртаклашуны күрермен, ихлас күңелдән юату сүзләре ишетермен дип башына да китермәде. Авырлыклар килгәндә ике дә уйламыйча «таяныр» кешеләре барлыгын белү Азлархановка тәэсир итми калмады, гадәттә бер-ике чәркә белән чикләнгән прокурор соңгыларыннан баш тарта алмады.

Официантлар исә тавыш-тынсыз гына үз вазифаларын башкардылар: салкын кабымлыкларны кайнарлары, бер деликатесны икенчесе алмаштырды, «Боржоми»ның суытылганнары өстәлә торды. Ул арада беренче аш китерделәр: Фәйзиев бөдәнәдән пылауны әлеге очрак өчен махсус үзе пешергәнен белдерде. Залда шау-гөр көчәя барды, ул да булмады, өстәл артына яңа кунаклар өстәлде. Шубарин барысын да күз унында тотты, әледән-әле Адикка ниндидер ишарәләр ясады, шул арада вакыты-вакыты белән үткәннәрне уйлап дөньядан киткәндәй утырган күршесен дә онытмады: тәлинкәсенә кабымлыклар өстәде, хуҗа буларак, тегесеннән-монысыннан авыз итәргә кыстады.

Урамда күптән төн канатын җәйгән, төбенә кадәр киереп ачылган тәрәзәләрдән ыргылып кергән саф һава кичке сәйранга вакыт икәнен белдерде. Прокурорның ялгызы гына каласы килсә дә, өстәл яныннан торып китәргә кыенсынды. Инде ничәнче мәртәбә Артур Александрович аның күңелендәгеен укыгандай, иелә төшеп әкрен генә:

—Саф һавага чыгасыгыз килмиме?—дип тәкъдим итте.

Җавап көтмәстән урыныннан торды да ишеккә атлады, прокурор да аңа иярде.

—Әйдәгез, сезнең гадәти маршрутыгыз буйлап атлыйк,—диде шеф.—Бәлки аппетит уяныр, авыз итәсе нәрсәләр шактый бугай—мантыдыр, бөккәндер дигәндәй. Фәйзиевны беләсез бит инде, бу өлкәдә аңа житеп булмый, эшендә дә шундый булса—бәяләп бетергесез булыр иде.

Прокурор Ларисаның каберенә салынган чәчәкләр өчен дә, бик яхшы оештырылган искә алу мәҗлесе, анда ишеткән күңелне кузгатырлык сүзләр өчен дә рәхмәт әйтергә кирәклеген аңлады, әмма нидер тыеп тора иде.

Озакка сузылган тынлыкны Шубаринның сүзләре өзде.

—Беләм, искә алу мәҗлесләрендә бүләкләр бирү кабул ителмәгән. Ләкин мин сезнең өчен күңелле яңалыкны җиткермичә булдыра алмыйм. Әгәр бу хәбәрем сезгә юаныч һәм күңел тынычлыгы китерсә, мин шат булыр идем.

Шубаринның ниндидер мөһим нәрсә турында әйтәчәген прокурор йөрәге белән сизде һәм ялгышмады.

—Бүген, ягъни Лариса Павловнаны искә алу көнендә хатыныгызның гомерен чикләгән җинаятьче—прокурор Әнвәр Бикхуҗаевны соңгы юлга озаттылар...

—Ялгышмыйсызмы?—дип сорады прокурор.

—Әллә монарчы әйткәннәремә икеләнерлек сәбәп биргәнем булдымы?—Сорауга сорау белән җавап бирде ул.—Аны кичә кич үтергәннәр, кем икәне дә мәгълүм.

—Кем инде ул?—Дулкынлануын һәм үзен чорнап алган куркуны никадәр генә яшерергә тырышса да, прокурорның тавышы калтыранып чыкты.

Шеф йөзе агарып киткән юристконсультантка рәсем сузды:

—Менә шушы яшь кеше.

Аклы-каралы фотографиянең алгы планында прокурор Бикхуҗаев төшерелгән, ә янәшәсендә кыска чәчле, килбәтсез чырайлы яшь егет. «Лидо» залында төшерелгән рәсемгә күпме генә текәлеп тормасын, кылый күзле, зур авызлы бу егет аңа таныш түгел иде.

Тынычлана төшкән прокурор, аның кемлеген сорады.

—Танымадыгызмыни? Сәер. Бу бит сезнең иске танышыгыз, хатыныгызны үтергән өчен утыра, дөресрәге дусты Әнвәр Бикхуҗаев урынына.

Прокурор бар игътибарын җигеп, фотографиягә текәлде.

—Танырлык түгел, үзгәргән...Әллә нинди, ерткыч сыман, минем истә малай-шалай кебек кенә калган...

—Биш ел узды, исән-имин калган, төзәлмәслек булып, чын бүрегә әйләнгән, күрмәгәннәрне күрсәтер әле ул. Әйткән идем бит: явызлык бары тик явызлыкны гына тудыра...

Прокурор күтәлмәгән чишелештән сискәнеп китте: ниһаять, ул Шубаринның бу адымына төшенде. Менә ничек итеп үзенә бәйләргә тели икән! Хәзер ул прокурорны уч төбендә тоя—бергә, гомергә бер җепкә төйнәлгән дип әйтмәкче. Җинаятьчеләргә хас алым—кан белән, ягъни үтереш белән бәйләп куймакчы. Димәк, әгәр Азат Ходайкуловка җавап тотарга туры килсә, күзен дә йоммыйча: «Хатыны өчен үч алырга дип прокурор яллады»,—диячәк.

—Нәрсә өчен? Алар бит дуслар, бергә буй җиткергәннәр, монысы чүпрәкләрдән арынуга тегесенең адъютанты булган диләр?

—Булган да онытылган. Балачак сукмаклары аерылган, шуңа үч алу теләге дә көчле. Бикхуҗаевлар әйткән сүзләрендә тормаганнар...Баштарак, дөрес, булышканнар, күчтәнәчләр җибәреп, күрешеп торганнар, авыру әнисен дә читкә какмаганнар. Акрынлап игътибарлары кимегән, Ходайкуловлар алар өчен авыр йөккә әверелгән. Әнисе бакыйлыкка күчкән, үләр алдыннан улына үлеменең сәбәпчесе—Бикхуҗаевлар дигән хат юллаган. Алар өчен утырганда, шундый кайгылы хәбәр алу җиңел дисеңме? Шул көннән ул балачак дустыннан үч алу теләге белән яна башлый. Дус санаган кешесенең тирә-якта явызлыгы, наданлыгы, кансызлыгы һәм ришвәтче булуы белән дан тоткан прокурор икәнен белеп алгач, төрмәдәшләре дә канын кыздырырга үз өлешләрен кызганмаганнар.Төрмәгә хәбәрләр тизрәк килеп җитә. Бер ел элек прокурор Бикхуҗаевны юлларыннан алып ташларга хөкем чыгарган шактый йогынтылы кешеләр барлыгын ишетеп, ул Ходай Тәгаләдән үзе котылганчыга кадәр аның гомерен саклавын сораган. Ә Азат кебекләр сүзләрен җилгә очырмыйлар, җинаятьчел дөньяда репутация гомердән алдан йөри.

—Теләү бер нәрсә, үтәү—икенче. Ул колониядән кача алдымы?

—Алай ук түгел. Сезнең белән килеп чыккан хәл турында, аннары бәхетсез егетнең нахакка утыруын ишеткәннән соң, икегезнең үй-теләкләрегез туры килә дип уйладым. Үземчә, соңга калып булса да, гаделлек торгызуны кирәк таптым. Азатны берничә сәгатькә «Лас-Вегаска» китерүләрен сорадым, аннары ресторанда сурәткә төшерттем. Нинди кеше икәнлеге, таянырга буламы-юкмы, ниятенең ни дәрәҗәдә җитди булуы турында читләтеп кенә сораштырдым. Ул төрмә мәктәбен уңышлы үткән, бик уйлап фикер

йөртә. Берничә шартка күнсә, мин аңа булышырга сүз бирдем—ул каршы килмәде.

—Сез аңар качарга ярдәм иттегезме?—дип сорады прокурор, кабаланып.

—Юк, нишләп, качу турында сүз булмады.

—Ул вакытта ничек үч алды соң ул?

—Монда баш ватарлык нәрсә юк. Нишләп әле таныш полковнигыгыз Иргашев сезгә каршы тору өчен Костаны ярты еллап иректә тота ала да, мин Азатны берничә сәгатькә чыгара алмыйм, ди? Ашот кешеләре Бикхуҗаевны күзәтү астына алдылар, әзергә-бәзер килгән Азатка нокта кую өчен биш минут житте.

—Димәк, бу жинаятьне ачу жинелләрдән булмаячак һәм куркыныч янамый?

—Авыр сорау. Мин бездә жинаять эшләре ничек ачылганын белмим, әмма хөкем ителүче өч сәгатьтән үз урынына—төрмәгә әйләнеп кайтты, монысын тәгаен әйтә алам. Ә хәзерге тәжрибәсе белән тагын бер үтерүне—дөрес, монысы үзенеке—өстенә алырга анын башы ике түгел, аннары, чыккач, минем ярдәмгә таяначак. Мин әйткән сүзне жилгә очыручылардан түгел—монысын да белә. Хәтерлисезме, сезгә: дошманны кем алып ташлый—кызыксындырмый, безгә нәтиҗәсе кыйбат, дигән идем. Әнвәр Бикхуҗаев үзенә теш кайрауларын чамалый, прокуратурада да бу турыда беләләр. Хәер, анын башын кыерга теләүчеләр болай да житәрлек иде, жинаятьчеләр, эшмәкәрләрдән тыш, донжуанлыгын кичермәүчеләр арт сабагын укытырга кымырҗып йөрделәр—беләсездер, районнарда андыйларга кырыс карыйлар. Ә ул тотты да үз халкынын намусына, әхлагына төкерде. Шулай итеп, тикшерүчеләр өчен жирлек бездән башка да житәрлек, кирәге чыкса—бүтән вариантлар да уйланылган, андагы үз кешебез күз унында тотачак. Үч кайтару өчен баш кирәкми, ә менә дошманнарнын кытыгын китерерлек итеп куанып яшәү теләсә кем кулыннан килми. Ахыр чиктә, Азат тагын биш ел безнең кул астында була әле,—диде Шубарин, гадәттәгечә уйланырга урын калдырып.

Сүзгә мавыгып шактый кителгән, борынгы Допидуз мәхәлләсенә житә язганнар. Кайтыр юлга борылгач, каршыларына сулуы капкан Коста килеп чыкты.

—Жәмәгатьчелек сезне көтә, Ким белән Георгади кузгалырга жыеналар,—диде ул шефына.

—Биш минуттан булалар дип әйт.—Коста, караңгыда эреп югалгандай, мизгел эчендә юк булды.

Алар банкет залына кергәндә, чын-чынлап күңел ачу мәжлесе башланган, күп кенә яна чырайлар өстәлгән, тик Артур Александровичны шәйләп алуга, шау-гөр, тавыш, көлеш юып алгандай булды, бар да тиз арада үз урыннарын алдылар. Коштабак тулы вәгъдә ителгән манты күренде—анын өстенә сибелгән яшеллек катнаш кызыл борыч шундый ымсындыргыч иде ки, дәррәү тамадага борылдылар. Тик шулвакыт мәжлес башыннан ук күзгә чалынган таныш түгел берәү урыныннан торды. Димәк, чираты житкән. Анын да нотыгы озынга сузылды, темадан читкә китмәскә тырышса да, Лариса Павловнаны күреп белмәгәнгә, жайлап кына сүзне икенчегә борды, күрәсен, аңа шундый бурыч куелган булгандыр. Ул күптәнге дусларынын дусты кайгысын уртаклаша алуын үзе өчен дәрәжә дип санавы, шундый хөрмәтле кешегә хезмәт күрсәтергә һәрвакыт әзер булуы турында сөйләде.

Сүзен тәмамлаганчы күзләрен Шубариннан алмады, тегесе ничек кабул итә, янәсе. Прокурор анлавынча, бүген шефлары үз «көтү»енә тагын бер

сүзе үтемле кешене тартып кертергә маташа, ахры.

Сөйләүчеләрне тынлаганда, прокурор яна гына ишеткән яналыктан тагын кемнәр хәбәрдар икәнен ачыкларга тырышты. Билгеле, иң беренче чиратта Фәйзиев беләдер, чөнки кайтып керешкә, чәркәсен күтәреп, тәбрик иткәндәй, башын селкеп куйды. Тагын кемнәр?

Очы-кырые күренмәгән мәҗлескә Ким белән Георгади нокта куйды, картлар китәргә җыендылар һәм шеф Ашот белән аларны илтә китте. Мәҗлес таралды, үзе туйса да, күзе туймаганнар оркестр уйнап торган зур залга үттеләр.

Өстәл артында прокурор белән Икрам, алардан аз гына читтәрәк әле һаман да тегесенә, монысына үрелгәләп утырган Коста гына калды. Урынбасарның юристконсультантка әйтер сүзе бар иде, ахры, Костага китәргә ишарә ясады. Тегесе тиз генә чыгу юлына китте, аның артыннан официантлар да кузгалдылар. Прокурор, бу ишарәне шәйләмәгәндәй, Фәйзиевка елыша төште һәм үзенә дә, анарга да коньяк салды—аның тизрәк үзенә кирәкле гәпне куертасы килде.

—Әйдәгез, хөрмәтлеләрнең хөрмәтлесе Артур Александрович исәнлегенә күтәреп куйыйк, мин ана соңгы сулышыма кадәр бурычлы һәм намус белән хезмәт итәрмен дип ышандырасым килә.

Фәйзиев ана сәерсенеп карады:

—Аның өченме? Рәхәтләнеп,—диде дә чәркәне авызына каплады.—Ә минә соңгы сулышка кадәр бурычлы булу мәсьәләсенә килгәндә... Минемчә, алдын-артын уйламыйча ашыгыч фикер йөртәсез.

—Сез бит белмисез,—дип бүлдерде аны прокурор, ачуы кабарган кеше шикелле кыланып.—Ул... Ул Ларисаның үлеме өчен үч алды һәм җанымны басып торган авыр таштан коткарды... Миңа хәзер берни кирәк түгел, гаделлек торгызылды, явызлык җиңелде.

—Ник белмәскә?—диде ул, ачы көлемсерәп.—Беләм. Сез минем турыда белеп бетермисез әле, бу эштә минем дә катнашым бар дип саныйм: төрмәгә юлны мин ачтым бит.

—Сезгә дә рәхмәт.—Профессор башын иде.

—Эш миндә түгел.—Тегесе ашыгып кулын селтәде.—Гаделлек торгызу өчен, имеш. Юк, сезнең хакка дип тә ялгышасыз—ул Робин Гуд түгел.

—Бернәрсә дә аңламыйм...Алайса ник үзен куркыныч астына куйды соң? Шулай да прокурор хәтле прокурорга һөҗүм бит...

—Менә нәкъ тә шуннан башларга иде,—диде Икрам үгет-нәсихәт биргәндәй. Мөгаен, ул да бүген юристны үз ягына аударып көн җитте дип санагандыр.—Эш менә нәрсәдә, моннан биш ел элек, әле сез прокурор булып торганда, шеф сезнең өлкә белән кызыксына башлаган иде. Башта, билгеле, аз-маз гына. Тик сез аның колачын беләсез бит, бармагыңны гына күрсәт, ә ул һап! кулыңны эләктерә. Ишеткәнегез булмадымы, Мәскәүдә бит аны Япон дип йөртәләр. Ни өченме? Чөнки беткән, табышсыз дип саналган житештерүне дә аякка бастырырга сәләтле булганга. Ул, чыннан да, коеп куйган инженер, ә икътисадчы һәм эшмәкәр буларак—даһи. Сезнең өлкәдә бөтенләйгә төпләнмәкче булды, резиденция шунда булачак, диде. Бик күп акча түкте, эшләре дә унай барды, яклаучылары да табылды. Кемнәр дип уйлыйсыз? Бикхуҗаевлар... Ярдәм кулы сузганда, алар, мөгаен, Шубаринның «тавыгы алтын күкәй салыр» дип күз алдына да китермәгәннәрдер—соңрак бит акча елга кебек акты. Бикхуҗаевлар бер нәрсәне исәпкә алмадылар: ул бүлешергә дә, түендырырга да риза, әмма эшнең һәм акчаларның хуҗасы дип фәкать үзен генә саный. Кыскасы, күчәр башлары орышты. Ул чакта Шубаринның җинаятьчел дөнья белән хәзерге кебек хакимлеге юк, урыннарына утырткан булыр иде, югыйсә.

Бикхуҗаевлар дуслары—өлкәгә яна куелган прокурор аша Шубаринны кысып алып, тын алырлыгын да калдырмадылар һәм ул башлаган эшен, шәхси җиһазларын, станокларын, тиешле паен да алмыйча, өлкәдән чыгып сызарга мәҗбүр булды. Шул эшләрнең шаһитлары булганнар әйтүенчә, ай-яй, бәргәләнеп караган ул чакта Япон! Юк, югалткан акчалары кызганыч булмаган—ул хыянәтне, мәкерне кичерә, мыскыл һәм түбәнлекне күтәрә алмаган һәм үз-үзенә Бикхуҗаевлардан кан белән түләтергә ант иткән. Менә сәгате сукты—черки дә борынын тыга алмаслык итеп исәп-хисап ясады. Күр дә тор: тегеләр бераз аңнарына килүгә, үзләренең иске дуслары Костаны ультиматум белән җибәрәчәк һәм тоткан чыгымнарын, шушы еллар өчен табышны таләп итәчәк. Ким һәм Георгади исәп-хисапны әллә кайчан әзерләп куйдылар инде. Кайтармыйлар икән—чираттагы Бикхуҗаевның башына җитәчәк, үзенекенә ирешкәнче шулай итәчәк—ул бик явыз кеше... Ә сумма зур, миллионнан артып китә.

Прокурор ирексездән:

—Куркыныч адәм!—дип ычкындырды.

—Чып-чын мафиоз,—дип килеште Фәйзиев.—Прокурор Халитов юкка гына шүрләми анардан. Беләсезме, аның яраткан фильмы—«Крестный отец», аны айга бер карамый калмый. Мина калса, ул аларда да—Италиядәме, Америкадамы—төшеп калмас иде, ә хәзер бу эшкә сезне дә китереп бутады...—Икрам Мәхмүтович, артыгын ычкындырганын аңлап, телен тешләде һәм Адикка кычкырып, чәй китерергә кушты.

Әңгәмә шуның белән сүтелде. Прокурор Икрамның аны үз лагерена тарту мөмкинлеген ычкындырганын аңлады.

Менә-менә Шубарин килеп җитәргә тиеш, вакыйгалар куерганнан-куера барганга, прокурорның беркемне дә күрәсе килмәде. Фәйзиевнең да өметен кисәсе итмәде, алдагысын кем белә, ярдәм кирәк булуы бар һәм ул киләчәктә исән-имин калу максаты белән:

—Сез күп нәрсәгә күзләремне ачтыгыз, рәхмәт,—диде.—Тик мин барысын да өр-яңадан уйларга тиешмен. Без бүгенге әңгәмәне дәвам итәрбез, алга таба мөнәсәбәтләребезне ачыкларбыз дип ышанам.—Һәм, урынбасарга уйланырга җирлек калдырып, залның икенче ягына—хатыны портреты янына юнәлде. Сак кына кыланып, фотографияне алды да тар коридор аша кунакханәгә китте.

Бусагадан атлап, ишекне ябуга, авызыннан беренче сүзе ыргылып чыкты:

—Үрмәкүчләр!

Бу сөйләшүдән ул шуны аңлады: хакимлек Шубарин кулында булмаса, вакытында җинелү ачыларын тоймаган булса, Фәйзиевлар аның белән мәчеле-тычканлы уйнап маташмаслар, Бикхуҗаевлар сыман барысын да тартып алырлар иде; тик хәзер Японның колагы сизгер, күзе үткен, менә шуңа урынбасарына ахыргача ышанып бетмәде.

Бәлки ул, Әнвәр Бикхуҗаевны алып ташлап, Фәйзиевларны кисәтергә теләгәндер? Шубарин—үткен кеше, Икрам Мәхмүтович һәм аның даирәсенең максаты ни икәнен төшенми калмагандыр? Сорау арты сорау... Тукта, ә нигә Фәйзиев: «Менә сезне дә бу эшкә бутады...»—диде дә сүзне икенчегә борды икән? Япон нишләтмәкче була икән аны?

Фәйзиевнең үзенә кабалага төшүен дә чамалады прокурор. Шубаринга бу сөйләшү хакында бер ым кагу җитә—тегенең тормышы тәмугка әйләнәчәк.

Кинәт аның күзләре фотографиягә төште һәм яшерен синдикат башлыклары, ялланган үтерүчеләр һәм башка шундый кабахәтләр турындагы уйлары үзеннән-үзе таралып юкка чыктылар. Бүген—Ларисаны искә алу

көне, боларны уйлау түгел, хәтта кичектергесез эшләрне дә казага калдырып тора торган көн. Ул стенадагы төсе унган репродукцияне алды да анын урынына кайгы тасмасын сүтеп алынган фотографияне элеп куйды.

«Әгәр Лариса исән булса, белә торып үземне нинди куркыныч астына куюымны аңлаган булыр иде микән?» Үткән тормышын күз алдыннан кичереп чыкканнан сон җавап бирде—әйе. Урыс зыялылары арасында үскән Лариса өчен «бурыч» сүзе беркайчан да буш сүз булмады, шуңа күрә ул иренен хәлен, һичшиксез, аңлар иде. Уйлары тагын «намус», «дәрәҗә», «бурыч» тирәсендә бөтерелә башлады һәм ул үзе өчен ачыш ясады: зур урында шактый еллар утырса да, аның бервакытта да хәзер алдында торган җаваплы карар кебекне кабул иткәне булмаган икән. Эченнән генә үзенең әле дә өстеннән прокурор вәкаләтләрен төшермәвен аңлап алды һәм кич буе кадак өстендә утырырга мәҗбүр иткән курку хисе юкка чыгып, күнеленә тынычлык иңде.

## 2

Ике атна инде прокурорның Шубарин белән очрашканы юк. Ларисаны искә алу мәҗлесеннән сон Мәскәүдән килгән төнге шалтырау шефны урыныннан торгызды һәм ул башкалага очты. Прокурор бу иркенлектән файдаланып калырга тырышты: Шубаринны куандырырлык документлар әзерләү белән бергә, кәгазьләрдә актарына торгач, какшамас айсбергның кайбер серләренә төшенде. Икътисад караклары өлкән яшьтәге Ким, Георгади һәм аларның башлыклары Японның хәйләкәр алымнары менә нидән гыйбарәт икән: алар бер үк штат каралган ике өлкә йә ике районда шактый предприятиеләр торгызганнар. Берсе чын, ә икенчесе ялган житештерү финанс һәм чимал мәсьәләсендә алдашулар өчен зур мөмкинлекләр ачкан. Прокурор Японны зур-зур суммаларга чек кенәгәләре белән тәэмин итеп торган берничә банкның эзенә төште, башка каналлар буенча «эшләп тапканнар»ын да, мөгаен, шушы банклар аша акчалата алып яталардыр дигән уйга килде. Теге көнне Костага йөзлекләрне тоттырганчы, прокурор төргәктәге штампны куен дәфтәренә теркәп куйган иде, хәзер шул банкның кәгазьләренә килеп юлыккач, дөрес юлдан баруын аңлады, «Синдикат» өчен эре купюраларны нәкъ шунда саклап тотканнар.

Көн уртасында Мәскәүдән кайтып төшкән Шубарин башта юристконсультант кабинетына сугылды.

—Сезне сау-сәламәт күрүемә шатмын,—диде ул, бусаганы атлап кергәч.—Шундый авыр чакта ташлап китте бу дип уйладыгызмы? Киткәндә Костаны бик нык кисәттем, үзем кайтканчы сездән күз дә алмаска куштым, бер көннән шалтыратып, шикле нәрсә сизелмиме дип белештем. Аллага шөкер, ул-бу юк, хәзер җаным тыныч, ярдәмчеләремә ышансам да, кем әйтмешли, үземә таянам. Нишлисең, эш—эш инде ул, аннары бәлагә тарганнарга да ярдәм кулы сузмый булмый—Мәскәүгә шуңа чакыртып алдылар, аларныкы белән бер очтан үземнекен дә рәткә салдым. Йә, сездә ничек, нинди уңышлар белән сөендерәсез?

Юрист сүзсез генә ана таба тышына «Имзага» дип сырланган папканы этәрде.

Шубарин тиз генә күзләрен документлар өстеннән йөртеп чыкты да, шаяруга борып:

—Миңа бу циркулярларны берәмтекләп сата ала идегез. Күпме чыгарып салсам да алданмаган булыр идем,—диде. Бераз гына уйланып торганнан соң:—Минем дә сезгә бүләгем бар,—дип, кайчандыр Коста кулында күргән «кейс»ка охшаган «дипломат»ын ачты.—Бу—швейцар сәгате, «Патек Филипп», сезгә ошар дип ышанам—үзе алтын, циферблаты белән уклары

ак алтыннан; күп функцияле «Кассио» хисап машинасы, кечкенә генә «шарп» диктофоны да бар—машинистканың әкрен кыймылдавы эчегезне пошыра иде, хәзер текстны кабинетыгыздан гына әйтә аласыз.

Прокурор тартманы ачты—сәгать,чынлап та, күз явын алырлык.

—Костаны көнләштерелек булган бу,—дигән булды Әмирхан Даутович, шаяртып. Тик тегесе башын чайкады:

—Көнләшмәс, аңа да сәгать алдым, аныкы—«Юлисс Нардан». Коста озак еллар Бикхуҗаевларның ышанычлысы булып торды, ул сезгә дә, миңа да бик кирәкле кеше, аның ярдәме белән тегеләргә аяктан егарлык тагын бер һөҗүм ясыйбыз әле.

Хуҗаның кайтканын ишетеп, өченче каттан Икрам төште. Юристның кулында сәгать тартмасы күреп, малай-шалай кебек үпкәләде:

—Ә миңа?—дип сорады.

Шубаринның, күрәсен, кәефе күтәренке иде, Фәйзиевне җилкәсеннән кочып:

—Ә сиңа бүләкнең җитдирәге: «мерседес»ынны алырга кешенне җибәр, менә дигән—Санобар машинасы аның янында гап-гади бер арба.

Фәйзиев куанычыннан чинаган тавышлар чыгарып, кабинет уртасында тыпырдарга тотынды, нәкъ шул вакытта сиам игезәкләре кебек аерылмас ике карт—Ким белән Георгади килеп керделәр.

Кабинетта ыгы-зыгы башланганын чамалап, Шубарин юристка күз кысты да чакырылмаган кунакларны үз кабинетына әйдәде.

Прокурорның, хәер, Ларисаның да үз гомерләрендә кыйбатлы чүпрәк-чапракларга, затлы әйберләргә исләре китмәде. Әле дә ул бу бүләккә сөенмәде дә, көенмәде дә—тартма ачык килеш өстәл өстендә ята бирде. «Кешене сатып алу өчен нинди генә юллар юк,—дип уйлады ул,—акча белән, дәрәҗә, хатын-кыз, машина, модалы кием-салым, сирәк китаплар, дача, антиквариат, кыйммәтле әйберләр, спорт кирәк-яраклары белән... Кем-кем, ә Артур Александрович кемгә нәрсә тәртәсен бик яхшы белә. Әйе, бик игътибарлы, зирәк аларның хуҗалары.

Костаның ике атна тирәсе инде аның тирәсендә бәбкәсен тилгәннән саклаган каз шикелле бөтерелүе исенә төште, димәк, ул борчымас өчен аңа берни белгертмәгән булып чыга. Кунакханә коридорында берничә тапкыр һәрнәрсәгә әзер торган, игътибарлы кыяфәттә очратты. Димәк, чынлап та, Шубарин искәрткән куркыныч булган? Бикхуҗаевлар тарафыннанмы? Кем белә, бәлки аны бик әһәмиятле мәгълүмат бирергә теләгән кешедән читләштерергә теләгәннәрдер? Ул очракта, кемнән? Прокурор Гадел Халитовтан түгелме? Алар бит теге чакта юньле-башлы аралаша да алмадылар, ә Ларисаны искә алу мәҗлесендә бер-берсенә якын килергә дә ирек бирмәделәр. Банкет залындагы кичне тагын бер кат башыннан уздырганнан соң, прокурор үзе өчен нәтиҗә ясады: әйе, Халитов чыннан да аңа нидер әйтергә, дөресрәге тапшырырга омтылган иде сыман. Шубарин системасын күрә алмаган Халитов элеккеге танышына нинди серне чишмәкче булды икән? Прокурор аның белән ничек булса да элемтәгә керергә уйлады. Бәлки аның кебек Халитов та Шубарин белән бәйләнешкә бердәнбер максат—аңа һөҗүм ясау өчен кергәндер? Тагын бер кат яхшылап уйларга, Халитовның Японнан курку сәбәбен ачыкларга кирәк. Әйе, Халитов кебек сер сыярдай кешен булса!—дип фикер йөртте Азлрханов, тик хәзергә ул бары үз көченә генә таяна алды.

Эш көне тәмамланыр алдыннан, Шубарин кабат юрист янына керде.

—Әйдәгез, минем кайту хөрмәтенә кичке ашны бергә ашыйк, берәттән әйбәт йөрсен дип, сәгатенне дә юарбыз,—дип тәкъдим кертте һәм, гадәтенчә,

җавап көтмәстән дәвам итте:—Мәскәүдән сез яраткан банкалы «Хейнекен» сырасы белән биш кило чамасы туңдырылган краб—диңгез кысласы алып кайттым. Икрам инде «Лидо»да, кичке ашны кайгырта. Картлачлар да киләчәк... Мин үз кешеләремнең һәрвакыт янәшәмдә, бигрәк тә бергә табын артында булуларын яратам, гаилә кебек димме.—Юристның суырылган йөзенә игътибарлы караш ташлап:—Әллә безнең самосуд борчыймы сезне, прокурор, кыяфәтегез шәптән күренми?—дип сорады.—Кызганыч, башка төрле үч алу юлын белмим. Мина калса, сездә психологик шок—миндә дә баштарак булды, аннары үзеннән-үзе иңләшәсең—зур эш нык нервлар таләп итә. Тукта, бәлки сезгә бер-ике атнага һава алмаштырыргадыр, бер очтан яхшы табибларга да күренерсез, ә? Берәр атнадан тире-тун цехы мөдире Гольдберг Мәскәүгә кирәкле кешеләрдән кайры тунга үлчәмнәр алырга бара, китегез шуның белән. Клиентлар белән таныштырыр, Мәскәү күрерсез, укыган чактагы дусларыгыз белән очрашырсыз. Урыныгыз «Советская» кунакханәсендә булыр, хосусый машина билгеләнер. Дөрес, Яков Наумович самолетта оча алмый, поездны ошата төшә, ике кешелек купе сезнең ихтыярда булыр. Менә дигән сәяхәт, шулай түгелме? Ничек? Ышандыра алдыммы?

Прокурор җанланып китте:

—Нигә, шәп идея.—Аның, чыннан да, аз гына вакытка булса да ялгыз калып, уйларын тәртипкә китерәсе килде.—Ышанмыйм, ниндидер бәла киләсен сизгән шикелле, төннәр буе йоклый алмыйм, әгәр янәшәмдә Коста булмаган булса, белмим, бөтенләй эштән чыккан булыр идем. Билгеле, әгәр Гольдберг каршы килмәсә, мин бик шат булыр идем, күптәннән Мәскәүдә булганым юк...

—Ә ни өчен ул каршы килергә тиеш әле? Юлда да, башкалада да вакытыгызны күңелле үткәрерсез дип уйлыйм. Сүз уңаенда, Яков Наумович МДУның философия факультетын тәмамлаган кеше, бик белемле, мин аның өендә еш булам. Ташкентта иң яхшы китапханәләрнең берсе, мөгаен, анардадыр, нинди генә сирәк китаплар юк...Килештек алайса. Юлга кирәкле бар нәрсәне әзерләрләр, тик бер үтенечем бар...—ул тавышын әкренәйтеп:—Беркемгә, хәтта Икрам Мәхмүтовичка да ләммим. Командировкагыз хакында китәсе көнегезнең алдагы кичендә үзем хәбәр итәрмен. Онытып язганмын, әгәр кыенсынмасагыз тагын бер үтенеч, монысы—шәхси,—дип кәчтүменең өске кесәсеннән кемнеңдер визит карточкасын чыгарды.—Язып алыгыз, зинһар: Кравцов Николай Федорович, эш телефоны... сез аның белән аспирантурада бер төркемдә укыгансыз. Аның белән элемтәләрегезне янартсагыз әйбәт булыр иде, ә аның аша башка курсташларыгызга чыгарсыз. Инглизләр нәрсә ди: кардәшлек бәйләнешләрен мәктәп галстугы ныграк берләштерә. Акча җәлләмәгез, яхшы ресторанда кичке аш оештырыгыз... Хәзергә менә шулар, алда күз күрер.

Шефы киткәннән соң, прокурор көтелмәгән тәкъдимне кабат башыннан үткәрде: Шубаринның уйлап эш итүенә инанды, әмма Кравцовның телефонын ашыгыбрак ибреп ташлады, шуның белән үз-үзен баштанаяк сатты. Ниһаять, ул Шубаринның ничек хәрәкәт итәсен сизенде һәм канатланып китте.

Кичке аш вакытында җаен китереп Шубариннан:

—Бер атнадан өй туе дип тора идем, хәзер нишләргә?—дип сорады. Артур Александрович, елмаеп, өстәлгә ымлады:

—Мәскәүдән минем шикелле тәм-том алып кайтасыз да үткәрәбез.

Шулай килештеләр дә, Шубарин календарьдан карап, барысына да өй туеның октябрьнең соңгы шимбәсендә булачагын хәбәр итте.

## 3

Мәскәүдә узган ике атна буе болытлы, янгырлы көннәр торды. Шубарин күз алдында тотканча, Яков Наумович белән юлда дуслашырга өлгерделәр, ни әйтсән дә өч көн аз вакыт түгел. «Үзбәкстан» фирма поездының ике кешелек купесында ашыкмый гына озын-озак әңгәмәләр корганда, икесенең берсе дә эшкә кагылмады. Прокурор вакыйгаларны ашыктырмаска карар кылса, Гольдбергнын сертотмас үрдәк хәлендә каласы килмәде, чөнки ул юлдашының эштә Японнан кала икенче кеше икәнен белә, алай гына да түгел әле, имеш-мимешләргә ышансаң, Шубарин белән Фәйзиев чын хужа түгел, Азлarханов барысыннан да өстен, фәлән кадәр—адәм ышанмаслык! өлеш анıкы икән. Гольдберг Шубаринны озак еллар белгәнгә, бу гайбәткә, билгеле, ышанмады, әмма үз гомерендә күпне күргәнгә, сак кыланып, эш турында сүз кузгатмаска тырышты—белмәссен!

Алар кояш батканда, саран дала табигатен күзәтеп, озаклап тәрәзә каршында басып тордылар. Прокурорның бу юлдан беренче узуы булса, Гольдберг өчен бар да таныш, шуна эшлекле сәфәрләре күнелле сәяхәтне хәтерләтте: яртысы диярлек балчык өйләрдән торган Шубаркубук, Челкар, Чиили, Кызыл-Орда, Арысь кебек колакка ятышсыз шәһәрләрдә тукталганда перронга чыктылар, саф һава суладылар...

Яков Наумович МДУда укыган чактагы илленче еллар Мәскәүен яхшы хәтерли: илле җидедә узган яшьләрнең бөтендөнья фестивале, беренче Мәскәү кинофестивале, Симона Синьоре, Иво Монтан, Жерар Филипплар килүе бүгенгедәй исендә. Мәскәү, аңа бәйле истәлекләр инде яшьләре гомер көзенә авышкан бу ике кешенең арасын тагын да якынайтты.

Кичләрен өстәл янында ашыкмый гына тәгам җыйганда, прокурорның Яков Наумовичтан, ныклы белеме булган һәм ике чит телдә яхшы аралаша алган кешенең нигә Мәскәүдән ерак китеп, шундый цехка китеп урнашуы турында сорашасы килеп теле кычытса да, вакытында тыелып кала белде. Сөйләндерә алган очракта да, үзенекенә охшаш тарих ишеткән булыр иде, мөгаен.

Купедашы белән никадәрле генә рәхәт булмасын, прокурор үз алдына куйган бурычлар турында да онытмады: һич уйламаганда Шубарин белән ачыктан-ачык йә булмаса яшерен рәвештә хезмәттәшлек итүче Мәскәүдә югары урыннарда утырган даирә белән танышу мөмкинлеге туды, аларның күбесен, бәлки, Яков Наумович якыннан беләдер. Аңарда шикләну тудырмаслык итеп, бу адәмнәр турында тулырак мәгълүматлар ала алсамы? Шул максат белән, соңгы араларда йөрәгенең борчып торуын сәбәп иткән булып, Гольдбергка «Советская» кунакханәсендә калдырылган берәр кешелек номерны ике кешелеккә алмаштырырга тәкъдим итте. Тегесе исә моны боерык кебек кабул күреп, шунда ук ризалыгын бирде; хәер, өч бүлмәле номер икесенә дә ошады.

Тәгәрмәчләр тукылдавын тынлап барганда, прокурор бер план корып өлгергән иде. Кунакханәнең бик матур ресторанында кичке аш янында, исе китмәгән кыяфәт чыгарып:

—Күптәннән Мәскәүдә булганым юк,—дип сүз башлады.—Үлчәм аласы кешеләрегезнең барысына йөреп, вакытымны әрәм итәсем килми. Зинһар, сезнең карашка иң «йогынтылы»ларының исемлеген төзегез дә шулары янына гына алып барырсыз, ә калган вакытымны үзем теләгәнчә үткәрермен, мина бит әле аерым бурыч та йөкләделәр.

—Ничек телисез,—дип җавап бирде Гольдберг.—Хужа сүзе—безнең өчен закон. Минемчә, андыйлары дистәдән артмыйдыр, калганнары, ничек дип әйтергә—урта катлам дипме, әмма алардан башка берни майтарып булмый.

Кичке аштан соң, номерга күтәрелделәр. Прокурор, үтенече турында оныткандай, душта коенырга юнәлде, ә тегесе исә телевизор кабызды. Юынып чыккач, Азлархәнов Гольдберг белән бергәләп телевизор карыйм дисә, тегесе кабинеттагы эш өстәле артында коленкор тышлы калын дәфтәрен актарып утыра иде. Юристны күргәч, ул җанланып китте:

—Аз гына сабыр итегез! Илле сигезенче үлчәмле бик дәрәҗәле бераү кайдадыр буталган. Хәзер табам да—исемлек әзер.

—Дәфтәрегезгә караганда, клиентларыгыз бер генә кайры тун белән калмаганнар, ахры?

—Төрлечә була, даими клиентлар да бар,—дип җавап бирде Яков Наумович, өстәлдән башын күтәрмичә.—Кызганыч, икесе үлде. Шәп кешеләр иде—зур түрәләр! Кайберләрен эшләрендә күтәрделәр йә икенче җиргә күчерделәр—андыйлары безне хәзер кызыксындырмый. Күпчелегенә—дөрес чамалагансыз—беренче генә тегүебез түгел. Ә менә кайда икән, таптым!—Аның тавышында шатлык сизелде.—Теге юлы аның берүзенә уникe тире китте, тагын да тазарды микәнни?—дип сөйләнә-сөйләнә, прокурорга исемлек сузды.

Прокурор шакмаклы дәфтәр битеннән күзен йөгерткәндәй итте дә, ялгызы калгач, игътибар белән карап чыгарга ниятләде.

—Бер атнада өлгерербез, шәт?

—Монарчы сыешып булмады,—Гольдберг бик теләп сүзгә кереште .—Алай ансат кына түгел шул ул. Үлчәм алыр өчен мина ун минут җитә, ә кайбер кабинет бусагасын узарга көннәр кирәк—йә киңәшмә, йә утырыш, йә көтмәгәндә министрлар Советына йә булмаса ҮКка чакыртып алганнар... Икенче берсен ресторанга чакырырга мәҗбүрбез, ә үлчәмен номерда алырга туры килә. Өченчесенең, күчтәнәчләр күтәреп, өенә барабыз. Башыгызны әллә нинди уйлар белән катырмагыз, бүген тынычлап ял итик тә, иртәгә иртән барысын да хәл итәрбез.

Сәфәрне уңышлы, хәтта бик уңышлы дип санарга була. Номердагы күршесе иртәнге телефон трубкасына ябышкан хәлдә башлап җибәрә, клиентларның адреслары һәм телефоннары язылган калын дәфтәр көннәр буе язу өстәлендә ята, ул бары тик кунаклар килгәндә генә күз уңыннан югала. Яков Наумович әйтмешли, мондый «егетләр мәҗлесләре»ндә кемнәрне генә күрмәде прокурор. Кайбер кунакларның Шубарин үзенә бүләк иткән кебек сәгать тактанын күреп: «Артур Александрович бүләге түгелме ?»—дип сорамый чак түзде. Әлбәттә, ялгышырга да мөмкин: монда, Мәскәүдә, Шубарин кебекләр җитәрлектер, андыйлар дефицитның уртасында кайнашадыр, илнең матди байлыклары белән идарә итә торгандыр, аларның бер ымыннан төбәк һәм тармакларның язмышы хәл ителергә мөмкин. Юк, бирсдә Шубарин сөрмәгән, чәчмәгән, ә уңышларын җыйнап алган.

Бу мәртәбәле кунакларның кунакханә ресторанына іяләшкәннәре күренеп тора: үзләрен бик иркен тоттылар, туйганчы ашадылар-эчтеләр. Мондый мәҗлесләрдән соң, прокурор ялгызы гына калып, теге калын дәфтәрдән үзенең кесә дәфтәренә күчкән адрес һәм телефоннар янына ниндидер мәгълүматлар терки барды.

Яков Наумович белән бергә кайбер югары түрәләрнең кабинетларында да булырга туры килде. Әгәр сабыр савыты тулып ташымаса, прокурор аларның һәрберсе белән очрашып чыга ала иде—тик кирәксенмәде. Шуңлыктан, кичектерелгән кабул итүләрне көтәргә чиктән тыш түзем Яков Наумовичка калдырып, яңгырлы урамга чыгып китте. Чираттагы ришвәтченең кайда утырганын белде—шул җитте.

Иң куандырганы: Шубарин очрашырга кыстаган Кравцов ялга киткән

булып чыкты. Ул Мәскәү районнарының берсенә прокурор булып урнашкан икән.

Эш белән матавыкланып, өй туе турында бөтенләй онытып җибәргән. Мехчы коткарды... Очрашырга вакыт табалмаган ике-өч эшем иясенең генә үлчәмен аласы калды. Беркөнне кичен Яков Наумович гадәттәгечә, тартмалар, төргәкләргә уралып кайтып керде. «Кунакханәдә үлчәмнәре алынганнарның берсе дә буш кул белән китәргә тиеш түгел—бу күптәннән килгән йола»,—дип, башта ук аңлатып куйган иде ул. Һәрберсенә коньяк йә кыйбатлы виски җыелмасы, кило ярым сыя торган банка белән икра, яхшы казылык һәм башка деликатеслар бирделәр. Әйберләрне суыткычка урнаштырганда, Гольдберг сорап куйды:

—Ә сезнең өй туегызга кайчан алабыз?

Прокурор каушап калмады—онытуын яшереп:

—Кичерегез, эшләрегез беткәч, үзегез хәл итәрсез, дип уйлаган идем,—диде.—Иртәгә үк барырга риза, нәрсәләр алырга кирәген дә әйтерсез, мин деликатесларда бик аермыйм.

—Уйлап-нитеп торасы юк, Артур Александрович аласы әйберләрнең исемлеген бирде, ә инде шеф тарафыннан искәртелми калган берәр затлы нәрсә килеп чыга калса, складта бездән башка да өстәрләр—андагылар Шубаринның зәвыгын беләләр.

Поездда кайтыр юлга чыккач, прокурор эченнән генә тагын бер кат очарга яратмавы өчен Яков Наумовичка рәхмәт укыды—озын юл ана нинди карарга килерен ачыкларга мөмкинлек бирәчәк. Янә дә сузуның мәгънәсе юк: хәзер, Мәскәү элемтәләрен ачыклагач, күп нәрсәгә күзе ачылды, айсбергның кай тарафына һөҗүм башласын тәгаенләде. Аңа бер-ике көн җитә: тынычлап кәгазьләрне тәртипкә китерергә һәм идарәнең иске еллык хисабыннан «күктән алынган» фамилияләргә хезмәт хакы түләнгән серле ведомостьне алырга да Ташкентка, ә бәлкем Мәскәүгәдер китеп югалырга. Ул башкалага Костасыз гына җибәрүләреннән Шубаринның үзенә ышанганын белде. Хәер, аның артыннан анда да күзәтергә мөмкиннәр бит; тик ресторанда да, урамда йөргәндә дә артыннан «койрык» ияргәнен сизмәде. Дөресрәге, сәбәп табылырлык итмәде, чөнки үзен кызыксындырган адәмнәрне ачыклау өчен кунакханә бусагасын атлап чыгасы булмады: күршесенең теге калын дәфтәреннән күчереп алды. Инде югалыр вакытын гына билгелисе калды: икенең берсе—йә өй туена кадәр, йә шимбә—кунаклар киләсе көнне.

Их, булсын иде аның бер ярдәмчесе йә сер сыяр кешесе! Ул аны Ташкентка, һичьюгы алдан билет хәстәрен күреп, аэропортка илткән булыр иде. Хәтер сандыгында күпме генә актарынмасын, андый кеше табылмады. Хәер, аның һәр адымы күзәтү астында, икенче берәүнең юрист янында кайнашуы тегеләрдә, мөгаен, шик уятыр иде.

Тагын юл коткарды... Тәгәрмәчләрнең тигез генә тукылдавын тыңлап барганда, хәтеренә келт итеп Костаның әйткәннәре төште: ул Чураевның хәзер подполковник булуы, Ташкентның бер районында җинаятьчеләрне эзләү бүлеген җитәкләве турында ычкындырган иде. Ни өчен? Чөнки аның узган елгы камерадашын Чураев шәхсән үзе ниндидер яшерен «хата»да эләктергән икән. «Дустыгыз әфсенләнгән, ахры,—дип шаяртырга маташты ул күңелсез генә,—аны пуля да, пычак та алмый. Ничә тапкырлар һөҗүмгә дучар булды, аның урынында башка берәү күптән бу эшен ташлаган булыр иде, ә бу—юк, киресенчә, тагын да усаллана, хәйләкәрләнә генә бара».

Бәлки, мөмкинлек чыгу белән капитан Чураев белән бәйләнешкә керергәдер? Машинасы белән «Лас-Вегас»ның берәр аулак почмагына чакырыргадыр? Никадәр тырышсалар да, аны Чураев кулыннан тартып ала алмаслар, бәлки? Капитан белән бер сүздән үк аңлашырлар һәм ул мөмкин

булган барлык саклану чараларын күрер, чөнки элеккеге прокурорның юк-барга тавыш куптарып, буяуларны куертып маташмавын белә: алар жилкәсендә күпме бергә башкарылган эшләр мона дәлил. «Нишләп, бу да бер вариант,—дип нәтижә ясады ул.—Әгәр тыныч кына качып югала алмаганда, вакытны отарга менә дигән очрак».

Ташкентка иртән килеп төштеләр. Аларны перронда Ашот каршы алды. Вокзал каршындагы мәйданга чыгып, шәхси машиналар тукталышындагы халык төркеме уратып алган ак «мерседес» янына килделәр.

Кузгалып киткәч, Яков Наумович:

—Синен кебек жилле кешегә Икрам «матуркаен» ничек ышанып тапшырды икән?—дип төрттереп куйды.

—Тапшырды, ди,—Ашот йөзен чытты.—Сезне каршыларга шеф аның үзен жибәрде, ә мин кирәге-чыга калса дип озата барырга тиеш булдым. Ул Дәүләт планына бер генә минутка дип кереп киткән иде—тиз генә очына чыгарлык булмады, ахры, вакыт кыскач, вокзалга мине жибәрде; хәзер аны кереп алабыз да—туп-туры өйгә. Ә машина—класс, кәртчеләр Икрамга капчык-капчык акча тәкъдим итәләр, тегенен мыек очы да селкенми. Аңа акча нәрсәгә, үзенекен дә кая куярга белми ич ул. Акча туплап бетерүгә, Артур Александрович миңа да табып бирергә ышандырды.

Икрам Мәхмүтович аларны баскыч төбендә көтеп тора иде инде, шунда ук руль артына кереп утырды. Шәһәр читенә чыгуга, спидометр уклары 120-140 тирәсендә уйнаклый башлады. Яков Наумович куркуыннан:

—Сез Ашотны да уздырасыз икән,—дип мыгырданып куйды.

Фәйзиев, авызын ерып, жавап бирде:

—Мондый машина белән «Жигули»ларга тагылу—хурлык, өстәвенә табынга ашыгам. Мәскәүдә хәтерегезне югалтмаган булсагыз, шефның соңга калуны өнәмәве исегездәдер.

Ашот Фәйзиев тавышына охшатып өстәп куйды:

—Төшке аш—изге эш...

Дәррәү көлеп жибәрделәр: Икрам теләсә нәрсәне үткәреп жибәрә ала—тик табынны гына түгел,—моны барысы да беләләр иде.

Нәкъ вакытында «Лидо»га килеп туктадылар. Шубарин белән Коста подъезд төбенә чыгып басканнар гына иде.

Юлчылар Артур Александрович белән тегесе-монысы турында сүз алышкан арада, Коста белән Ашот чемодан, сумка, тартмаларны өскә ташып, машинаны ресторан ишегалдына кертеп урнаштырдылар.

Өстәл тирәли тезелешкәндә, галәттәгечә шәһәр курантлары көндезге икене сукты.

Юрист белән сөйләшүне икәүдән-икәүгә калдырды, ахры, Шубарин күбрәк Гольдбергтан сорашты.

Гомер булмаганны Шубарин үзе сорап, Адиктан шампан шәрабе китертте, аның моңарчы көн уртасында алай иркенләгәнен күргәннәре юк иде.

—Барыгызны бер өстәл янында күрүемә шатмын. Үзегез беләсез, соңгы атналарда хәтта баш кашырга да вакыт тимәде. Табын турында әйтәсе дә юк, югыйсә, жыелыр сәбәпләр житәрлек иде...Узган атнада өченче квартал нәтижәләре буенча ике күчмә Кызыл байрак алдык—берсе өлкәнеке, икенчесе республиканыкы. Кеше эш белән генә яшәргә тиеш түгел, шуна сезнең исән-имин әйләнеп кайтуыгызны игътибарсыз калдырырга тиеш түгелбез. Әйдәгез, кичен банкет залына жыелып, ике вакыйганы бергә билгеләп үтик. Кичке сигезләргә әзерләп өлгертерләр микән?

Фәйзиев, авызындагы ризыгын иренеп кенә әйләндергәләп:

—Булыр, монысын үз өстемә алам,—диде.

—Килештек алайса.—Һәм Гольдбергка борылып сорады:—безнен

мәскәүлеләр дә буш кул белән кайтмаганнардыр дип ышанам?

Яков Наумович җөпләргә ашыкты:

—Әлбәттә, әлбәттә. Өй туена да, бүгенге кичкә дә җитәрлек. Йоланы онытмадым: Мәскәүдән соң—мәҗлес.

## 4

Төшке аштан соң Артур Александрович Гольдбергны алып цехка китте. Анда аларның кичектермәслек эшләре бар иде, ә прокурор кунакханәдә калды. Кузгалыр алдыннан Шубарин сәфәр турында шушы көннәрдә аулакта сөйләшәчәкләрен әйтте. Прокурор бүлмәсенә күтәрелде, номер яхшылап җыештырылган, җилләтелгән, өстәл өстенә тере чәчәкләр һәм җиләк-җимеш куелган. Бүлмә буйлап ишекле-түрле атлаганда, үзе дә сизмәстән суыткыч ишегенә орынды, ачып карагач, Адикны аның кайтуы турында кисәтүләрен аңлады. Әйе, Шубарин үзенең якыннарына игътибарсыз дип, берәү дә авызын ача алмас.

Ул зур итеп уелган тәрәзә каршына килеп басты, менә хәзер идарәгә барырга да юлда карар кылганча тизрәк кәгазьләргә күмелергә иде дә—ярамый: аның эшкә дәрте кемнедер сагайтырга мөмкин... Уйлары бүген булачак банкетка күчте. Ул кичәдә Ким белән Георгадиның булуларын теләде. Җаен туры китереп, һәрберсенә берничә сорау бирәсе бар, эштә андый сорауларны кузгатып булмый. Өстәвенә мондый җилле мәҗлесләрдән соң, картлар бер-ике көн баш күтәрә алмый өйләрендә яталар. Бу ике көн аның өчен бик озын—чөнки бухгалтериядә дә, план бүлегендәгеләр дә юристның һәрдаим теге яки бу документны таләп итүенә күнеккәннәр иде инде.

Юлдан кайткан килеш, кичен авырга туры киләчәк, әмма прокурор, тәне ял сорауга карамастан, бер генә минутка да җебеп төшәргә ярамаганлыгын яхшы аңлады. Чишелешнең якынлашуы аның тынычлыгын алды, йөрәге генә түгел, нервлары да чыгымлый башлады, ә бит монарчы ул үзен кулда тота алам дип саный иде. Ахырына життем дигәндә генә, ниндидер вак-төяктә абынуны күз алдына да китереп булмый, монда кечкенә генә хатаны да кичермиләр.

«Кызык, бүгенге кичке ашта Гадел Халитов булыр микән?»—дигән уй чагылып үтте аның башыннан. Ничек кенә үзенең дә аның белән очрашырга теләвен искәртергә икән? Бүген дә аларны күзгә-күз очраштырмас өчен бар тырышлыкларын куярлар микән? Кинәт башына суккан фикердән катып калгандай булды. Өстәл артына утырып кыска гына язу сырлады: «Миңа калса, сезнең миңа әйтер сүзегез бар бугай?» Ничек тапшырасын да тәгаенләде: очрашкан вакытта аның бердәнбер кочаклашып күрешкән кешесе—Халитов, калганы шул чакта башкарылыр. Тотыла калганда, язуда коточарлык сәбәп юк, ничек җавап бирәсен дә уйлап куйды. Ә уныш елмайса, Халитов белән икесенең бер сүздә икәнлеге аңлашылыр. Бу карары прокурорны җилкендереп җибәрде: ул Халитовның ярдәменә ышана алачак иде. Кичкә кадәр шундый уй-мәшәкатьләр белән ял итү теләге барып чыкмады. Сөйләшенгән вакытта ишек шакыдылар. Прокурор язуын кәчтүм кесәсенә тыга-тыга, ачарга ашыкты. Бусагада Коста басып тора иде, бәйрәмчә киенүеннән аның да чакырулы икәне кычкырып тора.

Бүген банкет залында кеше күбрәк, почмакта торган ике байракмы, әллә алар янына биек вазаларга куелган чәчәкләр аркасында микән, рәсмирәк тә тоелды юристка. «Болары, мөгаен, идарәнең тантаналы очракларында гына кулланыладыр»,—дип уйлады прокурор. Күзләре белән кунакларны айкап чыкты, әмма Халитов күренмәде.

Аның каравы, чакырылучылар арасында өлкә комитеты профсоюз хезмәткәрләре, шәһәр комитеты һәм шәһәр башкарма комитетыннан

килүчеләр житәрлек иде. Артур Александрович, сылтау табып, ачыктан-ачык шәхси мәнфәгатьләрен житештерүнеке белән бәйләп, урта катлам түрәләрен бай табын янына берләштергән.

Өстәлдә теге көнге затлы кашыгаяк урынын кыйммәтле эчемлекләр белән затлы кабымлыклар алган. Шубарин «Лас-Вегас» аппаратчыларының аппетитын яхшы белә, күрәсен. Гомумән, ул бервакытта да мәҗлес өчен акча жәлләмәде, бүгенге табынга куелган Мәскәү деликатеслары аеруча күренеп, табын артындагы тук чырайларны үзенә тартып тора иде.

Артур Александрович, гадәтенчә, түрдәге кәнәфигә чумды һәм беренче сүзне профсоюз кешесенә тапшырды, аннары китте: берсеннән-берсе йокыны китерерлек күнелсез тостлар бер түрәдән икенчесенә күчә барды. Кеше каршына басып, кызыл имән трибуналардан сөйләп шомарып беткән бу адәмнәрнен катып калган коры телләре прокурорны шаккатырды. Шул ук вакытта өстәл артындагы кайберәүләрнең очкын чәчеп торган күзләреннән: «Әйтеп карый бу, их, ничек шуның кебек оста телле булырга!»,—дигән кебегрәк фикерне укып була иде. Ул үзе өчен ачыш ясады—бу провинция түрәләре, номенклатур хезмәткәрләргә хас сөйләм теле—бары шул очракта гына алар кебекләр нәрсәгә булса дәгъва кыла алалар. Үзенен шундый ачышыннан соң күнеле күтәрелеп киткән прокурор игътибарын чираттагы күпертелгән буш сүзле нотыкка юнәлтте.

Артык түзә алмыйча, ул күршесенен колагына пышылдады:

—Сез театрыгызда нидер үзгәрттегезме әллә, бер генә артистка сүз биреп, калганнарын массовкада кулланырга уйлыйсызмы? Тик барып чыкмас—монда камера театрынын исе дә юк.

Шубарин чыгышларнын жирле сәнгать житәкчесе белән анын тугрылыклы ярдәмчесенә дан жырлаудан ерак китмәгәнен үзе дә аңлый; дөрес, кайбер алдан күрүчән тәлинкә тотарга яратучылары юристконсультантка да исәнлек-саулык юлларга онытмадылар.

Шулай бер-берсен юатып, үзара сүз алышкалап утыра торгач, кинәт Артур Александрович күнелле генә йомгаклап куйды:

—Сөйләнсеннәр әйдә... нишләтәсен, зур коллективның унышына катышлары бар төсле, шәп табын янында нотык тотарга ярата инде алар. Үзләрен томанда юл күрсәтүче, ягъни койрыкчылар дип күз алдына китерәләр. Кичә ахырында йола буенча Икрам һәрберсенә конверт өләшәсен, ә аны мактаганда башкалардан арттырып жибәргәннәренә үз кесәсеннән өстисен беләләр алар. Хәер, борчылырлык сәбәп күрмим, берәр сәгатьтән Мәскәүдән кайткан яхшы аракыны өч-дүрт чәркә жибәрсәләр, сезнен белән минем эзгә төшәчәкләр, бөтенләй онытып бетермәгән булсалар—кешечә сөйләшә башлаячаклар.

Дөрестән дә, бер сәгать уздымы-юкмы, вино һәм аракы үзенекен эшләде: аларның түрәлек дәрте сүнеп, кызыл сүзләре каядыр китеп югалды, сүз дилбегәсе дә башкаларга күчте. Бу юлы, идарәнең тыйнак хезмәтчәннәре дигән булып, хәтта Коста белән Ашотка да сүз бирелде.

Мәҗлес жанланганнан-жанлана барды, табын янында шау-гөр килделәр, көлеш-шаярыш башланды.

Бу юлы дәрәҗәгә бүлеп-нитеп тормадылар, кем кайда эләкте—шунда утырдылар, хәзер, кызып алгач, бигрәк тә—ата улны, ана кызны белмәгәндәй, тәмам буталышып беттеләр. Ким белән Георгадидан үзен кызыксындырган сорауларына жавап алган һәм Халитовнын килмәсенә ышанган прокурор, арыганлыгын сылтау итеп Шубарин белән саубуллашырга ниятләп торганда, Адик килде дә шыпырт кына шефка Бохарадан Беренче үзе телефон аша элемтәгә чыгарга кушуы турында хәбәр итте. Шубарин гажәпләнде һәм, дулкынлануын яшерә алмыйча, Азлархановтан китми торуын үтенде:

—Нәрсәдер булган, ахры, бәлки ярдәмегез кирәк булыр. Беренче тикмәгә генә мине кунакханәләрдән эзләтә торган кеше түгел.

Шул китүеннән Шубарин башка күренмәде. Ун минутлар узды микән, Адик юристны читкә дәшеп, өченче катка күтәрелүен сорады.

Шубарин, нервланып, үзенең иркен бүлмәсенең аркылысын буйга инли—сүзсез дә анлашыла: чыгырдан чыгарырлык нидер булган. Әмма юристконсультантны күрүгә, үзен кулга алып өлгерде—ул беркайчан беркемгә көчсезлеген сиздерергә яратмады.

—Әйе, чынлап та Үзе шалтыратты, зур бәла. Берәр сәгать элек Хәрәзмдә ҮКның беренче секретаре үлгән...

—Булмас, мин әле сигезенче яртыда гына телевизордан яналыклар программасын карадым, андый хәбәр булмады.

Шубарин катгый рәвештә аны бүлдерде:

—Тагын өч көн дәвамында бернинди мәгълүмат булмаячак. Сез ни әйткәнегезне ишетәсезме? Политбюро әгъзалыгына кандидат, көчлеләрдән саналган республика хуҗасы үлгән. Аны соңгы юлга озату белән бергә иң мөһиме—чираттан тыш пленумга әзерләнергә кирәк: аның урынын кем алыр? Моны беренчеләрдән булып кисәткәннәр, ахры, яратканнар рәтендә санала бит. Менә хәзер тиресенә сыеша алмый: бу урынны әләктерү максатыннан ярдәм итәрлек ышанычлы кешеләрен барлый.

Прокурор үз колакларына үзе ышанмыйча, кабатлап сорады:

—ҮКның беренче секретаре урынын?

—Ә нигә? Ул нык-таза өлкә белән җитәкчелек итә... аннары кайчан да булса республика хуҗасы булу теләген миннән яшергәне булмады. Көтмәгәндә эләккән мөмкинлекне нигә кулдан ычкындырырга? Мин өч сәгатьтән Бохарада булырга тиешмен, инде аэропортта самолет көтеп тора. Ул әйткәнчә, шушындый җаваплы сәгатьләрдә иң ышанычлы, тугрылыклы кешеләре аның янәшәсендә булырга тиеш. Үтенечем бар иде, идарәгә барып, кабинеттагы сейфны ачыгыз, анда сезгә таныш «кейс»бар, шуна акча тутырыгыз да тиз генә әйләнеп кайтыгыз. Ә мин Ташкентка шалтыратып алам, уйларымны тәртипкә китерәсе бар. Менә ачкычлар, аста машинада Ашот көтеп тора.

Прокурор, вакыйгаларны анларга тырышып, ашыкмый гына аска төште. Кабызып куелган машина, прокурор артыннан ишек ябылыр-ябылмас, урыныннан кузгалып китте. Күрәсең, Ашот та булган хәлләрдән хәбәрдар булса кирәк. Алар тиз генә идарәнең икенче катына күтәрелделәр.Шофер кабул итү бүлмәсендә калды, ә ул, соңгы минутка кадәр сейф һәм акча белән бәйле нинидер этлекне күзаллаган хәлдә, кабинетка юнәлде. Тик бар да Шубарин әйткәнчә булды. Сейфтагы буш «дипломат»ка сыйган кадәр йөзлекләрдән торган төргәкләрне дыңгычлады да үзен көтеп торган Ашот янына чыкты. Сүзсез-нисез генә аска төшеп киттеләр. Сәфәрләре ун минутка сыешты.

Алар номерга кергәндә, хуҗа чемоданына күлмәкләр салып тора иде, булган хәлләрдән әле дә аңына килә алмый аптырап басып торган прокурор кулындагы «дипломат»ка күз дә салмады.

—Рәхмәт,—диде ул үткән-сүткән арада,—әнә, диванга ыргытыгыз, сезгә авыр күтәрергә ярамый.—Чемоданының биген чертләтеп япты да:—Менә мин әзер дә,—диде.—Әгәр тагын акча кирәк булса, шылтыратырмын. Сейф ачкычы сездә калып торсын. Акчага йә Коста, йә Ашот кайтыр. Әйдәгез, саубуллашыйк, безгә уңыш елмая калса, киләсе елга министр урындыгы сезнең карамакта дип исәпләгез. Коста һәм Ашотны үзем белән алам, кирәкләре булуы бар, бәлки кадерле Беренчебезнең елдам көндәшләрен урыннарына утыртасы булыр, кем белә?—Артур Александрович тагын бер кат хушлашып, номердан чыгып китте.

Прокурор «Волга» кузгалып китүгә, ашыкмый гына, Шубарин белән

килешенгәнчә, банкет залына юнәлде. Хәбәрне хәтта Икрам да белергә тиеш түгел иде.

Ике сәгатьләр узгач, мәҗлесне Икрам җитәкчелегендә тагын кайдадыр дәвам итәргә тиешле кунаклар белән саубуллашып, прокурор, ниһаять, бүлмәсенә кайтты. Ут алынмаган караңгы номерында бик озак тәрәз каршында басып торды. Аста, кызып алган кунаклар «Лидо» каршында торган «мерседес»ка төялеп маташа, аларның шау-шулары дүртенче катка кадәр ишетелә, әмма ул боларга игътибар да итмәде: аның уйлары башкада иде.

«Бохаралының бүген үз өмете, минем—үземнеке!». Язмыш шаяруымы: теге—ҮКның беренче секретаре урынын дәгъва кыла, ә прокурор кулындагы документлары ярдәмендә, Беренче ин югары җәзага лаек булса да, аңа төрмә ятагы гарантияли алмый.

Бүгенге уй-кичерешләрдән башы түнгән прокурор йокларга ятты. Иртәгесен, тәнендә җинеллек сизгән хәлдә, гадәттәгедән сонрак уянды. Хәтта душ кергәндә күптән хәтердән сызылган кебек тоелган көйгә сызгыргалады.

Иртәнге ашта Икрам Мәхмүтович күренмәде, мөгаен, кичәгедән башы авыртадыр, төшсез күренмәс тә. Фәйзиевне очратмавы яхшы булды, Шубаринның истә-оста юкта чыгып югалу сәбәбен аңлатып торасы булмады; чын сәбәпләрне ачаргамы-юкмы—әлегә хәл итеп өлгермәде.

Юл унаенда универмагка кереп, Японныкы кебек үк булмаса да ярыйсы гына «дипломат» алып йөргәнгә, эшенә чак кына соңга калды. Күз алдына китергәнчә, Ким да, Георгади да эшкә чыкмаганнар, һәм ул, кабинетына узу белән, бухгалтериянең элекке хисап төпләмәләрен китерергә кушты. Үзен кызыксындырган ведомостьларның кайсы папкаларда ятканын тәгаен белә, аларны тиз генә эзләп тапты да, күчереп вакыт әрәм итмәс өчен, пөхтә генә кисеп алып, «дипломат»ындагы юридик тикшерүләре теркәлгән язулары янына сала барды.

«Дипломат» күз ачып йомганчы алдан билгеләп куелган төрле кәгазьләр, күчермәләр, боерыклар белән шыплап тулды. Өстәл өстендә актарынганда кулы әлегә юньләп файдаланырга өлгермәгән диктофонына кагылды. Адәм заты юклыктан файдаланып, диктофонга яңа кассета куйды да, ашыкмый-кабаланмый, хатынын тартып алган теге август көненнән соңгы биш елда күргәннәрен, кичергәннәрен сөйләргә тотынды.Туксан минут үткәне сизелмәде дә, ул әле үзен Бикхуҗаевлар прокурорлыктан читләштергән өлкә комитеты бюросына да барып җитә алмады. Сәгать икегә кадәр тагын бер кассета яздырырга өлгерде, анысында «Лас-Вегас»тагы вакыйгалар яктыртылса да, Шубарин белән танышу сыймады.

Вакыты-вакыты белән ул диктофонын сүндереп, уйга чумды: кая качарга? Мәскәүгәме, әллә Ташкенткамы? Тик җавапны әлегә таба алмады. Җәяүләп кенә «Лидо»га—төшке ашка китте. Икрам өстәл артында Шубаринны көтеп утыра иде, әмма ялгызы гына, өстәвенә шактый соңарып килгән юристны күрүгә сорамый түзә алмады:

—Кичә Япон үзенең башкисәрләре белән кая китеп югалды икән?

Бәйрәмнән әле яңа айнып килгән Фәйзиевка текәлеп, аңа серне чишүдән мәгънә барын чамалады, чөнки ул очракта прокурор аңардан кичкә кадәр котылып торасына өметләнде—артыгы кирәк тә түгел иде.

—Туктагыз, башта аңлатыгыз әле, кайда югалып йөрисез? Сезгә кичекмәс хәбәрем бар.

—Нинди яңалык? Эш нидә?—дип сорады ул, башын эшләтергә тырышып.

—Яңалык аяктан егарлык, башта үзегезне кулга алыгыз. Кичә сәфәре вакытында республика ҮКның беренче секретаре Хәрәзмдә вафат булган...

—Ничек вафат булган?—Фәйзиев урыныннан сикереп торды.

—Утырыгыз. Беренчедән, кычкырмагыз. Бу—әлегә сер. Үлемсез кешеләр булмый—инфаркт, диделәр.

—Хәзер аңлашылды, Шубарин шунда тайган икән!—Фәйзиевның ачудан йөзе кыйшады.—Бохарага элдерткән! Мөгаен, дан-шөһрәткә мөкиббән Бохара карсагының мөмкинлекне кулдан ычкындырмаскадыр исәбе, Шубаринның мафиясе белән шуңа кирәге чыккандыр.—Ул кулы белән маңгаена бәреп чыккан тирен сыпырып төшерде.—Ә безнең исәрләр берни белми иртәдән бирле баш төзәтәләр. Хайваннар, аларга тыгынырга гына булсын! Рәхмәт, Әмирхан Даутович, эчкерсез кеше икәнсез, мин Японның миңа әйтмәскә кушканын чамалыйм. Ә хәзер миңа ашыгырга кирәк, болай да унбишләп сәгатьне югалттык, ярар, бохаралыга караганда без Ташкентка якынрак.—Фәйзиев шунда ук айнып китте һәм аягына баскач:

—Әгәр ота калсак, сезнең хезмәт күрсәтүегезне беркайчан да истән чыгармабыз,—дип өстәде.

«Республикада хәзер нинди ыгы-зыгы купкандыр! Бикхуҗаевлар, Фәйзиевлар кым-кырыч килә, тагын бохаралылар күпме?» Прокурорның бу мәсьәләдә артыгын җәелләсе килмәде. Төшке аштан соң идарәгә барышлый, кирәге чыга калса дип, тагын ике кассета сатып алды. Эш көне тәмамланып килгәндә, болары да тулды, аларында инде ҮК секретареның үлеме турындагы хәбәрне дә кертеп, бар да сыеп бетте.

Китешли, сәркатип саубуллашып чыкты, ә прокурорның кунакханәгә кайтыр исәбе юк, кичкә анарда өр-яңа план туып өлгерде. Тик аны Шубаринның тугрылыклы ярдәмчесе Татьяна Сергеевна китмичә, тормышка ашырып булмый. Идарәдә аяк тавышлары тынып калуга, прокурор кабул итү бүлмәсен бикләде дә Артур Александрович бүлмәсенә керде. Кичә,«дипломат»ка акча тутырып маташканда, күзе сейфтагы нindидер кәгазьләргә төшкән иде; бәлки аларда ана мәгълүм булмаган серләр яшеренеп ятадыр? Беренче папкада ук бик зур суммаларга распискалар тапты—бәлки, таныш булмаган бу фамилияләр аның алда торган тикшерүләренә кирәк булыр? Калганнарында да шактый гына кызыклы мәгълүматлар чагылды, тик иркенләп актарырга вакыты кысан булганга, җентекле танышуны соңгарак калдырды һәм кирәкле санаган кәгазьләрне «дипломат»ына шудырды. Сейфны бикләгәндә, акчалар турында исенә төшерде һәм, ялган эзгә кертеп җибәрү өчен, алардан файдаланырга карар кылды: әйдә, комсызланып, прокурор урлаган дип уйласыннар. Берничә урауда сейфтагы акчаларны үзенекенә күчереп бетерде дә, кабинетын игътибар белән күзәтеп чыкканнан соң, аска төшеп китте: ул башка монда кайтмаячак.

Кичен, Адикның гаҗәпләнүенә, «Лидо»да тамак ялгап алгач, «Лас-Вегас»тагы соңгы сәйранына чыкты. Кайсы хакимияткә мөрәҗәгать итәсен уйлый-уйлый, Шанхайга кадәр барып җитте: әмма кайсы яктан карасаң да, икесендә дә «яклап» һәм «каршы» тавышлар җитәрлек иде. Кунакханәгә кайткач та бик озак уйланды. Юлга хәстәрләнәсе юк, чөнки кулындагы артык әйбер теләсә кайсының игътибарын җәлеп итәргә мөмкин. Кичке акыл иртәнгә ярамый, дигән мәкальгә таянып, прокурор хәлиткеч карар кабул итүне иртәнге якка калдырды.

Төн уртасында аны шәһәрара шылтырау уятты. Прокурор бик озак исен җыя алмады, трубкада Шубарин иде. Гадәттәгечә үзен тыныч тотып, башта юристның сәламәтлеге турында сорашты, Фәйзиев ниләр кылуы белән кызыксынды, аннары гына тынлап торучылар булса, аңламаслык итеп төп эшкә күчте. Ул Костаның иртәгә төш авышкач туры эшкә кайтасын әйтте, ә үзенең сәфәрдән кайчан кайтасын төгәл генә әйтә алмады: «Мин монда кирәк әле»,—диде дә саубуллаштылар.

«Димәк, тагын акча кирәк булган». Гажәп: шылтырау да, Шубарин да аны дулкынландыра алмады—ул шунда ук йокыга талды.

Гадәттәгедән иртәрәк торып, коенып чыккач, күнегүләр ясап алды, әмма башында бер генә уй—кая?

Ниһаять, чыгу юлын тапты кебек: башта Ташкентка барырга, анда күз күрер. Ресторан ачылырга әле ярты сәгатьләп бар, иртәнге ашка вакытын әрәм итеп тормаска булды һәм «дипломат»ын тотып аска төште. Подъезд каршында ун минутлап уйланып торгач, тыкрыклар аша ашыкмый гына автостанциягә юнәлде. Артында «койрык» күренмәде шикелле.

Ташкентка йөрүче шәһәрара автобусларның барысы да «Лас-Вегас»та туктала, монысы да Шубаринның тырышлыгы нәтиҗәсе—сатып алучылар ташкынын кулыннан ычкындырмас өчен эшләде ул аны. Хәзер прокурорның максаты—үтә сак кыланырга, күзгә-башка чалынмаска, чөнки мондагыларның күпчелеге аны йөзгә танып белә. Шуңа да иртә таннан гөжләп торган автовокзалга якынлашканда, башында бер план өлгереп житте. Узгынчы машиналар мәйданның теләсә кайсы урынында тукталалар, нинди дер тәртип турында уйлыйсы да юк. Ана ин яхшысы: төрле вак-төяк сата торган киоск янына килеп туктаячак автобусны көтү һәм кузгалам дигәндә генә килеп утыру. Андый уныш анарга унбиш минуттан елмайды, ул кузгала башлаган «Икарус»ның баскычына сикерде. Автобус ерактан—Каршидан ук килә икән, буш урын караштырып салон буйлап узганда таныш чырайлар очрамады—бу аның сулкылдап торган күңелен тынычландырып җибәрде. Тиз йөрешле автобус Каршидан бик иртә чыкканга, юлчыларның күбесе, башларын артка ташлап, йокыга чумган, озакламый ул үзе дә изрәп китте. Өрөзлексез: »Кая?»—дигән сорау борчыгангадыр инде, төшенә Мәскәү шәһәре керде. Элеккеге «Яра»ның купшы залы, имеш, чегәннәр, ә өстәл янында Гольдберг белән янәшә утырган яхшы тройка костюмлы, муенына озын алтын чылбыр таккан Шубаринның бабасы Артур Александровичка усал тавыш белән нидер сөйли. Ә бәйрәмчә ак костюм кигән Япон артында, кулларын кесәләренә тыгып, Коста белән Ашот басып торалар, имеш. Чыгу юлына якын гына өстәлдә Николай Федорович Кравцов утыра, аның янында Мәскәүдә кайчандыр бергә аспирантура тәмамлаган берничә иптәше дә бар, имеш. Төшендә аларның инде онытылып өлгергән йөз-кыяфәтләрен ап-ачык күрде. Ул «дипломат»ыннан кәгазьләр һәм кассеталар алып, Мәскәү прокуроры алдына куя, һәм Кравцов катгый итеп: »Бар да аңлашылды, бохаралыдан башлап барысын да фаш итәрбез...»—ди, имеш...

Нәкъ шул вакытта автобус селкетеп куйды да күзләрен ачты. Сәгатенә күз төшерде: бары унбиш минут узган. Йокының эзе дә калмады. Димәк, Мәскәүгә, бары тик Мәскәүгә!—дигән карарга килде прокурор. Монда Артур Александровичның мөмкинлекләре зур, яклаучылары житәрлек, әле карсак бохаралы да үз дигәненә ирешә калса...

Ташкентка керер алдыннан Көйлектә берничә корееялы төшеп калды, һәм автобус кузгала башлаганда гына, прокурор да жиргә сикерде. Аннары беренче очраган машинаны туктатып, унлык суз ды да: «Аэропортка сонга калам»,—диде. Акча үз эшен эшләде. Ярты сәгатьләп касса каршындагы чиратта торганнан соң, тәрәзәчек аша паспортын бирде һәм:

—Зинһар, Мәскәүгә, иң якын рейска,—дип үтенде.

Кассир гажәпләнүдән күзләрен шарландырды.

—Сез нәрсә, гражданин, Мәскәүгә иртәгә дигән билетлар да сатылып бетте,—һәм сөйләшү тәмам дигәндәй:—Чиратта кем?—дип сорады...

Көтелмәгән хәлдән прокурор югалып калды. Касса яныннан кузгалганда, башына бер уй килде. Теркәү баганасы янында басып торган махсус киемле

ике кешене күреп, бәхетен сынап карарга булды.

«Дипломат»ын каршыларына куйды да, читләтеп-нитеп тормыйча:

—Егетләр, Мәскәүгә очарга ярдәм итегез әле,—диде.—Менә сезгә хәлемә кергән өчен,—һәм алар алдына йөзлек куйды.

Шубарин белән аралашу җимешләрен бирә башлады. Хезмәткәрләр, тирә-якка күз салып, бераү дә күрмәгәнен төшенгәч, олырагы акчаны кесәсенә шудырды. Яшьрәге әйтте:

—Әйдә, абзый, паспорт белән акчанны бир дә ярты сәгатьтән әйләнерсең, борчылма, фирма гарантия бирә.

Ярты сәгатьтән билет кесәсендә иде инде. Оятсызлыгы чыраена язылган яшьрәге:

—Теләсә кайсы вакытта рәхим итегез, кемнедер рейстан төшереп булса да озатып җибәрербез,—дип, теш агартып маташты.

Әйткән сүзләрендә торуларына гаҗәпләнсә дә, прокурор аларга рәхмәт әйтеп маташмады. Теркәүгә кадәр әле биш сәгать бар икән: » Күбрәк »,—дип фикер йөртте ул. Аэропортның үзе өчен куркыныч урын икәнен чамалап, шәһәргә чыгарга булды, бер очтан тамак ялгарга исәпләде.

Шәһәр үзәгендәге «Ташкент» рестораныны бик тиз барып житте, кунакханә каршындагы киосктан берничә газета сатып алды да залга үтте. Ярты сәгатьләп утырды, әмма официант аның ягына борылып та карамады. Бу юлы да Шубарин, дөресрәге, аның бүләге коткарды: кайсыныңдыр күзенә кулындагы алтын «Патек Филипп» сәгате чагылып, монын ише кыйммәтле нәрсәнең мал-мөлкәтле кешеләрдә генә булуын аңлаган официантлар шунда ук аның тирәсендә бөтерелә башладылар. Прокурорның кәефе килде, киеренкелеге юкка чыкты, бераздан аларның, бер-берсен уздырып, өстәлгә кабымлыклар, җиләк-җимеш, яшеллек ташуын, мыек астыннан көлеп, күзәтеп утыра иде. »Махсус сезнең өчен генә, французныкы, «Камю»,—диган булып аз гына коньяк та китерделәр.

Төшке ашны тәмамлап килгәндә, сәгатенә күз салды һәм үзе дә сизмәстән: «Коста, мөгаен, инде «Лас-Вегас»тадыр»,—дип куйды. Әмма аның бу турыда баш ватасы килмәде, тыныч кына лимон салынган яшел чәен эчеп бетерде һәм исәп-хисап ясатты. Бары опера театры каршындагы мәйданга килеп, фонтан янындагы урындыкка утырып, кулына газеталар алгач кына башына китереп сукты: нинди аэропорт? Нинди Мәскәү? Коста аны «Лас-Вегас»та очрата алмагач, шунда ук Шубаринга хәбәр иткәндер, ә тегесе Ташкенттагы әшнәләрен аякка бастырып, иң беренче чиратта аэропортка юлны япканнардыр. Ана билет юнәткән ике егет шундый ук акчага Ашотның дусларына Азлархановның турында сатмагандыр дип кем әйтә ала, хәзер анда аны, мөгаен, көтеп торалардыр. Ул соңга калды—аэропортка юл юк инде...

«Ашыкма!—дип тынычландырырга тырышты ул үзен.—Чишелмәс төеннәр булмый—юлы табылыр». Һәм запаста торган соңгы өметенә ябышты—кичекмәстән капитан Чураев белән элемтәгә керергә!

Ул якындагы автоматка юнәлде, күпме сулар акса да хәтереннән җуелмаган МВД телефон номерен җыйды, капитанга ничек чыгасын ачыклады. Чураев җитәкләгән бүлектә, трубканы сәркатибе алды һәм капитанның хәзерге вакытта киңәшмә үткәрүе турында хәбәр итте. Тәмамлану вакытын сорашкач, сәркатипкә, бер сәгатьтән прокурор Азлархановның Чураевны республика прокуратурасы янында үтә әһәмиятле эш буенча көтеп тора, дип җиткерергә кушты.

Юристконсультант кабат фонтан янына килде, чөнки очрашу урыны моннан әллә ни ерак түгел—тәпиләп, ярты сәгатьтә барып җитәргә була. Укыйсы да, утырасы да килмәде, ашыкмый гына Горький паркына таба атлады, аннан прокуратура кул сузымында гына. Паркта чират торып квас эчте, сусынын басты.

Билгеләнгән вакыт житүгә, Гоголь урамына ашыкты.

Соңгы тапкыр прокуратура бусагасын атлап чыкканга биш ел узган. «Анда нинди үзгәрешләр бар икән?»—дип, үзенә ярдәм кулы сузарлык кешеләрне күңеленнән үткәрде. Аска карап, уйларына чумып атлый торгач, прокуратура янына ук килеп житкәнен абайламый да калды, башын күтәргәндә, урамның каршы ягында басып торган Джиоевны күреп алды. Коста аны бөтенләй икенче яктан көтә иде, нидер сизенгәндәй, кинәт бу якка борылуга, күзләре очрашты.

Прокурорның бинага якынрак торуын чамалап, тән сакчысы беренче булып кузгалды. Азлархановов көтелмәгән хәлдән, параличланган шикелле, баскан урынында катып калды, тик Костаның аңа таба йөгерүе бик тиз шок хәленнән чыгарды, ул да үзен коткарып калачак бинага ташланды.

Ара якын булса да, куркуыннан йөрәге бугазына менде. Таныш пыяла ишекнең тоткасына ябышканда, менә-менә Коста анын жиненнән эләктерер кебек тоелды һәм ул иркен холлга бәреп керде дә баскычлар буйлап өскә ыргылды.

—Кача алмассың!—дип хырылдады Коста.

Бер генә мизгелгә артына борылган прокурор сөртенеп китте һәм кулындагы «дипломат»ы, дөбердәп, мәрмәр баскычлар буенча түбән тәгәрәде, анын артыннан ук Азлархановов үзе дә куа килүченең аяк янына килеп төште. Егылганда, күзенә вахтада торган карт милиционерның куркудан кобурасын ычкындыра алмый маташуы күренеп калды. Коста «дипломат»ны эләктерде дә, сүгенә-сүгенә, прокурорга китереп типте. Артында кемнеңдер мышнаганын ишетеп, тиз генә борылды да кулындагы пистолетын сакчыга төбәде:

—Шаярма, атай, атам!—дип гыжылдады. Монарчы мондый хәлгә юлыкканы булмаган өлкән яшьтәге хезмәткәр, дерелди-дерелди, пистолетын ташларга мәжбүр булды.

Бу вакытта соңгы көчен жыеп аякка баскан прокурор, чытырдатып, Костаның пистолет тоткан кулына ябышты.

Коста авыр «дипломат» белән анын башына тондырды, тагын, тагын... ул да булмады прокурорның яраларыннан кан сиптерә башлады. Кулын ычкындыра алмагач, Коста башы белән каты иттереп анын йөзенә орды. Анын югалта барса да, Азлархановның чытырдап ябышкан бармаклары язылмады, ачуыннан шартларга житкән Коста аңа терәп атып жибәрде.

Көтмәгәндә кемдер аны прокурордан йолкып алды да ниндидер алым белән икегә сындырды. Костаның сөякләре шатырдап китте һәм ул, авыртуга түзә алмыйча, кыргый тавышлар чыгарып кычкырырга тотынды. Ул да булмады, башы белән стенага килеп сыланды да, тәгәрәп, милиционерның аягына килеп бәрелде.

Бөгелеп төшкән прокурорны кемдер тотып калырга ашыкты. Бу—ерактан ук прокуратура тирәсендәге хәлләрне күреп, Коста артыннан ук диярлек вестибюльгә бәреп кергән капитан Чураев иде.

Әмирхан Даутовичның канлы башын тезләренә куйган Чураев, янына жыелып өлгергән халыкны да сизмичә, өзми-куймый бер сүзне кабатлады:

—Кичер, прокурор, өлгерә алмадым, кичер...

*Ташкент, Голицино, Куктүбә.*



Сания
Әхмәтҗанова

## Сафлану

Тормыш шау-шуыннан җан талкынып,
Эшем төшкән чакта кулымнан,
Җитәкләшеп ялгызлыгым белән,
Кереп киттем урман юлыннан.

Изге мәгарәгә иңгән кебек,
Убылды уй серле упкынга.
Бер мизгелдә дөнья мәуласыннан[1]
Әверелдем гүя тоткынга.

Сихерләнгән кебек түбән төштем
Кемдер баскыч уйган сукмактан.
Урман ияләре—агач сыннар—
Кулын суза миңа як-яктан.

Кыңгыраулар каршы йөгереп чыга,
Күбәләкләр, уйнап, очына.
Каен җиләкләре, тәгәрәшеп,
Үзе өзелеп төшә учыма.

Томырылып ята тау иркендә
Куптарылган тамыр-гөрзиләр.
Тынычлыкны безнең бозмасмы дип,
Шыпырт кына мине күзлиләр.

Аулак дөнья. Монда вәхшиләрчә
Кул салмаган әле кыргыйлык.
Бу сәйранга җирнең куеныннан
Чишмә чыккан, әнә, ургылып.

Тау чишмәсе... саф уйларын уйлап,
Кая ага болай атлыгып?

[1] мәула—ия,хуҗа

Сания ӘХМӘТҖАНОВА—*шагыйрә; «Оч ирекккә, җырым!», «Пар алма» китаплары авторы; Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

Сәҗдә китеп, тәкатьсезлек белән
Тере суын эчтем йотлыгып.

И, Табигать, кыйпылчыгың итеп
Тойдым шунда кабат үземне.
Җиләс җилгә куйдым йөзләремне,
Рәхәтлектән йомып күземне.

Туган йортка кайткан кебек булдым,
Чын бәхеткә бүген тиендем.
Үз Җиремнең—үз өемнең мине
Чит итмәвен аңлап сөендем.

Кайтып киләм кире чынбарлыкка,
Яңа туган кебек, сафланып.
Яшь баладай ихлас хыялларым
Янәшәмнән йөгерә шатланып.

## Мин үзем!

Яхшы атлы булып, адым саен
Акыл бирүчегә шул сүзем:
Сорап алган киңәш кенә кыйммәт—
Борчылмагыз, зинһар... мин үзем...

Горурлыгым аяк чалды бүген,
Тезләнмәскә, Раббым, бир түзем?!
Егылганда ярдәм кирәк түгел—
Булышмагыз, рәхмәт ... мин үзем...

Шатлык арты шатлык килде беркөн—
Дус дигәннәр ачмый ник йөзен?
Бәхетемне гафу италмыйсыз?—
Гафу итәм сезне... мин үзем!

## Кайтаваз

Ерак дәвер төпкеленнән
Бага гүя Хәтер күзе...
Кайтаваздай кабатланып,
Җанны кага хәтәр сүзе:

—Синең кылган гамәлләрдән
Убылмасмы Күкләр йөзе?!
Асылыңа кайт син тизрәк,
Татар кызы?!
Та-та-ар кы-зы-ы ?!

## Дәвамчы

Бар җиһанга аваз салды сабый,
Кеше туды Җиргә—ир бала.
Биләүләнеп ап-ак өметләргә,
Җан түрендә бәхет тирбәлә.

Күкләр гүя хәер-дога укый,—
Ишетелә азан тавышы.
Кендек каны тамган шул мизгелдән
Башланамы Кеше язмышы?

Бишек җыры итеп, көйгә салып,
Изге теләк теләр әнкәсе.
Җисеменә туры килсен, диеп,
Матур исем эзләр әткәсе.

Яшь ананың күңел бишегендә
Якты уйлар гына тирбәлә.
Киләчәкне сайлап тавыш бирде
Нәсел дәвамчысы—ир бала.

## Калдырыгыз бүген ялгызымны

Калдырыгыз әле берүземне,
Һич югында бары бер көнгә.
Ишетәсем килми берәүне дә,
Сүз кушасым килми беркемгә.

Телефонны бүген өзеп торам—
Шылтыратып җанга тимәгез.
Күренеп кит, диеп чакырмагыз,
Сагынылган, диеп килмәгез.

Хаталардан авырайган җанны
Күз яшенә иде манасы,
Вөҗдан каршысында башны иеп,
Үз-үземнән хисап аласы.

Калдырыгыз бүген ялгызымны,
Бу халәтем минем вакытлы.
Гамәл дәфтәремне барлар өчен,
Мин туктатып торам вакытны.

Калдырыгыз бүген ялгызымны...

## Кыргый алма

Алма аттың миңа—тоталмадым,
Яннарымнан барды тәгәрәп.
Ник ымсындым, юкса дөньяларым
Алмалардай иде түгәрәк?

Тукталды да калды серле алма,
Адымнарым шул чак ялгышты...
Иелеп алдым гүя учларыма
Мин татырга тиеш язмышны.

Кыргый алма... Соң өлгергән алма...
Кирәк иде микән өзәргә?
Әче алма сутын сорый күңел
Кереп барган мәлдә көзләргә.

Очрадыңмы көзге бакчаларда
Мине үкенечкә салырга?
Тәкъдиремә язган, ахыры, миңа
Кыргый алмаң булып калырга.

Алма аттың миңа... тоталмадым...

## Гәрәбә

*Көз учыннан төшкән гәрәбә син,*
*Яралгансың диңгез балыннан...*
Марсель Галиев

Көз учыннан төшкән гәрәбә мин,
Яралтучым ләкин көз түгел.
Йөзегемнән төшеп тәгәрәдем,
Алтын кыса миңа төс түгел.

Көз учыннан төшкән гәрәбә мин,
Яшькелт күзле серле гәрәбә.
Тылсымыма әсир булмам димә,
Бер чагылып китсәм әгәр дә.

Көз учыннан төшкән гәрәбә мин,
Диңгез балы—сары гәрәбә.
Үз бәямне үзем белим әле,
Узмасын ла гомер әрәмгә.

Тик соңладым... Балкый алмадым шул
Сөю таҗындагы каш булып.
Кайтам кире диңгез куенына
Мин иясез асылташ булып.

Көз учыннан төшкән гәрәбә мин...

## Чалма чәчәк

*(Җыр)*

Бәхет бүләк иттең миңа, гөлләргә төреп,
Чалма чәчәк арасына адаштым кереп.
Гүя җаннар кавыштылар чәчәк туенда,
Мин гөл булып бөреләндем синең куеныңда.

Таҗ кидердең миңа шашкын хисләреңнән,
Исердем мин чалма чәчәк исләреннән.
Чалма чәчәк бөреләре алма-алма,
Сөю таҗы ачылганны күрми калма.

Керфекләре түбән төшә алсу гөлләрнең,
Чалымнары чагылып китсә моңсу күзләрнең...
Кер бакчама, миндә дөрли җәйләр челләсе—
Безгә әле мең кат үлеп, мең терелäсе.

Өзмә миңа чалма чәчәк, сулмасын иртә,
Гөл гомере бер вакытлык—үтә дә китә...
Сөюемә сөю белән белсәм туләрең,—
Назым белән сугарырмын күңелең гөлләрең.

## Сәфәр

Һәркем үзли җирдә үз кыйбласын,
Иртәге көн тәкъдир кулында.
Язмыш кичеп йөргән юлаучы без,
Мосафир без гомер юлында.

Ярты юл да әле үтелмәгән...
Тукталырга, дускай, бик иртә.
Биштәреңне ерак куймыйча тор:
Сәфәр көтә безне, юл көтә.

Якты өметләрне кабызыйк та
Җылытыйк бер арган җаннарны,
Бәхет яши торган тарафларга
Юлны дәвам итик аннары...

Әле генә таң сызылган иде,
Инде кояш байый офыкта.
Таулар менеп, таулар төшәсе бар
Гомер дигән кыска вакытта.

## Хакыйкать

Гомер итеп булмый икән
Җанны икегә ярып...
Мин барыбер үткәннәргә
Җитә алмадым барып.

Берексә дә куш игездәй
Ялганы–чыны бергә,
Куш йөрәк белән туамаган
Әле берәү дә Җиргә.

Мин кайда—бәхет тә шунда:
Яши-яши аңладым.
Төшкән җиремдә таш булыйм—
Бүгенгемне сайладым.



Рифә
Рахман

## ХИКӘЯЛӘР

### Алмашыну

Жиһанша абзый, кичке намазга хәзерләнеп, таһарәт алып йөргәндә, болдыр ишеген шакыдылар. Хатыны Мәхубзадә, ачлык хәлсезлегеннән рәтләнә алмыйча, ишек катындагы караватта яткан җиреннән кәефсез генә картына дәште:

—Башка бер вакыт булса... җинел генә кузгаласы да шай... Җиһанша, үзен чыгып ачарсың инде... Тышта чит кеше бар бугай.

Заһирәбану фермадан кайтып кермәгән иде әле. Һәр тиешне үз вакытында эшләргә күнеккән ир эченнән, намазым соңара инде, дип мыгырданды, әмма, комганын җылы плитә өстенә куйды да, Мәхубзадә аркылы гына үрелеп, тәрәзәдән карады: баскыч каршысындагы таныш шәүләнең кемлеген ачык кына фаразлый алмады. Аннан, ябыштырылып, ямалып беткән пыялага сак кына шакып:

—Кер, ишекнең эчке келәсе төшмәгән,—дигәнне кул ишарәсе белән аңлатты.

Ул да булмады, ишекне киң ачып, Әшрәфҗан кордыенын район банкында эшләүче малае килеп керде. Авылда соңгы вакытта бу күзгә мут, телгә оста, кыяфәткә фырт егетне Җиһаншаның төпчеге Заһирәбану артыннан йөри дигән сүз киткән иде. Кыз матур, эшкә унган, егетләр күзе төшмәслек түгел, элегрәк тә, тегесе кызыга икән, монысы ... дигән сүзләр еш килеп ишетелгәнгә, Җиһанша аларны әллә ни игътибарга алмады. Инде менә... коры холыклы ата каршысына батырчылык итеп килгән икән, гайбәт дигәненнең чын булып куюы да ихтимал.

Җиһанша Әшрәфҗанны элек-электән яратып бетермәде. Гомер бакый кеше малына кызыгыр, җир җимертеп эшләмәсә дә, тормышы яхшы

---

*Рифә РАХМАН—язучы; «Керфекле тәрәзәләр», «Күзләрең төймәләнсә» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

булыр. Балалары, үскәндә әллә кем булмасалар да, район да—нәчәлник урындыгында.

Жиһанша йортын аяктан еккан раскулачивание жилләре дә Әшрәфжаннарның каралтысын әйләнеп узды. Алай гына да түгел, әлеге хәлләрнең башында торып, күңелендә кинә йөрткәннәрнең барысыннан да үч алырга өлгерде кордые. Шуларның тәүгесе, бала чакта мәдрәсәдә яхшы укып, хәлфәләрнең сөеклесенә әверелеп, кытыгын китергән, инде мыек төрткәч, сабантуйларында бил бирмәгән, атасының байлыгын тагын да ишәйтеп жибәргән, дөньяны аркылыга-буйлыга гизеп, бар нәрсәдән хәбәрдар Жиһанша иде.

Әшрәфжанның иң нык ачуын китергәне Жиһаншаның атасы Әхмәтша су буып ясаган ике тегермән булды. Әле урыс патшасы ил башында утырганда ук, халыкны да яллямыйча, әзмәвердәй гәүдәле алты улы белән генә салган иде ул аларны. Атасының малы мирас булып Жиһаншага күчкәч, гомер бакый туйганчы тамагына ашамаган Әшрәфжан буылып үләргә житеште. Күмхүҗләр төзелә башлаганчы ук, авыл ярлылары белән берләшеп, тегермәннәрне Жиһаншадан тартып алдылар да бар халыкныкы иттеләр. Итүен иттеләр, тартырга ашлыгы гына калмады, бар житештергән жыелып, дәүләт амбарларына акты.

Тегермәннәр әкренләп таралды, каралмады, буалар саекты, юньләп буылмады да. Инде ашлыкның калхузга калдырылганы да урман артындагы ерак бер ар авылында тарттырыла башлады. Язгы баткагында да интектеләр, көзгесендә дә капчык өстенә капчык төягән атлар үр менәлми тилмерде, иллә дә мәгәр, тегермәннәрне генә рәтлик сон, дигән сүз ишетелмәде. Югарыдагыларга халыкны шулай тилмертү яхшырактыр, күрәсең, дип, үз-үзен тынычландырган кебек булса да, су буйларының карачкылары сыман утырган тегермәннәрен күргән саен, Жиһаншаның йөрәге сыкрады. Кирәкләре чыкмагае дипме, аларны сүтәргә ашыкмадылар, әмма авылда электр станциясе төзелгәч, бераз өстәрәк янасы—утта эшләгәне калыккач, узган тарихның онытылмас хәтеренә ия тегермәннәрне шунда ук оныттылар.

Үз көчен, бигрәк тә кул көчен кергәнне йөрәктән сызып ташлап буламыни?! Күңеле боек көннәрдә су буйларында йөрсә, Жиһанша абзый, такталары куба башлаган, калын сайгаклардан ясалган ишекләре каерылып ташланган тегермәнгә кереп, бер кырда яткан, ашлык тартырга да өлгерми калган ташка утырып хәл ала. Ярыклардан кереп искән жил тавышына моңая, аталары рухын уйлый, дога кыла. Динне бозу булмаса, жаны бар кебек тегермәнне дә догасыннан калдырасы түгел мәгәр...

Салкын тегермән ташында озак утыра алмыйсың. Күз яшьләрен эчкә йотып, яңадан елга буйлап үз очларына кайтып китә ул. Тыкрыктан урамга күтәрелгәндә, иң калку урынга житкәч, соң кат башын борып, Әхмәтшаның ишле гаиләсен мул табынлы, кулларын эшле иткән мәһабәт тегермәнгә карый. Күзен тагын яшь баса, йөрәгең калтыравык ала...

Инде менә Жиһанша гаиләсен эт көненә калдырган Әшрәфжан малае ишек төбендә утыра. Кем янына, ни дип килгән ул?!

—Ярар, кем, мур кыргыры, атың ни әле?

—Әшрәфжан малае булам мин, Зиннәтулла. Әле менә бер хуттан дигәндәй, монда төшешли әтәйләргә дә сугылдым, күп итеп сәламнәрен күндерде.

—Сәлам күндерде, дисең, инде алайса?!—Жиһанша, юк сакалын сыпырынгандай итеп, алмаларын жыеп, күзләрен хәйләкәрләндереп, егетнекеләргә карады. Сүрән ут яктысында ялтырап торган карашыннан нигә килгәнлегең тоярлык түгел иде, мәгәренки нидер сорап кермәгәне

ап-ачык. Аласын атасы алып бетерде инде, дип уйлап куйды эченнән Жиһанша. Инде шушы авыр заманда җан акыртып алган сыерына кул сузарга килмәгәндер?!..

Йортсыз-жирсез калганнан сон, Жиһаншаларнын хәлләре шәптән булмады. Ач үлемнән котылыйк дип Мәскәү тирәсендә яшәгән тумачаларына да китеп карадылар, аларнын да үз хәле хәл иде, кире әйләнеп кайттылар. Бер киткән килеш, башка энеләре кебек, шахта-мазар тирәсенә китеп югаласы, кала жиренә сыенасы булган икән ул. Ул ахмак, алай димичә кем дисен, бала-чагасын төяп, тагын да Өскесуга әйләнеп кайтты. Зур каралтыдан кечкенә бер келәт кенә торып калган иде. Сүтелмичә, ихата буйлап тырпаеп утырган иске мичләрнең кирпечләреннән шуңа янасын кордылар да кысынлыкта, анын каравы ата-ана нигезендә дип, сыкранмыйнитми генә көн итәргә керештеләр. Бераз хәлләнгәч, йорт-жирне янадан кинәйттеләр, мунчасын да, абзарын да салдылар, инде менә сыерын да сатып алдылар.

Авыл сәвите башына менеп утырган Әшрәфжан Жиһаншага, кеше рәтенә кергәнче, тагын көн күрсәтмәде. Мәскәүгә барып яшергән алтыннарыгызны алып кайтыгыз дип ай арты ай кәнсәләргә чакыртты, кордыенын танмавын күргәч, ихата тирәсенә яшердегезмени, дип, районн жиреннән кешеләр китереп, ул төштә, бу төштә, казындырды, ахырда кул селтәде бугай—килеп аптыратучылар күренмәде. Шулай да, эшкә житезлеген, тырышлыгын белсә дә, болай тиз генә аякка баскан Жиһаншага барыбер ышанмый, әле дә һич югы бер савыт алтыны бәрәнге базында булса да тәгәрәп ята дип уйлый иде ул.

Зиннәтулласы Заһирәбану артыннан йөри икән дигән сүз таралгач, Әшрәфжан сөенеп бетә алмады, болай, ин яхшы дигәндә, дәүләт казнасын тутырасы алтыннар инде турыдан-туры малае кулына күчәчәгенә шик юк. Жиһанша улларынын һәр каюсы башлы-күзле, тормышлары артык мактанырлык булмаса да, авыл жире өчен таманча. Йортта, татар гадәтен бозып, Жиһанша төпчек кызын калдырыр, картлыгын ялгыз уздырырга батырчылык итмәс кебек тоелды Әшрәфжанга, һәм Зиннәтуллага, унган, чибәр кызга күзең төшкән икән, инде кулыннан ычкындырма, дип көнен дә, төнен дә тукыды.

Гомер буе байлар рәтендә йөрергә кызыккан әтисенеке кебек, Әшрәфжаннын да хыялы әле кайчан гына авылнын бизәге кебек тегермәннәрне кулда тоткан Жиһаншаларга тин булу иде, чөнки белә: нинди эшкә дә рөхсәт кәгазенен пичәтен кесәсендә йөрткән рәисме син, авыл урамы буйлап кукыраеп узган милиционермы, бер төшермәсәләр, бер әтиеннән кем икәнлеген дә, ничек кеше булганынны да исенә төшерәчәкләр...

Жиһанша белән кодалашу зыян итмәс, билгеле. Аннан да акыллырак, тормышнын тәртибен белеп алып барган коданы чыра яндырып эзләсәң дә табасын юк. Шундый авыр елда да сыер юнәтү хәстәрен күргән ул, аннан башка, гаилән ишле булмаса да, көн итү авырлыгын аңлаган.

Кырык бишнен кышында, бигрәк тә кырык алтыда авыл халкы кырылды гына. Бөтен ашлыкны хөкүмәт амбарларына жибәреп бетергәч, кинәнеп чәчәрлеге дә калмады. Чын корылыкта да гектарыннан 16 центнердан ким иген бирмәгән кырлардан нибары 4-5 центнер жыеп алдылар. Әле башка якларда анысы да юк, имеш. Дәүләт биргән ашлык ссудасы дигәне дә яна план үтәлешенә китеп бетте. Сугышка түзгәнне, монысына да бер-ике ел гына түзәрбез дисәләр дә, һәркемнен хәле хәл иде, малын бөтенләй бетермәгәннәр генә кышларны жинелрәк чыкты. Урман-сулы Өскесуда әзерләсән коры килгән елны да печәне житәрлек иде анысы.

Сугыштан соңгы авыр еллар булса да, шахтага киткән улы Габделбари да җибәреп торгач, Җиһанша кулында ярыйсы гына акча тупланган иде. Җыелмаслык та түгел, алам дисәң, кибетендә әйберсе юк, үзең ач утырганда банкта саклавыңнан да файда күренми. Ар авылы Мукдунда сатлык сыер бар дигәч, барып белеште дә, хакын килешеп, өенә кайтып китте. Икенче көнне, ни кызганыч, Банкта техник ял көне булып чыкты. Җиһанша ел ахырында исәп-хисап ясауларыдыр инде дип уйлады, килергә сүз беркеткән булгач, кесәсе акчасыз көе генә, янә Муклунга китте.

Ар-чирмеш арасында Җиһаншаның белеше күп иде. Тегермәненә йөргәннәре дә бар, үткәндә-киткәндә чәйгә тукталганнары да юк түгел. Шулардан берсе белән баргач, сыер хуҗасы Әркәшә, килгән-килгән алып кит, иртәгә-берсөкөнгә акчасын кызың артыннан тапшырырсың, дип, сыерны җитәкләтеп кайтарып та җибәрде. Инде менә, малкайның элекке хуҗасын сагынып мөгерәгәне дә Җиһанша җанына җылылык биреп, йөрәгенә май булып ята. Сыерлы булганны белеп, бер-бер нәрсә майтармакчы мәллә бу иблис Әшрәфҗан?!

—Сәлам күндерде дисең инде алайса?!—дип кабатлады Җиһанша.—Шул сәламне китерер өчен генә ишекне шакымагансыңдыр?

Зиннәтулла үзен шулайрак каршы аласыларын белә, көткән һәм моңа әзер дә иде.

—Юк, Җиһанша абзый, төнгә каршы эш калдырып, авылга кайтмам лабаса! Бер-бер файдам тимәсме диеп кенә инде. Әле менә сезгә килешли ферма аша да узган идем... Заһирәбану... ни... әтәй янына сугылмассыңмы дип калды...

—Нинди хәл ул—егетне ата йортына җибәрү?!— дип, Җиһанша кызып китә генә башлаганда, Мәхубзадәнең:

—Чү, атасы, йомыш белән килгән кешегә...—дигәне ишетелде дә, карт шунда ук сабырланды:

—Йә, сөйлә инде алайса, ни йомыш?

—Йомыш дип... бүген төнлә акча алмашына, Җиһанша абзый, моны әле һичкем белми. Кемгә дә ишетелсә, мина—эштә утыру юк. Заһирәбану әтәйнең сыерга түлисе акчасы әле кулында, янмасын тагын, дигәч кенә... болай батырчылык итеп сезнең ишекне шакуым. Ышанып, кулыма бирсәгез, банк ачкычы—үземдә, тиз генә акчагызга, кичәге көн белән, яңадан чут ачам.

Җиһанша, ә, димәде, җә, димәде, башы әйләнеп китеп, мичкә килеп терәлде. Тормыш тагын рәтләнде генә дигәндә... Тагын шул Әшрәфҗан... Юк ла, бу малайның да, атасының да инде ни гаебе бар?! Ярдәм итәргә теләве дә чын булса?.. Бөртекләп җыйган акча төн эчендә кәлләргә калсын әле.

Җиһанша, бераз рәтләнгән кебек булгач, түргә кереп китте. Тимер-калай тавышы аның сандык ачып азапланганын аңлатып тора иде. Артык дулкынлангач, ачкыч-йозакның тиз генә җаен таба алмады, күрәсең. Бераздан сандык ишегенең ыңгырашып күтәрелгәне, кыштырдап акчалар саналганы, тиеннәр шалтыраганы аңлашылды. Ул да булмый, икмәк төрелә торган ашъяулыкка тартым җәймә тоткан Җиһанша янадан кече якка чыкты.

—Зиннәтулла дисең инде алайса... акча алмашына дисең инде... Ышаныргамы сина, юкмы? Шул тирәдә эшләгәч, әйткәнең хактыр да... Атаңны белгәч, явызлыгың тимәсә дә, сыер акчасы кадәр сыер акчасын кулыңа тоттырып җибәрергә кул бармый.

Җиһанша Зиннәтулла каршысына идәнгә килеп чүмәште дә ашъяулыкны ачып җибәрде. Бер өем кәгазь акча тирәсендә көндәлектә тотарга дигән

бакыры да җитәрлек булып чыкты. Анысын тотып карады Жиһанша, монысын, аннан, тимер акчаларны, өстәлдән тәлинкә алып, шуңа салгач, савыты-ние белән Зиннәтуллага китереп тоттырды:

—Уйладым-уйладым да алмаштырмаска булдым әле мин, балам. Без күрәсене кеше күрмәс. Нинди акча белән алырга килешсән, шундыйда бирергә кирәк булыр, Әркәшәгә иртәгә китерәм дигән сүзем бар, сүздә тормау яхшы сыйфат түгел. Аллаһе боерса, алмашына нитә калса, сәвит хөкүмәте ярлы кешене алдамас, тиерен бирер... Һәркөн радиу шул хакта әйтеп тора әнә. Жиһанша дигән исем дә бар бит әле минем. Ялганчы атын күтәрәсем килми. Бер дә булмаса, шушы тимер акчаларны гына ал да...

Зиннәтулла, китәргә теләвен аңлатып, бүреген башына киде, тәлинкәне өстәлгә кире куйды:

—Андые алмашынмаячак анын, Жиһанша абзый!

Андые алмашына, мондые юк. Бер дә ышандырырлык кебек түгел иде. Карт, ай-ваена карамый, тимер акчаларны Зиннәтулла кесәсенә шыплап тутырды:

—Яңасын Заһирәбану артыннан гына җибәрерсен.

Зиннәтулла сатулашырга чамалагандай итенсә дә, Жиһаншаның карары нык иде, егетне төрткәләбрәк тә ишектән чыгарып җибәрде.

Ул да булмады еламсыраган бер кыяфәттә Заһирәбану кайтып керде. Атасының нәрсә әйтәсен алдан ук сиземләгәнгә, сүзне үзе башлады:

—И әтәй, яхшылык эшли торган кешеме сон ул Зиннәтулла?! Шул минем хакка дип кенә тырыша лабаса! Сорап килсәм, кире бормасын тагын, дип, синнән дә куркуы. Әшрәфҗаннар йортына аяк басасым да юк! Әмма дә ләкин тынлыйсы иде сүзен, алмаштырасы иде акчаны! Утырып янабыз бит!!

Жиһанша ни дип әйтергә дә белмәде. Инде Заһирәсе дә болай чәпченгәч... Намаз укып ятарга да, кояш чыкканчы ук, Мукдунга Әркәшә янына китәргә булды. Зиннәтулла, әле халыкка әйтелмәгән, диде бит.... Ничек тә өлгерергә кирәк иде. Житмәсә, Яна Елга ни дә булса алырбыз дип, банктагы бөтен акчасын алып бетергән иде, чөнки кибеттә әйбернен—юк вакыты, бәяләрнең бик нык күперенгән чагы иде.

Кырык жиденең уналтынчы декабрь иртәсен кин юлын ай нуры яктырткан урман эчендә каршылады ул. Чынлап яктырып житкәнче, радиу дигәннәре яңа хәбәр җиткереп аваз салганчы, ничек тә Әркәшәгә барып житәргә кирәк иде. Кешенең күптән ныклап йөрмәгәнлеге күренеп торса да, кемдер бу төндә алайга-болайга узган. Маяк ылысларны бу кышта кар күмә язып яуган. Анда-санда куян-поши эзләре кисеп үткән юл алай да батып чумарлык түгел, төптәрәк шактый ныгыган икән.

Жиһанша хәлдән тайса да, вакытында барып житте, әле Әркәшә торган гына, ахрысы, кичтән бикләнми дә калдырылган ишекләреннән кергәндә, мич артындагы лаканда юынып маташа иде. Битен соңгы тапкыр сыпырып алды да, сөлгегә сөртә-сөртә, аның янына чыкты:

—Әйдүк, әйдүк, Жиканша, кер, үстәлгә кил, мин казер.

Жиһанша, дивар белән клүнкәсез-нисез генә әзерләнгән өстәл арасына кереп кысылгач, капчыгыннан тәфтишләп төргән акчалы ашъяулыгын тартып чыгарды:

—Менә китердем, санап ал, Әркәшә. Нәкъ килешкәнчә.

Әркәшә, сүзләрен сайлаганын белдертеп торган иреннәрен мимылдатып, өстәлнең каршы ягына утырды. Аннан таралып төшкән акчаларны танышы турысына этәрде:

—Жиканша, синең бу акчака казер сарык батие дә алынмас, мин сиңа буаз сыерымны туттырып чыкардым.

Җиһанша телсез калды. Ул шушы төндә генә Әшрәфҗаннын, малае районга китеп баруга ук, көнчелегенә чыдый алмыйча, булачак кодага зыян салам дип тә тормыйча, Мукдунга йөгергәнен, Әркәшәгә төндә акча алмашыначагын әйткәнлеген башына да китерми иде. Бераз вакыт сүзсез торганнан сон, ашъяулыкны акчалар астыннан кискенлек тартып чыгарды да, шыбырдап идәнгә коелганнарына да игътибар итмичә, киту ягына кузгалды:

—Син аларны, Әркәшә, утка як, өен салкынрак икән...—диде.

Ар авылы урамыннан бик төз генә, йөзенә сыкрау галәмәте чыгармый гына узса да, урманны көчкә үтте, авылына чак кайтып житте Җиһанша. Инде өйдәгеләр дә яналыкларнын сонгысын радиодан ишеткән, кара хәсрәткә баткан иде. Кер-ә-керешенә, Заһирәсе, каршысына килеп:

—Нәрсә, әтәй, алдымы?—дигәненә атасы кул гына селтәде. Анын көпә-көндез түр сәкегә кереп ятуыннан кара хәсрәттә икәнен анладылар.

Атна буе су гына капкалап урында ятканнан сон, ниһаять, йорт хуҗасы торды, әмма элекке Җиһаншаны танырлык түгел иде инде: күзләре утырган, чәчләре агарган, янак сөякләре калыккан.

Табын янына килгәч тә:

—Олаеп барган көнемдә бер сыер алып унны кайтарасымны белсәм, гомеремдә сөтле чәй күрмәсәм дә, риза булыр идем кана,—дип кенә әйтә алды.

Зиннәтулла, чыннан да, атасы кебек үк миһербансыз зат түгелме, яратуы көчле булдымы, бакыр акчаларны тапшырмаган, тиенен дә тотмаган, хушисле сабын, чәй ише нәрсәләр белән бергә төреп, Заһирәбану артыннан атна дигәндә җибәргән.

Акча алмашынганнан соң кибеткә кайтып тулган таварны алтын бәһасенә дә алырлык түгел иде. Шул көннән Җиһанша абзарга кермәс, чакырып мөгерәгән малкай ягына башын да бормас, сөтле чәйне авызына да алмас булды. Мал-туар бәяләре дә күтәрелеп китеп, инде Әркәшә сыерынын ун бәя генә дә йөрмәгәнен, түләүнең дә кызы Заһирәбануга каласын анлады. Бөтен өмете туачак бозауда иде.

Җиһанша килер җәйләрне күрә алмады. Авылдашлары, март жылысында, жилләнеп китеп, тегермәнгә төшеп утырган да, ташынын суыгын эләктергән икән... дип кенә сөйләштеләр дә, үз гамьнәре гамь иде, сәбәбен тирәннән уйламадылар, тора-бара бу иртә үлемне тәмам онyттылар. Бөтенләй күзәтүчесез хуҗасыз калган тегермәннәрне бала-чага уен жире итте, буасын да буып тормадылар. Хәер, анын инде кирәге бар дип тә уйламадылар. Авылга ерактан ут килде, кызы да кияүгә китеп, анасын үзе янына алдыргач, рөхсәт сорап-нитеп тә тормадылар, кешесез калган Җиһанша нигезенә пекарня корып куйдылар.

Төшлектә кибеткә килгән хушисле ипине алырга төшкән Әшрәфҗан карт сонгы араларда, урам буйлап турыдан кайтмыйча, тегермән аша әйләнергә гадәтләнде. Балаларына анын бу гадәте бик тә сәер тоела, үзгәрден син, әтәй, димиләр, алмашындын, дигән булалар. Вакыттыр инде, алмашынырга да вакыттыр...

Тегермән кебек нык ир иде Җиһанша, ул менә юк, тал кебек сыек кордые яши... Анын сеткасында—хушисле ипиләр. Бүлешсән, тирәк төбендә чүпләнгән каргаларга да, Әшрәфҗаннын оныкларына да, үзенә дә житә ул, әмма авыздан өзеп, балалар эшләгән акчага алынган икмәкне ерткыч кошларга барыбер бирәсе килми.

... Кем дип уйлап китте анын турында Җиһанша?

## Әйтер... иде...

Алма туташны Байкөчек авылына укытучы итеп билгеләделәр. Педучилище кызларына көтелмәгән бәхет иде бу. Күбесе Урта Азия якларына китеп барганда, үз районында калсын әле! Мона әнисе Миңлевафа да бик сөенде. Ире сугыштан әйләнеп кайтмагач, ялгызым балаларны ничек аякка бастырырмын дип кайгырган иде, инде менә олысы кул астына кереп килә. Алла кушып, кем белә, тиз арада башлы-күзле дә була калса, җимерелгән читтәннәр яңадан торгызылыр, мичнең кыйшык морҗасы тураер, бәлки әле, яна мунча да салынып, кыз белән кияүне һәр айда кунакка дәшәрләр.

Алманың уе гына башкача. Ир-атка бай нугай-үзбәк арасында иптәшләренең ялгыз калмаячагын белә ул, ә менә аз йортлы Юнәгәрдә кияү була алырлыкларны бармак белән санарлык. Алай да, ир кочагында булса да, чит җирләрдә каңгырып яшәгәнгә караганда, үз йортында әниең итәгенә ябышып ялгызың көн итүеннән җинелрәк булуы бар.

Байкөчеккә Алма белән бер үк көнне Зөлкамал исемле кызны да фельдшер итеп җибәргәннәр икән. Алар Сәудия карчыкның дүртпочмаклы гына йортына, кечкенә дип тормадылар, чиста-пөхтә күренгәч, фатирга төштеләр.

Кызларның халыкка хезмәт итүе икенче көнне үк чучкаларга яфрак әзерләүдән башланды. Аларны колхозчылар белән бергәләп ат арбалары өстендә изелгә—язын су баса торган таллы тугайларга озаттылар. Паромда су аркылы чыкканда, Алма гел авыл кешеләрен күзәтте. Кем ничек киенгән, кем ничек сөйләшә... Һәм көтмәгәндә карашы терсәге белән паром киртәсенә таянып барган үтә дә чибәр егеткә төште.

Егет башкалар сүзенә катнашмыйча, ерактагы ярларга текәлеп, уйчан гына тора. Укытучымы, агроном-фәләнме булырга охшаган. Аягында—иске булса да ботинка, башында—төсе уңганрак яшел фитыр эшләпә. Колхозчы ирләр «түбәтәй»не дә кул яулыгыннан гына ясаганнар, аякларында да—йә галуш, йә кирза итек.

Алма азсүзле ирләрне электән үк үз күрә. Аның әтисе дә артыгын сөйләшмәс, каралты-кура тирәсендә әкрен генә йөреп торыр, кулына һаман бер-бер эш табар кеше иде. Егетне кыз тәүге күрүдә үк мәрхүм әтисенә охшатты. Аның башкаларның тупасрак яңгыраган шаян сүзләренә кысылмавы, хатын-кызларга күз ялтыратып бармавы күнеленә бигрәк тә хуш килде. Егет сыйфатларын бер яктан икенчесенә салып торганда, кыз үзе дә сизмәстән Зөлкамалга: «әнә ул кара мыеклы, кылыч борынлы чибәркәй минеке булыр, аңа күз ташлама»,—дип әйтеп ташламасынмы!

Эчкәрәк, корырак җиргә кереп имән ботаганда да, ярга якынрак сазлыклырак җирләрдә тал сындырганда да Алма гел Дилияр янәшәсендә булырга тырышты. Инде ул аның исемен ишеткән, әмма әле кемлеген, авылда ниләр майтарып яшәгәнен, хәтта үзе эшләячәк мәктәпнең физика-математика укытучысы икәнлеген дә белми иде.

Менә төш вакыты җитте. Колхозчылар, арба күләгәләренә елышып, ашарга утырдылар. Алма белән Зөлкамал гына ризык алырга онытканнар булып чыкты. Алар, читкәрәк китеп, киң ябалдашлы карт имәннең кытыршы кәүсәсенә терәлеп утырдылар. Авылда башкалардан аерылып буламыни! Шунда ук яннарына Сәудия карчыкның күршесендә генә яшәгән Нилуфәр килеп басты:

—Сез нәрсә, ятим балалар шикелле, бер читтә чөмәшеп утырасыз! Яныгызда мина да урын бирегез әле. Бары бардан, югы юктан—әйдәгез, капкалап алыгыз! Чуар тавык, белгән кебек, өчебезгә өч йомырка җибәргән монда.

Кызлар ана каршы төшмәделәр, урталарына алдылар да алдына җәеп салган ашъяулыгындагы ризыкка үрелделәр. Көн эссе дип үзләре белән су алганнар иде алуын, кунак ашы кара-каршы, диештергәләп, ачык күнелле Нилуфәрне әле эсселәнеп бетмәгән яшел миллек әвене астында сакланган су белән сыйладылар.

Тамак ялгаулар тәмамланып килә иде. Кешеләрнең кайсы кая таралыша башлады, егетләрнең күпчелеге коенырга китте булса кирәк, хатын-кызның да кайберсе, җиләк-мазар, гөмбә караштырырга дип, каенлыкларга, наратлыкларга китте. Алма, косынкасын маңгаеннан күзләренәрәк төшереп, утырган килеш черем итеп алыйм гына дип торганда, Зөлкамал касыгына китереп төртте һәм башкаларныкыннан читтәрәк торган арба ягына ым какты.

Дилияр янында бик тә чибәр бер хатын, тәмләп, ашыкмыйча гына әле һаман да әбәтләп утыра иде. Хатынның түгәрәкләнеп килгән корсагын күргәч, Алма сүзсез дә аларның бер гаилә икәнлеген аңлады. Кызның кинәт тыны буылгандай булды, күз аллары караңгыланды, тотынып, көч-хәл белән урыныннан торды, башыннан косынкасын тартып алды, аягыннан кызыл күн чүәкләрен салды. Аннан, ефәк косынкасын җиргә сөйрәп, елга ярына таба атлады. Бераз баргач, борылып, күзләрен кысып, Зөлкамалга карады да:

—Мин инде аннан баш тарта алмыйм!—дип кычкырды. Башкалар эшкә ябышкач та, Алма бик озак күренмәде. Ул күлмәген дә салмый-нитми суга кереп киткән һәм арыганчы агымга каршы йөзгән дә йөзгән икән.

Зөлкамалга баштарак ашыга-кабаланып икесе өчен дә эшләргә туры килде. Кыз беренче көнне үк ялкау аты белән кеше теленә керүдән курыкты, исемнәренә тап төшерергә теләмәде.

Эңгер-меңгердә арбалар олавы кайтыр якка чыкты. Иртәгә ял көн булса да, кабат яфрак көлтәләргә чыгарга кушылган иде. Әллә көн буе сөйләшеп сүз беткән булды, әллә артык арылганмы, кайтканда һичкем уртак сүз башламады. Олауның иң сонында атлар-атламас кына кайткан Дилиярлар арбасыннан гына яшь ханымның кәефне төрлечә боргалый торган әле моңлы, әле дәртле тоелган җыры ишетелә иде:

Айрым торып еллар,
Аймыл булып юллар,
Нигә синнән читтә узган сон?
Бар шул инде парын,
Янып сөйгән ярын,
Кулларынны ана сузгансын.

Болын буйларына таралган, кошларны тын калдырырлык тоелган бу җыр Алма күнеленә ятмады. Яшь ханым аны үртәп, сүзләрне махсус сайлап җырлыйдыр, менә мин үз ярымда, миннән дә бәхетле кеше юк, дип бөтен дөньяга әйтергә телидер кебек тоелды ана.

Бу җыр йөрәгенә торган саен ныграк кадала барды:

Арта уйлар һаман,
Тарта сина табан,
Кыен мина ялгыз чакларда.
Сөенечкә дисәм,
Көенечкә икән
Күрешүләр сезнен якларда.

Исән-имин генә баласын тапсын әле, күрешүләрнең кемгә үкенечле

икәнлеген анлатыр аңа Алма, дип уйлады кыз, бер дә бер көнне Дилиярны үзенеке итәр дә куяр! Шундый да көчле агымга, ярга кагар дулкыннарга каршы бара алган икән, нигә әле язмыш белән көрәшеп карамаска?! Нигә әле бүген янып сөйгән ярын кочкан кулларын үзенә таба суздырмаска?!

Дилиярның Әнисәсе шул көздә үзе кебек кап-кара чәчле, зур күзле кыз бала тапты. Ана Нәфисә дип исем куштылар. Бәби туена укытучылар белән бергә Алма да чакырылган иде. Ул табынның башыннан ахырына кадәр берни дәшмичә, кара коелып утырды. Бәбинен Дилиярга охшамыйча, әнисенә тартуына кадәр ачуын чыгарды аның. Үзе, уендагысын кеше сизмәсен өчен, түргә узгач ук, бәби бишеген тирбәткәндәй итеп, Әнисәне:

—Бәхете белән үссен инде, исеме дә үзе кебек бик матур икән,—дип сөендереп алды, аннан өстенә күз явын алырдай жете кызыл тасмалар да куелган төргәк китереп тоттырды.—Бала бишектә чакта чүпрәктә дә үсә ул, минем күлмәкне зуррак үскәч кияр, Алма апаң биргән иде, диерсез, әнә шуңа алма рәсеме төшкәнен сайладым.

Дилияр белән Әнисә табынның түреннән, кыр чәчәкләре салынган ваза артыннан урын алдылар. Дилиярның, хатын-кызны ирләрдән аерым, ишек төбенә бер тирәгәрәк жыеп утырткан, игътибарларыннан читтә тоткан авыл мәжлесләренең гадәтләрен санга сукмавы Алманың күнеленә тиде. Житмәсә, ир хатынына ягымлы сүзләр белән генә дәшеп тора, әледән-әле жилкәләреннән кочкандай итеп куя иде.

Ачуың чыгарлык, көнләшерлек тә шул! Байкөчекнең иң абруйлы бер егете шушы пешмәгән, иренен күзенә генә карап торган, аның рөхсәтеннән башка сүз катарга да кыймаган бер нәмәстәгә эләксен әле! Чибәрен чибәр дә... Бала тапкач, Әнисә тагын да тулыланып, матурланып китте. Мәктәпнең яна гына педучилище бетереп кайткан, үзе белән яшьтәш Алма кебек туташларына да бирешерлек түгел иде әле ул. Капка төбендә кич утырган авыл апайлары да, йорт хужабикәсе Сәудия карчык та, булса булыр икән яхшы, булдыклы ир, карусыз хатын, бәхет аларга елмаймый, без толларга елмайсынмыни, дип уфтаныштылар. Клубларда вальска чакырылырга егет житмәгән кызлар кеше сөенеченә эчтән генә сызлылар.

Бәхетнең алдан йөргәненеңнән арттагысы яхшырак, ахрысы, билләһи! Бу парга мөнәсәбәт көн эчендә үзгәрде. Яшен-картын жир үкереп елар хәлгә төшереп, Әнисә, һичкем көтмәгәндә-уйламаганда, икенче баладан үлеп китте. Һаман да Дилиярны үзенеке итү уе белән янган Алма булып Алма моңа сөенмәде. Сагышлы мәхәббәт турындагы жыры күнел түрләренә кереп калган да Әнисә һаман исенә төшә, мәктәп коридорында стенага терәлеп сүзсез басып торган Дилияр кызгандырта, күргән саен күзенә яшь китерә иде.

Ялгыз гына йөрсә, хәсрәтне хәсрәт тә димә. Инде укулар тәмамланды, имтиханнар алынган, мәктәп бакчасындагы эшләр жайга салынды гына, дип торганда, икенче бер хәбәр байкөчеклеләрне тәмам аяктан екты—дәһшәтле сугыш башланды. Сабый баласын да исәпкә кертмәделәр, Дилиярны, Әнисәнең кырыгын да көтеп тормыйча, фронтка алып киттеләр. Кырык йортлы Байкөчектән тагын кемне жибәрәсең! Сугышка ярарлык ир-атлар барлы-юклы бер олау жыелды.

Әле сугышның башы гына, ул тиз арада бетәр кебек тоела иде, озатуны да мәжлесләп, зурдан кубып оештырдылар. Дилияр өчен табынны мәктәптә ясадылар. Өстәл артында тирән мәгънәгә ия нотыклар сөйләнде, берсеннән-берсе төче теләкләр әйтелде, эчтән исә күпчелек әтисез калган ике сабый турында уйлый иде. Алар хакында сүз катып, ата кеше йөрәгенә тоз саласылары килмәгәнгә генә, гел башка хәлләрне искә алдылар, Дилиярны тиз әйләнеп кайтасына өметләндерергә тырыштылар.

Дилияр, Әнисәсен югалткач, үзен бар нәрсәгә битараф бер кыяфәттә тотты. Олы кызын әнисенең аталарына урнаштырды, төпчеген, кайткач кире алу шарты белән, балалар йортына тапшырды. Мәҗлестә дә ул бу дөнья кешесе түгел кебек нәүмиз кыяфәттә, кеше сөйләгәнне генә тыңлап, теләкләргә рәхмәт урынына ым гына кагып, тып-тын утырды. Язмышының бөтенләй көтелмәгән борылышларга юлыгуын уйлады микән әллә ул?

***

Нәфисәгә олы улларының гаиләсе белән яшәгән баба йортында җиңел түгел иде. Иртә ирсез калган җиңгәсенең балалары янына алтынчы кашык булып үстәлде ул. Күп көнне бер тәгам ризык капмыйча мәктәпкә китә. Өстәл янына кыенсынып кына, кеше соңында гына утыра. Ни кушсалар—шуны җиренә җиткереп үтәргә тырыша, кемнән нинди кием калса—шуны кия. Юка киндер оекбашларында мәктәп коридоры буйлап барганда, тишегеннән җәй бу бакчада чүп утап ярылган табаннары күренеп-күренеп китә. Аның каравы, өстендә—ямь-яшел үлән арасында кып-кызыл алмалар тәгәрәшеп яткан күлмәк, чәчләрендә—җете кызыл тасмалардан җиңгәсе матурлап ясаган бантиклар.

Болар өстенә, Алма апасы да үз итә иде Нәфисәне. Беренче тапкыр мәктәпкә килүендә үк ул аны кочаклап үбеп алды, кап-кара күзләренә бик озак карап торды, яратып аркаларыннан сыйпады. Өенә китәр алдыннан калын, дәфтәрләр тутырылган сумкасыннан бер тартма буяу карандашлары, берничә альбом бите, язу карасы шикелле әйберләр чыгарып, Нәфисәгә тоттырды. Шул көннән башлап кыз өчен Алма апасыннан да кадерле кеше булмады. Ул аны гына яратты, аның турында гына уйлады, әкренләп күңеленнән әни сурәте дә җуелып, аның урынын чибәр Алма апасының йөзе алмаштырды.

Нәфисә мәктәпкә башкалар килгәнче үк килергә гадәтләнде. Утын ягып җылытыла торган иске мич артында алар көн дә Алма апасы белән өстенә бал да ягылган майлы ипи белән чәй эчәләр. Бөтнек исләре аңкып торган һинд чәен төсе тәмам җуелганчы шул көенә генә чөмерә дә чөмерә иде Нәфисә. Зәңгәр борчаклы чынаякларын Алма апасына сузганда, ул әллә ничә мәртәбә, әни, дип ычкындыра язды, үзенә бик тансык, туганиларыннан көн дә ишеткән, тел очларын кычыттырып, яндырып торган бу сүзне әйтүдән һәрчак көчкә тыелып калды.

Нәфисә фашистларны тиздән кырып бетерәм дә синең янына кайтам, дип хатлар язган әтисенең дә Алма апасын үзе кебек яратуын теләде, ул кайткач, бергә яшәрбез әле дип, төрле хыяллар корды. Сугыш бетмәде дә бетмәде, әмма Дилияр аның ахырын көтмәде, гимнастеркасының буш җиңен җилле генә селкеп, көннәрдән бер көнне Байкөчеккә кайтып та төште.

Сабый теләгенә фәрештәләр, амин, дип тора диюләре хак булып чыкты. Әтисе Нәфисә әйткәнне дә көтеп тормады, Алма апасы артыннан йөри дә башлады. Араларында мөнәсәбәт укытучыга рөхсәт ителгән киртәләрдән ары узмаса да, авыл буйлап алар хакында никадәр гайбәт таралды. Язга өйләнә, диюләре дә, урактан соң икән, диюләре дә чынга ашмады. Дилияр һаман да Әнисә белән яшәгән йортта Нәфисәне ялгыз гына тәрбияли иде. Авылдашлары бераздан Дилиярның хатынын онытa алмавын аңладылар, өйләнергә кыстап башын катырудан туктадылар.

Сул кулын сугышта төптән үк кистереп атса да, Дилиярның ирләрсез калган авылда дәрәҗәсе зур иде, аны башта—мәктәп директоры, бераздан колхоз рәисе итеп куйдылар. Нәфисәне карарга вакыты җитмәсә дә, Дилияр инде икәүләре генә яшәячәкләренә аны ныклап күңдерде, бераздан әнеңне дә яныбызга алырбыз, колхоз эшләрен генә җайлыйм да, дип еш сөйләштергәли башлады. Кызым, мин менә бу кулны төптән үк кисмичә

дә калдыра ала идем, сезнең хакка югалттым, врач, бармакларсыз гына барыбер өеңә кайтармаслар, бу әле сугышның башы, ин-ин котырган чагы, исән-имин кайтуыгыз икеле, балаларыңны кем карар, дигәч, күз яше белән ризалаштым,—диде ул бервакыт, юк килеш тә янгырлы көннәрдә сызлап газаплаган сул кулы урынына буш җиннәрен уа-уа.

Көннәр үтә торды, Нәфисәнең дә әниле булу теләге басылды, ул инде үзе дә кул арасына ныклап керә башлады, һәм әтисе, ана бик нык ышангангамы, йөрәге бик нык ашалгангамы, инде исәеп килгән Римзилне дә үз яннарына алды.

Язгы көннәрнең берсе иде. Ашарга такырайган, утыннар ягылып беткән чак. Базда орлык бәрәңгеләр генә калып килә. Он болгаткан аш ашап утырган көннәрнең берендә ишектән Алма апалары килеп керде. Килеп тә керде, Нәфисәне кочаклап, әйт әле әтиеңә, әниең булыр идем, дип елап та җибәрде. Кыз бер ана, бер еракта күнелсезләнеп, бу хәлләрне өнәмичә басып торган әтисенә карады, ни әйтергә белмәде. Укытучысы аның саен Нәфисәне ныграк коча, аның саен күзләренә ныграк ялварып карый иде, ахырда кыз түзмәде, Алма апасының ач чагында ипи ашатканы да исенә төшкәч, үкереп елап җибәрде.

Иң авыры, әлбәттә, Дилиярга иде. Анын Алмага өйләнәсе килмәгәне бөтен йөзенә чыккан, тик бу турыда сүз белән әйтеп кенә бирә алмый. Ахырда ул Нәфисәне Алмадан аерып алып җитәкләде дә, туганнар белән киңәшим әле дип күршедә яшәгән бабаларына кереп китте. Нәфисә моңа бик тә ышанган иде, әмма Дилияр монда тынычланырга, Алманың үзләреннән китеп барганын көтәргә генә кергән булып чыкты. Кич житте. Караңгы төште. Каршы як капка ачылмады да ачылмады. Ахырда сабырлыклары бетте, алар кире үз өйләренә керделәр. Ә анда, өстәл кырындагы сәкедә һаман да чәчбашы тузгыган, елаудан күзләре шешенеп беткән Алма апалары утыра һәм йокымсыраган Римзилне көйли-көйли генә кулларында тирбәтә иде.

Нәфисәнең шунда ук изрәп яткан Римзил урынында буласы, нәзек куллары белән Алма апасының муеныннан кочаклыйсы, анын матур әкиятләрен тыңлыйсы, тын аккан чишмә кебек җыры астында йокыга китәсе, яратып, әнием, дип эндәшәсе килде. Бу теләкләр шундый көчле иде, ул түзмәде, әтием, минем шундый да әниле буласым килә, Алма апаны үзебездә калдырыйк, дип, Дилиярның кулына асылынды.

Алма апалары белән тора башлагач, Нәфисәләр йортына нур инде. Йорттагы бөтен чүпрәк-чапрак янарды, тормышлары да бөтәебрәк китте. Алар ишәйделәр, Алма апалары бер-бер артлы өч бала алып кайтты. Сугыш та бетте. Чыр-чулы, шаулап-гөрләп торган йортта яшәве, бер караганда, күнелле дә кебек иде, әмма Нәфисә боекты. Алма аны какмады, сукмады, үзенең бер баласын да якынайтмый торган, тәртиптә тоткан, кырыс бер укытучы иде ул. Әмма кыз анын үз балаларыннан барыбер көнләште, чөнки аларга көннең һәр минутында әни дип әйтү хокукы бирелгән иде.

Әле беренче таңда, кояшның тәүге нурлары белән үк, әнием, дип күзләрен ачкан Нәфисәне якты чырай белән хәерле иртә теләгән Алма апасының:

—Үскәнем, әни ике булмый ул, синеке үлгән бит инде, мин апа дигәнеңә дә ризамын, Әнисә урынын дәгъваламыйм,—дигән сүзләре өшетеп җибәргәндәй итте.—Римзил әле кечкенә, менә аңа ничек әйтсә дә ярый...

***

Еллар узды. Нәфисә Байкөчекне калдырып Казанга китеп барды. Авыл капкасына кадәр озата барган, инде олаебрак та киткән Алма апасы, кулындагы чемоданын тоттырганда яшь аралаш әйтә куйды:

—Инде менә үз кызым кебек булып беттен, син киткәч бик сагынырмын...

Нәфисә жанга якын тоелырга тиеш кебек бу сүзләрдән өнсез торды, бераздан елмайгандай итте дә, хушлашып, артына борылмый-нитми генә, автобус тукталышлы күрше авылга таба атлады.

Нәфисә белән Алма апасының арасы, гомер узгач, үз балалары арасыныкыннан да ныграк якынайды. Энел-сенелләре кырыс холыклы, йомшак сүзгә саран укытучы әниләреннән шактый читләшеп, Дилиярга сыенырак үскәннәр иде. Алар эшкә булган, ярдәмчел, чибәр Нәфисәне дә бик яраттылар, апа-апа гына дип тордылар.

Әле кайчан гына ишегалдын тутырып уйнап йөргән балалар үзләре дә әни-әти булып беттеләр, илнең төрле почмакларында танылган кешеләргә әверелделәр, әмма туган йортларын онытмадылар. Алар соңгы елларда әтиләренең вафаты көнендә бергә жыелырга күнектеләр.

Иң соңгы кайтуларында аш мәжлесендә догаларны йомшаган, дин юлына баскан, килешле итеп ак яулыкларын япкан Алма укыды. Инде аны авылдашлары, элеккечә Алма Тәминдаровна дип түгел, яратып Алмазия әби дип йөртәләр иде.

Догалар кылынып, күрше-күлән таралып беткәч, балалар, түр өйдә хәл-әхвәл сорашырга, үз тормышларын сөйләргә дип әниләре тирәсенә жыелды. Савыт-саба жыеп соңгарак калган Нәфисә тупсадан узганда аларның, әни дә әни диешүеннән, бөтен балачагы исенә килгәндәй, кинәт туктап калды. Күз төпләренә утырган яшь тамчыларының менә-менә агып төшәргә торуына бөтен кеше игътибар итте.

Нәфисә бу вакытта үзен дөм ятим, кирәксез, чит кебек тойды, алар янына таба атларга базмыйча, бер читкә барып утырды. Ак шәлгә ябынган, күзләре бик ягымлы караган, аякларына Нәфисә алып кайткан жылы оекбашлар, өстенә ул бүләк иткән алма сурәтле күлмәк кигән бу әбекәй ана бик кадерле жан да кебек, әмма ана барыбер дә, әни, дип әйтергә ярамый иде.

Бүлмәгә урнашкан тынлыкны Алма апасы үзе бозды:

—Нәфисә кызым, якынрак кил, инде әтиең дә вафат, иң якын кешең булып калдым, хәзер, әни, диергә дә ярый торгандыр.

Нәфисә ничә еллар көтелгән ул сүзләрнең жанына таш булып бәрәчәген көтмәгән иде, үпкәләгән, ярсыган сабый бала шикелле өйдән чыгып йөгерде. Яшьлеге узган болын буйларын урагач, чишмәгә төшеп салкын сулар эчкәч, зыяратка барып дога укыгач, әнисе каберендә озаклап яшь түккәч, әтисе белән икесе генә яшәгән иске өйләренә әйләнеп кайтты ул. Йортның йозаклары алмаштырылмаган һәм бер ачкыч һаман да аның кесәсендә йөри иде.

Нәфисә бөтенләй тынычланган кебек иде, әмма такталары ныклыгын югалткан, күгәннәре шыгырдап ачылган чоланга узуга ук, тагын элекке халәтенә кайтты. Ул, астына качып, әле Алма апалары алар йортына күчеп килгәнче, әни, дип әйтергә өйрәнгән өстәл юк иде. Әллә ярып ук якканнар микән? Күзенә тагын яшь бөялде. Өйгә керәсе итмәде. Сул якка—ак келәт ишегенә таба атлады. Өстәлне анда күчергәннәр, Нәфисә үзе дә кечкенә тәбәнәк балалар өстәле астына инде сыярлык түгел икән. Хәзер ничек итеп әни дияргә өйрәнәсең?

*2009*



Әлфия
Ситдыйкова

# ИҢНӘРЕМДӘ ӨМЕТ-КАНАТ

***

**Өметләрдән алданам да...
Ялганам да—хыялларга.
Менеп басам—уем белән—
Буем җитмәс кыяларга...**

**Алданулар, ялганулар,
Сагыш тулы минем гомер.
Ышанамын: югалтулар
Аша миңа бәхет килер!**

**Ничәнче кат йотты упкын
Бөтенләе белән мине...
Үлгән саен терелә м дә,
Яшәп туя алмыйм, тиле.**

**Шул ышаныч сүнсә генә
Терелә алмам кебек кабат.
...Кыя тауда басып торам,
Иңнәремдә өмет-канат...**

***

**Беләбезме яшәү кадерләрен,
Беләбезме Вакыт кадерен?!
Яшибезме онытып хөрлек хисен,
Сүзсез үтәп ятлар әмерен?**

**Эчке тоем җаныбызны илтеп
Мәңгелеккә беркөн ялгарын—
Гомер йомгагының яртылабы
Сүтелгәчтен генә аңладым:**

**Җан әрнүем халкым әрнүенә
Кушылганын сиздем шул көнне.
Авыруга сабыштырган әрнү
Бәйләп куйды өмет-иркемне.**

**Ничек яшим, туган илем, телем—
Киләчәгем бәйсез булмагач?
...Төрле яктан кар-боз бәреп яуса,
Бөреләрен коя алмагач.**

---

*Әлфия СИТДЫЙКОВА — шагыйрә; Чаллы һәм Казан нәшриятларында дөнья күргән берничә китап авторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Чаллыда яши.*

Бөре койган агач чәчәк атмас,
Бирә алмас алтын алмасын...
Әрнүеңнән арынып, и милләтем,
Киләчәккә гомереңяласын.

***

Чигенүнең соңгы чигендә без?!
(Саттык телне, саттык милләтне?!)
...Тамак өчен җан асраган бәндәм,
Бармы җирдә башка кыйммәтең?!

Җаныбызга бүген кемнәр хуҗа?—
Санны көчкә сөйрәп атлыйбыз...
Таланган ил тавышын ишетмәсәк,
Суларга да юктыр хакыбыз.

Без бүгеннән уяныргa тиеш,
Уятырга тиеш күршене:
Иле, теле, гореф-гадәтләре
Кеше итә җирдә кешене!

Бетәбез ... дип зарга башың бәрмә,
Җаның әле саның эчендә.
Үзгеңә таян егылганчы,
Бердәмлекнең таян көченә!

***

Күкне томалаган күксел болыт
Кай тарафтан безгә килгәндер.
Бәлки—инде күптән без оныткан
Болгар дигән изге илдәндер.

Телне, илне, гореф-гадәтләрне
Яңартырга теләп хәтердә,
Тәрәзәне шакый көзге яңгыр:
—Үткәннәрне барла, кадерлә!

Гасырлардан урап кайткан тарих—
Өне шакый безнең аңнарны.
Гомер елгабызның юлы чикле,
Килер буын безне барлармы?!

Күкне томалаган күксел болыт
Уйчанланып бага күзләргә.
Табигатьнең телен аңлый башлый—
Кергәч кеше бары көзләргә...

***

Ашкыну күзенә
Күпме гамь, наз сыйган.
Кеше мин һәм тиеш
Ярсырга яз сыман.

Чишмәдәй ургылып
Бәрелдем ташларга.
Көч бирде иманым
Яңа юл башларга.

Бәхеткә сусаган—
Мең чакрым җир гизә...
Алкын су булып мин
Кушылдым диңгезгә.



# Миңнеруй

## Гөмбәз бишегендә

**Шомырт исе сибелгән төн—сихри,
Тансык сулкылдаулы балкышта...
Оныттырыр өчен барлык көннәр
Төнем белән әле дә алышта:**

**Әледән-әле балкып кояш чыга,
Ләйсән яңгыр китә чылатып.
Оныт инде, диеп, ялвара җил—
Ялваралар, мине елатып.**

**Болыт агышларын сабыр гына
Күтеп торган нурлы ай кебек,
Әледән-әле балкый күңелемдә
Язлар белән киткән төн—көлеп...**

**Онытырга куша якты таңнар,
«Оныт» диеп яза каләмем...
Шомырт исе бөркелгән төн—күптән
Гөмбәз бишегендә галәмнең.**

## Ярсу атлардыр без...

**Ярсу атлар нинди була дисәм,
Синең йөрәк җавап бирә күк:
«Бу дөньяда чабышкыдан чыдам
Булган мизгелләр шул миндә күп...»**

**Синең канда тормыш сөю тәме,
Ә җаныңның күге ап-аяз...
Гомер фасыллары—синең өчен
Мәңге яшел, мәңге гүзәл яз.**

Миңнеруй ГАЙФУЛЛИНА-ХӘБИБУЛЛИНА—*шагыйрә; «Күңел чишмәм», «Кешеләргә әле кирәк мин», «Зөһрә һәм диюләр патшасы» исемле китаплар авторы. Аксубайда яши.*

Ару-талу синнән ерак ләкин,
Йөрәгеңдә сагыш еш кунак:
Яшәү сөйгәннәрнең йөрәгендә
Имән түгел сагыш—тал-куак.

Тау суыдай ташкын синең гомер,
Тау-ташларны җиңеп агадыр.
Гомер ташкыныңнан җылы эзләр,
Матур эзләр генә каладыр.

Эзләреңә тулган тау суында
Чагыла Күк-Гөмбәз бизәге.
Бизәкләрдә уелып калган, дустым,
Кавемебезнең корыч үзәге.

«Ярсу атлармы без, Тәңрем?!» дисәм,
Җавап чигә зәңгәр Гөмбәзем:
«Чыдам чабышкылар кавеменнән сез,
Ялыгызга үрдем ак бәзем!»...

## Яшәүгә мин гашыйк

Җем-җем итә сары гәрәбәсе:
Алтын йөгертелгән урманга.
Янып торган кызыл тәлгәшләрне
Муенсалар иттем уйларга.

Утлы күмер—балан тәлгәшләре,
Якын килсәң, ялкын алыр күк.
Шул баландай утта януларым
Гомрем буйларына барыр күк...

Хисләремә кереп чума каен,
Челтәр шәлен җилдә уйнатып.
Йөрәгемне көзләр җилкетәдер—
Казлар хушлашуын уйлатып.

Каен шәле чуклы икән, дуслар,
Бизәкләрен кемнәр чиккәндер?
Туар таңга,үлемсез өметкә
Мине кемнәр гашыйк иткәндер?

Үреләм дә карыйм,үреләм дә...—
Каз юллары эреп сүнгәнче.
Мин гашыйкмын җиргә, көзгә, әйе,
Яшәүләргә гашыйк—үлгәнче.



Фирүзә
Җамалетдинова

# ИСЕМНӘРЕ ИСКӘНДӘР...

ХИКӘЯ

Күзнең көннәре төрле була. Кайчакта пыскак янгыр сибәли дә сибәли. Бу мәлдә гүя тамчылар булып хатирәләр коела. Салкын, караңгы һәм дә дымсу көндә адәм баласы ниндидер яктылык эзли... Таба да. Бу—гомернең мәңге кояшлы ягында калган балачак хатирәләре. Без җәй буена бергә уйнап, көзен мәктәпкә акбур, акшар, тузан исен һәм дә бер-беребезне сагынышып килгән балалар, инде күптән төрле якларга таралышканбыз. Очрашканыбыз да юк диярлек. Нишләмәк кирәк, иртәләр арасында киртәләр бар...

Ачык ишектән:

—Сезне телефонга чакыралар,— дигән тавыш ишетелде.

—Кая, кем чакыра?—дип эш бүлмәсеннән атылып чыктым мин. Авылда карт әнкәй япа-ялгызы, ул-бу булмагае, дигән шик йөрәгемне көйдереп үтте.

—Кем икәнен кем белгән, классташыгыз ди, бизнесмендыр мөгаен, тавышы көр күренә...— диде хезмәттәшем.— Хәкимова ди... Кара, Хәкимова иденме соң син кыз чакта?..

Мин Искәндәрнең тавышын таный алмыйча шактый азапландым.

—Көне шундый бугай, күкләре дә әллә ничек, балачакны искә төшерә. Кырда бәрәнге алган көзләрне...— диде ул миннән нидер көтеп.

—Иләп кенә тора шул...—дип кушылдым мин дә.

—Әйдә, Ләйлә, килим әле мин сиңа. Берәр җирдә сөйләшеп утырырбыз....

Мин киенеп тә тормыйча беренче катка төшеп киттем. Ул арада кара джип без эшли торган бинаның ишеге каршына килеп туктаган иде инде. Әлбәттә затлы машинаны күрми калу һич мөмкин түгел. Дөнья бае ул хәзер, дип сөйләшкәннәрен ишеткәләгән булсам да, бер дә әһәмият бирмәгәнмен икән.

Читенсенеп булса да кочаклашып күрештек.

—Кеше күз алдында әллә ничек, читен, Ләйлә, әйдә берәр ресторанга барып утырыйк,— диде Искәндәр.

---

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА—*язучы; «Утлы җил», «Яшен күзләре», «Толымлы ай» исемле китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

Укып бетергәннән бирле күрешкәнебез юк икән шул безнең. Авылга кайткач, әниләр аша сәлам тапшырышудан ары уза алмыйбыз.

—Алайса пальтоны эләктерә төшим,— дидем мин бу тәкъдимгә каршы килмичә.

—Кирәкмәс, машинада жылы,— диде Искәндәр,— мин сине шушында ук кайтарып куярмын.

—Хәтерлисеңме, без бала чакта Сәкинә апа бер хикәят сөйләгән иде:

Ике мосафир туннель аша чыгып баралар ди. Шуларның берсе сукыр икән. Юлның нәкъ урта бер жиренә житкәч ут сүнгән ди. Кинәт икесе дә туктап калганнар.

—Нигә туктадык без?—дип сораган сукыр мосафир.

—Ут сүнде,— дигән тегесе.

—Хәзер нишлибез инде?

—Хәзер ут кабынганны көтәбез,— дигән күзлесе.

—Юк, ди икән сукыр мосафир,— хәзер сине мин алып чыгам инде.

Шулай алар туннель аша чыгып ары киткәннәр ди. Ә ут янганны көтүчеләр әле һаман туннельдә басып торалар ди.

Рульгә тотынган көе башын артка ташлап көлде Искәндәр.

—Кайсыбыз сукыр була инде безнең?

—Кем белгән инде аны?—дип көлеп жибәрдем мин дә.

Аннан ул:

—Кара, синең әллә ниләр хәтереңдә, минем балачакны искә төшерергә һич вакыт юк,— дип тын калды.

Без мәктәптән авыл башына житкәнче очар кошларны күздән ычкындырмыйча, аларга кызыга-кызыга карап кайта торган идек. Тизлекләре зур, үзләре иркле, бик тиз күздән югала иде алар...

Инде машина очар коштай жилдерә. Без әллә нинди таш урамнар аша үтәбез. Болар берсе дә балачагыбызны хәтерләтмиләр генә түгел, безне ул дөньядан аерырга телиләр иде.

—Моннан да затлырак ресторан юк бу шәһәрдә,— диде Искәндәр машина ишеген ачып мине төшергәндә.—Монда шәһәрнең элитасы йөри.

Әлбәттә Искәндәр ресторанга кем белән килгәнен бик яхшы белә иде...

—Жаның теләгәнен сайла... Кара икра белән бутербродлар да бар анда. Кыйммәтле ризыкның сыйфат һәм тәм бәһасе чагыштыргысыз...— диде ул кара күзлек астыннан серле карап. Безнең янда кыска итәкле яшь һәм чибәр официант кыз басып тора икән, йокыдан яна уянгандай сискәнеп куйдым. Аңа күтәрелеп карадым.

—Миңа берәр төрле салат белән кайнар чәй бик житкән,— дидем өстәлдәге меню язылган кенәгәгә карамыйча да.

Кыз мыскыллы елмайды. Нинди авыл мокытын ияртеп килгәннәр янәсе...

Мин аңа үпкәләмәдем. Чөнки моңа язмыш гаепле иде. Язмыш безне—кояш чыгышы белән кояш баешын, байлык белән хәерчелекне бер өстәл артында чәкештерде.

Әмма бу табында мине гажәпләндерерлек берни дә юк иде. Бәрәңге боткасы белән гөмбәле бифштексны үзем дә тәмле пешерәм. Гөбәдия дә табыным өчен ят түгел. Бәйрәмнәрдә булса да кара икраны да авыз итештерәбез...

Бюджет карамагында эшләү ул даими мул яшәтмәсә дә ачка үләргә ирек куймый. Чөнки дәүләт дигән сүз бит инде ул... Безгә карап дәүләткә бәя бирелә.

Түшәмнән чекрәеп карарга тырышучы тоныкк күзле лампалар да минем рухымны яктыртмый. Гомумән, мондый йортлар һич тә минем өчен түгел икән. Монда яшьлекне искә төшерәсе дә килмәс. Мин шуны аңладым. Уйларым белән әллә кая, авыл тарафларына очтым.

***

Сыйныф ишеге сыкрап ачылды. Укытучы апа исәнләшергә дә онытып күзләре белән Искәндәрне эзләп тапты.

—Сине өегездән эзләп килгәннәр, Искәндәр. Атлы агай көтеп тора анда...

Укытучы сүзсез калды. Җавап көтеп малайга карады. «Әнине ераккарак дәваланырга җибәрмәкчеләрдер мөгаен»,—дип уйлады бугай Искәндәр сумкасына китап-дәфтәрләрен тутырганда. Күрше авыл интернатында ул әле беренче елын гына укый, шуңа күнеле күп очракта әнисе янында. Аның авырганын да белә, әмма «тиздән терелэм, менә күрерсез...» дип юатканын да өйгә кайткан саен ишетә иде. Уйларына бирелеп, борынын тарта-тарта, пәлтәсенең муен төбендәге бер төймәсен элэктергән көе Искәндәр класстан чыгып китте. Ишек сулкылдап ябылды.

—Искәндәрнең әнисе үлгән, балалар,— диде укытучы парлы тәрәзә аша сыйныфташыбызны озата баруыбызны күреп. Тәрәзәләр буйлап буй-буй тамчылар тәгәрәп төште. Тамчы эзләреннән караңгы күк йөзе ачыграк та күренә: соргылт болыт адашкан коштай куркынып катып калган иде.

—Дәресне башлыйбыз, балалар,— дип йомшак кына эндәште укытучы. Күзләр сыйныфка күчте. Тик класска әллә ни булган: мизгел эчендә ул котсыз, караңгы һәм шыксызга әверелгән түгелме? Һәркем үз уена чумган; без үзебезне Искәндәр урынына куеп караган бер мәлдә, әнигә әҗәлне түгел, җилне дә якын китерәсебез килми иде. Үлем белән яшәү чиге якынайганда, әнидән дә кадерлерәк затның дөньяда була алмавын беренче мәртәбә аңлаган әрнүле мизгел иде бу.

—Балалар,—диде Сәкинә апа безне авыр уйлардан бүлеп,— Искәндәр хәзер ятим, аның әнисе кайтмас инде, сезнең әниләрегез, Аллага шөкер, исән-саулар. Тәмле әйберләр пешерәләрдер... Кабартма, коймак алып килсәгез, Искәндәрне дә өлешсез итмәссез...

Мәктәпкә Искәндәр әнисенең өчесен уздырганнан соң килде. Әллә нишләгән иде ул. Күзләре төссезләнеп калган, бармаклары Шүрәле бармакларыдай уйнап тора. Апа такта янына чакырганда алар ешрак та хәрәкәтләнәләр сыман. Искәндәр тартмадагы озын акбурны кулына алып, тактага яза башлый. Акбур шарт сына да икегә бүленеп идәнгә тәгәри. Такта каршысына—идәнгә гүя энже бөртекләре чәчелә. Безнең кот оча; хәзер орышачак инде апа аны... Нигә зурына тотынырга инде, җә? Алдан әзерләп, бүлеп-бүлеп куйган акбурлар да әллә ничәү бит югыйсә. Әмма, әлегәчә бу хәлне кичерә алмаган Сәкинә апа күзлеге өстеннән карап, кетер-кетер көлә. Аңа без дә кушылабыз. Иллә дә күнелле була.

Әнисе үлеп бер атна үткәч, Искәндәрнең туган көне булды. Без аны уртага алып:

«Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Искәндәр.
Бәхеткә илтәсе җилләр
Сезнең яктан исkәннәр»,—дип җыр җырладык. Карандаш белән сызыклы дәфтәр бүләк иттек. Беренче кат шунда елмайды ул...

Искәндәр минем арттагы партада утыра. Дәрес вакытында аның сары толымнарым очындагы ап-ак тасмаларымны учларына алып кысканын сизеп торам. Тик Искәндәрнең бер кат та минем чәчләремнән тартканы юк. Ул берәү генә шундый. Кызларны рәнҗетми. Югыйсә, безнең класста кызлар башын май чүлмәгенә дә санамаган малайлар әз түгел. Кайчакта «Русская литература» китабы башка килеп төшкәч, күзгә Пушкин күренә башлый...

Ә безнең кышлар турында үзе бер кыйсса язарлык...

***

—Искәндәр, син капка төбегездәге тауны хәтерлисенме?

—Хәтерләмичә...

Ул күзлеген салып сынар колагыннан эләктерде дә пиджагының күкрәк кесәсенә элеп куйды. Күзләре шундый якты иде аның. Түшәмдәге лампочкалар түгел, гүя бу залны Искәндәр күзләрендәге нур яктырта иде.

—Теге зур чананы беләсенме кем ясап бирде? Әхмәдулла бабай... Ясап бир инде дип аптыратып бетердем мин аны... Таудан кем кызын утыртып төшмәкче буласың, ди. Ә мин тоттым да әйттем: Ләйләне дидем. «Ләйлә утырмаса нишләрсен?»—ди картлач. Ул утырмаса, Раиләне утыртырмын дидем... Кстати, Раиләне чирли дип ишеткән идем... Мин ана ярдәм итә алам...— диде Искәндәр кулын калын кесәсе ягына хәрәкәтләндереп, һәм авыр сулады:

—Их, яратмадыгыз, кызлар, сез мине... Яратмадыгыз.

Раиләнең чирләгәнен авылда өч-дүрт кеше генә белә. Шуларның берсе—мин. Очраклы рәвештә ишеттем... Авылдан килешли күмер ала чыгыйм дип, аптекага кагылдым. Әнкәй янында сый-хөрмәтнең иге-чиге юк. Безнең өчен пешергәч, әнинең күнелен без ашап күрәбез... Үрдәк, каз бәлешләре артыннан күмер кабып җибәрсәң, ашказанына хәл кергәндәй була...

Аптекада Раиләнең кызы нәкъ әнисенең яшь чагы булып каршыма килә. Туктап калдым. Әллә ничек, яшьлегем белән очрашкандай булдым. Әнисенә кирәкле даруны таба алмаганга кәефе кырылып чыгып бара икән ул.

—Ләйлә апа, сезме бу? Абау менә кайда күрешергә язган,— диде кыз елмаерга тырышып.

—Берәр хәл юктыр бит, Лилия сенелем?—дип сорадым мин аның борчулы кыяфәтен күреп.

—Юк та... Дару эзләп килгән идем. Булмады...

—Нинди дару кирәк соң? Бәлки мин булыша аламдыр. Апаның эше аптекалар белән бәйле... Хәер, беләсең инде.

Лилия дару исемен атауга бар гәүдәмә каз тәне күтәрелде.

—Кемгә кирәк ул?

—Әнигә,—диде Лилия.— Тик беркемгә дә әйтмәгез инде, Ләйлә апа...

Әлбәттә без әле моннан сон да Лилия аша авылга дарулар җибәреп тордык. Әлбәттә бездән сүз чыкмады.

Ә Лилия бездән башка да ул даруларны таба алыр иде. Аның әнисен әллә ничә кат санаторийга урнаштырып ял иттерүен бөтен авыл белә. Больницага ятса да санаторийда дип уйлыйлар. Лилиянең машинасы кулында. Андый иномарка белән безнең авылга ике генә кеше кайта. Берсе—Искәндәр, икенчесе—Раиләнең кызы. Утырта да, ала да китә ул әнисен, ала да китә. Лилиянең Казанда ике фатиры барлыгын да беләләр авылда. Тагын да бардыр... Тырыш һәм ушлы бала шул ул.

Нигәдер безнең ярдәмгә Лилия каршы төшмәде. Әнисенең күнелен күрер өчен ахирәтеннән дә берәр яхшылык эшләтәсе килде бугай. Без даруларны ихлас күнелдән шифасы булсын дип юлладык. Шифа табуын Раиләнең үз авызыннан ишетү безгә олы сөенеч булды.

—Раиләгә берәр ярдәм кирәк булса, мин булыша алам,— дип кабатлады Искәндәр.— Һәм бер якка кәкрәеп кесәсеннән кирпеч калынлыгы акча төргәген тартып ук чыгарды.

—Белмим шул...— дидем мин битараф кына.

Искәндәр миңа гаҗәпләнеп карап торды, әйтер сүз тапмады. Төргәкне шактый интегеп янә үз урынына урнаштырды.

Бер тынга икебез дә сүзсез калдык. Ул ни уйлагандыр, белмим. Ә мин бу мәлдә Аллаһының кодрәтенә шаккаткан бер таш сын идем. Йә күр инде син, Раиләгә ул чирен биргән, әмма аны байлар каршында иелерлек итмәгән...

—Беләсеңме, Ләйлә,— диде Искәндәр,— тугызынчы класста укыган кышта, Раиләне озата баргач, ул оч малайлары мине әт итеп кыйнап җибәргәннәр иде. Борыннан кан ага да ага, һич туктамый гына... Битне кар белән юдым да өйгә йөгердем... Әти белән әни мине күрмәделәр дә имеш... Минем малайга сугып карасыннар шулай! Бармак очлары белән кагылып карасыннар әле! Күрсәтер идем мин аларга!..

—Безнең заман малайлары җегет иде шул һәммәсе дә,— дип сүзне ялгап киттем мин.—Сиңа шул бер генә эләккәндер инде. Анысы да ялгыш кына дигәндәй...

—Әйе шул... Шулайдыр да шул...—дип елмайды Искәндәр.

***

Көзнең көннәре төрле була. Еш кына берөзлексез пыскак яңгыр сибәли. Ул тамчылар да безнең кебек төрлеләр. Кайсыдыр минем керфек очына куна, кайсыдыр Искәндәрнең битенә сырыша, кайсыдыр туп-туры җир куенына чума. Без күп, һәм төрле булсак та, күрше авылга укырга йөрсәк тә, туган авылыбыз бөтенебез өчен берәү генә. Җәй буена без аның урманында мәмрәп торган җиләкле аланнарыннан чыга алмыйбыз, күз ачык көе зәңгәр күккә карасаң—зәңгәрлектә җиләкләр биешә; чиләкләр тула, әмма күз туймый. Киң болыннарында көтү көтәбез. Көз көне аның иркен кырларын инләп-буйлап уңыш җыябыз.

—Бу кадәре хөрмәткә дәүләт ничек чыдар, сез безне дә уздырмакчы, парин,—дип көлеп калды минем бабай кырга озатканда... Искәндәрне ул көнне ят бер апа озатты. Урамга ук чыгып, тунмыйча, исән-сау эшләп кайтуыбызны теләп, капка баганасына сөялде... «Әтисе яна әни алып кайткан»—дип пышылдады Сәвия күршем.

Йөрәгем кинәт кысылып куйды. Искәндәр бик тә, бик тә кызгыныч булып китте. Без ул көнне дәрестә «Үги ана» әкиятен үткән идек шул...

Пыскак яңгыр сибәли дә сибәли. Без кыр ягына җыелдык. Курткалар юка, һәммәбез яланкул. Юк, юк... һәммәбез дә түгел. Искәндәрнең кулында ап-ак пирчәткәләр... Пирчәткә эчендә аның бармакларының тагын да житезрәк, газаплы хәрәкәтләнгәне сизелеп тора. Кыр капкасына якынлашканда мин артка борылып карадым. Томан эчендә авыл җәйрәп ята. Томан эчендәге капка төбендә Искәндәрнең яңа әнисе ак шәүлә кебек кенә күренә иде.

Ул арада машина килеп туктады. Әрҗәсенә төялешеп, көйсез машинаны тигезсез тавыш белән үкертеп, көч-хәлгә кыр ягына чыктык. Пыскак яңгыр гына туктарга җыенмады.

—Ай-һай, ни эш кыра алырсыз икән? Яңгыры да салкын...— диде шофер Фәргать абый.

—Әллә кермиктәме соң инде бу басуга?—дип уйга калды укытучы апа.— Әйдә, кермибез,—диде ул үз соравына үзе җавап биреп. Без өшеп кызарган юеш кулларыбызны уа-уа шаярыштык, юктан да кызык табып көлештек. Ап-ак пирчәткәләрен киеп Искәндәр бер кырыйда һич хәрәкәтсез басып торды.

—Әйдәгез, балалар, кайтыйк булмаса...— диде Сәкинә апа үкенечле тавыш белән. Без яңадан әрҗәгә төялештек. Машина кырыенда үзе ап-ак, үзе йомшак куян балаларын тоткандай, учларына карап, Искәндәр генә басып калды.

—Туктагызчы, әти хатынының пирчәткәләрен буяп алыйм әле мин,— диде ул һәм иелеп ике кулын дегеттәй сазга батырды...

Минем күз алларым караңгыланды. Хәтта апа да бер сүз дә әйтә алмады. Искәндәрнең әнисен бик тә-бик тә яратканын белә идек шул без... Шуңа аны кызганып, көн саен кем дә булса беребез кабартма, йә коймак алып килә идек. Тик нигәдер алмый иде ул аларны. Хәер, чит әниләр пешергән кабартманы кем яратып ашасын инде?! Үз әниең булмаганда бигрәк тә...

Аннан энже чәчәк кебек читтәрәк, тынрак, күләгәдәрәк калырга яратса да, ялгызлыкны өнәми иде ул. Яңа әни килеп кергән йортта үзен япа-ялгыз хис иткән күрәсең. Күрше апаның әнигә сөйләгән сүзләре минем дә колакка чалынды. Искәндәр мендәре астына ипи кисәге яшергән. Ашамаган ул аны, шул көе йоклап та киткән. Иртән торып мәктәпкә йөгергән. Яшь ана урын җыя башлаган. Искәндәрнең мендәрен күтәрсә, ни күрсен—каткан ипи телеме тәгәрәп ята икән...

Үги әни моны елый-елый сөйләгән ди. Авылда да кешеләр төрле: кемдер җәлли, эчкерлерәкләре сөенә. Әмма Нурхәят апа, ни авырлык күрсәм дә, Ходай каршындагы олы вазифадан качарга җыенмыйм: үземнеке дип кабул иттем инде мин Искәндәрне, дигән имеш...

Чынлап та Нурхәят апа хакындагы һәр гайбәт әйбәт иде. Хәер, аларны гыйбрәт итеп кенә сөйләгәннәрдер. Авыл ул күрү белән чит кешегә бәя бирми. Бәһане безнең авылга килен булып төшүчеләр кылган гамәлләре белән яулап алалар.

Кышын, ял көннәрендә, без капка буена өелгән таудан чана шуабыз. Искәндәрләрнең капкасы безнекеннән тәбәнәгрәк, таулары биегрәк булганга чаналарыбызны өстерәп шунда җыелабыз. Бераздан саф һавага коймак исе тарала. Һәм йорт яктан тавыш ишетелә:

—Кер инде балакаем, туңгансыңдыр, коймагым да әзер... Җылынгач тагын чыгарсың...

Бу Нурхәят апа була инде.

Ә калганын исә күреп беләбез: мәктәпкә без кабартма алып килгәндә, Искәндәр—өчпочмак, без коймак ашаганда ул сумкасыннан кыстыбый тартып чыгара торган булды... Еш кына аның тәм-томнарын минем белән бүлешәсе килә.

—Ләйлә, борыл әле,—ди ул тасмамнан йомшак кына тартып. Үзе тиз-тиз кыстыбыйны икегә аера.

—Мә, аша, тәмле ул...

Мин кыстыбыйга үрелмим дә. Чөнки минем үз әнием бар...

***

Ресторанның чекрәйгән күзле лампалары мина торган саен ятрак итеп карыйлар. Вакыт-вакыт бөтенләй ерагаялар кебек тоела. Үзем дә аларга теләр-теләмәс кенә күз төшереп алам.

—Мин ел саен Сабантуйга кайтам. Спонсор буларак... Неужели син мине бер дә күрмисең?—дип сорады Искәндәр уйларымнан бүлеп.

Бездә сабантуйлар табигатьнең оҗмах бакчасында үтә. Авылның инкү, бер җилсез, үтә тыныч урыны ул. Тирә-якта урман, сакка таулар тезелеп баскан...

—Кайтсам да минем анда төшкәнем юк шул. Рухташлар юк бит инде анда хәзер,— дидем мин. Әлбәттә Искәндәргә җавабым ошамады.

Ошамаса да сүз әйтмәде, чөнки ул үзе дә яхшы белә: безнең якта сабантуйларга ике төркем халык йөри: спонсорлар һәм алардан нидер өмет итүчеләр...

Спонсор сүзе чыгуга авылыбызның горур манаралы мәчете күз алдыма килде. Искәндәр төзеткән мәчет ул. Хатыны Гөлкәй кайтып өлкәннәрне дин сабакларына да өйрәтә икән әле.

—Мәчет салдыруыңны авылдашлар бик игелекле гамәл дип саный, барысы да рәхмәт укый,— дип дәвам иттем күрше-күләннең сөйләшкәнен ишеткәнем булганга.

—Шулаймы? Авылдашлар шулай диме?!

Искәндәрнең күзләре очкынланып китте.

—Шулай диләр шул.Әйдә берәр журналисттан язып чыгуын сорыйк. Бөтен республика күрсен үзеңне,— дидем янә үз-үземә ихлас ышанып.—

Игелек игелек аша кайтырга тиеш бит инде... Хак түгелме?

Искәндәр башын артка ташлап бөтен залны яңгыратып көлде. Аннан, миңа иелеп, шыпырт кына:

—Зинһар, Ләйлә, язып мине харап итә күрмә,кирпечен кадәр тикшерерләр...— дип куйды. Ни әйтергә дә белмәдем. Мин мәчетләрнең барысы да хәләл кирпечтән салына дип уйлаган идем. Әйткән сүземә чиксез уңайсызландым.

—Авылга бәлки юл салырга кирәктер,—диде Искәндәр сөйләшүне дәвам итеп.— Күрше Ихти агай да кайткан саен шулай ди. Үзе дә сизмичә ул калын кесәсен янә сыйпап алды.— Чишмәне дә авылга борып җибәрсәң була...

Ихти агай турында сүз чыккач мин көлеп җибәрдем. Безнең авылның мәзәгрәк бер җан иясе инде ул. Миңа да ел саен бер үк төрле итеп: «Искәндәрдән юл салдырам быел»,—ди.Аннан өсти: «Замана бозык булыр, юллары төзек булыр...» Искәндәргә бу хакта авыз да ачмадым.

—Зиратка юл юклыктан да бик интегәләр инде авылда. Анда минем әтием дә, синең әти-әниең дә ята. Әби-бабайлар шунда. Бөтен авыл шунда... Барып карасаң берүзең адашып кына жир өстендә йөрисең күк тоела,—дидем мин авылыбыздан күпкә кинрәк мәйданны билгән каберстанны күз алдыма китереп.

—Шулай...— Уйлар хәтерне тирәнәйткән бер мәлдә аның да тавышы калтыранып куйды.

Ресторанның заманча чирәбендә тамчылар биеште. Тышта янгыр бурап-бурап, сендереп ява башлаган иде.

—Озакка бозылдымыни инде көн?—дип сораулы төбәлде Искәндәр.

—Көзнең көннәре төрле була,— дидем мин.

—Шулай...

***

Әниләр әйтмешли, без дә буй життек. Сигезенче сыйныфка күчтек. Чәчләрдәге тасмалар сүтелде. Класстагы кызлардан калышмаска тырышып мин дә толымнарымны кисеп ташладым, шулай итеп Искәндәр белән бер-беребезне тоташтырган бердәнбер жеп өзелде...

Тик безне һаман басу-кырларыбыздан аермадылар. Көзнең көннәре төрле була. Еш кына пыскак яңгыр сибәли. Һаман шулай машина әрҗәсендә барабыз. Янгырга жил өстәп машина кузгалып китә. Бөрешеп, иннәрне күтәрә төшәбез. Искәндәр әкрен генә миңа елыша.

—Ләйлә,— ди ул,— өшисең бит... Кил әле, минем күкрәк жылысын тоеп барсын әле аркаң...

Мин оялудан нишләргә белмим. Ярый аның сүзләрен әни ишетми. Сигезенчегә күчкәч, безгә сыйныф житәкчесе итеп әнине билгеләделәр. Мәктәп бусагасыннан безне әни озатты. Миннән кала ул һәрбер укучысына һөнәр сайларга ярдәм итте. Гел бишкә укыган, химия, биологияне су кебек эчкән кызын—мине ул һичшиксез врач булыр дип күзаллый иде. Ә мин башка якка китеп бардым... Рухи байлыкны сайладым. Уңдыммы соң?..

***

—Миңа юл күрсәтүче синең әниең, Ләйлә. Безнең апа бит инде ул. «Син, Искәндәр, мөгаен, инженер булырсың. Математикаң шәп. Кыяфәтең дә килгән»,—ди берчакны.—Ә мин инженерның ни эш башкарганын һич күз алдыма китерә алмыйм. Төзүчеләр институтына документларымны тапшырганда әйттем: минем инженер буласым килә, апа шулай кушты, дидем... Алдылар... Эшкә дә өйрәтеп чыгардылар...

Әйт әле, Ләйлә, апага ни кирәк?—дип кинәт сорап куйды Искәндәр

янә кесәсенә үрелеп. Һәм шунда ук кулын кире үз халәтенә кайтарды. Ул акчалардан үзе дә арыган иде бугай Искәндәр. Күпкә китсә, чүпкә китә, диләр бит... Хактыр...

—Апага ни кирәк?—дип кабатлап сорады ул.

— Мин моны каян белим? Ни кирәк дисә, шуны без үзебез кайтарып торабыз ана,—дидем мин.— Һаман шунда, Ак Йорт авылының Үзәк дигән урамында яши ул минем әни...

«Үзеннән сора син анын» дияргә теләвемне Искәндәр аңламаганга салышты. Мона сөендем генә әлбәттә. Әнинен укучылары күп. Хәлен белүчеләр дә әз түгел.

—Мин үзем дә шәһәр читендә яшим. Урман өйгә терәлеп тора,— диде Искәндәр кулын кесәсеннән алып. Этемне дә бәйдә тотканым юк, йорт буйлап, рәхәтләнеп йөгереп йөри...

—Ничек курыкмыйсың? Берәрсен таласа нишләрсен...— дип куйдым мин. Искәндәр көлде генә. Оялуымны сиздермәскә тырышып, үзем дә кушылдым. Мин Нурхәят апалар йортын күз алдына китерәм икән бит. Без тормышка икебез ике күзлектән карыйбыз икән. Шул мәлдә Нурхәят апаның сөйләгәне искә төште: «Искәндәрем минем хан сараенда яши. Йорты өч катлы. Янәшәсендә урман. Бер якта борынгы авыл җиргә сыенган.. Икенче якта—«Кинәт байлар урамы» күккә ашкан, анысы—Искәндәрләр ягы була инде»,—дигән иде ул. Мин ул чакта да рәхәтләнеп бер кычкырып көлгән идем.

«Кинәт байлар урамы» дидегезме?—дип сорадым кабатлап. Берәр авазны ялгыш ишеттем мәллә, дип уйладым.

—Авыл халкы шундый исем кушкан,— диде Нурхәят апа һич гаҗәпләнмичә.— Әле дә шушы балам бар, көн дими, төн дими, атна уртасы дими, кайта да житә, әлһәмделиллаһи шөкер. Көзнең көннәре төрле була... Тормыш булгач, ипи-тозы да кирәк... Ходай рәхмәтеннән ташламасын аны...

Көзнең көннәре төрле була. Затлы чирәпкә салкын тамчылар бәрелә. Кайсы йомшаграк төшә, кайсы чирәпне сызып үтә. Алар да төрле.

—Ичмасам, бер виноград та өзеп капмадың. Әйдә мин сина өстәгеләрдән берәү яраткан тортны китертим әле,— диде ул бик таныш хөкүмәт кешесенең исемен атап. Минем күңелне күрергә теләве ихластан иде кебек анын.

—Кирәк түгел,— дип карышсам да өстәл зурлыгы шау чәчкәдән торган тортны безнең каршыга чыгарып куйдылар.

—Юк, юк, кисмәгез,—дидем мин һаман үз дигәнемдә торып.

—Ярар, өеңдә гаилән белән бергәләп чәй эчәрсез алайса,—дип сүзне йомгаклады Искәндәр.

***

—Карале, Ләйлә, син мине бер дә яшьлектән чыгармадың бүген. Минем егерме биш ел буена бу дөньяга кереп тә караганым юк икән бит. Гаҗәп күңелле һәм рәхәт икән бит анда! Рәхмәт сиңа, Ләйлә!

Искәндәр тынып калды. Аннан:

—Беләсеңме, Ләйлә, мин егерме биш ел буена бер тамчы да үзгәрмәгән бер генә кешене күрдем... Ничек шулай була ала икән ул, ә?—дип өстәде.

—Мәктәптән кайтканда, хәтерлисеңме, «җәен соры, кышын—ак» куяннарны...

—Аңа шулай яхшырак,— дип кушылды Искәндәр.— Чынлап та безнең юлга йөгереп чыгуны чүпкә дә санамыйлар иде ул озын колаклар... Урман хәрәкәтләнә... Агач башлары шаулый... Шунда кыр якка йомры йомгак тәгәри...

Ул янә уйлары эчендә адашты.

—Теге туннель аша чыгучылар турындагы хикәятне дә хәтерләдем мин.

Апа сөйләгәне искә төште... Булган икән безнең бәхетле чаклар!

Яшьлек чынлап та, бик рәхәт бит ул. Дөньяда бер тәртипсезлек күрмисең, чөнки анда мәхәббәт бар, хыял бар. Мәхәббәт дөньяны яктырта, хыял аны җимерелүдән саклый.

Машина түбәсенә янгыр җилләп-җилләп бәрә дә бәрә. Парлы тәрәзәләрдән буй-буй тезелешеп тамчылар йөгерә. Тамчы эзләреннән караңгы күк йөзе ачыграк та күренә: соргылт болытлар безнен авыл ягына агыла...

Мин үзебезне озата йөргән шундый ук джипны килгәндә үк күрсәм дә, моңа һич әһәмият бирмәгәнмен. Ул кинәт безнен машинаны узып алга чыкты.

***

Ачы һәм явыз итеп сүгенде Искәндәр. Анын ни рәвешле күзләре зураеп киткәне каршыдагы көзгедә чагылып алды.

—Туктат, төшеп калам мин,— дидем нишләргә белмичә.

—Гафу ит, Ләйлә, әле пәлтәңне кереп алабыз да, мин сине өенә илтеп куям...— дип сөйләнде ул.—Гафу ит, мин бит Искәндәр... Син мине беләсең ич, Ләйлә...

Их мине!.. Әнием авылга кайткан саен «Көзге юлга кием ал, язгы юлга азык ал» дип тукып кына тора бит югыйсә...

Мин бу гамәлне ни дип тә анлый алмадым. Теге машинаны барганда ук күрүем кирәк булган күрәсең...

Күңел һич ышанмый: яман сүзләр әйтеп сүгенүче Искәндәрме? Улмы? Әллә байлыкка мөкиббән китмәвем өченме бу? Әллә минем тырнак астыннан кер эзләвем генәме? Һай яшьлектән ераклашу харап итә лә кешене. Акыл керү харап итә лә,— дип мин аны акламакчы булып та маташтым...

—Менә туннельдән чыгып та життек,— диде Искәндәр, безнен өй каршына килеп туктагач. Мин уйга калдым:

Йә, әйт кайсыбыз сукыр инде безнең?—дип сорадым.

—Тормышта һәркем үзенчә юл эзли инде, нишләмәк кирәк,— диде Искәндәр.

***

—Әни, син нигә розаларыңны суга утыртмадың,—дигән тавышка уянып киттем.— Әти дә утыртмаган. Абый да күрмәгән...

Безнең ирем белән бер-беребездән яшерен серләребез юк. Искәндәр мине бер кочак кызыл розалар һәм бизәкләп бәйләнгән зур торт белән фатир ишеге төбенәчә озатып куйды. Аны ирем дә яхшы белә. Илдә социалистик жәмгыятьне бергә төзегән чорда без барыбыз да вокзалда очрашып, авылга бер автобуста кайта идек... Капитализм баш төрткәч Искәндәр үзенә жәмгыять төзеде. Аннан шәхси машинага күчте. Хәзер рульгә дә сирәк утыра икән ул. Аны башкалар йөртә. Ә без бар күңелебезне салып хезмәт иткән, үзебез ышанган дәүләткә тугрылыклы калдык...

Ирем белән әлеге очрашу турында сөйләшә-сөйләшә йоклап ук киткәнбез. Шыбыр—шыбыр, туктаусыз тәрәзәгә көзге яңгыр бәрде. Йокы аралаш булса да мин аны гел ишетеп тордым. Мондый төндә безнен балачак үзе дә гаҗәеп тәмле бер төш иде...

Урынымнан торып көзге каршындагы тумбага күз төшереп җибәрсәм, шаккаттым: бер кочак кып—кызыл розалар башларын салындырып кибеп ята...

Көзнең көннәре төрле була. Ә бүген минем вакыт-вакыт, пыскак яңгыр сибәләгәндә караңгы күренгән өем шулкадәр дә якты, тәрәзәләремә һәр өлгесе саен нур тулган иде...



Алисә
Зарипова

## КҮБӘЛӘККӘ ТИМӘГЕЗ СЕЗ...

***

**Салкын.. —**
**Ә син беләсеңме ялкын тулы салкын төннәрне?**
**Япа-ялгыз мендәр кочагында**
**Күз дә йоммый таңны көтүләрне?**
**Ялкын...—**
**Сиңа таныш сүзләр**
**Бу мәгънәгә ияме икән?**
**Күзләреңдә тоташ бозлар,**
**Нигә минем ялкын сине ише иткән?—**
**Көтәм...**
**Синең карашыңнан бер назлы нур көтәм...**
**Елмаюың, сүзең шундый кирәк, иркәм...—**
**Сөям...**
**Тын алырга куркып, шәмне кулда тотам...**
**Эреп, тып-тып учка тама—җанга яра сала.**

**Сине сөю генә үтми әле—кала...**

***

**Караш...**
**Синең күзләр миңа төбәлгән,**
**Минекеләр—сиңа...**
**Араларда дивар, дивар, дивар...**
**Күреп шундый каршылыклар—**
**Алып батыр елар.**

**Синең күздә ризасызлык,**
**Миндә—сабыр җебе белән теккән түзем,**
**Ике күзем яшьле, тик нигәдер**
**Әйтер өчен җитми сүзем...**

**Елар өчен яшьне, әйтер өчен сүзне,**
**Сөяр өчен хисне—сорап алмыйлар ла,**
**Бар да үтә, тик моң-сагыш катыш**
**Хисләр кала...**

Алисә ЗАРИПОВА – *КДУ студенты; вакытлы матбугатта даими басылган шигырьләр авторы. Казанда яши.*

***

Күзләреңне миннән яшерәсең,
Елмаясың...
Сөюемне әллә тоясың...
Тоясың да, тыясың да—
Мәхәббәткә киртә куясың...

***

Кытай иле ак чәчәктә әле,
Ак сакура ап-ак яшь коя...
Мин әлегә яратмыйм да кебек,
Тик жил генә эземне куа...

## Күбәләккә тимәгез сез!

Күбәләккә тимәгез сез, очсын әле!
Үтсен очып бар диварны—караңгыны!—
Кояшына очсын әле томырылып,
Тимәгез соң, ул да бит җан,
Ул да бит кан!
Бер гомергә, бер очышка, мәхәббәткә,
Үз назына сусаган аң!..
Ирек биреп алдаганнар:
Кояш—лампа гына икән...
Һәм ул алданута күнеп үлде.
Янып үлде...
Сынып үлде...
Беркемгә дә сиздермичә,
Канат очларында мәхәббәтен кочып.
Яшәвенә дәлил булып бер тап калды
Шул лампада...
Берәү килеп сөртеп алды аны да...
Гүя таплар калдырмаска тиеш Кеше.

***

Яңгыр ява, тәрәзәмне ачтым әле!
Әйдә керсен күкрәве дә, яшене дә!
Үткәндәге бөтен хаталарны
Юып кына алсын әле!
Яңгыр ява...
Шәһәр өстен шарлавыктай элпә каплый,
Кем өчендер Алла бабай һаман әле
Иман саклый...

***

Кар эри...
Быел язлар кабатланып (кабаланып!) килер төсле...
Ташулар да тиз-тиз генә үтәр төсле...
Бар төсләрне бер тамчыга туплап
Ләйсән ява!
Тәүге тамчы—гүя иренемә дәва!

Кыш салкыны яз башында кабатлана.
Көтмәдем лә хыянәтең...—
Җанда яра... Яра...

Октябрь аенда Россиядә үтәчәк халык исәбен алу темасын Башкортстаннан башларга булдык. Чөнки бу республика—татар җанисәбенең сигез ел буе кан саркып торган авыр җәрәхәте ул.

«Бөтен татарлар да—татар»—ошбу «зирәк ачыш» күпчелек укучыларыбызга көлке тоелыр. Ләкин Башкортстанда бу—ике төрле чишелеше булган үзәк мәсьәлә. Биредә арифметика да үзгә: ике икең өч тә, биш тә була ала.

2002 елгы җанисәпнең Башкортстанда ничек үтүе турында журналда язган идек инде.[1] Республикада мондый четерекле милли вәзгыятьне китереп чыгарган сәбәпләр турында Әмирхан ага Еники дә бик борчылып язган.[2]

Биредә без журналист **Фәнис ФӘТХИ**нең галим **Илдар ГАБДРАФЫЙКОВ** белән әңгәмәсен бирәбез.

# БЕЗ—ТАТАРЛАР!

***Быел октябрьдә Россиядә үтәчәк халык исәбен алу—Башкортстан шартларында аеруча четерекле мәсьәлә. Республика татарлары 2002 елда 230 мең кешегә кимеп, халык саны буенча урыслардан кала икенче урыннан өченчегә тәгәрәгән иде. Бу гаҗәп хәлне тарих фәннәре кандидаты, этносәясәт белгече Илдар Габдрафыйков та җентекләп өйрәнде һәм гыйльми тикшеренүләре йомгакларын төрле бәйсез мәгълүмат чараларында бастырып та чыгарды.***

***Башкортстан шартларында әлеге мөһим кампаниягә алдан ук әзерләнә башлау зарур икәнлеген яхшы аңлап, узган ел азагында ук, татар милли оешмалары махсус киңәшмәләрен үткәрделәр. Анда милли хәрәкәт вәкилләре 2010 елгы җанисәпне «Без—татарлар!» шигаре[3] астында алып барырга дип килештеләр. Башкортстандагы этнология һәм этнодемография фәне белән шөгыльләнүче татар галимнәре әлеге саннарны чып-чын хәрәмләшү нәтиҗәсе дип раслый. Илдар әфәнде җитәкчелегендә БР татар милли оешмалары җанисәп уңаеннан махсус программа әзерләгән иде. «Бу программа өч өлештән тора: җанисәпкә әзерлек чорындагы эшчәнлек, җанисәп барышындагы чаралар һәм җанисәптән соң башкарылырга тиешле эшләр»,—диде Илдар Габдрафыйков.***

**—Илдар әфәнде, бу программага тәгаенрәк тукталганда, нәрсәләрне эченә ала ул?**

—Аның тулы эшләнгән бик ачыклыйсы да килми. Ни өчен дигәндә, барлык серләрне дә әйтсәк, безгә аяк чалырга әзер торучылар да артачак. Шуны әйтә алам, җанисәпкә әзерлек чорында татар милли хәрәкәте, танылган галимнәребезне җәлеп итеп, берничә фәнни-гамәли конференция үткәрәчәк. Шулай ук үзебезнең «Халык ихтыяры» исемле бәйсез газетне тергезәчәкбез. Башка мәгълүмат чараларын, шул исәптән, бәйсез Интернет сәхифәләрен дә файдаланачакбыз үзебезнең хак мәгълүматларны җәмәгатьчелеккә җиткерүдә. Милли хәрәкәт активистларының байтагы татар авылларында эш алып бара. Алар анда яшәүчеләрнең исемлеген төзи һәм, аларның милләтен сорап, имзаларын куйдыра. Бу үзенчә алдан үткәрелгән альтернатив җанисәп рәвешен ала. Билгеле инде, әлеге күрсәткечләр 2002 елдагы рәсми нәтиҗәләрдән бик нык аерыла. Халык исәбен

---

[1] Кара: Безне санадылар. Р. Юнысның Дамир Исхаков белән әңгәмәсе. «Ике икең биш башкорт?» дигән бүлек. 2005, № 7.

[2] Кара: Еники Ә. Тигезлек аша татулыкка. 2009, № 3.

[3] Шигар—лозунг.

алу башлангач, үзебезнең күзәтүчеләр төркемнәрен дә эшкә җигәчәкбез. Бу кампания тәмамлангач, хәрәмләшүләр ачыкланган очраклар буенча мәхкәмә *(суд)* аша эш башлау карала һәм тагын күп кенә башка чаралар күздә тотыла.

**—Рәсми вакытлы матбугат басмаларындагы язмаларда һәм радио-телевидение тапшыруларында Башкортстанның көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш төбәгендәге телләрен җуйган башкортлар үз асылына кайта башлады, алар үзләрен янә дә башкорт итеп күрсәтәчәк дигән фикер үткәрелә.**

—Әйе, бу көтелгән хәл иде. 2002 елдагы халык исәбен алуда да рәсми хакимият басымы, алар кулындагы мәгълүмат чаралары әрсез, агрессив рәвештә кулланылды. Шушы ук хәл әле дә кабатлана. Быелгы халык исәбен алуга әзерлектә дә, узганындагы кебек үк, Башкортстанның рәсми мәгълүмат чаралары зур пропаганда эшен җәелдерә. Телевидениедә бу темага махсус тапшыруларның күпчелеге татар авылларыннан әзерләнә. Халык аңына анда яшәүче татарлар— телләрен җуйган башкортлар дигән фикер сеңдерелә. Башкорт телендә чыгучы газит-журналлар да бу темага күп урын бирә. Алай гына да түгел, бу гамәлгә республикадагы татар басмалары да җәлеп ителә. Башкортстанның саф татар районнарында татарлашкан башкортлар яши дигән фикерне үткәрүдә башкорт галимнәре Марат Колшәрипов, Фирдәвес Хисаметдинова, Нияз Мәҗитов, Әхмәт Сөләйманов, Рәшит Шәкүр һәм башкалар бик актив катнаша. Быел Башкортстанда үтәчәк җанисәп барышында да мутлашулар булачагы шиксез. Узган җанисәптә башкортлар 20 проценттан 30 процентка җитеп, татарларны да узды һәм икенче урынга менде. Ә бу юлы башкортлар санын 40 процентка җиткереп, урысларны да узу һәм беренче урынга чыгу максат ителә. Бу инде аларга Башкортстанда башкорт хакимиятенең үзләренә файдалы сәясәтен үткәрүне легальләштерүгә юл ачачак.

**—Республикадагы татар этнолог галимнәре һәм татар милли оешмалары җитәкчеләре 2002 елдагы халык исәбен алуда бик күп ялганлашулар булуы һәм бихисап татарларның башкорт дип яздырылуы хакында һәрдаим әйтә килде. Бу хәлне хәтта сезнең Мәскәүдәге җитәкчегез В. Тишков та таныды. Нинди дер нәтиҗәләр ясалдымы?**

—Тәгаен нәтиҗәләр ясалмады. Тәгаен нәтиҗә ясау—ул Башкортстандагы җанисәпне гамәлдән чыгару булыр иде. Әмма бу эшләнмәде. Мәскәүгә бу бик кирәкми дә. Шулай да В. Тишков әфәнде бу хакта зур трибуналардан, хәтта РФ Дәүләт Думасында да, РФ Иҗтимагый Пулатында да әйтте. Бу халык исәбен алуда В. Тишков күзәтү катырак булачак дип ышандыра. Әйе, узган халык исәбен алуда республиканың рәсми газитләре, радио һәм телевидениесе халык аңын бутау өчен һөҗүмчән пропаганда алып барды. Башкортстанның татар районнарында күпчелек халыкны татарлар түгел, татарлашкан башкортлар тәшкил итә дигән фикерне халык аңына көчләп сеңдерү юнәлешендә көне-төне үгет-нәсихәт һәм коткы тарату барды. Ә инде тиешле кәгазьләрне тутыруда мутлашулар турында әйтсәм дә түгел. Аларга мин шул чакта, районнарда йөргәндә, үзем шаһит булгаладым. Халык исәбен алучыларга татарларны башкорт дип яздырту өчен алдан ук «файдалы» күрсәтмәләр бирелгән булган. Моны җанисәп алучылар үзләре дә таныды.

Алдан ук фаразлаулар буенча, шундый хәрәмләшүләр аркасында Башкортстанда татарлар халык исәбе буенча моңарчы булган икенче урыннан өченчегә тәгәрәгән, ә башкортлар, киресенчә, кеше ышанмаслык дәрәҗәдә артып, икенче урынга менгән дип күренә иде. 2002 елгы халык санын алу йомгакларына караганда, Башкортстанда шул чорга җәмгысе 4 млн. 104 мең 336 кеше теркәлгән. Шуларның 1 млн. 490 мең 715е—урыслар (36,3 %). Икенче урынга 1 млн. 221 мең 302 кеше белән башкортлар чыккан. Бу—29,8 процент дигән сүз. Ә татарлар саны 990 мең 702 кешегә генә торып калган (нибары 24,1 процент). Шулай итеп, ике халык исәбен алу арасында Башкортстан татарлары 230 меңгә кимегән, башкортлар саны исә, киресенчә, 260 меңгә арткан булып чыга. Әлбәттә, мондый хәл республика татар җәмәгатьчелегендә зур канәгатьсезлек тудырды. Шуңа да, татар милли хәрәкәте лидерлары раславынча, җанисәпнең милли составка караган өлеше турындагы материалларны республика хакимияте ярты ел яшереп тоткан да инде. Әмма безне капчыкта озак саклый алмыйсың. Бу юлы да шулай булды. Мәскәүгә бер баруымда мин Русия Дәүләт статистика

комитетыннан җанисәпнең милләтләргә кагылышлы өлеше мәгълүматларын алып кайттым. Ул саннарны «Коточкыч ялганлаумы, әллә халыкларны кырумы?» дип аталган зур күләмле мәкаләмдә җәмәгатьчелеккә тәкъдим иттем. Менә шуннан соң гына Башкортстан хакимиятенең дә җанисәп мәгълүматларын игълан итүдән башка чарасы калмады. Халык исәбенең милләтләргә караган өлеше башта урыс телле газитләрдә чыкса, аннан бу саннарны башкорт газитләрендә дә бастыра башладылар. Мисал өчен, башкорт телендә чыгучы «Йәшлек» үзенең бер санында шул мәгълүматларны игълан итеп кенә калмыйча, газитнең барлык битләрен дә диярлек шушы темага багышлады. Газитнең беренче бите зур хәрефләр белән җыелган, «Башкортларым, арттык, тагы да арту кирәк!» дигән сүзләр белән ачылган иде... Газиттәге «Яшәүгә ихтыяр көче бездә таң калырлык» дип аталган язма Башкортстанда төрле елларда халык исәбен алу нәтиҗәләрен бәян итә. Башкорт галимнәре Р. Шәкүр, Ә. Сөләйманов, Н. Мәҗитов, Р. Янугужин, Ә. Юлдашбаев, үз татарыбыз Ә. Гаязов һәм башкалар үз мәкаләләрен төрле газит-журналларда бастырып, республикадагы башкорт халкының элекке җанисәпләрдә кимүе татарларга бәйле дигән фикерне халык аңына сеңдерергә тырышты.

Гади халык арасында үзләрен татармы, башкортмы итеп язуга әллә ни әһәмият бирмәүчеләр дә күп. Менә шул хәлдән башкорт милли оешмалары, рәсми хакимият булышлыгында, бик оста файдаланды. Халыклар нисбәтен кискен үзгәртеп, башкортлар санын ясалма рәвештә арттыруга ирешә алды. Бу юлы да шуңа өметләнә башкорт туганнарыбыз. Әлеге икътисад төшенкелеге чорында да гади халык көнкүреш, дөнья көтмеш турында күбрәк уйлый. Ана татармы, башкортмы булу әллә ни мөһим түгел кебек. Менә шушы хәлдә татар зыялылары һәм милли оешмалары да үз эшчәнлеген җәелдерә.

**—Илдар әфәнде, башкорт галимнәре көнбатыш районнарда XIX гасырда ук бик күпләр башкорт булган дип раслый ич.**

—Бу билгеле фактны алар үз файдасына юнәлтә. Күп кенә татарлар чынлап та башкорт булып язылган, чөнки башкорт булып язылу байтак ташламалар, өстенлекләр биргән. Ләкин башкорт сословиесенә карау ул әле башкорт булу дигән сүз түгел. Халык санын үзгәртүдәге «уйнаулар»ны бу мәсьәләне яхшы белгән галимнәрдән яшереп булмый. Этнодемографик үзгәрешләрне өйрәнүче белгеч буларак, мин 1989 елдан алып ел саен Башкортстан Дәүләт статистика комитетыннан төрле мәгълүматлар, шул исәптән милләтләргә кагылышлы саннарны да сорап алам. Менә шул вакыттан 2002 елга кадәр, ягъни ике җанисәп арасында, һәр елны милләтләр нисбәтенә кагылышлы дөрес мәгълүматлар бирелеп килгән иде. Ләкин, БР Дәүләт статистика комитеты саннарына карасаң, нинди дер могҗиза белән нәкъ менә 2002 елда Башкортстан татарлары арасында туучылар саны ышанмаслык дәрәҗәдә кимегән һәм, киресенчә, үлүчеләр саны кискен арткан булып чыга. Шул елны республика татарларының табигый кимүе 34 процентка җиткән имеш.

Шул ук елны татарларның республикага миграция хәрәкәтендә дә кешe ышанмастай хәлләр булган. 1989 елдан башлап һәр елны республикага иң күп кайтучылар татарлар иде. Бөтен кайтучыларның 40 проценттан артыграгын тәшкил итте бу сан. Хәтта моңа кайбер тар күңелле башкорт милли оешмалары вәкилләре ризасызлык белдереп тә чыгыш ясый килде. Ә менә җанисәп үткән 2002 елны республикага кайткан татарлар саны 3 тапкыр кимегән итеп күрсәтелә. Шул ук вакытта башкортлар бик күп кайткан дигән саннар бирелә. Бу да чеп-чи ялганга корылган нәтиҗә. Болар барысы да хакимият кушуы буенча эшләнгән хөсетлек иде.

Хәрәмләшүләрнең ачык бер мисалын бер генә башкорт авылы да булмаган Дүртөйле районы мисалында да китерергә мөмкин. Анда без җентекле тикшерү оештырган идек. Дүртөйле шәһәрен алыйк, анда ике халык санын алу арасында—1989-2002 елларда татарлар саны 28 процентка, ә башкортлар 8 процентка арткан булып күренә. Шул ук вакытта район авылларында шушы ике җанисәп арасында имештер капма-каршы күренеш күзәтелә. Янәсе татарлар 29 процентка кимегән, ә башкортлар, киресенчә, өч тапкыр (!) арткан. Күрәсең, шәһәр җирендә татарларны башкорт дип яздыру ансат түгелдер, ә авыл халкының башын бутау җиңелдер. Мондый хәлләр бер Дүртөйлегә генә хас түгел. Барлык татар районнарында да һәм

алардагы шәһәрләрдә башкортлар шул рәвешле «арткан».

**—Башкорт галимнәре моны хәрәмләшү дип түгел, ә бәлки башкортларның, ниһаять, үз асылына кайта башлавы дип раслый.**

—Әйе, алар моны һәр адымда тәкрарлый. Башкорт тел галимнәре һәм тарихчылары 2002 елгы халык исәбен алу нәтиҗәләреннән бик тә бәхетле. «Татарлар арасында эреп югала баручы башкортларның үзаңы уяна башлады һәм алар соңгы җанисәптә үзләрен «башкорт» буларак күрсәтте дип белдерергә ашыкты алар. Ләкин Башкортстанның көнбатыш районнарында гомер-гомергә татарча сөйләшкән халыкның яшәгәнен танылган галимебез профессор Радик Сибәгатов та, башкалар да кире каккысыз дәлилләр белән раслаган иде. Ул хакыйкатькә күз йомып булмый. Элгәредән үк килгән чын башкортлар, татар төбәгендә яшәсәләр дә, телен дә, үзанын да җуймый ул. Моңа ачык мисал итеп Бүздәк районындагы данлыклы башкорт авылы Канны-Төркәйне китерергә мөмкин. 500 еллык тарихы булган бу авыл халкы, Бүздәк төбәгендә саф татарлар «камалышында» гомер кичерсә дә, башкорт булып калган.

Американың күренекле язучысы Марк Твен язганча, ялганның өч төре бар—ялган, оятсыз ялган һәм статистика. Ләкин әгәр дә хакимият өчен ялганлашу көндәлек тормышның аерылгысыз бер өлеше булса, бу инде аларның тәмаман чыгырдан чыгуын күрсәтә.

Республика җитәкчеләре татар халкының рухи мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү буенча элегрәк биргән вәгъдәләрен үтәми. Мәгълүм ки, 2003 елның 4 июлендә президент Мортаза Рәхимов «Башкортстан татарларының милли-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү юнәлешендә өстәмә чаралар» дип исемләнгән фәрманын имзалаган иде. Ул документта Башкортстанда татарча укытучы урта гомум белем бирү мәктәпләре һәм татар классларының санын арттыру, татар телен укытуга кулай мөмкинлекләр булдыру бурычы куелган иде. Карарда шулай ук татар халкының милли-мәдәни мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү өчен дә кайбер тәгаен чаралар билгеләнгән. Әмма Башкортстан президенты күрсәтмәләре бөтенләй дә санга сугылмый һәм алар тормышка ашырылмый.

Башкортстан президенты 2003 елдагы сайлауда, беренче турда җиңә алмагач, икенче тур алдыннан, республикада татар теленә дә дәүләт теле статусы бирүне вәгъдә иткән иде. Чөнки беренче турда татар районнары М. Рәхимовка аз тавыш бирде. Әмма бу вәгъдә дә сүздә генә калды. Хәтта, киресенчә, республикада элегрәк ирешелгәнне дә сызып ташлаучы эшләр кылынып ята.

**—Узган ел азагында Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, Уфада Мортаза Рәхимов белән очрашканда, Башкортстанда татар халкы файдасына яңа гамәлләр тормышка ашырылачак, шул исәптән, «Татарстан-Яңа гасыр» телевидениесе тапшырулары күрсәтелә башлаячак дип әйткән.**

—Күп вәгъдәләр сүздә генә кала ич. Мисал өчен, шул ук татарча укытуны алыйк. Республика түрәләре татар балалары рәхәтләнеп үз ана телендә белем ала дип тәкрарларга ярата. Шул ук вакытта елдан-ел татар мәктәпләре һәм сыйныфлары саны кими бара. Районнардагы татар мәктәпләренә ел саен республика Мәгариф министрлыгының күрсәтмәсе килеп төшә. Шуңа ярашлы рәвештә, республикадагы татар мәктәпләрендә һәм гимназияләрендә башкорт теле, дәүләт теле буларак, мәҗбүри укытыла. Алай гына да түгел, моңарчы татар телен һәм әдәбиятын укыткан мөгаллимнәр хәзер башкортча укытуга күчте. Башкорт телен укытучылар төрле өстенлекләрдән файдалана. Аларга өстәмә түләү дә каралган һәм фатир да бушлай бирелә.

Илеш, Дүртөйле, Чакмагыш, Борай, Балтач, Янавыл кебек саф татар районнарында, 2002 елдагы җанисәптән соң, 70-90 процентка кадәр халык (татарлар дип аңла) башкорт санала. Ә инде алар «башкорт» икән, димәк, нигә әле алар үзләренең «ана телен» өйрәнергә тиеш түгел, дигән таләпне куя хәзер башкорт милләтчеләре һәм республика Мәгариф министрлыгы түрәләре. Ләкин шул ук вакытта бер гаделсезлек тагын өскә чыга. Республиканың татарлар яшәгән төньяк-көнбатыш районнары мәгарифе гел игътибардан читтә калдырыла. Мисал кирәкме? Бар андый мисаллар. Шуларның берсе—мәгариф буенча республика август киңәшмәләренең ел саен көньяктагы башкорт районнарында гына оештырылуы. Моның ни гаебе бар инде дип каршы чыгучылар да булырга мөмкин.

Эш шунда ки, республика август кинәшмәләре уздырылучы районнар бер ел алдан ук билгеләнә һәм аларда яна мәктәпләр төзү, искеләрен заманча итеп янартуга, юллар салуга һәм янартуга йөзләрчә миллион сум акча күчерелә. Август кинәшмәләре зурлап оештырыла башлаганнан бирле алар фәкать саф башкорт районнарында гына үткәрелде. Акча да шунда гына акты. Мәктәпләр дә төзелде һәм алар иң заманча компьютерлар һәм башка техник җайланмалар белән дә җиһазландырылды.

**—Башкорт галимнәре «Башкортстан—башкорт халкы өчен бердәнбер төп нигез, шуңа күрә дә биредә аларга аерым игътибар бирелергә тиеш», дип белдерә. Бер караганда, дөрес тә кебек бу таләп.**

—Бу таләп начар түгел, ләкин аның да чамасы-чиге булырга тиеш. Башкорт милләтчеләре соңгы елларда Башкортстанны 130дан артык милләт яшәгән төбәк дип түгел, «башкорт иле» дип атый һәм шушы «төшенчәне» барлык халык аңына дыңгычлап тутырырга тырыша. Бу республикага башкортлар төп хуҗа, алар гына биредә асаба халык, титуллы милләт булып чыга. Алар гына һәр өлкәдә, һәр эштә башкаларның төшенә дә кермәгән өстенлекләргә ия. Ә калган халыклар килмешәк һәм алар башкорт туганыбызга биредә яшәткәне өчен рәхмәт укып, шөкер кылып кына торырга тиеш булып чыга. Барлык җитәкче вазифаларга башкорт милләтле туганнарыбыз тәгаенләнә, депутат урыннарына да алар гына «сайлатыла». Ә татарлар Башкортстан шартларында хакимияткә йә сайлау алдыннан тавыш өчен генә, йә халык исәбен алганда башкорт санын арттыру өчен генә кирәк. Әлбәттә, башкорт булу Башкортстанда советлар чорыннан ук отышлы иде. Шуңа күрә дә бихисап татар зыялылары, башкорт булып язылып, үз тормышларын шактый җайлады. Шул ук шагыйрьләрне, сәнгать әһелләрен генә алсак та, алар башкортча иҗат итәргә мәҗбүр булды. Әйе, Башкортстанда башкорт булып йөрү электән дә мактаулы иде. Ләкин соңгы егерме елда башкорт булып язылу һәм башкортка хезмәт итү аеруча көчле хуплауга лаек була башлады. Чөнки башкортлаштыру рәсми хакимият дәрәҗәсенә менгән зур сәясәткә әверелде.

Әйе, башкорт хакимияте 2002 елдагы халык исәбен алуда үз максатына иреште. 2010 елда үтәчәк җанисәптә дә аларның, республикада башкортның санын тагын да арттыру өчен, үзләре кулланган (сыналган) алымнарны кулланачагына шик юк. Башкортстанда татарларның халык саны буенча өченче урынга тәгәрәвенә күз йомып, кул селтәп карарга ярамый. Киләчәк буын татарларыбыз бу битарафлыкны гафу итмәс.

**—Быелгы җанисәп нәтиҗәсе нинди булыр дип уйлыйсыз?**

—Әгәр рәсми хакимиятнең басымы булмаса, татарлар 1989 елгы дәрәҗәдән дә бераз артып, 30 процентка җитәргә тиеш. Әлбәттә, табигый арту нәтиҗәсендә, башкортларның да артуы күзәтелә. Чынлыкта алар 21 проценттан 22-23 процентка җиткәндер дип уйлыйбыз. Урыслар бераз кимеде—алар 36 процент чамасы булырга тиеш. Әмма бу фаразлар җанисәп дөрес үткәрелсә генә тормышка аша. Ә аның дөрес үткәрелүе бик шикле.

**—Илдар әфәнде, милләтләрнең саклануы хакында киңрәк фикер йөрткәндә, тагын бер сорау килеп туа, Русиядә 30-40 елдан соң татар һәм башкорт телләре һәм гомумән шушы ике тугандаш халыкның милләт буларак саклануы ни дәрәҗәдә булыр?**

—Бу сорау татар һәм башкортны гына түгел, урысларны да борчый. Ни өчен дигәндә, 2050 елларга Русиядә урысларның да саны шактый кимиячәк, шул ук вакытта читтән килүче башка милләтләр саны бермә-бер артачак. Аеруча кытай милләте вәкилләре бик нык ишәергә мөмкин. Аларның гомум тормышка йогынтысы да көчле булачагы фаразлана. Хәзер, глобальләштерү заманында хәл-вакыйгалар көне-сәгате белән үзгәрә. Татар белән башкортның да милләт буларак саклануы хәвеф астында. Менә шул шартларда башкорт туганнарыбызның бүгенге белән генә яшәве, алдагы көнне уйламыйча, татарлар исәбенә ишәергә тырышып ятуы һич кенә дә аңлашылмый. Безгә, киресенчә, бер-беребезне кысмыйча, рәнҗетмичә, якын туганнарча яшәү хәерле. Татар күңелендә бүгенге хәлләрдән юшкын калса, башкорт туганыбызга авыр чакта ярдәмгә килмәскә, таяныч булмаска да мөмкин бит ул.

# БАТЫР ЙӨРӘК ШИГЪРИЯТЕ

## «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫНДА Ф. КӘРИМНЕҢ ИКЕ ТОМЛЫК САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘРЕ БАСЫЛЫП ЧЫГУ УҢАЕННАН

Фатих Кәрим—күренекле патриот-шагыйрь һәм каһарман солдат. Ул 1945 елда, икенче бөтендөнья сугышы тәмамланырга санаулы атналар калганда, яу кырында һәлак булган. Фатих Кәримнең шигырь юллары, канатлы сүзләргә әверелеп, бик күпләрнең күңел түрендә яши.

*Үлем турында уйлама,*
*Илең турында уйла.*
*Илең турында уйласаң,*
*Гомерең озын була.*

***

*Фашист илгә үлем генә китерә,*
*Фашизмның язы, таңы юк.*

***

*Синең өчен, шушы балам өчен,*
*Нәселем өчен, Туган ил өчен*
*Мылтык тотып баскан җиремнән*
*Бер адым да артка чигенмәм!*

«Ант», «Кыңгыраулы яшел гармун», «Ватан өчен», «Пионерка Гөлчәчәккә хат» кебек әсәрләргә хас булган гаҗәеп кайнар, самими хисләр, ирләрчә кыю, туры әйтелгән ихлас фикерләр адәм баласын мәктәп елларыннан чал картлыкка кадәр озатып бара. Тукай, Такташ, Җәлил шигырьләре кебек үк, алар туган телне, әдәбиятны яратучы татар кешесенең күкрәгендә кайтаваз булып яңгырый.

Фатих Кәримнең егерменче гасырның иң хәтәр елларында тудырган әсәрләре халкыбызның рухи елъязмасы булып тора. Фатих Кәрим иҗатының татар әдәбиятында тоткан урынын, XXI гасыр кешеләренә ничек тәэсир итүен хәзерге шартларда билгеләү иң мөһим, актуаль мәсьәләләрнең берсенә әверелде. Милләт яшәеше, аның киләчәге белән төрле чорларда иҗат ителгән мәдәни мирас арасында турыдан-туры элемтә бар. Сталин репрессияләре чорында да, фашизмга каршы алып барылган коточкыч каты сугыш елларында да милләт зыялылары, гомумән, татар халкы кичергән куанычлар һәм кайгы-хәсрәтләр, аларның рухи-әхлакый тәҗрибәсе киләчәк буыннар өчен гыйбрәтле.

Фатих Кәрим кичергән фаҗигале вакыйгалар, бигрәк тә тоткынлык, төрмә лирикасы чагыштырмача күптән түгел генә халыкка мәгълүм булды. Шагыйрьнең тууына 90 ел тулу унаеннан, бу турыда матбугатта тәфсилләп язылды. Әмма, ни гаҗәп, шуннан соң үткән ун ел дәвамында әдәби җәмәгатьчелекнең фикер сөрешендә әллә ни зур борылыш сизелмәде. Фатих Кәрим турында 40—50 нче елларда формалашкан «патриот-шагыйрь» билгеләмәсе үтеп киткән дистә ел дәвамында сизелерлек кинәймәде, тирәнәймәде. Шагыйрьнең иҗатын өйрәнүгә күп еллар багышлаган Зәет Мәҗитов арабыздан киткәч, бу темага фәнни хезмәтләр язу, шагыйрьнең әсәрләрен бастыру тукталып калды. Яңа заманда төзелгән мәктәп программаларында, дәреслекләрдә, хрестоматияләрдә Фатих Кәрим исеме сирәк күренә башлады.




Чыннан да, кешелек XXI гасыр түренә ныклап кереп барганда, Фатих Кәрим кебек шәхесләр дә үзләренең чордашлары белән берьюлы тарихка күчә барырга мөмкин. Моның өчен җитди сәбәпләр дә бар.

Беренчедән, Фатих Кәрим кайнар канын агызып, фашизмнан саклап калган ил инде таралган.

Икенчедән, ул яшәгән җәмгыять, иҗтимагый-сәяси система һәм идеология җимерелгән. «Патриот», «Ватан» сүзләренең төсмерләре дә шактый үзгәргән.

Хәзерге иҗтимагый тормышта ватанпәрвәрлекне сәяси корал итеп куллану, аның асылына игътибар итмәү еш рак очрый.

Белгәнебезчә, Фатих Кәримнең әтисе мулла булу аны хөкем итү өчен сылтау рәвешендә кулланылган. Бүгенге чорда дингә мөнәсәбәт унай якка үзгәрсә дә, диннәрнең төрлелеге, сәясәт һәм терроризм гамәлләре белән аерым диннәрне бәйләп күрсәтү шактый катлаулы хәлләр китереп чыгара. Ә дин белән бәйле фаҗигаләр, эзәрлекләүләр халык хәтереннән тиз генә җуелмый.

Базар икътисады, шоу-бизнес, реклама һәм PR колач җәя барган хәзерге чор белән XX гасырның 30 нчы елларындагы социализм төзү, яңа рухият булдыру романтикасына, дошман эзләү һәм фаш итү шомына исергән заман арасында аерма бик зур. Узган гасырдагы күмәкләштерү, индустрияләштерү, «социализм төзелеше алга барган саен, сыйнфый көрәшнең көчәюе» яшь буынга аңлашылып бетми.

Хәзер инде башка идеаллар, бүтән әдәбият, үзгә аудитория, башка «йолдызлар» заманы килгән. Яңа чор каһарманнары алай күтәренке рухлы, самими, беркатлы түгел, ә прагматик акыл, файда күрү максаты белән яшиләр. «Илең турында уйла» дип өндәүчеләр хәзер сирәк очрый. «Үзең турында уйласаң, гомерең ямьле була» гыйбарәсе торган саен көчәя бара. Глобальләшү, илләр, милләтләрнең ярышуы, ахырзаман һәм инкыйраз билгеләре белән берьюлы рухи терелү, тәрәккыят, милли үсеш тә күзгә ташлана.

Мондый шартларда Фатих Кәрим совет әдәбияты вәкиле буларак тоныклана, хәтерләрдә сүнә башларга да мөмкин кебек иде. Совет әдәбиятының зур өлеше булган милли әдәбиятлар мөстәкыйль илләрнең мәдәни мохитенә аерылып китү татар әдәбиятына да тәэсир итә. Алар Совет чоры тарихы буларак китап киштәләрендә, архив һәм музейларда гына калмасмы? Киләчәк буын галимнәре бу тарих битләрен һәм әдәби әсәрләрне өйрәнерләр, бәлки. Әмма юбилейлар яки фәнни тикшерүләр унаеннан аерым даирәдәге кызыксынулар белән генә канәгатьләнергә туры килмәсме?

Кешелек XXI гасырга аяк баскач, элеккеге СССРның дәвамчысы булган Россия Федерациясендә базар икътисады, XX гасырдагы сәяси идеалларга капма-каршы

булган төшенчәләр һәм максатлар, яңа каһарманнар һәм ориентирлар хөкем сөрә башлады. Матди дөнья гына түгел, халыкның яшәү рәвеше, фикерләве, өметләре һәм гадәтләре дә үзгәрә. Такташ, Җәлил, Фатих Кәрим чорындагы хыялый пафос һәм лозунглар чамадан тыш гади, беркатлы булып күренә башлады. Глобальләшү шаукымы, милли әдәбият һәм мәдәниятнең, каушап калып, читкә этәрелә башлавы, дәүләт төзелешенең үзгәрүе совет әдәбияты мохитеннән, һавасыннан нык аерыла, әлбәттә. Ләкин әдәбиятка табынучылар, милләтне кадерләүчеләр, туган телне белүчеләр кимеп барган бу чорда Тукай, Такташ, Җәлил, Ф.Кәрим кебек шагыйрьләрнең исемнәре, иҗатлары янадан яшәрә, тагын да кинрәк тарала башладылар. Аларның әсәрләренә ихтыяҗ, алар тудырган рухи кыйммәтләргә сусау, аларның идеаллары белән кызыксыну артты. Тукайның 120 еллык, Такташ һәм Җәлилнең 100 еллык юбилейлары шуны күрсәтте. Милләтнең һәм рухиятнең язмышы менә шундый бөек шәхесләрнең иҗатына, аларның яңа «сулышына» бәйле икәнлеге күзгә ташланды.

Уникаль язмышлы, күпкырлы олы иҗатка ия, катлаулы шәхес булган Фатих Кәрим исеме меңнәрчә, миллионнарча сугыш корбаннары арасында югалып кала алмый. Фатих Кәрим кебек талант ияләренең һәлакәте татар рухияте өчен никадәр зур югалту икәнлеген дә онытып булмый. Совет системасы белән бергә, шул системаның корбаны, туган халкы, Ватаны, әдәбият өчен кыйммәтле зат булган Фатих Кәримнең иҗатын да архив киштәләренә салып кую милли рухиятне шактый ярлыландырыр иде. Мондый шәхесләрнең язмышы һәм иҗаты галимнәр тарафыннан тирәнтен тикшерелергә, аларның иҗади казанышлары киң җәмәгатьчелеккә таратылырга, киләчәк буыннарга җиткерелергә лаеклы.

Егерменче гасырның 30 нчы елларында, яшен ташы кебек, иҗат күгендә кабынган, шул чорның иҗтимагый-әдәби тормышында кайнашкан Фатих Кәрим бүгенге рухияткә дә тәңгәл килә ләбаса! Бөек Ватан сугышы елларында иң көчле, иң үтемле әсәрләр иҗат итеп, фашизмны җиңәргә санаулы атналар калганда һәлак булган яугир иҗатчы яңа буыннарның да күңеленә үтеп керә. Дүрт ел төрмәдә, лагерьларда газапланып, тирән кичерешле гүзәл әсәрләр тудырган, Ватанына, халкына ышанычын югалтмаган, тагы дүрт ел дәвамында, сугыш уты эчендә кан түгеп, йөзләрчә шигырь-поэмалар иҗат иткән, шәхси каһарманлыгы белән күпләрне таң калдырган Фатих Кәрим белән янәшә куярлык шәхесләр бик аз. Төрмәдә, сөргендә озак еллар йөргән Хәсән Туфанның лирик шигырьләре әдәбиятта кабатланмас урын алды. Рус язучысы Александр Солженицынның төрмә һәм лагерь тормышын тасвирлаган әсәрләре Нобель бүләгенә лаек булды.

Фатих Кәримнең тууына 100 тулу уңаеннан оештырылган чараларның киң колачлы булуы шуны раслады: халыкчан телле, кайнар хисле шагыйрьнең әсәрләре, бүгенге тормыштан аерылып, тарихи фактка әверелми икән!

Европа уртасында фашизм белән көрәшкән, башы гильотинага салынгач та, гүзәл шигырьләр иҗат иткән Муса Җәлил татар халкының горурлыгы, каһарманлык үрнәге булып тора. Казан Кремле каршында Муса Җәлилгә куелган бронза сын аның кебек үк легендар шәхесләргә, батыр, талантлы татар иҗатчыларына уртак һәйкәл булып күренә. Каһарман шагыйрь Фатих Кәрим, талантлы язучы Гадел Кутуй, танылган композитор Фәрит Яруллин кебек кадерле затларыбызның истәлеге дә Муса Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә куелган һәйкәлдә чагыла. Алар барысы да—ирекккә омтылган, иҗатлары белән таң калдырган, дәһшәтле яуда һәлак булган бөек шәхесләр.

Чорлар һәм шартлар һәрвакыт үзгәреп тора. Яңа заман кешеләре дә әдәби әсәрләрдә үзләре өчен мөһим фикерләр, яңа төсмерләр эзли. Һәр кавем, һәр ил классик әдәбиятны, үз күзе белән карап, үз «иләгеннән» үткәрсә дә, бөек әсәрләр гомумкешелек байлыгы сандыгында саклана.

Фатих Кәрим иҗаты да шундыйлардан. Бигрәк тә аның фашизмга каршы барган авыр көрәшнең иң кайнар нокталарында язылган шигъри һәм чәчмә әсәрләре Россия халыклары әдәбиятында иң югары урыннар биләргә хаклы.

Аларның эчтәлеге, гуманистик идеяләре, халыкчанлыгы, форма ягыннан камиллеге теләсә кайсы зур әдәбиятның иң күркәм казанышлары дәрәҗәсендә. Сугыш хакыйкате, ватанпәрвәрлек, фидакарьлек, ихтыяр көче, күңел байлыгы аерым бер чорга гына түгел, гомумән, төрле заманнар, халыклар өчен рухи таяныч, үрнәк булырлык.

Сугыш елларында иҗат иткән билгеле рус шагыйрьләренең «Жди меня», «Я убит подо Ржевом», «Меня зарыли в шар земной» кебек тирән лирик шигырьләре миллионнар йөрәгендә саклана. Фатих Кәримнең «Ант» шигыре дә шул ук дәрәҗәдә халыкчан, ихлас ватанпәрвәрлек сыйфатына ия.

Чорлар үзгәрү белән, мондый шигырьләрнең әһәмияте кимеми. Халык азатлыгын, тарихын, рухи-мәдәни байлыкларын, туган телне саклап калу өчен мылтык тотып кына түгел, акыл, гыйлем, заманча технология, табигый сәләт, фидакарь хезмәт белән «коралланып», аяк терәп, бер адым да чигенмәү кирәклеге кимеми, киресенчә, торган саен көчәя генә бара.

Фатих Кәрим кебек әдипләр һәм аларның иҗаты әдәбиятта, мәгариф-тәрбия системасында тагын да зуррак урын алырга лаеклы. Дөрес, яшь буынга бу хакыйкатьне аңлау, кабул итү җиңел түгел. Чөнки, һәр иҗатчы кебек үк, Фатих Кәрим дә—үз заманын чагылдыручы, үз чорында яшәгән шәхес. Шагыйрьнең катлаулы 30 нчы елларда кичергәннәрен, аның «тормыш университетларын» белү генә Фатих Кәримнең фикерләү рәвешен, әсәрләрен аңларга ярдәм итә ала.

Фатих Кәрим Башкортстан җирендә, хәзерге Бишбүләк районы Аеть авылында яшьли сукырайган Әхмәтвәли мулла гаиләсендә туа. Балачактан ук гыйлемгә тартылу, әтисе, Габдулла абыйсы (Ярлы Кәрим) язган шигырьләрне, әнисе Гөлҗамалның мөнәҗәтләрен тыңлау Фатихка көчле тәэсир ясый.

13 яшьлек Фатихны Габдулла абыйсы Бәләбәй педтехникумының әзерлек курсларына урнаштыра. Ул, Гази Кашшаф, Кәшфи Басыйров кебек яшь әдәбиятчылар белән бергә, шигырьләр яза, кульязма журнал чыгара, үзлектән белем тупларга өйрәнү, зур юлга аяк басу өчен, нигез шул чорда салына.

Ф.Кәрим унбиш яшендә Казанга килә, Крупская исемендәге яшүсмерләр йортында бер ел гомер иткәннән соң, җир төзү техникумына укырга керә. Көндәлек матбугатта эшләү, иҗат белән ныклап шөгыльләнү, әдәбият түгәрәкләре оештыру шул чакта башлана. Ф.Кәримнең беренче шигыре 1927 елда, Мәскәүдә нәшир ителүче «Кечкенә иптәшләр» журналында басылып чыга.

Яшь шагыйрь яңа тормышны аңларга һәм аңлатырга тырышкан, үзләренең талантлары һәм хыяллары белән гаҗәпләндергән Һади Такташ, Хәсән Туфан, Кави Нәҗми һ.б. тәэси-рендә үсә һәм шактый зур уңышларга ирешә. Редакцияләрдә эшләү аңа иҗтимагый һәм сәяси вакыйгаларны аңларга, тормышны тирәнрәк төшенергә ярдәм итә.

Фатих Кәримнең 30 нчы еллардагы иҗаты гаҗәеп уңышлы була. Ул, танылган әдипләр белән бергә, СССР һәм ТАССР Язучылар берлекләрен оештыруда катнаша, Союзга беренче булып кабул ителгән иң олы язучылар арасында 25 яшьлек Фатих Кәрим дә була. Татарстан китап нәшриятында балалар әдәбияты секциясен оештыргач, аның беренче мөдире Фатих Кәримгә бу юнәлешнең әйдәп баручысы вазифасы йөкләнә. «Улак белән еракка» повесте, «Гармунчы аю белән җырчы маймыл» поэмасы балалар һәм яшүсмерләр өчен иң кызыклы, иң мәгънәле әсәрләр буларак әдәбиятка кереп калалар. «Җиденче мич», «Тавышлы таң», «Аникин» поэмаларында иҗтимагый һәм социаль-икътисади тормыш вакыйгалары тасвирлана. Һәм бу әсәрләр актуальлек белән генә түгел, әдәби камиллек ягыннан да аерылып тора.

Дөньяда беренче тапкыр гадел пролетар җәмгыять төзү, изелгәннәрнең богауларын чишеп, дөнья дилбегәсен кулга алырга омтылуы чорындагы әдәби процесс бик катлаулы булган. Сәясәт белән рухиятне, агитация белән әдәбиятны бер төенгә төйнәгән гамәлләрнең уртасында кайнаган Фатих Кәрим иҗади һәм сәяси элитаның иң югары катламына керә. Һәм... 1937 елда, иң талантлы, иң күренекле

әдипләр белән бергә, сәяси репрессиягә эләгә. Ул вакыттагы язучылар, галимнәр, мәгърифәтчеләр арасындагы энтузиазмны да, дәүләт һәм партия органнарының юнәлтеп, төрткәләп торуын да, үзара иҗади көндәшлекне дә күз алдына китерү авыр түгел.

Шагыйрьнең фаҗигале язмышы, нахак гаепләнүе, 4 ел дәвамында кыйналулар, ач торулар газабына чыдап, рухын һәм иманын саклау тарихы әле дә күпләрнең зиһененә барып җитмәгән. Төрмәдә язылган үзәк өзгеч шигырьләр әлегә дәреслекләргә кертелмәгән, алар аерым даирәгә генә билгеле.

Бу инде—бөтенләй башка әдәбият. Төрмә лирикасында хәрби-патриотик тәрбия, сәяси мобилизация максатлары күзгә ташланмый. Камераларда, лагерьларда язылган шигырьләрнең кемгә барып җитәчәге ул вакытта шагыйрьнең үзенә дә мәгълүм булмаган. Җәлил әйткәнчә, палач балтасы астында язылган бу шигырьләр һәркемне тетрәндерерлек.

*Диңгез төбендәге кораб сыман,*
*Караңгыга чумган таш төрмә.*
*Таш төрмәнең цемент идәнендә*
*Йоклап яткан ристан төш күрә.*

Төрмә идәнендә аунаучы лирик геройның төшенә нинди манзаралар керә? Ни өчен Фатих Кәрим, Кави Нәҗми, Кәрим Тинчурин, Шамил Усманов, Хәсән Туфан кебек шәхесләр төрмәгә ябылган? Андый шәхесләрнең фаҗигасен аңлау өчен аларның язмышын, иҗатын яңадан өйрәнү ихтыяҗы бар.

1937—1938 елларда Ф. Кәримнең иректә калу шансы булмаган. Бер тәрәге булмаган килеш, ул Казанда белем, тәҗрибә туплаган, 5—6 ел эчендә 10лап китап чыгарган. Ул дәртләнеп эшләгән, кеше өстеннән донос язып, кемнедер «фаш» итеп абруй казанырга тырышмаган. Аның хакыйкатьне турыдан-туры ярып сала торган холкын да исәпкә алмый мөмкин түгел. Такташ, Туфан һ. б. зур талантлар арасында кайнашу да Фатихның репрессиягә эләгү котылгысызлыгын арттырган.

«Шәхес культы» тамгасы астында бер Сталин гына түгел, ә коллектив карьерист-палачлардан торган бюрократик административ машина һәм ул тудырган шомлы рухи мохит тә, кешеләрнең куркып-йомылып калу фаҗигасе дә ята. Фатих Кәримнең шул вакыттагы система корбаны булуын, шул тәмугны үткәндә дә ихлас, чиста, самими һәм кыю шигырьләр язуын белмәүчеләр яки аңлап бетермәүчеләр әле дә бардыр. Ничек инде ул, патриот-шагыйрь, иле турында уйлап, корбан булырга чакыручы Фатих Кәрим шул илнең дәүләт машинасында туралсын, ди? Әмма бу, чыннан да, нәкъ шулай булган. Ихтимал, шагыйрьнең шәхси һәм иҗади сыйфатлары, әдәби куәтенең зурлыгы аның башы өстендә балта күтәрелүгә сәбәп булгандыр.

Бөтен җаны-тәне белән туган илен яраткан, җәмгыятьтә барган яңа төзелешне әсәрләрендә яктырткан, матбугатта үз эшен җиренә җиткереп башкарган, җәмәгать эшләрендә үзен булдыклы шәхес итеп күрсәткән язучыдан гаеп табу җиңел булмаган. 1937 елның 29 мартында «Яшь ленинчы» газетасының һәм «Пионер каләме» журналының баш мөхәррире язучы Ләбиб Гыйльми республика матбугатында Фатих Кәримне чит элемент, халык дошманы, советка каршы коткы таратучы дип «фаш итә». Имеш, ул мулла малае булуын яшергән, «троцкист» Павел Васильев белән очрашкан. Язучы Рафаэль Мостафин, архивларда тикшереп, яшерен шымчыларның әләкләвен дә өйрәнгән. Якын дуслары белән сөйләшкәндә, Фатих Кәрим: «Бездә талант партбилетсыз үзенә юл яра алмый»,—дип ычкындырган. Нәкъ шул вакытта тәнкыйтьче Гомәр Гали кулга алынгач, бер мәҗлестә дустын кызганып елаган, Г. Галинең тизрәк әйләнеп кайтуын теләгән. Менә шундыйрак гөнаһлары өчен Фатих Кәрим 1937 елның маенда нәшрияттан куыла. Эшсез йөргәндә, нинди куркыныч янавын сиземләгән шагыйрь хатыны Кадрияне һәм кызлары Ада белән Ләйләне Уфага, туганнары янына җибәрә. Кулга алырга ордер 1937 елның 29 декабрендә имзалана. Ул Якуб Чанышев, Кави Нәҗми, Газиз

Иделле һ. б. белән бергә хәрби контрреволюцион троцкийчы оешмада катнашуда гаепләнә. Имештер, ул оборона темасына язылган әдәбиятны, тоткарлап, дөньяга чыгармаган.

НКВД тарафыннан кулга алынган Кави Нәҗмине, кыйнап, җәзалап, контрреволюцион оешмага Фатих Кәримне җәлеп итүен таныргa мәҗбүрләгәннәр. Фатих Кәрим үзенең контрлык эшенең нидән гыйбарәт булуын сорагач, Кави Нәҗми бер генә дә факт китерә алмый. Ул, Фатих Кәримне яшерен оешмага тартсам да, шагыйрь үзе бу турыда белмәде, дип аңлаткан. Сонрак, үз гаепләре расланмыйча аклангач, Якуб Чанышев һәм Кави Нәҗми Фатих Кәримне дә иреккә чыгару өчен көрәшәләр. 10 елга хөкем ителгән шагыйрьне Печора тайгаларыннан Казанга кайтару өчен тагын бер ел сарыф ителә.

Дүрт ел дәвамында төрмә камерасы, тимер юл вагоннары, Архангельск, Печора лагерьлары, Казан Кремле янындагы төрмәнең тынчу камерасы Фатих Кәрим өчен иҗат һәм яшәү «лабораториясенә» әйләнә. 1941 елның 3 декабрендә аның гаепсез икәнлеге танылып, тулысынча акланып иреккә чыкканнан соң, Фатих Кәримнең кичерешләрен, Совет дәүләтенә һәм Сталин режимына мөнәсәбәтен күз алдына китерү мөмкин түгел. Ул Гитлер фашизмы белән сугышка, туган илне, нәселен, гаиләсен саклауга җаны-тәне белән бирелә. Димәк, барлык хәсрәтләр, рәнҗүләр, нахакка гаепләнүләр каядыр таралып юкка чыга.

Шулай да төрмә һәм лагерь елларында иҗат иткән шигырьләрдә аны җәзалаучыларга мөнәсәбәте сизелә.

*Җырым аша белсен халкым,*
*Айнытсын аңын.*
*Дошманнар богаулап куйган*
*Улы мин аның...*

Төрмәдә утыручы шагыйрь, үз кулына богау салучыларны дошман дип атап, үзен үлем җәзасы куркынычы астына куя. Ләкин ул башкача яши, фикерли торган кеше түгел.

*Еллар үтә, ерагая бара*
*Кояш белән Җирнең арасы.*
*Шуннан беләм: Җирдә тормыш бетеп,*
*Бер боз шары булып каласын.*

Фатих Кәримнең бу юлларыннан күренгәнчә, ул берничә миллиард елдан соң Җирнең Кояштан ерагаячагын, ә Кояшның сүнәчәгенниндидер фәнни чыганаклардан белгән. Хәзерге галимнәрнең иң кыю фаразларына узган гасырның 38 нче елында иҗат ителгән шигырьдәге фикернең тәңгәл килүе үзе бер сенсация.

Шул ук шигырьдә Фатих Кәрим үзенең озак еллар төрмәләрдә, лагерьларда ятуын сөйгән хатыны күтәрә алмас, суыныр, читләшер дип өзгәләнә.

*Барсына да риза, мең кат риза.*
*Утка яксын, әйдә, нибарсын.*
*Йөрәгенә бер җиңеллек бирсә,*
*Үземне дә салып яндырсын.*

Шагыйрь хәтта, якыннарының аяныч хәлен җиңеләйтү өчен, үзен онытуга да ризалашыр иде. Шул ук вакытта ул барыбер сөйгәненең үзенә суынмаячагын, оныта алмаячагын да аңлый. Гап-гади, туры фикерле, илне зурлаучы патриот-шагыйрьнең төрмә лирикасы һәм тоткынлыкта кичергәннәрен, аның фикер-хисләренең никадәр катлаулы, каршылыклы, аяныч булуын күз алдына китерергә мөмкин. Фатих Кәрим кебек катлаулы, күпьяклы, тирән фикерле, нәзберек хисле шәхесләрнең сирәк очравы бары тик хәзер генә өлешчә ачыла бара.

Чыннан да, мөстәкыйль фикерле, дөреслеккә табынучылар канлы тегермән ташына салынган утыз җиденче елларда Фатих Кәрим кебек шәхесләрнең иректә исән калу форсаты булмаган.

Шагыйрь үзенең яу кырында һәлак буласын алдан сизгән. Әмма бу сиземләү анын күнелен төшерми, шагыйрь юлбарыстай сугыша! Җинаять кодексының 58 нче маддәсе буенча 10 елга хөкем ителеп, соңыннан акланып ireккә чыккан татар кешесенең Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнүе Советлар Союзы Герое исеменә лаек булудан да зуррак бүләк икәнлеген аңларга кирәк. 1945 елның 19 февралендә ике тапкыр яралангач та, карлы-канлы окопта калып, соңгы өченче ядрә йөрәген тишкәнгә кадәр сугышкан шагыйрьнең, гаиләсен кайтып күрү турында хыялланып, күрәләтә үлемгә керү фаҗигасен ничек аңларга соң?

Фатих Кәримнең яу кырыннан исән кайтырга шансы булмаганлыгын аның сугышка кадәрге яшәү рәвешеннән, хатларыннан һәм истәлекләрдән күрергә мөмкин. Дүрт ел дәвамында «халык дошманы», «контра» булып кыйналулар, йоклатмыйча сорау алулар, рухи изелүләр аша үткән шагыйрь, тулысынча акланып, өенә кайта, газиз балаларын, хатынын, Казанын күрә. Ул хәзер рухи яктан да, җисми яктан да халкы, иле белән бергә, аның гаиләсенә газап китерү куркынычы юкка чыккан. Унда-сулда үзебезнекеләр, алда дошман булган чакта, фашизмның бөтен халык, илләр алдындагы реаль явызлык, куркыныч афәт булуы кичәге ристан-шагыйрьне өр-яңа вазгыятькә куйган. Ул, ireккә чыгуына сөенеп, ут эченә ыргылган, чыннан да, үлем турында куркып уйлаудан бигрәк, иле турында уйлаган. Сугыш алды чорының никадәр катлаулы, фаҗигале булуы фронтта язылган җор телле шигырь-поэмалар, хикәя-повестьларда берничек тә чагылмый.

Фатих Кәримнең тәрҗемәи хәлен һәм яшәү рәвешен һәрберсе дүрт елдан торган биш дәвергә бүлеп карарга мөмкин.

1925—1929 еллар—техникумда уку, редакцияләр эшендә катнашу.

1929—1933 еллар—көндәлек матбугатта чыныгу, «Яшь ленинчы», «Крестьян гәзите», «Атака» басмаларында эшләү, сәяси тәҗрибә туплау, талантлы, кыю романтик шагыйрьләр арасында үсү, буынга утыру.

1933—1937 еллар—китап нәшриятының балалар һәм яшьләр әдәбияты секторында эшләү, Язучылар союзын оештыруда, әдәби процесста катнашу. Әлеге 8—10 ел дәвамында романтик шигырьләр, җәмгыятьтәге үзгәрешләр, төзелешләр турында шигырьләр, балладалар, поэмалар, хикәяләр, повестьлар, мәкаләләр языла. Проза һәм шигъри әсәрләре 9—10 китап булып зур тиражлар белән чыга. 30 яшен дә тутырмаган Фатих Кәрим үз чорының әдәби йолдызы булып шул чакта кабына. Андыйларга карата системаның һәм көндәшләренең рәхимсез булуы билгеле.

1937—1941 еллар—төрмәдә утыру, Печора лагерьларында эшләү, авыр кичерешләре, сагыну һәм хыяллары турында шигырьләр иҗат итү.

1942 елның 3 гыйнварыннан 1945 елның февраленә кадәр—фронт хәбәрчесе түгел, ә гади солдат, аннары лейтенант, взвод командиры буларак, окопта, сугыш уты эчендә көрәш алып бару, ике тапкыр җәрәхәт алып, госпитальләрдә дәвалану, ике орденга лаек булу, соңгы алышта бер көндә ике җәрәхәт алганнан соң да яу кырыннан китмичә, өченче ядрә йөрәгенә тиеп һәлак булу. Һәм шул ук дүрт еллык чорда 150 шигырь, 8 поэма, 2 повесть һәм зур күләмле драма иҗат итү. Шигъри дүртьюллыкларны хәтерләткән дүрт еллык циклларданторган бу гомернең төрле чорлары бер-берсенә охшамаган булса да, Фатих Кәрим кичергән язмышның гомуми аһәне, бер сулыш белән үтүе һәркемне таң калдырырлык. Бу феномен әдәбият, мәгариф-тәрбия, тарих белгечләре тарафыннан тирәнтен өйрәнелергә тиештер.

Шагыйрьнең рухи тамырлары татар халкы язмышы, туган җире белән бәйле. Фатих Кәрим яшүсмер чагында ук Аеt авылыннан Бәләбәйгә, аннан соң Казанга чыгып китә. Туган ягы аның өчен иң газиз төбәк, илһам чыганагы булып торган. 80 чакрымда урнашкан Бәләбәйдә укыганда, ул еш кына җәяү Аетка кайтып йөргән. Туган авылында гомеренең 12—13 елын гына үткәрсә

дә, Фатих Кәрим һәрвакыт барлык вакыйгаларны, ел фасылларын шул ук Ает, Дим буйлары сурәтләре аша күзаллый. «Дим кызы Фатима», «Улак белән еракка» кебек чәчмә әсәрләре документаль нигездә, хәтта кеше исемнәре дә үзгәртелмичә язылган.

Фатих Кәрим, Дим буйлары турында төрле чорларда язса да, һәрвакыт туган җир-суына мәхәббәтен йөгәнләми.

*Мин сагындым!*
*Яз күңелемне*
*Алып кайтты туган Димемә...*
*...Түтәл буйларында йөргән кызлар*
*Мәк чәчәге булып күренә.*
*Ә Дим калды берьялгызы,*
*Тик ай йөри аның төбендә.*

1938 елда Казан Кремле янындагы кысан бөркү төрмә камерасында да шагыйрь Дим буен искә төшерә. Кадриягә багышланган шигырендә дә ул болай яза:

*Тышта яз бит, бәгърем, яз бит тышта,*
*Күз алдыма килә Дим буе.*
*Дим буенда хәзер язгы ташкын*
*Ярларына кире кайткандыр.*
*Балалыгым үткән болыннарда*
*Инде шомырт чәчәк аткандыр...*

Фатих Кәрим замана техникасына, бигрәк тә күккә очуга мөкиббән булган. Кечкенә чагында Дим буенда куаклыкта бозау эзләп йөргән малайны күктә очып баручы аэроплан тәэсирләндерә.

*Такта капка чаклы канатлары—*
*Бер кош очып килә ләбаса...*
*Килә бу кош, әй вырылдый үзе,*
*тәпиләре тәгәрмәч сыман...*
*Бу кош үтеп китте төньякка;*
*Гөрелдәвеннән һава калтырады,*
*Дерелдәшеп калды яфраклар.*

(«Истәлек», 1934)

«Дулкынланып китте ак болыт» шигырендә дә Фатих Кәримне һавага очу романтикасы канатландыра. Парашют белән очкычтан сикергән кыз турында ул болай яза:

*Йомшак саклык белән самолетның*
*Канатына чыгып бастың да*
*Сикердең син киң бушлыкка.*
*Дулкынланып китте ак болыт,*
*Ниндидер көч һәммәбезнең*
*Йөрәкләрен кысты шул вакыт.*

Шагыйрь бу гамәлне күзалларлык сурәт ясый:

*Зонтик чаклы ап-ак чәчәк тотып,*
*Син һавада кинәт тукталдың.*

...Күп еллар үткәч, 2009 елнын 23 февралендә шагыйрьнең тууына 100 ел, һәлак

булуына 64 ел тулган көннәрдә аның туган ягында могҗизави вакыйга булды. Берничә ел орбитада эшләгән космос корабы, алдан билгеләнгән урыннан 200 чакрымга читкәрәк китеп, нәкъ Бишбүләк районының Ает авылы каршындагы Дим буе тугаена, халык җырларында, Фатих Кәрим шигырьләрендә тасвирланган өянке-таллар, шомырт куаклары арасына килеп төшә. Печән кибәне кадәр тимер аппарат җиргә кагылганда, аның «койрыгындагы» тормоз җайланмалары ут сибеп, «шартлап», галәм очкычының йомшак кына утыруын шагыйранә тасвирлау өчен, Фатих Кәрим каләме кирәктер. Могҗизага ышанучан аетлылар космик корабның якташ шагыйрь Фатих Кәрим туып-үскән йорт янындагы куаклыкка килеп төшүен ниндидер язмыш ишарәсе буларак кабул иттеләр.

Башкортстанның Бишбүләк районында якташларын һәрвакыт яратып, сагынып искә алалар. 1971 елда Аетта шагыйрьнең беренче музее ачылды. Аны оештыруга Фатих Кәрим исемендәге Ает урта мәктәбендә озак еллар дәвамында татар телен һәм әдәбиятын укыткан Хатирә Гыйззәтуллина күп көч салган. (Заманында мин дә Фатих Кәрим рухы хөкем сөргән шул мәктәпне тәмамлавымны зур рәхмәт һәм горурлык хисләре белән искә алам.) Шагыйрьнең тормыш юлын өйрәнү, экспонатлар табу өчен, журналист Лотфи Гадилов Уфа, Казан, Мәскәү архивларында эзләнүләр алып барган. Музейның беренче мөдире булып 20 ел эшләгән Саимә Хәйруллина Фатих Әхмәтвәли улы Кәримгә мәхәббәтне авылдашларына гына түгел, бөтен тирәюньгә тараткан. Шагыйрьнең тууына 90 ел тулу уңаеннан, Бишбүләк районының ул вакыттагы администрация башлыгы, соңрак Башкортстан Республикасының дәүләт органнарында зур вазифалар башкарган Илдар Гыймаев тырышлыгы белән, Фатих Кәрим музеена яңа бина салынган. 2007 елда шагыйрьнең скульптор Х.Хәбибрахманов иҗат иткән бронза сыны музей алдына куелган. Соңгы елларда Фатих Кәрим музеенда эшләүче Рәйсә Хафизова, шагыйрь исемендәге Ает мәктәбе укытучылары һәм укучылары, мәдәният йорты хезмәткәрләре Башкортстан һәм Татарстан районнары, Калининград өлкәсе һәм башка төбәкләр белән элемтәне җанландырып җибәрделәр. Бишбүләк районына баручылар, Аетка килеп, Фатих Кәрим бусагасына аяк басарга тырышалар. Шагыйрьнең катлаулы язмышы, иҗаты белән кызыксыну арта.

Казанда Фатих Кәрим урамында, шагыйрь яшәгән ике йортның диварында таш такталар куелган. Болар барысы да шагыйрь язмышының беренче гасырында эшләнгән. Хәзер инде көн тәртибенә Фатих Кәримнең истәлеген мәңгеләштерү, аның әсәрләренең кыйммәтен яңа заман үлчәмнәре белән билгеләү, аларның рухын яшь буынга җиткерү мәсьәләсе яңадан килеп басты. Гомумән, классик шигърият, Дәрдемәнд, Тукай, Такташ, Җәлил, Фатих Кәримнәрнең рухы һәм иҗаты хәзерге чорда милли җәмәгатьчелеккә яңадан кайтырга, халык күңелендә сакланырга тиеш. Аларның иҗатыннан әдәбият, мәдәният, милләт язмышын хәл иткәндә таяныч булырлык рухи көч, илһам чишмәсе агып чыга.

2009 елның 9 гыйнварында күренекле шагыйрь Фатих Кәримнең тууына 100 ел тулды. Әлеге вакыйгага кешеләрнең мөнәсәбәте, Фатих Кәримгә һәм аның иҗатына күрсәтелгән игътибар һәм мәхәббәт көтелгәннән дә көчлерәк булып чыкты. Бу көнне шагыйрьнең кызы Ләйлә ханым Кәримова, Татарстан халык шагыйре Ренат Харис һәм Язучылар берлеге җитәкчесе Илфак Ибраһимов Калининград өлкәсенә, шагыйрьнең соңгы тамчы каны тамган, җәсәде күмелгән урынга киттеләр. Багратионовск шәһәрендә яшәүчеләр Фатих Кәрим каберенә мәһабәт һәйкәл куйганнар, аның юбилеена багышлап, 3000 данә шигырьле истәлек рәсемнәре чыгарганнар. Шул ук көннәрдә шагыйрьнең туган авылында, ул укыган Бәләбәй педкөллиятендә, Казанда, Түбән Камада, Чаллыда, Буада, Татарстанның башка район-шәһәрләрендә Фатих Кәримгә багышланган кичәләр, әдәби очрашулар башланып китте. Юбилей елы дәвамында барган бу кичәләрдә мәктәп укучылары, студентлар, укытучылар Фатих Кәрим шигырьләрен илһамланып укыдылар, аның тормышын, каһарманлыгын искә алдылар. «Мәгърифәт» газетасында оештырылган викторина сорауларына җавап бирүчеләрнең саны, җавапларның саллылыгы бигрәк тә күзгә ташланды. Фатих Кәрим белән кызыксыну, аның шигырьләрен уку, тыңлау,

шагыйрьнең каһарманлыгына, фидакарьлегенә, эчкерсезлегенә гаҗәпләнү, татар шигъриятенә тартылу, ихлас, халыкчан әсәрләргә сусау күренешләре яна заманның сенсациясе булып күренде.

Мәктәп программаларында Фатих Кәрим иҗатын өйрәнү кыскартылуга карамастан, мәктәпләрдә шагыйрьнең әсәрләре буенча әдәби-музыкаль композицияләр күрсәтәләр. Өстән күрсәтмә бирелмәгән килеш тә, Уфадагы «Нур» театры Фатих Кәрим әсәрләре һәм язмышы нигезендә «Ясмин гөле» спектакле куйды.

Татарстан Милли музеенда югары сәнгатьле әдәби-музыкаль кичә оештырып, анда катнашу һәм аны күрү зыялылар арасында зур дәрәҗәле гамәл буларак танылды. 30 нчы елларда Фатих Кәрим җаваплы сәркатип булып эшләгән «Сөембикә» (элеккеге «Азат хатын») журналы редакциясе шагыйрьнең иҗаты һәм тормыш юлы турында бик күп язмалар әзерләде. Журнал 2009 елны Фатих Кәрим елы дип игълан итте.

Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис 40 ел дәвамында шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗатын үз әсәрләрендә чагылдыра. Шагыйрьнең 100 еллыгы уңаеннан ул әзерләгән «Соңгы дәфтәр» факсимиль тупланмасы «Идел-Пресс» нәшриятында басылып чыкты. Ренат Харис шагыйрьнең мәхәббәтенә багышланган «Кадрия» поэмасы, бозлы диңгез суында, үлем баржасында һәлак булудан котылып калуын, нахак гаепләү һәм репрессияләр золымын чагылдырган пьеса иҗат итте. Мондый эшләр, фәнни-иҗади планнар яки социаль заказ буенча түгел, ә йөрәк кушуы, шәхси әхлакый ихтыяҗ тәэсирендә башкарыла. Омск өлкәсендә туып-үскән Гыйрфан Бәхтияров, Фатих Кәримнең Калининград өлкәсендәге җәсәден Багратионовск шәһәренә күчереп, анда истәлек ташы, аннары һәйкәл куюны да үзенең намус эше дип саный. Чисталык, фидакарьлек, рухи бөеклек һәм халыкчан әдәбият шул рәвешчә йөрәктән-йөрәккә, күңелдән-күңелгә менә шундый рухи җылылык тарата.

Фатих Кәрим мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре алырга өлгермәсә дә, чын халык шагыйре, татар халкының каһарман улы буларак алыштыргысыз урын биләп тора. Фатих Кәримнең илкүләм тарихи шәхес булуын аның фронтташлары яхшы аңлаган. Шагыйрь һәлак булган көнне полкташлары Фатих Кәримнең шинелен, итеген һәм шигырь язылган дәфтәрләрен, тартмага салып, Казанга җибәргәннәр. Мондый кешенең халык күңелендә калачагы, шәхси әйберләренең музейда торырга тиешлеге аларга 1945 елның 19 февралендә үк аңлашылган.

Фатих Кәримнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә, хакыйкатьне табуга, аның әсәрләрен бастыруга гомерен багышлаган галим Зәет Мәҗитовның хезмәте бәяләп бетергесез. Шагыйрьнең кызы Ләйлә Кәримова, әтисенең тормыш юлын, шигырьләрен һәм поэмаларын, проза әсәрләрен һәм «Шакир Шигаев» пьесасын бастырып, халыкка җиткерү өчен фәнни институт кадәр эш башкара. Әгәр дә шушы ике шәхес озак еллар дәвамында шагыйрьнең мирасын барлау, саклау, аңлату белән шөгыльләнмәсә, әдәбиятыбыз һәм рухи дөньябыз шактый зур югалтуларга дучар булыр иде.

Шагыйрьнең тууына 100 ел тулу уңаеннан һәм сугыш тәмамлануга 65 ел якынлашканда, Фатих Кәрим иҗатын, тормышын гыйльми яктан өйрәнү, бәяләү буенча эшчәнлек җанланды. 2009 елның маенда Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге катнашлыгында «Фатих Кәрим—шагыйрь һәм яугир» дигән темага төбәкара фәнни-гамәли конференция уздырылды. Соңгы елларда каһарман шагыйрьнең иҗатына багышланган фәнни хезмәтләр, аның сайланма әсәрләре басылмаса да, Фатих Кәримнең тормышы, иҗат юлы киң җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгеннән китмәгән булып чыкты. Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, күренекле язучы Рафаэль Мостафин, әдәбият галимнәре Фоат Галимуллин, Тәлгат Галиуллин, Азат Әхмәдуллин, мәгърифәт белгечләре шактый тирән, актуаль чыгышлар ясады. Фатих Кәримнең гыйбрәтле язмышын һәм кызыклы иҗатын югары бәяләүдән гайре, бередә актуаль

проблемаларга заманча фикерләр яңгырады. Шагыйрьнең ин билгеле патриотик шигырьләрен мәктәп программасына кайтару тәкъдиме дә шунда әйтелде. Чыннан да, Фатих Кәрим кебек олы шәхесләргә мөнәсәбәт, аларның әһәмияте һәрвакыт үзгәреп, бәхәсләр уятып тора.

Әдәбият галиме Равил Рахмани, мәсәлән, шагыйрь иҗатының тирәнлеген һәм тулылыгын аңлауны кыенлаштыручы догмаларга игътибар итә. Фатих Кәрим турында фикерләрнең инерция буенча яшәп килү сәбәпләрен ул болай аңлата:

1. Ватан сугышының дәһшәте тәэсиреннән һаман әле айнып җитмәү, сугыш ветераннарына булган хөрмәтне механик төстә сугышның үзенә күчерү, кыскасы, сугыштан курку, аңа табыну һәм аны идеаллаштыру.

2. Фатих Кәрим иҗатында нәниләр, балалар, үсмерләр һәм яшьләр шигърияте казанышларын бәяләп бетермәү.

3. Шагыйрьнең төрмә чоры шигырьләренә һәм аларның кыйммәтенә күз йому.

4. Сугышның үзенә дә фәлсәфи бәя биреп, аның дәүләт кулындагы идеологик сәяси көрәш чарасы булуына игътибар итмәү.

5. Әдипнең сугыш чоры шигырьләре философиясен идеаллаштырып аңлау.

Алдагы сәбәпләрнең уртак нәтиҗәсе буларак, симфоник оркестр кебек күп авазлы, гармонияле бу шигъриятнең гомумсоциаль яңгырашлы бер ягына артык игътибар итеп, икенче, нечкәрәк, тирәндәрәк яткан милли психология, эстетик эшләнеш үзенчәлекләрен күз уңыннан ычкындыру, димәк, шагыйрь иҗатын тулаем дөрес бәяләмәү. «Менә шушы сәбәпләр,—дип белдерә Равил Рахмани,—аны (Фатих Кәримне) коеп куйган фронтовик шагыйрь ясый да инде. Әйтерсең лә шагыйрь, полководец кебек, дөньяга сугышыр өчен генә килә... Ни генә булмасын, бүген шагыйрь иҗаты бездән яна, объектив бәя көтә».

Яна бәя бирү өчен, фәнни тикшеренүләр, чорга һәм әдәби әсәрләргә, язмышларга сәяси конъюнктурадан азат булган объектив караш кирәк. Хәзерге чорда Фатих Кәримнең балалар, яшьләр өчен әсәрләрен өйрәнергә комачалаучы сәбәпләр юк. Шигырьләрен, проза һәм публицистикасын, сәяси ихтыяҗдан аерып, сәнгать кануннары аша бәяләргә дә мөмкинлек бар.

Соңгы елларда кая барсаң да Фатих Кәримнең китапларын сорыйлар. Китапханәләрдәге иске җыентыклар күптән тузган, әле генә чыккан кебек «Кыр казы» (2004), «Соңгы дәфтәр» (2009) китаплары да тиз арада таралып беткән. Нәкъ шул чорда шагыйрьнең 100 еллык юбилее уңаеннан «Мәгариф» нәшриятында Фатих Кәримнең ике томлык сайланма әсәрләре басылып чыгу, татар әдәбияты һәм мәгарифе өчен бик зур вакыйга булып, үлем турында уйламаган чын халык шагыйренең яңадан халкына, иленә кайтуы аның гомеренең озын булуын раслый.

**Римзил ВӘЛИ,**

*журналист, Ф.Кәрим исемендәге премия лауреаты,*
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

# ИЛҺАМ УЧАГЫҢ СҮРЕЛМӘСЕН...

## РАШАТ НИЗАМИ ИҖАТЫ ТУРЫНДА УЙЛАНУ

Бернечә ел элек бу әдипнең «Тормыш трамвае» исемле шигырьләр китабын нигез итеп алып «Һәр шагыйрьнең үз бизәге...» исемле мәкалә язып чыккан идем. Ул әүвәл «Идел» журналында басылды, сонрак «Әдәбият—хәтер хәзинәсе» (2008) дигән хезмәтемдә урын алды. Р. Низаминың прозасы, әтрафлы публицистикасы, эссеистикасы да читтә калырга тиеш түгел дип уйлап йөри идем, менә янәдән аның иҗаты турында фикеремне әйтергә форсат чыкты. Терекөмеш кебек хәрәкәтчән, житез, өлгер, күнеле гел изгегә тартылып торган, язның беренче көнендә туган, унбер китап авторы иҗатына мөнәсәбәтемне белдерү нияте белән рәхәтләнеп кулыма каләмемне алдым. Тормышында да, иҗатында да үзе булып кала алган, бер әдәби жанрга да диярлек «тынгы» бирмәгән язучы турында язырга да, бәхәсләшергә дә мөмкиндер.



*«Казан утлары» журналы редакциясендә. Алгы рәттә (сулдан уңга): Рәшат Низами, Рәдиф Гаташ, Кояш Тимбикова; икенче рәттә: Флүс Латыйфи, Тәүфыйк Әйди, Җәүдәт Миңнуллин. 1987 ел.*

Р. Низами чал тарихлы татар шигъриятенә «Йолдыз яңгыры» (1980) исемле җыентыгы белән үзе турында ым салып, алдагы елларда кешелек дөньясын, рухиятне, табигать ямен, халкыбызны борчыган мәшәкать-кайгыларны үзенчә күрә, сурәтли белүче сүз остасы, җәмәгать эшлеклесе буларак үсеп китте, иҗатында мәгънә вә тасвир чиксезлеген эзләүче, метафорага, шартлылыкка таянучы каләм иясе буларак танылды.

Чыннан да, кем соң ул Р. Низами? Аның тормыш юлы, иҗаты кайсы яклары, үзенчәлекләре белән таләпчән күңелләргә хуш килә икән? Ул—үткән гасырның соңгы чирегенә туры килгән милли уяну чорында шәхес һәм шагыйрь, прозаик, эссеист буларак житлеккән затларыбызның берсе. Бер әңгәмәсендә әдип бераз кылтаеп (бәлки, кемгәдер ияреп) «холкым белән мин «волк-одиночка», дип үзен мыскылласа да, кирәксә-кирәкмәсә, сәхнәгә сикереп чыгып, кешеләрне арзанлы көлдерү юлына басмыйча, мәгәр сүзен өздереп әйтә белгән Рашат туган халкына, аның мәдәниятенә 40 елга якын фидакарьләрчә хезмәт итә икән. Иҗатны хезмәткә тиңләсәк, юл башы бишенче сыйныфта укыганда «Ялкын» журналында басылып чыккан тәүге шигырьгә үк барып чыга. Саба районы Иске Икшермә авылында урта мәктәпне, Казан дәүләт дәрелфөнүненең татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, ике ел мәктәптә укыта, күптиражлы газетада, «Татарстан яшьләре»ндә хәбәрче, бүлек мөдире, җаваплы сәркатип, «Ялкын», «Казан утлары»нда бүлек мөхәррире, баш мөхәррир урынбасары вазифаларын башкара. Аның ун елга якын (1997-2006) яшьләр басмасы «Идел»дә баш

мөхәррир буларак Римзил Вәлиев, ФәизЗөлкәрнәев кебек кодрәтле оештыручылар күтәреп калдырган сыйфат кимәлен төшермәскә тырышып эшләвен дә искә алып китү зарурдыр. Икенче бер әңгәмәсен ул, шуклык чапанын иненнән ташлап, «Яшәү өчен көрәш тукталмасын» дип атый, «Хакыйкать эзләгәндә» шигырендә яшәеш үзәнен, тормыш маягын ничек, ни рәвешле күзаллавын калкытып куя.

*Бөтен курыкканым—пыскып яшәү,*
*Яшим икән, яшьнәр утым булсын.*
*Юлга чыксам—кабарыма икмәк,*
*Учак ягарыма утын булсын.*

Р. Низами мәңгелек матурлык, табигать хозурлыгы, мәхәббәт кебек хисләр турында язганда да, бер мизгелгә дә газиз милләтенең язмышы, теле, киләчәге, татарны татар буларак саклаган гореф-гадәтләрнең сынмыйча-сыгылмыйча яңа буыннарда яшәве өчен борчыла. Аның җан дошманы—«кыска хәтер». Шул исемдәге шигырендә ул килешмәүчән пафос белән болай ди:

*«Уян» дип, туган тел чаң кага,*
*Хәтернең күзеннән яшь ага.*

Шагыйрь «нәсел-нәсәбен» онытып маңкортка әйләнә барган оныкларын ояту нияте белән тарихи аңга мөрәҗәгать итә:

*Тарихи хәтернең күзлары*
*Сүнмәсен, калмасын бозланып!*

«Туган телгә мәдхия» шигырендә лирик зат яңа пешкән икмәк кебек тәмле, хуш исле, җанга якын һәм «Тукайлар чиккән байрак»ны саклаган татар теленә артык төчеләнмичә, иң матур, затлы сүзләрен юллый:

*Үлемсез дастаннар кебек*
*Моңлы син, туган телем.*
*Чишмә-чишмә җырлар белән*
*Мөлдерәп тулган көнең.*

(«Туган телгә мәдхия»).

Аның шигърияте ике юнәлештә үсеп китә. Бер яктан, замана таләпләренә җавап буларак, халык язмышы белән бәйле олы проблемаларны эченә алган публицистик аһәңле лирика әһәмиятле урын алса, икенчедән, шагыйрьнең рухына, нечкә күңеленә бәйле, табигать сурәтен, мәхәббәт кичерешләрен, яшәеш низагъларын чагылдырган идиллик лирика мөһим юнәлеш тәшкил итә. Бу ике агымны Тукай, М. Җәлил, С. Хәкимнәр үстергән реалистик калыпка тугрылык, кеше образы якынлаштыра; шәфкатьлелек фәлсәфәсе бер җепкә тезә. Шагыйрь яшьлегендә сайлаган юлыннан бер кәррә дә чигенмичә, төрле чорда үзенчә баш калкыткан «изм»нар шаукымына бирешмичә, кешенең рухи дөньясын сурәтләүнең мөмкинлекләрен эзләүне дәвам итте. «Бирче, дөнья!..» исемле программ шигырьләренең берсендә ул болай ди: «Сабыйлар—Кояшка, өлкәннәр бомбага сузылган заманда миңа күпне күрү, күпне ишетү кирәк!» Декларация бер хәл, әмма мондый илаһи көчкә ия булу өчен Тукай колачы, Тукай зирәклеге, Тукай карашы лязим икән. Шуңа да шигырь галәмгә риторик эндәш, үтенеч белән башлана һәм тәгәлләнә:

*Әй дөнья,*
*Бирче миңа Тукай күзләрен!*

«Шагыйрьне каршылау»да автор халык мәхәббәтенең гасырлар караңгылыгын җиңгән олылыгын, ә Тукайның буыннарны тоташтыру сәләтенә ия бөек шәхес

икәнен шигъри юлларда чагылдыру нияте алга чыга:

*Казан өсләрендә дөрли кояш,*
*Ул шагыйрьне күргән ут-чәчәк.*
*Гасырларны ерып бара Тукай.*
*Һәм каршылый аны киләчәк.*

Шагыйрьне борчыган, төн йокыларын качырган мәүзуг—милләтенең изелеп, кысылып, рәнҗетелеп яшәве, уртак ватан өчен канны койса да, үзен яклый алмавы: «Күпме җирне мәскәүләләр өчен, Әй, татарым, сугышып алдың син». Аның сәнгатьчә җитлеккән шигырьләренә иҗтимагый рух, килешмәүчән пафос хас.

«Азатлык тәме», «Акчарлаклар», «Туган телгә мәдхия», «Әйт сүзенне, яна парламент» кебек шигырьләрендә лирик герой туган халкының тарихи хокукларын яклап, милләтләр муенына аркан кидерү белән мәшгуль Дума әгъзаларына дәгъвасын белдерүдә сатира угын да чыгарып ала. Аларга иң төгәл бәя «үрдәк» икән, чөнки халык сайлап куйган депутатлар «арты белән суга чумалар». «Әйт сүзенне, яна парламент» шигыре XX гасыр азагында Татарстан кичергән сәяси халәтне, «вулкан булып, тарих катламнары кайнап-кайнап» күтәрелгән, киләчәккә «өмет белән тулы» чорны искә төшерүдән башланып китеп, гаепне билгесез көчләргә сылтап калдырмыйча, йомшаклыкны үзебездән эзли: «Кирәк булган япь-яшь Азатлыкны корыч куллар белән сакларга».

Р.Низами каләменнән төшкән «Баш министрга ачык хат», «Чукындыру», «Тәкъдир» шигырьләре хәзерге әдәбиятыбызның сәяси һәм гражданлык лирикасының үрнәкләре саналырга лаеклы.

Яшәүне үлемнән, азатлыкны пыскып, тук яшәүдән өстенрәк күргән лирик геройның җирдә кылачак гамәлләре искитмәле фәһемле, биниһая күп һәм төрле икән. «Тормыш трамвае» исемле шигырендә шуларның берсенә һәм иң әһәмиятлесенә игътибар юнәлтелә:

*Яшьнәп яшәр өчен бу тормышта*
*Гашыйк булу кирәк иң элек.*

Р. Низами күзаллавында мәхәббәт дигән «серле йомгак» ике яшь җилкенчәкнең айга карап тын алырга куркып утыруына, мәхәббәт хисеннән әлсерәгән йөрәкләрнең талпынуына гына кайтып калмый. Лирик геройның мәхәббәте сөйгән ярына, гомерлек юлдашына, туган иленең бай табигатенә, иркен кырларына, талтирәкләренә, һәркайсы үз яме белән килгән ел фасылларына, хәтта иң демократик хәрәкәт чарасы—трамвайга да кагыла. «Яшьлеккә хат» повестенда Р. Низами Л. Н. Толстойның бөтен иҗатына юллама итеп куелырлык фикерен юкка гына китерми: «Чын мәхәббәт—берәүне яратудан тыш, рухи халәтең белән бар дөньяны да яратуга әзерлек дигән сүз».

Мәгәр әле моннан шагыйрь «Җир мәхәббәте» ләззәтләренә дә каршы дигән фикер туарга тиеш түгел. «Тополь», «Сөю алмасы», «Сөюне көткәндә», «Син миңа», «Син әйттең» шигырьләрендә автор натуралистик ваклыклар дәрәҗәсенә төшмичә, мәхәббәтне илаһи бер бүләк итеп, романтик күпертү, чагыштырусынландырулар ясауда халык җырларыннан күнеленә ингән бизәкләү чараларына таяна, үстерә:

*Ике битең пешкән алма кебек,*
*Бер алмага карыйм, бер сиңа.*
(«Сөю алмасы»).

*Урман эчендәге ак каендай,*
*Яктырдың син үтеп барышлый.*
(«Таныш түгел кызга»).

Р. Низами иҗатында табигать тынсыз, битараф бизәк түгел, ул тирәлекнең югары казанышы, күрке, һәр күренешенә гашыйк Кеше аның җаны икән ләбаса («Узып барышлый», «Җәйге чиллә», «Сыерчыклар көткәндә», «Печән чабам»). «Син һәм мин» шигырендә «сары шәлен болгап, тын бакчадан күз йөгереп чыга» каршысына, ул да булмый «ак байрагын тотып кыш чаба», дип шагыйрь ел фасылларының алышына бару манзарасын тудыра. «Кич» шигырендә кеше тормышының өмет һәм ышаныч саркып тыныч кына агышын үзәккә ала.

*Ага гомер, салмак дәрья сыман,*
*Ага гомер, булмый туктатып.*

Р. Низами сүзнең, туры мәгънәсенә өстенлек бирүче шагыйрь булса да, ихтыяҗ чыкканда, эре образлар ясаудан, текә борылышлардан тартынып тормый.

*Кояш мөнбәренә*
*Ак йолдызлар менеп кунаклады...*
*Тагын бер көн үлде галәмдә.*
(«Вакыт сурәте»).

Р. Низами иҗатына төсләр куелыгы, фикер тәвәккәллеге, шатлыкны да, фаҗигане дә чагылдыруга буйсынган кичереш хәрәкәте хас. Аның шигъри дөньясы үзе бер халәт, автор сүз белән сурәт ясый, сурәткә матурлык үрә, күңел җәүһәрләрен йөрәкләргә индерә бара. Ул «кешнәү кайтавазын йөрәгенә кыскан болыт»ның «хәленә» керә, ап-ак карны кызыл итеп күрә, каһарманы күктәге «Йолдызларны тотып-тотып карау» турында хыяллана. Ә хыялсыз кеше—мескен кеше диләр түгелме? Юк, аның каләменнән төшкән персонажлар Гоголь Маниловы кебек буш өметләр, тормышка ашмас ниятләр белән яшәүче, чегән арбасыннан төшеп калган буш, затсыз адәмнәр түгел. Сугышта уң кулының бармакларын өздереп кайтса да, тормыш дәрте, яшәүгә омтылышы бөтен тән күзәнәкләреннән бөркеп торган Кирам—моңсыз, гармунсыз тора алмый. Гармунының телләрен кучереп, сул кулының бармакларын ихтыярына буйсындырып, бәгырьләрне телгәли-телгәли, өздереп-өздереп тальянкасын тарта. Исемнәреннән үк күренгәнчә, Р. Низами проза әсәрләрендә дә («Кызыл кар яугач», «Ут һәм җыр», «Яшьлеккә хат», «Урман эчендә урман» һ. б.) шигъри җанлы, романтик табигатьле иҗатчы булып кала. «Без Рәшатка шат» исемле мәкаләсендә («В.Т.»—2000.—3 март) сабакташы Р. Сибат аны «Романтик рухтагы реалист» дип атый. Тормышны ал төсләрдә, хисләр дулкынында гына кабул итеп, бизәп сурәтләүче романтикмы ул, әллә майламаган арба тәгәрмәче кебек ачуны китереп шыгырдап баручы натуралистмы, дөреслекне күзгә карап әйтүдән курыкмаучы реалистмы—анысын билгеләүне киләчәккә калдырып—Р. Низаминың холкы, дөньяга карашы урнашкан, һәр шәйгә анык бәясе булган, үзен вак-төяк дөнья матавыкларыннан өстен куя белгән шәхес, сүз сәнгатебездә үз лаеклы урынын тапкан язучы икәнлеген генә искәртәсе килә.

Чәчмә әсәрләрендә дә автор милләт гаме белән бәйле проблемаларга килеп чыга. Аерым алганда, Р. Низами мәдәниятебез тарихында якты эз калдырган олы шәхесләребез язмышына игътибарлы. Бу төр әсәрләрендә ул, бер яктан, халкыбызның талантларга бай булуын ассызыклап үтсә, икенчедән, әдип бөекләребезнең мирасын, исемен саклый белү, ачышларын яңа буыннарга җиткерү турында онытмаска чакыра.

XX гасыр даһиларының тормыш юллары, иҗатлары—әдип өчен сүнмәс-сүрелмәс илһам чыганагы. Өч олы шәхесебез һәрдаим аның игътибар үзәгендә: Гаяз Исхакый, Фәрит Яруллин, Салих Сәйдәш... Жанрын роман-хроника дип билгеләгән, атаклы кешеләр сериясендә басылып чыккан, кайта-кайта төзәткән, тулыландырылган «Ут һәм җыр» әсәре татар халкын дөньяга таныткан атаклы «Шүрәле» балеты авторы Фәрит Яруллин турында. Р. Низами композиторның шәҗәрәсен, ата-бабасы тарихын, эзләнү-үсеш чорларын сурәтләү, ахыр триумфын күрсәтү белән генә чикләнми. Яшь талантның музыкага килү юлының каршылыклы, әрнүле, хәтта

үзеннән тормаган фаҗигале булуын тормышчан детальләргә, фактларга таянып күз алдына бастырып, көнчелек, битарафлык нәтиҗәсендә милләт былбылын сугыштан алып калу хәстәрен күрмәгән композиторлар берлегенә, хөкүмәт житәкчеләренә кырыс бәя бирә, үпкәсен сиздерә. Автор каһарманын бизәп, үз чорыннан аерып сурәтләми. Совет мәктәбендә, җәмгыятендә «ура» патриотизм рухында тәрбияләнгән композитор егет—күнеленда да, хатларында да немецларны шәхси дошманнары итеп күрә, үзен башкалардан аерып кую мөмкинлеген эзләми; талантның халык байлыгы булуын башына да китермичә, үзен гадәти сугышчыга һәм гражданинга санап, утка керә. Бу ир-егетнең бөеклеген аңлаган Мәскәү профессоры Литинский гына аны саклап калырга тырыша. Автор бу олы җанлы затка рәхмәтен әйтергә онытмый.

Фәрит Яруллинның үлемен әдип татар милләтенә явыз көчләр тарафыннан җибәрелгән фаҗига итеп сурәтли, исәннәрне аның якты исемен мәңгеләштерүгә чакыра. Романда Р. Низами яшь композиторның уйлану-эзләнүләренә таянып, татар җырының, моңының үзенчәлекләре, галәми яңгырашы, халык тарихында тоткан урыны турында фикерләре белән дә уртаклаша.

Кайбер урыннарда композиторның биографиясенә ияреп бару, фактология бертөслелек китереп чыгарса да, гомумирәк рухтагы фәлсәфи, милләт балалары язмышы турында әхлакый уйлану-фикерләр романның офыгын киңәйтеп җибәрә.

Икенче бөек маэстробыз исталеге турында да онытмый икән Рашат. Салих Сәйдәшевкә, аның фаҗигале соңгы елына багышланган кыйссасын әдип үзенең юбилеена саклап тоткан икән. «Казан утлары» журналы 2010 ел башында укучысын шул әсәр белән таныштырды. Тукай, Урманчеләр сафын бизәп торучы олуг тарихи шәхесебез турында Р. Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасыннан соң күләмле әсәрнең күренгәне юк иде кебек.

Фәрит Яруллин, Сәйдәш... Нигә дип әле Рашат иптәш, татар халык моңына, җырына таянып, музыка сәнгатебезне профессиональ югарылыкка күтәргән асыл затларыбызга шулай мөкиббән китеп яши, исемнәрен халык күңеленә сеңдерү юлларын эзли дигән соальнең тууы табигый. Мине дә бу сорау беркадәр тәшвишкә салган иде. «Ут һәм җыр» авторының кулында гармун күреп, нәкъ безнең яшь чактагы авыл «биетүчеләре» кебек, башын әле уң әле сул иңенә салып, милли көйләребезне өздереп, моңландырып уйнавын күргәч, көйле, моңлы, сызланучан шәхес икәнен аңлагач, бу «чиренең» сәбәбенә төшендем. Шигырь, җыр, көй, күңел сагышы—һәммәсе халкыбызның рух җимеше. Р. Низаминың музыкаль әсәрләргә, аның иҗатчыларына белгечләр дәрәҗәсендә бәя бирә алуында, сәнгатебезнең бу тармагын җаны белән тоюдан, нәзберек хисеннән килә икән.

Бөек шәхесебез Гаяз Исхакый намена «Ике мөһаҗир» исемле поэмасын багышлавы шулай ук җинел аңлатыла. Үзе дә Исхакый кебек тормыш юлын укытучы мөгаллим, гәҗитәче вазифасында башлап, шигырь аша прозага, публицистикага юл ала, хәленнән килгәнчә, туган халкының язмышы өчен җан атып йөри. Инкыйлаблар заманында яшәсә, бәлки, ул да Исхакый кебек илгизәрлек язмышын сайлар иде.

Р. Низаминың ошбу әсәре турында фикерләремне укучыларга житкергаләгән булсам да, «Ике мөһаҗир»нең сәяси юнәлешенә, сәнгати үзенчәлекләренә нисбәтән берничә күзәтүем белән уртаклашмасам, дөрес булмастыр. Хәер, татар шигъриятен каһарман шәхесебезгә игътибарсызлыкта гаепли алмыйбыз. Г. Исхакыйның эшчәнлегенә, көрәш юлына, әдәби мирасының мотивларына, мөһаҗирлек язмышына төрле кимәлдәге дистәләрчә шигырьләр, җырлар, поэмалар иҗат ителгән. Р. Низами берәүне дә кабатламыйча, һәр бөеклек түбәнлек белән чагыштыруда күренә дигән ышанычын маяк итеп алып, поэмасының фабула үзәгенә төрки дөньясының ике күренекле шәхесен—Г. Исхакый белән төрек шагыйре Назыйм Хикмәт образларын ала.

Совет режимының асылын, милләтләргә, зыялыларына мөнәсәбәтен вакытында аңлаган беренчесенең чит илгә, нигездә Төркиягә китәргә мәҗбүр булуын, икенчесенең исә Төркиядән качып яңа, бәхетле тормыш вәгъдәләре белән күз буяган большевиклар мәрхәмәте астына килеп сыенган Н.Хикмәт образларын төрле-төрле

вакыйга-хәлләр аша тасвирлый. Поэма каһарманнарын туган илләреннән читтә яшәү мәҗбүрияте тудырган фаҗигале язмышлары якынлаштыра. Икесе дә—туган илләрендә урнашкан хакимиятнең дошманнары. Ләкин каршылыкның шартлары, мотивлары төрле, капма-каршы. Гаяз Исхакый чит илләрдә яшәгәндә дә туган милләтен чарасызлык упкынына ташлаган советларга каршы көрәшен соңгы сулышына чаклы дәвам итә. Төрек шагыйре, киресенчә, коммунистлар йөзендә дөньяны коллык богауларыннан азат итәргә килгән изге көч күрә һәм Ататөрек төзегән демократик республикага каршы көрәш юлына баса. Каһарманнарының сәяси карашларына бәя биргәнче, автор тормышта үз юлыңны табуның шактый катлаулы булуына басым ясый:

*Тормыш бит ул чуар калейдоскоп—*
*Кайда золым, кайда тамаша...*

Поэманың үзегенә шул рәвешле дөньяга ике төрле караш тудырган сәяси конфликт куела:

*Исхакыйны Назыйм Хикмәт белән*
*Куеп карыйм кайчак янәшә.*
*Назыйм Хикмәт—сәяси бер корбан,*
*Ә Исхакый*
*Туры Тукайга тиң ләбаса.*

Төрек шагыйренең дә ахыр нияте изге: ул да халкына изгелек, бәхет тели, мәгәр азатлыкны коммунистик идеаллар гына алып килә дип уйлап ялгыша. Автор аның бу ышанычын шактый төгәл чагылдыра: «Чит илдә татлыдыр шикелле Азатлык һәм Ирек һавасы», «СССРның алсу төс икәнен ишетеп белдем мин». Төрек шагыйренең фаҗигасе чынбарлыкны чалыш күзгә аша күреп, хыялны гамәл белән бутау яссылыгында ята.

Н. Хикмәтнең антиподы Г. Исхакыйның туган җиренә, милли теленә мөнәсәбәте, халкының киләчәге өчен иң кыен шартларда фидаиләрчә көрәше поэмада үзәк мотив булып кала: «Татар өчен жаны актарыла, уйный канда фикер хәрәкәте».

Әдәби әсәр үткәнне сурәтләү аша бүгенге вәзгыятькә бәя бирүгә дә омтылырга тиеш. Поэма авторы үзенең дәртле монологларында хәзерге житәкчелекнен күпмилләтле ил белән идарә итүдә шул ук империячел алымнарга таянуын фаш итә.

*Һаман бер сүз—«Единая...» диеп*
*Кабатлыйлар, гүя попугай.*

Чор һәм олы сәясәт турында әтрафлы фикерләрен автор «Идел белән Урал арасы», «Казан. Ирек мәйданында уйлану» исемле соңгы бүлекләрдә алга чыгара, азатлык өчен көрәш юлына баскан каләмдәшләренә рәхмәтен әйтеп, жир йөзендәге һәр халык үз менталитеты, холкы, моны белән үз туган төбәгендә, хуҗа булып яшәргә хаклы дигән теләген, таләбен калкытып куя.

«Ике мөһажир» Р. Низаминың фаҗигале хәлләрне үзәккә алып, аерым кеше язмышын олы сәясәткә бәйләп ачуга сәләтле сүз остасы икәнен раслады. Автор мөһажирләр тормышын сурәтләү аша халыкның хәзер үзеннән генә тормаган сәбәпләргә бәйле киләчәген яралы жаны аша уздыра, сызлана, әрни.

Р. Низами поэма жанрына сирәк мөрәҗәгать итсә дә, «Ике мөһажир» әсәре лиро-эпик төрдә дә аның мөмкинлекләре житди икәнлекне раслады.

Р. Низами офыклар артында күренер-күренмәс жемелдәп күренеп алган хыялый образларга караганда, реаль хәлләргә, документаль нигезгә утыртылган вакыйгаларга, реаль, тарихи шәхесләрне сурәтләүгә өстенлек бирә икән. Бу—иҗатының буеннан-буена сузылган бер үзенчәлеге. Русның бөек гуманист язучысы Л. Н. Толстой, киләчәктә уйдырма әсәрләргә караганда тормышта булган хәлләрне, таныш кешеләрне, тарихи шәхесләрне (үзенең Кутузов, Наполеон, патша кебек тарихи

затларга игътибарын искә төшерегез) тасвирлаган әсәрләрне яратыбрак кабул итәчәкләр, дигән. Р. Низамины язучы буларак күтәргән әсәрләренен нигез өлгесендә абыйсы, якташлары, дуслары яисә татар халкының күренекле шәхесләре образлары тора. Реаль тормыштан алынган каһарманнарны тасвирлаганда ул натурализм дәрәҗәсенә төшмәскә, образлылык белән фотокопияне бутамаска тырыша.

Тормышта берәүгә дә тынычлык юк ди кебек әдип. Аның күпчелек каһарманнары рухи һәм физик сынаулар үтәләр. Сыер караучы Галия, очучы Шаһинур, солдат хезмәтеннән кайткан Фәрит, әтисез үскән 9 яшьлек Госман, әсир мөһаҗирләр Вәлит, бомж Тимержан, язмыш сынауларына бирешмичә, һәрберсе—үз кыйблаларын эзлиләр. Һәркайсы кабатланмас шәхес.

Р. Низами сәнгатькяр буларак гадәти төшенчәләр, әзер өлгеләр, күнегелгән төсләр белән генә эш итәргә яратмый. Ул аеруча җете төсләргә мөкиббән: ап-ак, кып-кызыл, зәп-зәңгәр, карасу-яшел, аксыл-көрән... Төсләрне оста рәссамнар киндергә буяу төшергән кебек сайлап алу осталыгы, тел-сурәтләү чараларына игътибарлы булуы, һәр берәмлекнең мәгънәне чагылдырудагы урынын бәйләве—әзләнүчән һәм үткен күзле булуы турында сөйли. Йоклатучан бертөслелек язучының кабатланмас йөзен үтерүче явыз көч ди кебек автор.

Шигъриятендә дә ул ритмик төгәллеккә һәм рифма-кафия төгәллегенә өстенлек бирсә дә, дүртюллыкларын арадаш кафия белән бизәргә дә ярата («Тама торгач»— а-а; а-а), сонет, баллада кебек Көнбатыштан иңгән каноник шәкелләр мөмкинлекләреннән иркен файдалана, ике-өчюллыкларда да фикерен уеп сала белә.

Язучыны җәмгыять һәм халкы өчен кирәкле, файдалы, мөрәүвәтле иткән сыйфатлар турында уйланулары белән Р. Низами «Алдым кулыма каләм» (2007) исемле китабында уртаклаша. Матбугатта унай бәя алган (Р. Мостафин), язучы хезмәтенен серләрен ачуга багышланган бу әсәренә заминне ул студент елларында ук җыя башлаган икән. Әдәбият тарихыбызда М. Әмир, Ф. Хөсни, И. Гази, Х. Сарьян, Г. Ахунов кебек мөхтәрәмнәребезнең үз тәҗрибәләре белән уртаклашкан язмалары мәгълүм булса да, Р. Низами җыентыгының авторы—коллектив. Әдип ярым фәнни, ярым популяр хезмәтендә төрле жанрларда иҗат итүче берничә буын әдипләрнең фикерләрен, теләк-ниятләрен, фаразларын бер җепкә тезеп, уртак композициягә буйсындырып, кызыклы нәтиҗәләр ясый, яшь каләм ияләренә файдалы киңәшләр бирә. Каләмдәшләрне вакытларын юк-бар, вак-төяк проблемалар белән уздырмаска чакыруы—халык язмышы хакында уйлануга өндәү кебек яңгырый. «Зур гамьнәр, проблема-борчулар белән яшәү, әйтер сүзең булу шулай ук мөһим. Юкса, буш сүз очырудан, чыпчыктай туктаусыз чыркылдаудан, графоманлыктан файда юк»,—дип яза автор.

Р. Низами иҗатының янә бер үзенчәлеге—автор образының сурәтләнгән вакыйга хәлләргә битарафлык сакламыйча, әңгәмә уртасына «бәреп» кереп, үз фикерен әйтә белүе. Замандашына җиде хат рәвешендә язылган мөрәҗәгатендә ул болай ди: «Беләсеңме микән, синен барлык кичерешләрен, яндырып-яндырып минем йөрәк аша да узды. Синең пакь, керсез йөрәгең күтәрелгән биеклеккә асылда мин дә күтәрелдем».

Шул күтәрелгән биеклегендә кала алсын иде Рәшат Низами—иҗатында да, тормышында да. Җыеп кына әйткәндә, мәкаләбез каһарманы үзенең 60 яшьлек бәйрәмен халык гаме һәм милләт ихтыяҗларын үзәккә куйган, ихласлы, эзләнүчән прозаик, ялкынлы публицист, житлеккән шагыйрь буларак каршы ала.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы.*

# ТАТАР ТРАГЕДИЯСЕ

Татар әдәбиятында драматургия шактый соңарып, XIX гасырның соңгы чирегендә генә мәйданга килә. Әмма иҗтимагый-мәдәни тормыштагы Янарыш шартларында ул тизләтелгән үсеш кичерә һәм XX гасырның унынчы елларында инде тулысынча формалашып җиткән, драма һәм комедия жанрларының уңышлы үрнәкләре белән танылган әдәби төр буларак яши. Бу чорда татар әдәбияты, мәгърифәтчелек реализмы белән бергә, тормыш-чынбарлыкны тәнкыйди реализмга хас әдәби-эстетик күзаллауларга нигезләнеп чагылдыра башлый. Эзләнүләрнең тагын бер юнәлеше исә урта гасырлардан килүче үзенчәлекле романтик сурәтләү урынына Европа тибындагы романтизмга күчә бару белән бәйле.

Татар сүз сәнгатендә трагедия жанрының беренче үрнәкләре дә әнә шундый шартларда языла. Әлеге жанрның асылын билгеләгән сыйфатларны һәм милли үзенчәлекләрне шул чор белән тыгыз бәйләнештә карау кирәк. XX йөз башы—татар халкы тормышында гаять әһәмиятле чор. XIX гасырның икенче яртысында башланып киткән мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм аның яңа баскычы булган җәдитчелек халык тормышының бөтен өлкәләренә үтеп кереп, җитди үзгәрешләргә юл ача. Бу аеруча мәгариф системасын үзгәртеп коруда, ягъни мәктәп-мәдрәсәләрдә дөньяви фәннәр укыта башлауда, ислам динен реформалаштыруда, ягъни аны заманга яраклаштыруда; татар телен җанлы сөйләм теленә якынайтуда, китап бастыру һәм тарату эшен җайга салуда, вакытлы матбугат булдыруда чагылыш таба. Болар янында тагын бер җитди күренеш калкып чыга: бу—милләт буларак формалашу процессы кичергән татар халкының сәяси партияләр төзеп («Иттифак»), парламент юлы белән үз хокуклары өчен көрәшкә чыгуы. Әлеге һәм башка төрле чаралар, эшчәнлек халыкта милли үзаң үсүгә, аның үз тарихы, мәдәнияте белән кызыксынуга, рус-татар мөнәсәбәтләре турында уйлануга китерә.

Россия тарихында кан-яшь белән язылган күренешләрнең берсе—мөселман халыкларын, беренче чиратта татарларны, көчләп чукындыру белән бәйле. Татар драмтургиясе тарихындагы беренче трагедия әнә шул вакыйгаларга мөнәсәбәтле языла. Г. Исхакыйның «Зөләйха» пьесасында (1912) шәхес, гаилә трагедиясе милләт фаҗигасе буларак ачыла. «Трагедиянең төп герое тирәсендәге башка персонажлар, аларның аянычлы хәлләре, гасырдан-гасырга күчеп килә торган милли каршылык белән бәйле булып, әсәрнең финалы фаҗига белән бетә»,—дип яза М. Җәләлиева. Эстетик аспектта алгы планга кыюлык-батырлыктан бигрәк, әрнү һәм газаплану чыга. Гадәттән тыш рухи көчкә ия булган Зөләйха кичерешләрен укучы-тамашачының үзенеке дип кабул итүе җан-рух хәрәкәтенә китерә, фаҗигале шәхескә соклану, хөрмәт хисе уята.

Ф. Борнашның «Таһир-Зөһрә»(1918) трагедиясендә чагылыш тапкан шәхеснең рухи азатлыгы һәм социаль-иҗтимагый идеалларның яклануы инкыйлаблар чорына авазлаш. Уңай идеаллар белән яшәүче Таһир үз мәхәббәте хакына хан хакимлеге белән үтеп чыга алмаслык каршылыкка керә һәм һәлак була. Таһирнең һәм сөйгәнен югалткан Зөһрәнең үлеме укучы-тамашачыга гаять көчле тәэсир итә, шәхес иреге, саф мәхәббәт, тигезлек, гаделлек төшенчәләренең мәңгелек булуы турында уйлануларга этәрә.

Совет чорында бездә трагедия жанры әкрен темплар белән үсә. Халык тарихы

гаять фажигале булуга, Россия составында тарих каршылыкларының бөтен авырлыгын үз жилкәсендә татуга, XX гасырда гына да өч инкыйлаб, гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары, коллективлаштыру, репрессияләр кебек коточкыч хәлләрне кичерүгә карамастан, әлеге жанр яшәп килгән система таләпләреннән читтәрәк кала. Моның төп сәбәбе билгеле: әдәбиятнын социалистик реализм кысаларында булуы, идеологик нормаларга буйсындырылуы. Һәрхәлдә, эстетик категория буларак трагизмны, бигрәк тә совет кешесе фажигасен сурәтләү гайре табигый хәл буларак кабул ителә. Шулай да талантлы каләм ияләре әлеге жанрның сүнеп-бетеп калуына юл куймыйлар. Һ. Такташнын «Жир уллары трагедиясе» (1922), К. Тинчуриннын «Зар» (1923), Н. Исәнбәтнең «Спартак» (1933), «Идегәй» (1941), «Муса Жәлил» (1955), Н. Фәттахның «Кол Гали» (1973), Ә. Баянның «Алтын кашбау» (1974), И. Юзеевнын «Соңгы сынау» (1968 ), «Очты дөнья читлегеннән»(1980-1991), «Мәңгелек белән очрашу» (1982) кебек әсәрләре һәркайсы сәхнә әдәбияты тарихында билгеле бер эз калдыра.

XX гасыр ахырында татар драматургиясендә трагедия жанры активлашып китә. «Соңгы елларда буа ерылды. Татар драматургиясенең бөтен тарихына караганда да күбрәк язылып, дистәгә якын әйбәт трагедияләр ижат ителде»,—дип яза А. Әхмәдуллин. Жәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле, драматургларның игътибары, бер яктан, үткән тарихның каршылыклы һәм гыйбрәтле якларына, танылган шәхесләрнең фажигале язмышына юнәлсә, икенче яктан, үзгәртеп корулар китереп чыгарган тормыш катаклизмнары, «кыргый» капитализм шартлары тудырган шәхес фажигаләре сурәтләү объектына әверелә. Әлеге һәм башка мәсьәләләрне трагедия жанры кысаларында уңышлы чагылдырган әсәрләр рәтендә түбәндәгеләр бар: А. Гыйләжев. «Өч аршын жир» (1987), Р. Хәмид. «Актамырлар иле (1990), «Хан кызы» (1995), Ю. Сафиуллин. «Идегәй» (1994), «Йөзек һәм хәнжәр» (1998), З. Хәким. «Шайтан куентыгы» (1999), М. Маликова. «Сөембикә» ( 2002 ) һ. б.

Әсәрләрдә жанрның үткәндәге традицияләренә таяну белән бергә, жәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле тарих-заман-шәхес проблемасын яңа ижтимагый-эстетик планда ачу, шул максаттан форма-алымнар, сурәт чаралары байлыгыннан файдалануның яңа юлларын эзләү бара.

Югарыда саналган пьесаларда трагик шәхес концепциясе чагылыш тапса да, аның бирелеш һәм чишелеш юллары бертөрле генә бәяләнми. Хәзерге рус драматургиясенең бер үзенчәлеген билгеләп, М. И. Громова болай дип яза: «Чиста формада» трагедияләр «традицион» рәвештә бик аз, гәрчә эстетик категория буларак фажигалелек үзенең күптөрлелегендә чагылса да, аерым алганда, тарихи һәм борынгы әдәбият сюжетларына нигезләнгән пьеса-«эшләнмәләрдә», легенда һәм мифларның хәзерге шәрехләүләрендә...» Әлеге күренеш белән татар сәхнә әдәбиятында да очрашабыз. Ерактагы тарихка мөрәжәгать иткән пьесаларда тиранга каршы көрәш идеясе милли характер тудыру омтылышы, гомумән, милләт каршындагы жаваплылык идеясе белән кушылып китә.

А. Гыйләжевнын «Өч аршын жир» трагедиясендә заман каршылыкларында адашып калган, соңрак үз асылына кайта алмыйча газапланган Мирвәли һәм аның хатыны Шәмсегаян язмышы сурәтләнә. Социаль-психологик эчтәлекле әсәрдә геройларның катлаулы, фажигале рухи дөньясын ачуны максат итә драматург. Мирвәли образы татар сәхнә әдәбиятына яңалык алып килә. Ул моңа кадәр урын алган шәхес концепциясенә сыймый, чөнки совет чоры әдәбияты яклаган һәм мактаган уңай герой тибы түгел. Киресенчә, Мирвәли—колхозлашу чорының аяусыз, кешелексез кануннарын кабул итә алмыйча, туган жирен, авылдашларын каргап, йортына ут төртеп чыгып киткән һәм шуның белән үзен дә, хатынын да гомерлек хәсрәткә, борчуга салган фажигале шәхес. Авторның табышы шунда, ул Мирвәлине бөтен кузәнәкләренә кадәр аңлый, шуңа да укучы-тамашачы каршында туры сызык буенча хәрәкәт итүче түгел, бәлки жан газаплары кичерүче, артык горур, кызу табигатьле, көчле, шул ук вакытта чын хакыйкатьне, ягъни хаксызлыгын башкалардан гына түгел, хәтта үзеннән дә яшерергә омтылучы герой ачыла. Әлеге жан бәргәләнүләреннән котыла алмаган Мирвәли, бик сонарып, туган туфрактагы өч аршын жирнең кыйммәтен аңлауга килә. Бу исә күңелендәге үкенечне, зур,

олы тормышның янәшәдән үтеп китүен тоемлауны тагы да тирәнәйтә, нечкәртә. Шуңа да авылдашларының хатынына булган олы хөрмәтен, үзен гафу итүләрен, кешелекле мөнәсәбәтләрен аның яралы йөрәге күтәрә алмый.

Мирвәли белән Шәмсегаянның үзара мөнәсәбәтләрен, бер-берсенә мәхәббәтен сурәтләүдә дә драматург яңа юлдан бара. Яшь чакта бер-берсенә гашыйк булган, егетнең кызны осталыгы, кыюлыгы, көче белән көрәшеп алуын белгән укучы-тамашачы аларның мәхәббәтенә шикләнми. Әмма... Мирвәли бит Шәмсегаянның чит җирдә тилмереп, сагынып-саргаеп яшәвен күрә. Яраткан кешенне шундый газапларга салуны ничек бәяләргә? Тирә-якта матурлыгы, хезмәт яратуы, булдыклылыгы белән танылган Шәмсегаян читтә үзен гомерлек бәхетсезлеккә дучар итә. Җан мәхәббәте генә түгел, тән мәхәббәте дә булмаган ир белән хатын мөнәсәбәтен ничек аңларга? Моны Шәмсегаянның миллилеге, татар хатынына хас сабырлыгы, түземлеге, ирен ир итеп яшәве, үз язмышын яшь вакытта сайлаган кешегә бәйләп каравы белән генә аңлатып була. Шул рәвешле, Мирвәли һәм Шәмсегаян язмышы үз җирләреннән китеп, читтә—ят мәдәни-рухи мохитта яшәүче меңнәрчә милләттәшләребезнең ачы язмышы чагылышы булып тора.

Ю. Сафиуллинның, халык эпосы мотивларына нигезләнеп, XX гасыр ахырында язылган «Идегәй» трагедиясендә вакыйгалар XIV гасыр ахыры—XV гасыр башында Алтын Урдада бара. Пьесаның төп геройлары—исемнәре билгеле тарихи шәхесләр: Туктамыш хан, Идегәй, Аксак Тимер, Норадын һ.б. Алтын Урда тарихында билгеле бер эз калдырган әлеге кешеләрнең эш-гамәлендә тарихи дөреслек белән автор уйланмасы үзара үрелеп бара. Билгеле булганча, Туктамыш хан Җучи Олысы белән 14 гасыр ахыры—15 гасыр башында идарә итә. Үзенең атаклы гаскәр башлыгы Идегәй белән каршылыкка керә һәм соңгысы уртак дошманнары булган Аксак Тимергә кушыла. Аксак Тимер яулары нәтиҗәсендә Хансарай җимерелә, Туктамыш хан үтерелә. Моннан соң инде Алтын Урда үзенең бердәм, көчле хәленә кайта алмый. Эчке каршылыклар, ханнарның еш алышынып торуы аның таркалуын тизләтә.

Драматургның игътибар үзәгендә котылгысыз каршылыкка кергән Туктамыш белән Идегәйнең һәм якыннарының максат-омтылышын, шуңа бәйле эш-гамәлләрен ачыклау тора. Авторның төп табышы шунда ки, аның төп геройлары билгеле бер рамкаларга сыймый: һәрберсе үз характеры, үз йөзе, рухи дөньясы белән һәм гаять каршылыклы шәхесләр булып ачыла.

Трагедиянең төп герое буларак Идегәйнең эш-гамәлләрен, әйләнә-тирәдәгеләр белән мөнәсәбәтен, хыял-омтылышларын, каршылыклы характерын ачуга киң урын бирелә. Чөнки авторның игътибар үзәгендә, беренче чиратта, әлеге герой фаҗигасенең сәбәпләрен ачу омтылышы тора. Баштагы күренешләрдә Кобыгыл белән Туктамыш хан арасындагы ачык күренеп тормаган каршылык шәхси ясcылыкны гына үз эченә ала. Кобыгыл күңелендәге ачу-ярсуны басып, иленә тугры хезмәт итә. Аның шәхси үчлектән өстен торуын драматург төрле күренешләр аша күрсәтә. Туктамыш хан да гаскәр башлыгының халкына, җиренә, ханына бирелгәнлеген, үз-үзен җәлләмичә хезмәт итүен югары бәяли. Кобыгыл би пьесада ил-халык улы буларак калка. Драматург аның күңелендәге көрәшне, каршылыкны, икеләнүле уйларын бөтен тирәнлегендә ача алган. Гаделсезлек, халыкның яклаучысыз калуы, бер яктан, шәхси үч алу теләге, икенче яктан, аны Туктамыш ханга һәм аның властена каршылыкка этәрсә дә, ул ашыгыч адымнан саклана. Үзенең эш-гамәле белән Җучи Олысында таркаулык тудыру, аннан ил дошманнары файдалану мөмкинлеген яхшы аңлый. Шуңа да шәхси мәнфәгать һәм ил өчен җаваплылык мәсьәләсендә Кобыгыл-Идегәй икенчесенә өстенлек бирә. Әмма үлем куркынычы аны Аксак Тимергә качарга мәҗбүр итә.

Шәхси теләк һәм ил-халык мәнфәгатенә нигезләнгән конфликт ата-бала каршылыгы, мәхәббәт коллизияләре, аерым кешеләрнең мәкер-хыянәте аша тагын да үстерелә, тирәнәйтелә. Билгеле булганча, трагедия жанрының бер үзенчәлеге шунда, фаҗига очраклылыкка, аерым геройның эш-гамәленә бәйле кебек тоела. Әйе, алар трагик финалны тизләтергә мөмкиннәр, әмма һич тә төп каршылыкның нигезе була алмыйлар. «Идегәй» дә, югарыда әйтелгәнчә, төп конфликт илнең җимерелүе, таркалуы һәм төрле теләк-омтылышлы геройларның үлеме җирлегендә

Идегәй белән Туктамыш хан арасында оеша. Аның чишелешендә Жанәкә белән Жанбай билгеле бер роль уйнасалар да, төп асылында ул Идегәй белән Туктамыш хан эш-гамәленә бәйле хәл ителә.

Трагедиядә вакыйгалар дәүләтнен жимерелүе, төп геройларнын бер-берсен үтерүе белән тәмамлана. 14-15 гасырлар чигендә барган вакыйгалар һәр чорга, һәр заманга хас яңгыраш ала. Драматург төрки-татарнын фажигале тарихы аша сабак бирә, милли рухны уята, үзаң тәрбияли. Кешелек жәмгыятендә формалашкан кыйммәтләр—гаделлек, намус, миһербанлык, ил-халык мәнфәгатен кайгыртып яшәү, дуслык-бердәмлек, шәхес азатлыгы һ. б.—өчен жаваплылык тойгысы тәрбияли.

Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән Казан ханлыгы, аның ханнары, аеруча соңгы ханбикәсе Сөембикә гасырлар дәвамында татар һәм рус әдипләренен, тарихчыларынын игътибарын жәлеп итеп килә. Тарихыбызнын әлеге чоры белән кызыксыну соңгы елларда аеруча артты. Сөембикә-ханбикәнен яшьлек еллары анык кына билгеле түгел. Илнен иминлеге өчен дип, улы белән Мәскәү патшасына тотык итеп жибәрелгән ханбикәнен язмышы да билгесезлек пәрдәсе белән капланган. Болар, үз чиратында, Сөембикә турында төрле риваять һәм легендаларнын кин таралуына китерә. Соңгысы исә әдипләргә ул чор вакыйга-күренешләренә бәйле Сөембикә образын ачуда төрле фикер-карашларга, язмышын төрле юнәлештә ачарга мөмкинлек бирә. Р. Хәмид инде билгеле булган сюжетларны кабатламыйча, кызыклы ды, гыйбрәтле дә һәм фажига белән тулы «Хан кызы» (1995) пьесасын ижат итә.

Әсәрнен яңалыгы шунда, алдагы вакыйга-күренешләр халык арасыннан чыгып, халкы һәм ханлыгы өчен Сөембикә фажигасен үз фажигасе дип кабул иткән, алар өчен үлемгә барудан курыкмаган Язгөленен романтик образы белән бәйләнә. Геройнын эш-гамәлләрендә кешегә хас булган иң матур, иң изге башлангычлар тулы ачыла һәм пьесада аларнын һәртөр караңгылык, түбәнлек, хыянәттән өстенлеге, жинеп чыгачагы раслана. Пьесанын төп каршылыгы туган иленә, жиренә бирелгән, анын азатлыгын бар нәрсәдән өстен күргән шәхесләр белән үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, бүгенге көннәре белән генә яшәүче, шуна да хыянәт-мәкер белән эш итүче, төрле түбәнлеккә барырга әзер кешеләр арасында булып, үзенен иң югары ноктасына—трагик чишелешенә—Язгөле белән Шаһгали бәрелешендә житә.

Вакыйга-күренешләрдә автор халык кызы Язгөлене һәм халыкнын яраткан ханбикәсе Сөембикәне бербөтен буларак ачуга ирешә. Монда мәсьәлә аларнын тышкы охшашлыгында түгел, билгеле. Гәрчә анысы да житди роль уйный. Иң мөһиме—әлеге ике хатын-кызны ил язмышы өчен тирәнтен борчылу, анын өчен теләсә нинди кыенлыкларны үтеп чыгарга, хәтта гомерен дә бирергә әзер булу берләштерә. Сөембикә белән Язгөленен рухи бердәмлегендә, якынлыгында халыкнын ханбикәгә булган мөнәсәбәте, уртак максатка омтылышы чагыла. Р.Хәмид үзенен трагик геройларын халык бәхете, анын киләчәге өчен явыз көчләр белән бәрелешкә кереп һәлак булган олы характерлар итеп сурәтли.

Тарихи эчтәлекле трагедия буларак, автор тарихи фактларга таяна, үзенен фантазиясе аша аларны үстерә, баета, ул чор вакыйгаларына карата яңа фикер-карашлар, уйланулар тудыра. Драматург тәкъдим иткән яңа легенда Сөембикә образын яңача күзалларга, бәяләргә, халык белән мөнәсәбәтен ачыграк билгеләргә мөмкинлек бирә. Трагедиянен төп идеясе—халык язмышын үз язмышлары иткән Сөембикә һәм Язгөленен үлемсезлеген раслауда. Автор Казан ханлыгы фажигасенен сәбәпләрен ачып, аны бүгенгебезгә китереп тоташтыра. Трагик геройлар омтылган якты идеалларнын киләчәктә жинеп чыгачагына ышаныч уята.

М. Маликованың «Сөембикә» пьесасында Казан ханлыгынын гаять хәвефле вакыты тасвирлана. Хәрәкәтне тудыручы каршылык, бер яктан, ханлык эчендәге йә ачыктан-ачык, йә яшертен рәвештә барган бәрелешкә, икенче яктан, Казан ханлыгы белән рус дәүләте арасындагы конфликт рәвешендә бирелә. Ул ханбикә белән анын улын Мәскәүгә алып китү белән тәмамлана. Вакыйгалар үзегендә, билгеле инде, Сөембикә тора. Автор аны акыллы, булдыклы, белемле, сугыш

эшен дә яхшы белүче, кырыс ханбикә итеп тә, шул ук вакытта ирен сагынып яшәүче, романтик рухлы, йомшак күнелле ана буларак та ача. Вакыйга-күренешләр аша Сөмбикә фаҗигасенең төп сәбәпләре ачыла: берсе—ил эчендәге хыянәт, морзаларның үз мәнфәгатьләре белән генә яшәве, икенчесе—татар ханлыклары арасындагы таркаулык, өстен чыгарга тырышу, бер-берсенең көчен бетерү. Шуңа да автор кешенең рухи бөеклеге һәм түбәнлегенең асылын анларга омтыла. Киләчәк тарих бирәчәк бәя дә ачык сиземләнә: Сөембикә халкыбыз күнелендә азатлыкка омтылу символы булып урын алса, Шаһгали, Нурали морза кебекләр түбәнлек, хурлык, хыянәт үрнәген тәшкил итә. Шулай да пьеса зур янгыраш алмый. Сәбәбе, күрәсең, төп геройларның бөек идеаллар өчен көрәшүдә эзлекле булмавында. Аларга югары романтик пафос, фаҗигане белә торып, көрәшкә ташлану рухы житми.

XX гасыр ахырында иҗтимагый-социаль каршылыклар китереп чыгарган кризис күренешләре, аерым алганда, рухи кыйммәтләрнең үзгәрүе халыкның билгеле бер катламында киләчәккә ышанычны какшата, ризасызлык, җәмгыятьтән читләшү тудыра. Бу исә яшәешнең мәгънәсезлеге турында уйлануларга һәм пьесаларда сызлану мотивының өстенлек алуына, субъективлыкка, кеше ирекен абсолютлаштыруга этәрә. Аерым әсәрләрдә социаль һәм милли яшәеш проблемалары каршында куркып, икеләнеп калган, яшәешнең асылын анламаган, мәгънәсен тапмаган, авырлыклардан котылу юлы үлемдә дип санаган персонажларны мәйданга чыгара. XX гасыр ахырында халыкның бай-ярлыга кызу темплар белән бүленүе, гаделлеккә нигезләнүче принципларның бозылуы, еш кына кире кагылуы әдәбият-сәнгатьтә субъективлык, индивидуализм һәм нигилизм күренешләренең үзенчәлекле чагылышына китерә.

Р. Хәмиднең «Актамырлар иле» трагедия-реквиемында милләт язмышы, ана янаган юкка чыгу, ассимиляцияләшү куркынычы гыйбрәтле күренешләрдә ачыла. Пьесаның төп конфликты өлкән буын белән милли яшәү рәвешен кире каккан яшь буын арасында. Шуларга бәйле рәвештә автор авылларның таркалуы, гореф-гадәтләрнең юкка чыгуы, әхлаксызлык күренешләренең артуы, эчкечелекнең тирән үтеп керүе, ата-ана белән бала арасында рухи бәйләнешнең югалуы кебек гаять актуаль мәсьәләләрне алга куя. Әхлакый кыйммәтләрне санга сукмаган буын шундый ук нәсел калдыра дип саный драматург. Мөштәри картның кызы Фаягөл никахсыз бала табып, аны чүпрәккә төреп, чүплеккә ыргыткан булган. Очраклы рәвештә Борхан килеп чыгып, баланы коткарган. Анасы салган эздән улы Гәрәй дә атлый. Ул үз баласына ана дуңгыз имчәге каптырып кына калмый, улының тапталып үлүенә дә юл куя. Әлеге тетрәндергеч күренешләрнең нәтиҗәсе эпилогта бирелә. Балаларының ата-ана фатихасын санга сукмавы, өч кызының да рус егетләренә кияүгә чыгуы, берәүләрнең атасы баш сөягеннән ясалган тустаганнан аракы эчүе кебек хәл-күренешләрне күз алдыннан үткәргән Мөштәри картның йөрәге түзми—ул егылып үлә. Шул рәвешле әсәрдә милләт язмышы мәсьәләсе яшәү фәлсәфәсе буларак күтәрелә. Трагедиядә Актамырлар иле турындагы риваять катнаш никахның милләт язмышына куркыныч ясавын искәртә. Әсәр ахырында Кифая карчык белән яшь хатын Фәридәнең уенчык курчакны юындырулары, шул ук вакытта яңгыраган халык җыры пьесада сурәтләнгән фаҗиганең сәбәбен аңларга һәм аны булдырмау юлларын эзләүгә булыша.

Җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә күзәтелгән кризис тормыш мәгънәсе, анда үз урыныңны табу кебек мәсьәләләрне әхлакый-психологик планда чагылдыруга этәрә. Мондый әсәрләрнең конфликт характеры һәм трагик герой бирелеше ягыннан трагедия жанрының традицион принципларына туры килүе бәхәс тә уятырга мөмкин. Әмма алар арасында трагедия жанры кысаларында бәяләнергә хаклы булганнары да бар. Ю. Борев язганча, «билгеле бер шартларда трагедияне кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре дә китереп чыгара ала. Кабул ителмәгән, бәхетсез мәхәббәт һәрбер җәмгыятьтә гадәттән тыш тирән кичерешләр һәм фаҗигаләр чыганагы булырга мөмкин». Арада З. Хәкимнең «Шайтан куентыгы» пьесасы авторның кызыклы алым-чараларга мөрәҗәгать итүе, фаҗигале финалы, үзенчәлекле геройлары белән аерылып тора. Кеше рухының чыганагы кайда,

нәрсәдә? Тормыш лабиринтларыннан әхлакый йөзенне саклаган хәлдә ничек чыгарга? Әлеге сораулар алгы планга куелган пьесада кара төсмерләр өстенлек итә. Бала чактан бергә уйнап үскән, үзара яратышкан Разим белән Фәнзиләне зур тормыш «елгасы» үз агымына ияртә. Шәһәргә укырга киткән Фәнзиләне, алтын балык вәгъдә итеп, «шайтан куентыгы»—серле, ялтыравыклы тормыш каршылыклары үзенә тартып ала. Яшьлек антын бозган кыз күңеленә шайтан оялый һәм явызлык аны үзе белән алып китә. Ир кеше кыяфәтендәге Илгиз-Шайтанны Фәнзилә генә күрә. Шундый ук хәл Разим белән дә була. Егет Илгизә-Шайтан өстерәгән эчкечелек сазына бата. Әсәргә ике дөнья—реаль һәм мифик дөньялар сурәте килеп керә. Әлеге алым кеше күңелендәге Яхшылык һәм Явызлык көрәшенең диалектик бәйләнешен тулырак ачуга хезмәт итә. Тормышнын житди каршылыгына очраган егет белән кыз ялгыш адым атлауларын, нәрсәнедер үзгәртергә кирәклеген, антларына тугры калырга тиешлекләрен аңламыйлар, шул сәбәпле яшәешнең кырыс кануннарын үтеп чыга алмыйлар. Шайтан котыртуына ияргән Разим белән Фәнзилә, әтиләре кебек үк, елганын Шайтан куентыгы дип аталган жиренә сикереп, үлемгә дучар булалар.

XX гасырның 90нчы еллары икенче яртысындагы чечен сугышы жир йөзеннән юк ителгән авыллар, меңнәрчә корбаннар белән чечен халкынын кан-яшенә әверелсә, үтерелгән яисә яраланган солдат-офицерлар аша Россиянен үзенә дә әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт кенә алып килә.

Россиядә яшәүче күпсанлы халыкларның канлы ярасына әверелгән чечен сугышы темасына татар әдәбиятында беренчеләрдән булып Ю. Сафиуллин мөрәҗәгать итә. Драматург «Йөзек һәм хәнҗәр» трагедиясендә сугыш вакыйгаларынын, кайтаваз буларак Татарстан жиренә килеп, кеше язмышларына гаять зур йогынты ясавын үзенчәлекле вакыйгалар, кабатланмас геройлар аша сурәтли.

Бер яктан, сугыш афәтен үткән егетләр белән әйләнә-тирәдәгеләр арасында, икенче яктан, Россия армиясендә командир приказын үтәп, чечен авылларын жимергән, кулларына корал тотып каршылык күрсәтүчеләргә генә түгел, бәлки хатын-кыз һәм бала-чагаларга каршы да танк белән барган Линар һәм Рәсим белән йорт-жирләрен, сөйгәннәрен югалтып, туган иленнән качып китәргә мәжбүр булган Хания һәм Разия арасында конфликт оеша. Боларга өченче төр каршылык—төп геройлар күңелендә барган рухи көрәш үрелеп бара. Авторны аеруча Линар белән Рәсимнен жан бәргәләнүләре, тыныч тормышта үзләренә урын таба алмаулары борчый. Пьесанын «Йөзек һәм хәнҗәр» дип аталуы да шуңа ишарә итә. Йөзек—яшәү билгесе, мәхәббәтне, тормышта тынычлыкка өстенлек бирүне аңлата. Хәнҗәр исә—үлем, кайгы-хәсрәт алып килүче, дошманлыкка илтүче төшенчәне белдерә. Үзен көчләргә теләгән Линар белән танышканда Хания сөйгәне, чечен егете Абрек бүләк иткән йөзекне югалта. Пьесадагы вакыйгалар әнә шул йөзекне эзләү фонында бара. Монда башкалар белән бергә Линар да актив катнаша. Егетнең мәхәббәт, тынычлык символын эзләве күңелендәге психологик тартышка, жанына тынычлык эзләвенә, «чечен синдромы» н жинеп, гөнаһларыннан арынып, тыныч тормышка кайту өчен үз-үзе белән көрәшенә метафора булып тора.

Күңелендә үзгәрешләр башланган Линарга дусларыннан берсе Игорьнең үлеме гаять көчле тәэсир итә. Жимерелгән авыл-калалар, үтерелгән гөнаһсыз кешеләр егетләрнең жанына тынычлык бирми. Икенче сәбәп—сугыш афәтен үткәннәрнең жәмгыять, дәүләт, яшәп килгән система тарафыннан читкә кагылуы, онытылуы. Алар кайгы-хәсрәтләре, күңел яралары белән үзләре генә калдырылган. Моны Игорь кебек, чечен сугышыннан кайтып, үзен үзе үтергән егерме егет тә яхшы аңлаган. Линар белән Рәсимгә дә тынычлык бирми ул, жаннарын әрнетә. Шул рәвешле, пьесадагы каршылыкларны үзенә туплаган төп конфликт калкып чыга. Ул—шәхес һәм система каршылыгы.

Ниһаять, Линар белән Хания һәм егетнен күңелендәге каршылык иң югары ноктасына житә. Роман биргән хәнҗәрне Линар Ханиягә күрсәтә. Россия солдатлары тарафыннан үтерелгән сөйгән егете Абрек хәнҗәрен кыз тиз танып ала. Андагы язу да икеләнүләргә урын калдырмый. Гаять киеренке халәттә, үч алу тойгысына

бирелеп, Хания хәнҗәрне Линар йөрәгенә батыра. Чечен сугышыннан рухи имгәнеп, яшәү шатлыгын югалтып кайткан, җәмгыятьтә үзенә урын таба алмаган яшь егет үлемен шатланып ( гаять сәер яңгыраса да) каршы ала. «Коткардың, мен рәхмәт!-ди ул Ханиягә, җан газапларыннан котылуын белдереп. Әлеге хәнҗәрне Линарга Роман бирүен ишеткәч, Хания ялгышлык белән кеше канын коюын аңлый һәм бу гөнаһыннан арыну юлын үлемдә генә күрә. Шул рәвешле тыныч шартларда ике яшь кешенең гомере өзелә. Драматург гаепләү актын сугышка, аны башлаучыларга юнәлтә.

Шулай итеп, хәзерге татар драматургиясендә трагедия жанры, сан ягыннан күп булмаса да, әдәби процесста мөһим роль уйный, драматургларның тема һәм проблематика, жанр һәм жанр формасы, сәнгати сурәтләүдәге эзләнүләрен шактый тулы чагылдыра. Ерактагы һәм якындагы тарихка мөрәҗәгать итеп язсә төрле легенда-риваятьларга нигезләнеп язылган пьесаларда жанр таләпләре, төп сыйфатлары, нигездә, саклана. Бүгенге тормышның төрле якларына багышланган әсәрләрдә авторлар хәзерге чынбарлыкның асылын ачу, шуна бәйле аерым кешеләр һәм, гомумән, җәмгыять яшәешенең социаль һәм әхлакый аспектларын билгеләү омтылышы ясыйлар. Төп герой буларак тәкъдим ителгән образлар социаль-экзистенциаль характерда сурәтләнә, шуңа да аларны аңлауда һәм бәяләүдә төрлелек, хәтта каршылык күзәтелә. Шул рәвешле, чор үзгәрешләре тәэсирендә, башка жанрлар кебек үк, трагедия дә билгеле бер үзгәреш кичерә. Алар түбәндәгеләрдә чагылыш таба: беренчедән, трагик конфликт табигатен аңлау үзгәреш кичереп, жанрның әдәби функциясе милләтне инкыйраздан саклап калуга юнәлтелә. Ә бу исә татар пьесаларында фәлсәфилекнең милли һәм әхлакый кыйммәтләр белән тыгыз үрелеп баруына китерә. Икенчедән, трагедияләрдә татар тамашачысы аеруча яраткан мелодрамага хас элементларның, аерым алганда лирик-эмоциональ һәм романтик катламның киң урын алуы. Өченчедән, хәзерге трагедияләрдә бурыч һәм шәхси теләк каршылыгы милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге өчен борчылу төсмере ала һәм, гадәттә, мәхәббәткә бәйле сюжет линиясе белән үрелеп бара. Дүртенчедән, трагик конфликт геройның үзеннән өстен көч белән бәрелешеннән бигрәк кешенең эчке табигатеннән, яшәп килгән тәртипләр белән килешә алмаудан үсеп чыга. Тормышта үз урынын таба алмаган шәхес трагедиясен ачу киңрәк урын ала бара. Бишенчедән, фаҗигале әсәрләрдә без үзенчәлекле милли геройлар белән очрашабыз. Аларда «үзен һәрвакыт кимсетелгән итеп тоючы татар характерының фаҗигале халәте». (Рәшит Әхмәтов) күрәбез, әмма татар авылы белән бәйле милли геройлар еш кына очракта сайлаган юлларыннан, максатларыннан чигенмәүче олы характерлар дәрәҗәсенә үсеп житми. Төп трагик пафосны шәхес ирегенә омтылучы, матур хыяллар белән яшәүче геройның явызлык дөньясы, гаделсезлек белән бәрелеше китереп чыгара. Ул еш кына кеше ялгызлыгы, экзистенциаль халәт-тоемлау белән кушылып китә.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

*Мөхәммәт Мәһдиевнең вафат булуына да 15 ел вакыт үткән икән! Исән булса, быел аңа 80 яшь тулган булыр иде...*

*Танылган берәр шәхес вафат булгач, хушлашу сүзләре—некрологларда гадәттә, «Син безнең күңелләрдә мәңге сакланырсың» дигән сүзләр әйтелә. Тәртибе шундый. Әмма күбесе бик тиз онытыла шул. Исемен дә, кылган хезмәтләрен дә яңа буыннар күңелләрендә сакларга бик ашкынып тормыйлар. Ә менә Мөхәммәт Мәһдиевкә онытылу насыйп булмаска ошаган. Аның әсәрләре халык арасында көннән көн популяр була бара. Хикмәте шул: ул—чын мәгънәсендәге халык язучысы. Рәсми титулы булмаса да (М. М.—указлы халык язучысы), халык аны барыбер үзенеке итеп таныр иде.*

*Мөхәммәт Мәһдиев әдәбиятка чагыштырмача соңарып—60нчы еллар ахырында килде. Аңа инде бу вакытта 40 яшьләр тулып узган иде. 20-25 ел эчендә ул, онытылмас әсәрләр иҗат итеп, татар халкының яраткан язучысына әверелә алды.*

*Аның барлык әсәрләре дә диярлек иң әүвәл безнең «Казан утлары» журналында басылып килде. Беренче зур әсәре «Без—кырык беренче ел балалары» журналыбызда 1968 елны басылды. (Дөрес, бер ел алдан аның «Этюдлар» дигән баш астында берничә кыска хикәясе чыккан иде.) Аннан соң бер-бер артлы «Фронтовиклар», «Кеше китә—җыры кала», «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү», «Ачы тәҗрибә» роман-повестьлары, һәммәсе дә беренче мәртәбә, «Казан утлары»нда дөнья күрде. Алардан тыш бик күп әдәби-фәнни хезмәтләре дә безнең журналда басылды. Ул озак еллар журналыбызның редколлегия әгъзасы булып торды, фикер-киңәшләре белән басмабызның үсешенә сизелерлек өлеш кертте.*

*Кеше китә—җыры кала... Без хәзер дә аның мирасына еш мөрәҗәгать итәбез. Иншалла, алга таба да шулай булыр. Бу санда олуг әдибебезнең 80 еллык юбилее уңаеннан, замандаш каләмдәшләренең аның турында язып калдырган уй-фикерләрен кыска язмаларда урнаштырабыз.*

**Гомәр БӘШИРОВ**

...Мөхәммәтне искә алганда, күңел түрендә һәрвакыт үкенечле бер фикер уяна: арабыздан бик тә вакытсыз китеп барды. Ул әле галим буларак та, әдәби әсәрләр иҗат итүче талантлы әдип буларак та, киләчәктә әдәбиятыбызга бик кыйммәтле яңа әсәрләр бүләк итәргә сәләтле иде. Ләкин... нихәл итмәк кирәк? Язмыш безнең теләгебез белән исәпләшми ләбаса, ул үз кануннары буенча эш итә. Димәк, без инде Мөхәммәт калдырган әдәби мирасның кадерен белергә, әсәрләрен халыкка мөмкин кадәр тулырак, ешрак җиткерү чарасын күрергә тиеш булабыз...

## Гариф АХУНОВ

Илленче еллар башында проза мәйданына килгән, ун-унбиш ел эчендә инде танылып өлгергән әдипләрне ул—алардан унбиш елга сонрак яза башласа да—бик тиз куып житте, татар язучыларының алдынгы сафына килеп чыкты. Дөрес, аның язучылык биографиясе асфальт җәйгән такыр юлдан элдертеп кенә бармады, уңышсызлыкка очрап, борынын салындырып йөргән чаклары да булды, тик ул «уңышсызлык» дигәнебез аның үзенә генә бәйле түгел, шул заманның тоталитар режимы белән дә бәйләнгән иде.

Ул гомере буена авылны җырлады, авылның бүгенге ямьсез хәлен түгел, киләчәк матурлыгын язып калдырды. Әмма ул аларны бүгенге Гөберчәкнең гап-гади кешеләре, намуслы һәм иманлы җир кешеләре аркылы, хезмәт кешеләре аркылы сурәтләп бирде. Аларның күңел матурлыгын, җаннарының гүзәллеген ача алды.

## Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ

...Әгәр рухыбызның үсеш юнәлешен, җитмешенче, сиксәненче елларда әдәбиятыбызның югарылыгын, аның ни дәрәҗәдә гадел һәм саф булуын өйрәнергә теләсәк, турыдан-туры Мөхәммәт Мәһдиев повестьларына мөрәҗәгать итәргә туры киләчәк...

...Мәһдиев теле—милли байлыгыбыз. Аның сурәтләү чараларының палитрасы, тел бизәкләре безнең кабатланмас вә тутыкмас көзгебез түгелмени?.. Тел, әйткәнемчә, милләтнең какшамас нигезе (какшатулары да ихтимал, абай булырга вакыт!), телнең билгеле бер чордагы хәлен бары тик милләт вәкилләре генә әдәбиятта беркетеп кала ала. Татар теле моңлы тел, Мөхәммәтнең әсәрләре монсу гына түгел, алар гаҗәеп дәрәҗәдә моңлы да. Автор табигатебезнең һәр кеше күңеленең бөтен үзгәрешләренә нәкъ менә кин күңелле татар кешесе булып карый ала, Мөхәммәт—үз җиренең тулы хокуклы улы, җир өчен, ил изгелеге өчен җаны көя торган, күңеле сулкылдап җылый ала торган чын кеше. Бер үк вакытта ул гайрәтле сугышчы да, иманыбыз өчен бил баглап алышка да чыгарга әзер!

## Туфан МИҢНУЛЛИН

Татар әдәбияты бай әдәбият. Ул хәзинәне үзләштереп бетерү әдәбият белән махсус шөгыльләнгән галимнәрнең генә кулыннан киләдер. Мин дә, әлбәттә, күп укырга, күп белергә тырышам. Әмма язылганнарның барысын да укып бара алмыйм. Иҗатын тулысынча күзәтеп укып барган язучыларым ике-өч кенәдер, мөгаен. Шуларның беренчесе—Мөхәммәт Мәһдиев. Мин ул язганнарның (матбугатта басылганнарын) өтеренә хәтле укып чыктым шикелле. Мин ул турыда үзенә дә әйтә идем. Шуңа күрәдер минем китапханәмдә Мөхәммәт автограф язып бүләк иткән китаплар шактый. Алар минем үземнең китаплар янында «почетлы урында» торалар. Алар миңа үз китапларым кебек кадерле, дисәм, бәлки, арттырыбрак җибәрү булыр, ләкин аларны мин еш кына кулыма алып, үземә аеруча ошаган урыннарын кабат укыйм.

## Рафаэль МОСТАФИН

Мәһдиевнең әсәрләре милли тел белән генә түгел, милли рух, милли аң, милли фикер йөртү рәвешендә язылган. Шуңа да аның әсәрләрен җиңел генә башка телгә тәрҗемә итеп булмый. Бәлки, киләчәктә ике телне дә яхшы белүче, татар рухын аңлаучы зур талант иясе табылса гына, бу җитди һәм мөһим эш уңышлы башкарыла алыр.

## Тәлгат ГАЛИУЛЛИН

...Иҗат юлы—таба асты мәсле шома, тигез була алмый. Язучыга зиһен хәзинәсен тирәнрәк ачу, әсәрләрен бастырып чыгару, үзен раслау өчен берөзлексез көрәшергә туры килә. Ә гомер исә, шаһрен каешыдай, һәр көнне кими, кыскара бара. Халык

Мәһдиевне рухына, жанына үткәреп, яраткан язучысы итеп кабул кылганнан соң да, байтак вакыт узгач кына ана рәсми танылу килде. Сәбәпләре төрле. Холкы-фигыле дә, тегермән канаты төсле, жил искән якка кыйбласын үзгәртеп торуны өнәми. Үзен тәкәбберлек дәрәҗәсендә горур тотуы, кемгәдер ялагайлану, мәдхия яудыру юлына төшмәве, дөресе, булдыра алмавы, Мәһдиевнең тормышын кыенлаштыра. Мәгәр үзе булып калырга мөмкинлек бирә.

**Марсель ГАЛИЕВ**

Аның кебек тә кызыклы әңгәмәдәшне, вакыйганың өресен генә жыя белеп, вакыты белән үзеннән дә көлеп, ялыктырмыйча, хикмәтле сүзләрне бик тә урынлы кулланып, хәтер шәплегеннән тантана итеп, сабыр-үтемле итеп сөйли белүчене бу дөньялыкта бүтән очратмам инде мин. Ул, кешене күңел мендәренә утыртып, холык-фигыленең үзе генә белгән якларын шундый яратып һәм купайтып сурәтли иде ки, чынбарлыктагыдан кызыклырак итеп күз алдына бастыра да куя.

...Артык дөрес яшәгән, изүе ябык кешеләрнең дөньяда барлыгы белән юклыгы арасында әллә ни аерма сизелми. Яфрак кебек өзелә гомерләре, хәтер иелеп алырлык берни калмый. Көчле шәхес үткән еллар эзендә исә моңланып та, елмаеп та сөйләрлек гыйбрәтле, мәзәк хәл бер гомергә генә сыя алмый икән шул. Бу җәһәттән Мөхәммәт ага Мәһдиев—бай тарихлы гомер хәзинәсе иде.

**Ркаил Зәйдулла**

Мөхәммәт Мәһдиев шагыйранә теле, нечкә юморы белән бүтән язучылардан аерылып тора. Әмма аның төп үзенчәлеге—әсәрләренең документальлеге, шул документальлекне, лирик буяулар белән бизәп, шагыйранә итүдә.

**Зөлфәт**

## Күрешә калсак

**Томанлы таңда наз иңә җиргә,**
**Әйтерсең сыер бозавын ялый...**
**Ходайның изге сәгате инде—**
**Уҗымнар шыта, Мөхәммәт абый...**
**Газаплы ләззәт, ләззәтле газап**
**Җылы туфрактан гарешкә аша.**
**Ходаем, берүк ярдәм ит җиргә—**
**Җир уҗымлаган мәлләр ләбаса...**
**Яшәүнең сере ачылган мәлләр...**
**Тик крестьян гына сизенә моны:**
**Сискәнә җирдә уҗымнар түгел—**
**Фани дөньяның мәңгелек моңы.**
**Безнең бетүләр шушы микәнни,**
**Дигән шикелле, күңел ут йота—**
**Тынычлан, адәм баласы, диеп,**
**Мөхәммәт абый, уҗымнар шыта...**
**Йөргән җирендә, хәтта гүрендә**
**Уҗымнарга күз саласы килә.**
**Игенен чәчкән бер крестьян булып,**
**Басу түрендә каласы килә.**
**Шул басу түре—бар дөньяң синең,**
**Бар дөньяң—шушы уҗым бит инде.**
**Тургайлар никтер оча эзләнеп,**
**Кайда соң үзе, диләр шикелле.**
**Исә дә исә уҗымнар җиле...**
**Вакыт алдында без һаман сабый.**
**Күрешсәк анда,**
**сөйләрмен таңда**
**Уҗым шытканын, Мөхәммәт абый!..**

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Кышкар

Кышкар авылы Арча районындагы борынгы торак пунктлар территориясенә керә. Ул район үзәге Арчадан 31, Казаннан 90 чакрым ераклыкта урнашкан.

Кышкар—тарихи чыганакларга кергән атама. 1602-03 еллардагы мәгълүматларны туплаган Казан өязенең теркәү кенәгәсендә бу авылда йомышлы татарлар яшәгәнлеге әйтелә.

И. Ермолаев хезмәтендә 1590-91 елларда Кышкар суы ярындагы Кышкар бушлыгы (пустошь) искә алына. Авыл янында археологлар соңгы болгар чорларына караган табылдык әйберләр билгеләгәннәр.

Д. А. Корсаков хезмәтендә (XVIII йөз) авыл «Нәянгуш печән пакуслары» һәм «Нәянгул печән пакуслары» дип искә алына. Авылда 92 ясаклы татар яшәгән. Симет суы янына утырган бу авылның 130 хуҗалыгында 608 ир-ат һәм 590 хатын-кыз көн иткән. Авылда бер мәчет, 5 мәдрәсә, 2 гади киже-мамык туку фабрикасы булган.

Ашыт суының кушылдыгы Симет ярына утырган Кышкар, Симетбаш, Олы Мәңгәр, Иске Мәңгәр, Яңа Мәңгәр, Бәхтияр, Яңа Кишет, Иске Кишет авыллары бергәләшеп июнь ахырларында Кишет җыены үткәргәннәр. Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дип аталган хезмәтендә Кышкар авылы турында болай языла: «Элек заманнан ук дәүләтле байлары һәм зур мәдрәсә тотып, күп шәкертләр җыеп дәрес әйтүче имамнары белән дан һәм шөһрәт казанган авыл». Авыл исеме тагын бу хезмәттә Мелла Шәмсетдин бине Габдеррәшид әл-Кышкарый турында сөйләгәндә дә искә алына. Бу шәхес тумышы белән Кышкар авылыннан бер ятим бала була. Ташкичү кешесе Баязид бине Ибраһим бине Әбәк бине Туйхуҗа—күп маллы бер бай кеше—үзенең баласы булмаганлыктан, Шәмсетдинне уллыкка алып тәрбияли һәм укытып камиллеккә ирештерә. Ахырда Бохарга җибәреп белем алдырып кайтарып, Ташкичүдә имам, хатиб һәм мөдәррис итеп билгеләүгә ирешә. Әлеге Баязид бай мелла Шәмсетдин өчен, бик киң һәм биек итеп, ике кара-каршы бинадан торган зур мәдрәсә салдыра.

Симет суы ярына урнашкан Кышкар авылы басуында, Яңа Кишет авылы каршында археологлар Алтын Урда чорына мөнәсәбәтле керамика кыйпылчыклары таптылар.

Авылны нигезләүчеләр иген чәчү өчен басу-кырларны урман чистартып, яндырып ясаганнар. Билгеле булганча, мондый басулар ышна дип атала.

Жирнең кадере зур булган, аны тырышып сөргәннәр, тырмалаганнар. Чәчү вакыты җиткәч ирләр муен-иңнәренә тубал асканнар. Чәчүгә керешкәнче

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

кулларына тавык йомыркаларының ин зурларын сайлап, иген унсын өчен, башта шуларны тәгәрәтеп җибәргәннәр, аннан соң гына илаһи эшне—басуга иген чәчүне башлаганнар.

Кышкар авылы ике яктан—Кышкар һәм Нәянгуш өлешләреннән торган. Кышкар ягы казаклы булып хөкүмәткә солдат биргән. Нәянгуш ягы ясаклы булган. Бу якта марилар да яшәгән. Шулай ук монда мануфактура тоткан Муса һәм Мортаза байларның эшчеләре гомер иткән.

Кышкарга кыш көне фабрикага эшләргә килгәннәр, ә җәйгә алпавытка кайтып китә торган булганнар. Шуннан авыл исеме дә Кышкар булып калган. Нәянгуш ягына каяндыр печән чабарга килгән кешеләр утырып калган, имеш.

Авылда Муса һәм Мортаза байларның кытат (тыгыз ефәк тукыма) фабрикалары булган. Урманда лашманчылар хөкүмәт өчен агач кисkәннәр. Кышкар авылы мәдрәсәсе белән данлыклы булган. Авыл бабайлары сөйләвенә караганда, Кышкар мәдрәсәсе шәкертләрен күзәтеп тору өчен бер жандарм куелган. Ул керәшен татары булып, мулла вәгазь сөйләгәнне тынлап утырган.

XIX йөздә төзелгән мәдрәсә бинасы хәзер архитектура һәйкәле булып исәпләнә. Заманасында бу мәдрәсәдә Габдулла Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф, татар драматургиясенең күренекле вәкиле Фатыйх Халиди, татар мәгариф эшлеклесе Мотыйгулла Төхфәтуллин һ.б. укыган.

Авылда архитектура һәйкәлләре исемлегенә тагын XIX йөз ахыры XX йөз башында төзелгән мулла йорты һәм ике мәчет кергән. Мәчетләрнең берсе XVIII йөзнең соңгы чирегендә төзелгән, 1865 елда бераз үзгәртелгән. Мәчет бинасы Баязит бине Госман әл-Кышкари тарафыннан салынган. Икенче мәчет 1889 елда төзелгән.

Авылда тагын Үтәмешевлар йорты булган. Бер катлы агач йорт XIX—XX гасырлар чигендә төзелгән, имам-хатыйб Габдрахман Исмәгыйль улы Үтәмешевнең милке саналган. Г. И. Үтәмешев чыгышы белән Мәчкәрә авылының атаклы сәүдәгәрләре нәселеннән. Аның әтисе Исмәгыйль Муса улы Үтәмешев (1887 елда вафат). 1844 елда Бохарадан укып кайтып Кышкарда мулла була, заманының укымышлы кешесе, тирән белемле мөдәррис буларак дан казана, шәкертләр туплый.

## Мөндеш авыллары

Мөндеш авылы Арча районына карый, ул район үзәге Арчадан 9, Казаннан 75 чакрым ераклыкта урнашкан.

Д. А. Корсаков җыентыгында (XVIII йөз) әйтелгәнчә, Мөндеш суы ярына утырган Карачүрмә авылында (тарихи хезмәтләрдә ул икенче исеме белән—Олы Мөндеш дип тә әйтелә—Ф. Г.) 76 йомышлы татар көн иткән. Н. Б. Борһанова мәгълүматларына караганда, Мөндеш авылы халкы күршедәге Өчиле, Югары Бирәзә (Бирәзәбаш), Урта Бирәзә, Зур Бирәзә, Югары Әзәк, Түбән Әзәк, Мөндеш, Югары Мәтәскә, Түбән Мәтәскә, Кәче, Күкчә Бирәзә авыллары белән бергәләшеп июль башларында Күкчә җыены үткәргән.

Мөндеш авылы руханиларыннан тарихта тирән эз калдырган шәхес—имам Фәйзулла Мортазин әл-Мөндеши (1850 елда вафат). Замандашлары тарафыннан «йолдызчы» дип исемләнгән Фәйзулла хәзрәт камил белемле кеше, зыялы була. Ул математика фәннәре һәм астрономия өлкәсендә тирән белемнәр үзләштерә, кояш һәм айның тәүлеклек хәрәкәтен исәпләп календарьлар төзи, сәгатьләр һәм астрономик әсбаплар ясый. Бу әйберләр озак еллар дәвамында Ш. Мәрҗанидә саклана.

Һәр авыл халкы күңелендә үз авылларының кайчан оешуы турында дөреслеккә азмы-күпме туры килгән истәлекләр саклана һәм буыннан-буынга бирелә килә. Арча районы Мөндеш өлкәннәре түбәндәгеләрне сөйлиләр.

Авылны иң беренче нигезләүче алты баба Идел буендагы Кан тау башы (кайсы район икәнен төгәл генә әйтмиләр) дигән урыннан килеп утырганнар. Башта алар хәзерге Мөндеш күпере тирәсенә, Кырлай белән Мөндеш аралыгындагы урман эченә урнашканнар. Соңыннанрак хәзерге урыннарын сайлаганнар. Күчеп утыру

сәбәпсез булмагандыр, билгеле. Ләкин бу хакта төпле мәгълүмат юк.

Авылда хәзер татарлар гына яшәсә дә, халык үз араларында чирмеш (мари) нәселләре булуын хәтерли. Алар элек Кирәмәткә табынганнар (Мөндеш басуында Кирәмәт елгасы һәм Кирәмәт тавы бар).

Авылның төп елгасы—Ия суы. Биредә Арпаяз, Тәүшәм түбәсе исемле таулар, зур булмаган алма бакчасы бар.

***

Мөндеш авылы Әтнә районында да бар, ул район үзәге Олы Әтнәдән 9 чакрымда, Арча тимер юл станциясеннән—32, Казаннан 81 чакрым ераклыкта урнашкан.

Симет суы буена утырган Мөндештә, XVIII йөз мәгълүматларына караганда (Д. А. Корсаков җыентыгы), 44 ясаклы татар яшәгән. Авылда бер агач мәчет һәм бер мәйханә булган. Мөндеш крәстиәннәре су тегермәнен Иске Кишет авылы крәстиәннәренә арендага биреп торганнар. Тормышлары таза булган, кирпеч сукканнар, мич чыгару эше белән шөгыльләнгәннәр, он тарттырганнар.

Өлкән яшьтәгеләр үз авыллары турында болай сөйли: «Иң элек бу тирәләрдә Мөндеш белән Тарлау авыллары гына булган. Мөндештә бер мәчет һәм икешәр-өчәр катлы агач йортлар күп иде. Хәзер алар бетте инде. Авыл зиратыннан ерак түгел генә изгеләр зираты урнашкан, анда 7 борынгы таш сакланып калган иде. 1920 еллар тирәсендә аларның икесен сыерлар җимергәч (изгеләр зираты киртә-рәшәткә белән тотылмаган булган— Ф. Г.), ташларны авыл зиратына күчереп куйганнар. Шул вакытта ике ташны Яңа Мәңгәр кешеләре алып киткән, ләкин мөндешләләр даулап ташларны кире алганнар. Хәзер алар авыл зиратында».

Картлар сүзенә караганда, авыл мөселманнары арасында чирмеш нәселләрен дәвам итүчеләр бар икән. Алар инде күптән исламга чыкканнар. Авыл янындагы Шәрнә тавында Шәрнә исемле мари яшәгән, диләр.

Мөндеш атамасы нәрсә аңлата?

Бу атаманың мәгънәсен ачу шактый катлаулы. Ул—Нугай Урдасы татарларының мең кабиләсе утырган деш—шеш (төш) мәгънәсен бирә. Бу тирәләргә, димәк, татарларның мин—мең исемен алган кабилә-кавемнәре килеп утырган. Мин—мең этнонимы белән ясалган атамалар Татарстан җирендә шактый җыела. Әтнә районындагы Олы Мәңгәр һәм Иске Мәңгәр авылы атамаларында без «мең + ир» сүзләрен күрәбез. Актаныш районындагы Меңнәр авылы, Саба районындагы Алан-Елга авылының элек урнашкан урыны «Мең йорт өсте», болгар чорларындагы «Мең кабиләләре яшәгән Шонгат» атамаларында да мин—мең кабиләләре исеме ныгып калган.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

*Хәсән Сарьянның туууына 80 ел*

Марсель Галиев

# ИКЕ УРМАН ЧИГЕНДӘ...

*Хыялы тарихның нәкъеше улды,*
*Сүзе—дилдә, хыялы күздә калды.*
Г.Кандалый

Төнге дала... Караеп күренгән балбалның мең еллар буена җил-су-кояш ашаган таш чыраен учак шәүләсе ялмап-ялмап ала. Якында гына тышаулы атлар пошкыра. Учак тирәли яугирләр тезелеп яткан. Садакларында—уклар, кыныларында үткен кылычлар черем итә. Бары тик сакчы гына керфек какмый, учакка кизәк өсти-өсти, үзалдына мөнганып утыра. Бераздан ул да ялан дала күкрәгеннән сирпелгән әрем исеннән изрәп калгып китә. Ә офык артында—бөек Урда йорты, олуг ханның Алтын таш сарае. «Уяу бул! Уяу бул!»—дип пышылдый күпне күргән балбал. Аның сагаюы учак ялкынына күчә. Үрсәләнгән ялкын—учакның сары җаны...



Сарыҗан... Сарьян... Борынгыдан килгән әнә нинди мәгънәле исем кушканнар икән аңа. Сәер дә, серле дә. Бер ишетүдә хәтергә уелып та кала. Әдәбиятта үз тәхетен тоткан проза остасы Хәсән Сарьян тормышта да, исеменә хас булганча, үзенчәлекле шәхес иде. Мин аны беренче күрүдә ошатып та бетермәдем шикелле. Кырыс күренә. Төмсәрәк чырай. Аз сүзле. Кара кысалы калын күзлек, кара чәч, үҗәт кысылган иреннәр, каш арасыннан маңгайга таба үрләгән таләпчән ике җыерчыкны да өстәгәч, тиз генә якын мөгамәләгә кереп китәрдәй, күңел капкалары шар ачып ташланган беркатлы шәхес дип уйламыйсың аны. Тавышы нечкә дә, калын да түгел. Музыка белгечләре аны нинди тембрга да кертергә белмичә аптырарлар иде.

Нәзберек гөл шытымын иң нечкә тамырларына кадәр имгәтмичә казып алган кебек, һәр сүзне ул кадерләп, күкрәк эченнән ала, җеген җеккә китереп, ашыкмыйча әйтә, нәкъ язуындагы кебек, тулы җөмлә белән сөйли. Тавышыннан талгын җил канатыннан саркып киткән әрем тәме килә төсле...

Гадәттә, роман-повестьлар укыганда, аны язган әдипнең йөз-кыяфәтен үзеңчә күз алдыңа китерәсең. Китап битендәге вакыйгалар аша хәтта тавышына кадәр ишеткәндәй буласың. Ә инде үзе белән чынбарлыкта күреп танышкач, күңелеңдә ялгыз сурәттән шактый аермалык күреп нәүмизләнәсең. Бары тик ныклап аралаша башлагач кына бу аерма бетә, килешәсең, күнегәсең.

Хәсән Сарьянның бикле күңел дөньясын аз гына булса да ачып карау, аңлау өчен шактый аралашырга, төнге Казан урамнарын бергә гизәргә, озын юлларга чыгарга, иҗади бәхәсләр белән шаулы яшәп алырга кирәк иде әле.

Бервакыт Лаеш районына чыгып киттек. Өчәү идек: арабызда иң өлкән икәнен

тамак кырып куюы белән искәрткәләгән Сарьян абый, шәһәр ераклашкан саен, мәҗүси елмаюы күзләренә күчә барган шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов һәм исеме халыкка билгеле шәхесләр әргәсендә берничә көн яшәп алуны бәхеткә санаган мин фәкыйрегез.

Атабай, Саралангагы көннәр аеруча истә калган. Яшьтәшләр буларак, авыл советы рәисе Вазыйх абзый белән Сарьян шунда ук уртак тел таптылар. Тормыштагы кызыкларны күрә белүче, фикерле, иҗади күңелле иде рәис. Рәхәтләнеп, чишелеп бер сөйләшеп утырырга бик тә сусаган булгандыр ул. Зур көймә белән табигать хозурына чыккач, шәһәрнең таш киеменнән котылган Хәсән Сарьян да иркенәеп, берьюлы ачылып китте. Мин ул чакта океан-диңгезләр күрмәгән әле, Кама белән Идел кушылган урында аргы яры зәңгәр томаннар артында югалган чиксез киңлекне акылыма сыйдыра алмыйча хәйран калып йөрим. Көчле дулкыннар тетрәткән яр—гүя Идел-йорт сыйган материкның иң кырый ноктасы. Каршында—чиксезлек... Ә табын янында Вазыйх абзый белән Сарьян авызга авыз. Әңгәмә арасында бүленеп, Хәсән Сарьян үзе өчен кызыклы санаган сүзләрне блокнотына төшереп бара. Шунысы гаҗәп: рәсми кәгазьме, кулъязмамы—ниндие генә булмасын, ул искиткеч төгәл, камил итеп, баш хәрефләрнең койрыкларын купшы бөтереп: иренмичә, күзне иркәләрлек итеп яза. Үземнең исә җомга көнне язган хәрефләр шимбәнекенә бөтенләй тәңгәл килмәскә мөмкин. Кәефкә карап үзгәрмәгән язу рәвеше холык ныклыгын белдерәдер, мөгаен.

Вазыйх абзый ул көнне өенә кайтып тормады, безнең белән бергә кунакханәдә калды. Төне буе сөйләшеп чыктык. Икенче көнне дә ул очрашу оештырды.

Клублар шыгрым тулы була иде ул елларда. Кичәне Хәсән Сарьян ачып җибәрә (тел ачкычы өчен дип, сәхнәгә чыгар алдыннан стакан тулар-тулмас акны салып куя, монысын инде алдан хәстәрләп торабыз). Әдәбиятның үткәнен-бүгенгесен тәфсилләп, үтемле итеп сөйләп, халыкны әзерләп бетергәч, безгә чират җитә.

Иң соңыннан Мөдәррис Әгъләмов чыгып трибунага олпатларча таяна. Трибуна аның Тукай буйлык гәүдәсенә чамалап эшләнмәгән, бераз биегрәк. Залдан караганда калкып торган ике терсәк арасына чумган ялтыр пеләше генә күренәдер. Ә кырыйдан аның кыяфәте Чили шагыйре Пабло Неруданың бераз кечерәйтелгән рәвешен хәтерләтә. Җиңел ябык гәүдәдән борынгы шагыйрьләрдән килгән кодрәтле тавыш ургылып чыгуга, сүз хасиятеннән зал сыгылып, сулышын тыя.

*Сөембикә кебек гүзәл хатын*
*Кыйссаларга кереп калырлык.*
*Авылында шундый чибәр барда,*
*Ирләренә бирсен сабырлык!*

Мишәр карчыгы «Канат әби...»не сөйләгәндә, өлкәннәр күзендә яшь күренә. Сарьян абыйны күзәтәм: Мөдәррисне ул һәрчак, беренче тапкыр күргән кебек, бирелеп тыңлый.

Болгавыр тормышта гөнаһсыз гына алдашырга, уйнарга яратса да, Мөдәррис иҗатында бакый сүз изгелегенә хыянәт итми, җанын актарып ташлап яза. Юк, язмый... әзер шигырьне фәрештәләр кулыннан үрелеп кенә ала сыман.

Атабай тугайлары бүгенгедәй күз алдында. Сентябрь җиле... Чалып аяктан егарга теләгәндәй, дулкыннар ярга сикерә. Кодрәтле шавын тыңлап, Мөдәррис Әгъләмов белән яр буенда йөрибез. Без яшь әле, утызга да җитмәгән. Тукай яшеме? Анысы Ходай Тәгалә тарафыннан индерелгән бәхетле ялгыш. Егерме җидедә бөеклеккә ирешү бүтән кабатланмаячак...

Мөдәррис Кандалыйлардан, Бабичтан шигырь юллары китерә. Кол Гали, Хафизларны искә ала. Минем Гарсия Лоркалар, Евтушенколар белән җенләнгән чак. Каян соң әле бу сандык төбеннән «нафталинлы шигырьләр» тартып чыгара, архаизм, дип, Мөдәррискә эчтән көлебрәк карап куям. Ә ул шигъриятенә кирәкле көй, сулыш, сүз егәренең асыл микъдарын Шәрыкнең дастани тирән тамырларыннан алырга икәнен үз акыл-зиһене белән шул чакта ук төшенгән булган, каһәр! Бисмилласыз чорда яшәү рәвешең рәтле күренмәскә дә мөмкин. Әмма уй-гамь

олпатлыгы ана тумыштан бирелгән: иң мөһиме—эчке дөньяң шигъри догадан тукылган ак намазлыклы булсын...

Атабай тугайлары... Жете зәңгәр сентябрь күге... Учак-табын янына түгәрәкләнәбез. Хәсән Сарьян, хискә бирелеп, Вазыйх абыйның иненнән кагып-кагып ала:

—Шагыйрь син, билләһи! Шагыйрь! Киттек безнең белән Казанга!

Вазыйх абзый көлә, үрелеп ярга таба карап-карап ала. Анда биниһая зур көймәсен аның дулкыннар чылбырыннан өзеп алып китәргә теләп кыйный-йолкачайкалдыра.

Шуннан соң ун еллап вакыт үтте микән, беркөнне редакция коридорында мине бер кыз туктатты (йөз-кыяфәте, керфекләренә кадәр «илһам колы» икәне сизелеп тора):

—Сез безнең авылга—Сараланга килгән елны миңа сигез яшь иде. Сезне кунак иткән Вазыйх минем әтием иде,—диде.

—Шулаймыни?! Сарьян абый әтиенне чак шагыйрь итми калды ул чакта,—дим көлеп.

—Әти язмады инде. Үз урынына мине җибәрде Казанга,—диде эчкерсез елмаеп университет студенты, зәңгәр күзле кыз.

Саралан кызы—Илсөяр Иксанова—берничә елдан татарның кабатланмас шагыйрьләре йолдызлыгына үз моңы белән кушылыр.

* * *

Кичәләр үткәреп Мари ягында, Бәрәнге районында йөрибез. Халкыбызның меңъеллык әдәбият тарихын кыска, үтемле итеп сөйләп чыккан Хәсән Сарьянның тоныклык тавышын еллар аша аермачык ишетәм. Кәефе килгәндә, ул төрек акценты белән сөйли башлый, аннары, «онытылып китеп», бөтенләй төрекчәгә күчә торган иде. Кызганыч, ул елларда аңа иптәш кеше арабызда юк, «төрек» дигән сүзне дә сагаеп, як-якка каранып кына әйтә торган идек. Үзе әйтүенчә, төрекчәгә аны бала чакта әнисе өйрәткән булган. Житмешенче елларда шушы телдә бер иркенләп сөйләшеп, үзен сынап карау өчен аңа турист буларак Төркиягә бару бәхете дә тәтегән иде.

Мәктәп укучылары каршында да ул төрекчә шигырьне укымыйча калмый иде:

> *Йолк-йолукъ юрелер шаирләр,*
> *Багъырлар йылдызлара...*

Менә ул Төркиядә балаларның бик ярлы шартларда интегеп яшәүләре, бәләкәйдән үк авыр эшкә дучар ителүләре хакында сөндереп сөйли. Укучылар аның авызына карап сулышсыз калганнар. Төрекнең бәхетсез балаларын жәлләп күңелләре тулган, кайсылары менә-менә елап җибәрерләр шикелле.

Без, Рәдиф Гаташ белән, пәрдә артына чыгып китәбез, арттыра бу дип, түзә алмыйча, авызны тотып кына көлешәбез.

Үземнең башлангыч мәктәптә укыган елларымны искә төшерәм. Капиталистик илләрдәге хәерчелек, балаларның рәтсез тормышы хакында сөйләгәндә, «нигә безнең якка чыкмыйлар икән ул бәхетсез балалар?» дип аптырап уйлана идем. Чик буеннан сәламә киемле төркем-төркем балаларның безнең илгә таба агылуы күз алдыма килә иде. Үзем чит ил балаларын кызганган булам, ә үземнең бозда шуарга юньле тимераягым юк, китаплар салырга рәтле сумкам юк, тагын әлләниләр юк. Юклыгынны онытып, иң бәхетле илдә яшибез дигән сөенү генә бар...

Укучылар белән очрашудан соң Рәдиф Гаташ:

—Алай ук түгелдер инде, Сарьян абый, бигрәк бетереп ташладың Төркияне!—диде.

Сарьян абый бер сүз дә дәшмәде, борын эченнән кыңг итеп, күзлек кысасын төзәтә-төзәтә арлы-бирле йөренде дә, бераздан соң гына:

—Төркияне барып бер күргән кеше икенче тапкыр бармый түзә алмый. Дөресен сөйләсәм, юлымны ябам бит...—диде.—Төрки халыклар арасында бердәнбер бәйсез ил бит ул,— дип, әллә ниләр сөйләргә җыенган сыман булды да кәефсезләнеп туктап

калды. Күнелендәгән ачып салмыйча, вакытында тыела белү утызынчы елларда туып үскәннәргә гомумән хас сыйфат шикелле тоела мина.

Уйлаганбызмыни... Төркиянен Измир, Конья, Анкара, Истанбул кебек калаларын тамаша кылып йөрербез дә (1985 ел), Рәдиф Гаташ белән шунда Хәсән Сарьянны еш кына искә алырбыз дип кем уйлаган... Төркиянең көнкүрешендә, архитектурасында гасыр-дәверләр чиратлаша. Йөзләрчә манаралардан иртәнгекичке азан—ислам моңы яңгырап шәһәрләр өстенә изге нур сибә. Кая барсаң да бер тел—төрек теле... Чибәр, горур халык. Яшь егетләр «Мин төрек!» дип күкрәк кагып торалар. Үз дәүләте булган халыкның күз карашы, гәүдә тотышы, буй-сыны, рухы башка икән шул. Кызыгасын, көнләшәсең, чагыштырып карыйсың да... үз халкыңның язмышын уйлап, эчтән әрнеп, өметсезләнергә генә кала.

Ә теге чакта Сарьян күргән малайлар, киләчәктә бизнес эше ачарга дип, Алманиядә акча туплыйлардыр. Кая карама төрек малайлары сату итә, туфли чистарта, фаэтоннарга утыртып туристларны йөртә. Телләре дә, куллары да уйнап тора. Француз белән французча, инглиз белән инглизчә, алман белән алманча теттереп сөйләшәләр. Бәләкәйдән үк кыюлыкка, телгә, эшләп алган акчаның тәмен белергә өйрәнеп үсәләр ич төрекнең күмер күзле малайлары!

Хәсән Сарьян үзе дә боларның эшчәнлегенә сокланып йөргәндер. Ул таза, нык гаиләдә, бәләкәйдән үк һөнәргә өйрәнеп үскән. Уфа татарларының матур табигатьле Илеш төбәген ул еш сагына, жае чыкканда кайтып килергә тырыша иде. Туган йортынын фотосын да күрсәткәне бар. Фронтоннары агачтан чигеп эшләнгән мансардалы байлар йорты булып истә калган. Хәсән Сарьян әле Уфа университетында укытып, башлап язучы булып йөргән чакта, Мостай Кәрим:

—Октябрь революциясе булмаса, без язучы түгел, ә Сарьянда батрак буласы идек,—дип юкка гына шаяртып әйтмәгәндер.

Кай арада еракка кителде, вакыйга Бәрәнге районының шыңгырдап торган нарат клубында бара иде бит әле. Хәсән Сарьянга купшылык, купайту хас түгел, гадел итеп, саран гына мактап безне халыкка тәкъдим итә. Ин соңыннан сәхнәгә Рәдиф Гаташ чыга. Аудиторияләрне күп күргән тәжрибәле, сүз куәсен чамалый белгән шагыйрь. Аның һәрчак кулланып, тамашачының күңелен ача торган серле ачкычы бар:

—Иптәшләр, мин сүземне су эчүдән башлыйм әле!—дип, ул стаканга тотына, бер йотым гына уртлап куя. Шул мәлдә залдан жинелчә көлү дулкыны уза, ике арада якынлык урнаша. Гаташ, башын чөеп, көр тавыш белән «Ирләр булыйк!»ны сөйли башлый. Озын кулын нәзакәтле сузган, әйтерсен лә учына көзге яшереп, шуна карап укый.

Кичәләр шулай бер жай гына бара иде, өченчеме көнне нәтабигый хәл булды. Хәсән Сарьян, гадәтенчә, беренче булып трибуна артына чыкты да:

—Иптәшләр, мин сүземне су эчүдән башлыйм әле...—дип, бер тын калып, күз кырыен гына Гаташка төшереп алды.

Рәдиф Гаташ коелып төште, ризасызлык шәүләсе күзлек пыялаларына кадәр жәелде. Үз чираты житкәч, ул трибуна янына авыр сулап килде дә ачкычын югалтып, бикле ишек катында чарасыз калган шикелле бераз таптанып торды, аннары элеккеге кыюлыгын жуйган тавыш белән шигырьләрен сөйләүгә күчте.

Соңыннан инде, әлбәттә, аңлашу булды.

—Ул бит минем табыш, мин аны ничә еллар инде дога кебек кулланам,—дип, Гаташ, Хәсән Сарьянның әле уң ягына, әле сул ягына чыгып, кулын селки-селки аңлата.

Сирәк шаярта торган Сарьян канәгать калып көлә. «Сине сынап карамакчы идем...»—ди. Дусларча үпкәләшүнең соңы тирәнгә китә димени, айлы төн безне үз кочагына ала.

Бәрәнге поселогы да, Йошкар-Ола кибетләре дә гажәп бай: кием-салым дисенме, башкасымы, хәтта лимонга кадәр сатуда бар (1978 ел бит бу!). Бер кибеттә без—«Казан хәерчеләре»н сатучы ханым: «Әллә әртисләр килгән инде?..»—дип, ягымлы елмаеп каршы алды. Төрле тәм-томнар арасында күзне кызыктырган цейлон чәенен бер кулга икешәр генә кап бирелүен белеп алгач, мин, бөтен сәләтемне эшкә жигеп,

сатучы ханымны авызыма караттым. Казаннан зур концерт әзерләп киләчәкбез, иң шәп урынга билет сезгә, имеш. Ниһаять, минем тел юмартлыгы өчебезгә дә унар кап чәй белән бәһаләнде.

Урамга чыккач, Хәсән Сарьян мине мактап бетерә алмады:

—Күз алдында бер башка үсеп киттең. Синең белән юлга чыгарга була икән!..

—Шәп! Чәй хакына гөнаһсыз алдашырга ярый,—диде Рәдиф Гаташ.

Шулай кәефле сөйләшә-көлешә якындагы ипи кибетенә килеп кердек. Кердек тә бер-беребезгә карашып аптырап калдык. Бер кырыйда зур-зур тартмаларда чүмәләмә өелгән цейлон чәе тора, бу кадәрле байлыкны минем гомеремдә дә күргәнем юк иде. Сатучы белән безнең арада шундый сөйләшү булып алды: «Бу чәйләр сатыламы?»—«Күргәзмәгә куймаган идек, абый жаннарым, сатарга дип куйдык...»—«Ничә кап алырга мөмкин?»—«Кесәгезгә карап инде, хет яшниге белән алып китегез, абый жаннарым...»

Минем шунда ук кикрик шинде, базарым төште. Юлдашларым миннән көләргә тотындылар. Боларга кушылып, үз-үземнән көлеп кенә мин хәлемне жиңеләйтә ала идем.

Көлүне читкә куеп, житдирәк уйлансаң, сәер чынбарлык ачыла: безнең республика миллионнарча тонна нефть озата, иген кырларын таптап, зур-зур заводлар кора, ә кибетләрдә фәкыйрь жил уйный. Бәрәңге иккән мари ягында исә шартлар башка... Мәскәүчә тәэмин ителгән кибетләрдә—апельсин-лимон, һинд чәе. Татар, бичара, желегең суырган саен дәртләнебрәк эшли, үзеннән көлгән саен сөенебрәк югарыга рапорт бирә. Бу турыда ачынып сөйләшүдән ары китә алмый идек шул без ул чакларда.

Ә шулай да... Калын мари урманнары белән уратып алынган татар төбәген яраттык без. Ул карлы кичләрнең кәгазьгә сыя алмаган күпме хатирәләре кем белән дә бүлешеп булмый торган сагынуга әйләнеп калгандыр... Без китәсе көнне эре-эре кар ява иде. Йошкар-Ола автобусына кереп утырдык. Күңелдә ниндидер моңсулык. Күперенке башлык кигән чибәр-чибәр кызлар тәрәзә янынннан үтеп-сүтеп тора. Их, кичә кайларда идегез микән сез, чибәркәйләр?.. Ирексездән шушындый юллар хәтергә төште:

*Салмак кына йөзеп калды*
*без тотмаган балыклар...*

Үз эченә йомылып, төксе генә утырган Хәсән Сарьян кинәт башын күтәрде дә:

—Шәп сүзләр! Шигырь ич бу!—диде.

Энциклопедик хәтерле Рәдиф Гаташ шунда ук бу юлларның Роберт Әхмәтжанов шигыреннән икәнен әйтеп бирде. Шигъриятне ярата иде Хәсән Сарьян. Бервакыт Казаннан «Елочка» (хәзерге «Банк-клуб») кафесында кәеф-сафа корып утырабыз. Арада Ерак Көнчыгыштан хәрби хезмәт срогын тутырып кайткан яшь офицер Зиннур Мансуров та бар. Аның яшь шагыйрь икәнен дә белгәч, Хәсән Сарьян: «Синмени инде ул ана турында тетрәндергеч шигырь язган Мансуров?..»—дип, аның «Казан утлары»нда чыккан циклыннан шундый юлларын хәтергә төшерде:

*Ник ашыктың, әни,*
*туй күлмәгең*
*син икенче тапкыр кияргә?*
*«...Туй күлмәгем белән...*
*жир асты да*
*якты, нурлы булсын...»—дияргә.*

Лейтенант-шагыйрьнең үз авызыннан кабат-кабат сөйләтеп, ул шушы шигырь моңында хозурланып утырган иде ул көнне.

Әдәби бәхәсләр вакытында масаебрак киткән без яшьләрне Хәсән Сарьян: «Галимжан Ибраһимовны узуы жиңел, тик аны башта куып житәргә кирәк әле...»—дип оялтып куя иде. Телгә аерата сизгер, аз гына төгәлсезлектән дә рәнжи

торган әдипнең беренче проза китабыма эчке рецензия язарга алынуы минем өчен бәхет иде. Шул кульязмамны алырга дип, мин аның дачасына бардым. Төп сүзгә керешкәнче, ул, кыл кебек бер эздән чигелгән кадак башларына кадәр күрсәтеп үзе төзегән йортны үтә бер тәм-ләззәт белән аңлатып, таныштырып йөрде. Агач эшенә дә оста икәнен мин аның «Әткәм һөнәре» повестеннан укып та, болай ишетеп тә белә идем. Сарьян абый өчен монда иң яраткан урын бакчаның өй каршындагы почмагы иде, ахрысы. Инглизләр төгәллеге белән кырт кисеп калдырылган кыргый үләнлек, кырыйда мәһабәт имән үсеп утыра. Берәү булса, күләгә төшерә дип, имәнне кисеп, төбе-тамыры белән каерып алып, анда җиләк-җимеш утыртыр иде.

—Дача җире алу белән күпләр кисеп ташладылар,—диде ул.—Сал аягыңны!—дип, үзе дә чишенеп, үлән өстенә җәелеп утырды.

Имән күләгәсе төшкән бу нәни генә оазиста һәр үлән санаулы, һәр чәчәк үзенчә матур-кадерле иде.

—Печәнен, курпысын чабып торам,—диде Хәсән Сарьян. Минем өчен сәер тоелды: шушы уч төбе кебек җирдә печән чап, имеш. Ул чакта минем әти-әни исән, авылыма кайтып, җәй саен киерелеп печән чабам. Туган нигезең булгач, урман-болыннарга да үзеңне хуҗа итеп саныйсың. Хәзер инде менә печән чоры җитсә, җан талпына, чалгы җыры төшләргә керә, печән чабасы килеп кул кычыта башлый. Кайтып кына булмый, нигез беткән, ара өзелгән. Менә кайчан аңладым мин Сарьян абыйны. Чалгы тавышы аның еракта калган хатирәләрен уяткандыр, шушы кульяулык кадәр җирдә печән чапкан мәлдә туган ягы тугайларын искә төшереп юангандыр. Төннәрен, исән калдыруына рәхмәтле булып, талгын җилдә шаулаган имән төбендә монаеп утыргандыр.

Без ул көнне урман аланнарында кузгалак өзеп каба-каба сәгатьләр буе сөйләшеп йөрдек. Күптән түгел генә аның яңа повесте—«Бер ананың биш улы» басылып чыккан иде. Үзең яратып язган әсәрне халык хөкеменә тапшыру—язучы өчен сирәк килгән бәйрәмдер. Гадәттә, дача киемнәреннән генә йөрергә яраткан Сарьян абый ул көннәрдә саргылт төстәге яңа плащ киеп, кулына дипломат тотып нәшриятка килә иде. Бөтенесе дә кулын кысып котлыйлар. Аның йөзендә эчке мәгърурлыгын чак тыеп торган канәгатьлек һәм шул ук вакытта үзе генә белгән ризасызлык та чагыла. Повесть редакторлар тарафыннан кыркылып төзәттерелмәсә, нәкъ ул язганча басылса, тәэсире тагын да көчлерәк буласы иде. Кызганыч, заманасы шундыйрак иде шул... Бу әсәрен ул, басылып чыкканчы, кульязма килеш мина укыткан иде. Фаҗигале симфония кебек үтә камил, тетрәндергеч әсәрнең вакыйгаларын онытырлыкмыни: бәхетле гаиләдә берсеннән-берсе таза, чибәр биш малай үсә. Сабантуйлар, авылның самими гадәтләре, Агыйделдән сал агызулар... Шулай кинәнеп яшәргә килгән егетләр тормышның кайсыдыр борылышында эчкечелек агуына биреләләр. Бертуган егетләрнең өчесе фаҗигале үлемгә дучар була. Дүртенчесе үз-үзенә кул сала. Әсәрнең соңы ананың хыялыйлануы белән бетә иде.

Журналда үз вакытында чыксын өчен нинди генә шартларга күнмисең. Цензура таләбе аяусыз иде шул ул елларда. Хәсән Сарьянга да повестьтагы персонажларны кабаттан терелтү, әсәрне имгәтеп чыгаруга йөрәген кисеп ризалашу җиңел бирелмәгәндер...

Узган гасырның сиксәненче елларында Хәсән Сарьян шушы әсәре белән генә дә үзен олуг әдип икәнен раслады. Татарның милләт буларак таркала башлавын, аың генетик кодына нинди хәтәр куркыныч янавын ул "Бер ананың биш улы"нда бәгырьгә үтәрлек итеп искәрткән булган. Бу тирән мәгънәле әсәрнең баштагы, төп нөсхәсе бастырып чыгарырга иде, ясалма каланчага менгереп, мифик классик ясаган кайбер каләм ияләренең буш кибәктән торган язмаларын бер кырыйга этебрәк куеп, җан кисәтүенә корылган шушы югары кимәлдәге әдәби әсәрне мәктәп дәреслекләренә кертергә иде.

Ул чакта, Идел ягыннан дымлы сулыш сирпелгән урманда гәп корып йөргәндә дә, безнең уй-гамебез, сүз сөреше һаман шул әдәбияттан ерак китә алмый иде.

—Сукырлар турындагы повестегызны кайчан язасыз инде, Сарьян абый?

—Чират шуңа житте инде. Тиздән тотынам. Күзгә...

Малай чакта аны тома сукырлардан гына торган артистлар труппасына алалар. Шулар белән ул концертлар, спектакльләр куеп, авылдан авылга йөри. Сукырлар гаҗәп кызык халык, бөтенләй бүтән дөнья, аларга көн дә бер, төн дә бер, дип, мавыктыргыч итеп, күп тапкырлар сөйләгәне бар иде аның.

—Труппа житәкчесе көчле ихтыярлы кеше иде, шуны Казан урамында очратып исәнләштем. Сукырлар колакка сизгер була бит. Тавышымнан таныды, унжиде ел үткән бит югыйсә... «Сарьян энекәш, син ич бу! Үскәнсен, үскәнсен...»—дип, буемны чамалап, баштан сыйпап алды.

Хәсән Сарьян үзе әйткәнчә, «утырып яуган янгыр кебек» тел белән ашыкмыйча, ипле итеп, һәр күренешнең күләгәсенә кадәр метекләп, нечкә жеп белән үрә-үрә яза белә иде. Әсәрен укыганда, тел хасияте сиздермичә дә сине олыгайта бара, кайчакларда бу тәэсиргә бирешәсе килмичә, күнелдәге яшьлек таенын дөрес кагыйдәләр кысасыннан читкә сикереп, үзенчә юл сабарга теләп үрсәләнүе дә гаҗәп түгел...

—Үсмерчак хатирәләре... Романтик рухта язарга кирәк инде бу әсәрегезне,—дип акыл саткан булам.

Хәсән Сарьян, дәшмичә, баш кына селкеп куя. Күнелендә инде анын тере образлар яши, мәйданга чыгарга омтыла, әмма язучының ак кәгазь каршында туачак газаплы мизгелне сузып, ашыкмыйча, ләззәт кичергән чаклары иде, күрәсең. Ничә еллар буе жаныннан аерырга кызганып йөргән бу әсәрне язарга өлгерә алмаячагын, ул вакыйгаларны бүтән беркем дә, беркайчан да яза алмасын без ул чакта уебызга да китерә алмый идек шул. Көне нинди иде бит... Кояшлы хозурлыктан кинәнгән көндә без, бу дөньяга мәңгегә килгән кебек, «Алла бирсә»не дә онытып, уй-ниятләребезне уртаклашып йөрибез.

Кошлар авазына күмелгән каенлы-усаклы урманны кинәт тоташ наратлык алыштырды. Хәсән Сарьян тукталды да:

—Менә монда чик сызыгы...—диде.—Сизәсенме, һавасы кинәт үзгәрде. Бәлзәм,—дип, ул, наратлыкка кергәч, күкрәк тутырып сулыш ала башлады. Жиз кәүсәле мәһабәт наратлар арасында чынлап та әллә нинди иркенлек, жанны иркәли торган саф тынлык иде.

—Менә шушында һава кырт киселә,—дип, ул яналан мине каенлы якка алып чыкты.—Аерманы сизәсенме?—Ике арада һава чиге булуына ул мине сабыйларча үжәтлек белән төшендерергә керешге.

Ике урман арасы...

Туган жиренең елгаларын кан тамырлары белән чагыштырып язган әдипнең йөрәгендә тетрәнүләр барамы—берүзе генә беләдер. Зарлану гадәте аңа хас түгел. Әнә бит ул, вакыт-вакыт күзлеген сала да чигәләрен кысып тора (кан басымы югары булган кешеләргә хас сыйфат-гадәт).

Уфа—Казан арасы...

Бу ара Хәсән Сарьян өчен ерак та, якын да түгел, бу ара әдипнең бәгыре белән тоташкан. Менә бүген дә ул хатирәләргә бирелде, язучылар арасындагы эчкерсез мәзәк хәлләрне көлә-көлә сөйли, Уфа университетында укыткан еллары искә төшкәч, ачынып бер-ике сүз әйтеп куя да үз эченә йомыла. Тел хасиятенен тирән тарлавыкларына төшә белгән әдипкә гыйлемлек сәләте тумыштан бирелгән. Аңа бәрәкәтле мәйдан гына кирәк булган. Ләкин утызынчы елларда төптән киселгән чын зыялылар урынына килгән үзешчән, мөтәгалимнәр арасында ул ышанычлы терәк таба алмый. Милләтләрне аерып, тарихтан олы баба эзләп, мирасны бүлешеп кайнашкан фәһемсез вә фәнсез даирәне ташлап, Казанга күчәргә мәжбүр була.

Әдәбиятчылар арасында да жанына урын таба алмый. Олыны олы, кечене кече итеп, кемгәдер ачылып китәргә ниятләп талпынып та куя, тагын сагаеп, үз кабыгына яшеренә. Мондый чакта ул ягымсыз, мыжык булып тоела. Эчтән күнеле сыкрап торганда, ничек инде ваемсыз сүз сөрешенә кушылып китә алсын. Кемгә сыенасын? Тарих тәмен жуйган өлкән әдипләрнен дә халык язмышына караган хәтере шушы гасыр белән генә чикләнә... Әллә сон һәркем эчтән, аерым-аерым гына сызамы? Йә, кем бар?! Мондый өметсез мәлләрдә, инендәге ташны кагып төшереп, Сарыжан кычкырып жибәрер шикелле... «Уйсыз да, буйсыз да, Алласыз

да, мулласыз да әдәбият быргычылары, ишетәсезме?! Юк, мин кычкырмыйм, күңелемнән генә әрнеп эндәшәм... Юк, сезгә түгел, үз-үземә... Кичерегез...»

Ике халык арасы...

Сарьян сагынып Уфага бара да күңелсезләнеп кайта. Ике халыкны аерган сызык, упкын булып, киңәйгәннән-киңәя бара. Бер башы Уралда, казакъ далаларына тирәлгән, икенче башы Иделгәчә житкән олы дәүләт булып яшисе бер тел-ләгать агачындагы ике җимеш бит без югыйсә, татар-башкорт кавеме. Ни җитми? Кем булә? Кем дигәне ике араны болгатып торучы бер өер. Держава кулы аларны үсендереп тора. Аерылганны аю булып, бүленгәнне бүре булып ашерен генә бугазлап бара.

Ике халык арасы...

Әз генә бу ара җылына башладымы, бәләкәй «Идегәйләр» калкып чыга. Юк, болар кылыч тотып иярга утырырлык та, җәя тартырлык та хәлдә түгел. Болар—«Өченче Рим» учыннан төшүгә туфрак буласы астыртын мәхлуклар, алданган бичаралар... «Ник берегез дә эндәшми? Мин дә дәшмим...» Сарыҗан карашында—әрнү-кисәтү, рәнҗү-шелтә-чарасызлык... Ә эчтә—гомер кыясы убылганнан-убыла бара...

Ике урман арасы...

Сарьян абый кайсы якка чыгыйм икән дип икеләнгәндәй туктап калды, тагын чигәләрен кысып торды. Әллә авырыйсызмы? дип сорау бирмәсен дигәндәй, күз төпләрен сыйпап алды да, акланган сыман:

—Безнең яшьтә шулай инде, кул белән тигезләп тә карыйсың, җыерчыклар артканнан-арта гына бара,—диде.

— Кая әле сезгә картаю турында уйлау.

—Безнең нәсел озын гомерле. Кимендә туксанга кадәр яшим әле мин,—дип, Сарьян абый үз-үзен юаткан кебек әйтеп куйды. Кинәт ул беләгемнән кысып тотты:—Ишетәсеңме, күке кычкырды?!

Әллә кычкырды, әллә юк, мин ул әйткәч кенә кайтавазын ишеткән кебек булдым.

—Бу вакытта күке кычкырмый, сакаулана,—дип, ул эчтән нидер юраган-сораган кебек сагаеп тыңланды.

Бер кычкырды да тынды кәккүк. Бәлки, ул күк катларыннан иңгән тәкъдир тавышы булгандыр...

Шәһәр ыгы-зыгысыннан арынып, урман аланнарында бер-беребезне тиң итеп, ачылып сөйләшеп йөрүнең соңы житте. Көн кичкә авышкан талгын бер мәлдә без күл аша салынган асылмалы күпер төбендә хушлаштык. Ул аргы ярда басып калды. Соңгы... дигән хәтәр хакыйкатьне белмәү бәхете бирелгән шул адәм баласына...

Безнең нәсел озын гомерле, дигән иде югыйсә. Әмма эчтән сызган, халык язмышын сыйдырган йөрәге түзмәде. Әгәр ул бүгенге көндә исән булса... Күпме каләм ияләре үз язмасына нокта куйгач, Хәсән ага Сарьян ни әйтер икән, телнең асыл сафлыгына хыянәт итмәдемме, дип, җаваплылык хисе тоеп, дулкынланып куярлар иде. Әдәби телебез сагында ул гадел-кырыс, таләпчән аксакал сыйфатында кадер тәхетен биләгән булыр иде.

Сары күз Хәсән Сарьянны безнең арадан мәңге тынлык иленә алып китте. (1978 елның 21 сентябре.) Аңа нибары кырык тугыз яшь иде.

Сарьян, диюгә, миңа әлеге ике урман чиге күз алдына килә. Шул чикнең кайсы ягына чыгып кунарга белми җилфердәп очкан сары күбәләк күрсәгез, тимәгез аңа. Бәлки, ул олуг әдипнең сары җаныдыр. Балбаллы дала күкрәгендә янган борынгы учагын эзләп очадыр...

## ӘНИЛӘР–АПАЛАР ТУРЫНДА

Рәссамга хас булмаган эшкә–каләмгә ябышуымның сәбәбе гаҗәеп матур, үтә зәвыклы, тирән мәгънәле һәм күптән көтелгән китапчыкның кулыма килеп керүе булды. Ул да булса Өммегөлсем Тәлгать кызы Ардашированың «Идел-Пресс» нәшриятында рус телендә чыккан («Сынлы сәнгатьтә ана образы) дигән җыйнак китабы.



Китапның эчтәлеге турында сөйли башлаганчы авторның тәрҗемәи хәле турында бераз мәгълүмат биреп китәсем килә: педагогия фәннәре докторы, профессор Өммегөлсем Тәлгать кызы чыгышы белән мәшһүр Галимҗан Нигъмәтиләр нәселеннән, Мәскәүдә академиклар Б. Лихачев, В. Кузин, Н. Ростовцев кебек югары катлам мохиттә тәрбияләнгән, инде менә үзе дә бай фәнни мая туплап, Татар дәүләт гуманитар педагогика университеты ректоры чакыруы буенча Казаныбызга кайтты. Ул–тиз арада әлеге уку йортында сынлы сәнгать һәм дизайн факультетын ачып җибәргән, аның деканы булган шәхес. Шунысын да ассызыклап үтәсе килә, мондый факультетка тиңнәр хәтта Рәсәйдә дә юктыр. Өммегөлсем ханым биредә, татар яшьләреннән аерым төркем оештырып, рәсем дәресләрен ана телебездә алып бару хыялын тормышка ашыра.

Инде әлеге китапка килсәк, өч өлештән торачак шәлкемнең беренчесе ул. Дөньяви сынлы сәнгать әсәрләренә нигезләнеп, хәзерге заманда онытылып бара торган Бөек Ана, бала, гаилә, изге әхлакый төшенчәләр турында янә уйланырга этәрә әлеге китап.

Бу язмада мина еш кына «беренче» дигән сүзне кулланырга туры килә. Беренче махсус факультет, беренче татар төркеме, рәсем сәнгатен беренче буларак Ана телебездә укыту... һәм тагын шунысы: Бөек Ана дөньяви сынлы сәнгать тарихында тәүге тапкыр бөек әхлакый кыйммәтләр күзлегеннән өйрәнелә анда. Әйе, автор Бакый Урманче, Илдар Зарипов, Искәндәр Рафыйков һәм шул ук вакытта мин фәкыйрегезне дә Рафаэль, Ренуар, Дюрер кебекләр белән бер югарылыкка куеп тасвирларга омтыла. Мондый омтылышта, билгеле инде, кыюлык, татар җанлы булу гына аз, монда мәсьәләне тирәнтен өйрәнү, аңлау, зур җаваплылык тою да таләп ителә. Бу хакта мәгълүм булгач, Мәскәүнең кайбер танылган сәнгать

белгечләренең ирен чите белән генә елмаеп куюлары да билгеле булды. Күр инде, гомер булмаганны татарны шулар белән янәшә куя, янәсе! Әмма безнең галимәбез тоткан кыйбласына тугры булып кала.

Китапны карап, укып чыккач, укучыбызда, табигый ки, горурлык хисләре уяна. Әйе, безнең мәдәниятебез дөнья мәдәнияты хәзинәсенең аерылмас бер өлеше. «Сынлы сәнгать әсәре никадәр милли жанлы булса, ул башка милләтләр өчен дә шулкадәр үк кызыклы һәм кыйммәтле»–әлеге классик әйтемнең хаклыгына тагын бер кат инанасың әлеге китап белән танышкач. Мондый хезмәтне әзерләп чыгаруга татар хатынының алынуы бер дә очраклы түгел. Чөнки безнең халыкның аңы гасырлар буена Ислам тәгълиматләре нигезендә формлашкан. Ә Хатын-кыз, Ана анда бик югары бәяләнә торган төшенчәләр. Әни кеше эндәшкәндә хәтта намазны да (!) бүлеп торырга мөмкин булганлыгын да онытмыйк.

Шул ук вакытта башка милләтләрнең мәдәнияте тәэсирендә, халкыбызның да алар йогынтысына бирелеп китүе дә юктан гына түгел... Болар барысы да уйландыра. Китап шуның белән укучының зәвыгын тәрбияли, аның фикерләү сәләтен үстерә. Чын затлы сынлы сәнгать әсәрен затсыз, шикле әйберләрдән аера белергә өйрәтә. Шуңа да ул фикерле белүче укучыларыбызга, бигрәк тә яшьләргә, җәмгыятебезнең әхлакый нормалары аска тәгәри барган чорда, бик тә затлы бүләк булырлык хезмәт.

Шуны әйтергә кирәк: автор сәнгать белгечләрен үзебезнең милли рәссамнарыбызның иҗатын тирәнтен өйрәнергә һәм пропагандаларга өнди.

**P. S:** *Күптән түгел шатлыклы хәбәр алдык. Сочида үткәрелгән сынлы сәнгать бәйгесендә Өммегөлсем Ардашированың «Образ матери в изобразительном искусстве» китабы «Иң яхшы фәнни хезмәт» номинациясендә лауреат исеменә лаеклы булган. Әлеге китапны чит илләрдә бастырырга да тәкъдим булган. Афәрин, Өммегөлсем ханым!*

**Рифкать ВАХИТОВ,**
*рәссам, Татрстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.*

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

# К

**КАШАПОВ** Газиз (Газизжан) Салих улы (псевд. Газиз Кашшаф-Үзиле) (21.8.1942, Аксубай р-ны Яна Үзи ав.—30.8.1991, Яр Чаллы шәһ. вафат була, туган авылында җирләнгән), язучы, Благовещенье хәрби уч-щесын, Казан ун-тын (1979) тәмамлый. 1974-82 елларда Татар. кит. нәшр.-нда кадрлар бүлеге инспекторы, «Хезмәт байрагы» (Әлмәт шәһ.), «Социалистик Татарстан» газеталары хәбәрчесе вазифаларын башкара. 1987-89 да ТАССР Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлеге җаваплы секретаре. Беренче әсәрләре 1974 елда «Ялкын» ж-лында басылып чыга. «Сәмум җиле» (1978) автобиографик повесте чик сакчыларына багышланган, ә «Җир җылысы» (1983) повесте һәм «Язмышына ышан» (1987) романы зур промышленность объектларын һәм яна шәһәрләр төзүчеләр турында. К. шулай ук «Еллар тыныч иде» (1983), «Вөҗдан хәтере» (1989) кебек замана яшьләре проблемаларын күтәргән повестьлары, шагыйрь Х.Туфан турында «Киек каз юлы» (1992) дигән документаль роман; публицистик мәкаләләр, популяр җыр текстлары авторы да. 1992 елда К.ның туган авылында бюст куелды һәм музей ачылды.

Әд.: Нәҗмиев Т. Үзи авылының Газизҗаны // Казан утлары. 2002. №8.

**КАШГАРИ** Мәхмүд, к. Мәхмүд Кашгари.

**КАШТАНОВ** Нәкыйп Фәсхетдин улы (8.1.1942, Чуваш Республикасының Батыр р-ны Кыр-Бикшик ав. туа), табиб, язучы. Казан медицина ин-тын тәмамлагач (1971) Чистай үзәк район хастаханәсендә эшли, 1974-80 дә—Казанның медицина оешмаларында. 1981 дән Республика клиник хастаханәсе табибы. «Гангрена лёгких. Эмболия лёгких. Тромбоз. Инфаркт лёгких» (2001) монографиясе авторы. Беренче шигырьләре һәм хикәяләре 1970 еллар азагында басыла башлый. Балалар өчен «Төлке» операциясе» (1995), «Айгөлнең туган көне» (1997), «Тылсымлы курай» (2001), «Канатлы чәчәкләр» (2004) китаплары фантазиягә бай, юмор белән сугарылган. Шигырьләре «Язмыш орчыгы» (2002), «Күкләргә кунмый тузан» (2004), «Кыйссаи Йосыфка»ка сәяхәт» (2005) җыентыкларына тупланган.

**КАШШАФ** (Кашшафетдинов) Гази (Миргази) Солтан улы (15.4.1907, Уфа губ., Бәләбәй өязе, Яна Арсланбәк а.—9.12.1975, Казан), әдәбият тәнкыйтьчесе (әдәби тәнкыйтьче), әдәбият галиме, филол. фән. кандидаты (1960). Көнчыгыш пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1929), укытучылык итә. 1937-42 дә Татарстан китап нәшриятында (Таттосиздат), 1942-45 тә «Совет әдәбияты» ж-лында, 1945-47 дә ТАССР Язучылар берлегендә референт-консультант, 1947-50 дә СССР ФАКФ Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1950-58 «Казан утлары» ж-лында баш мөхәррир булып эшли. 1961 дән Казан ун-тында. Милли театр мәсьәләләренә, татар язучылары (Г.Тукай, Г.Камал, М.Гали, Ш.Камал, Ә.Фәйзи, К.Нәҗми, М.Галәү һ.б.) иҗатына караган мәкаләләр б-н чыгышлар ясый, урта мәктәп өчен хрестоматияләр төзүдә катнаша. М.Җәлил иҗатын һәм тормышын өйрәнә: «Моабит дәфтәре»нә фәнни комментарий яза, аның әсәрләрен басмага әзерләгәндә текстологик яктан эшкәртә, шагыйрьнең фотография альбомын төзи, замандашларының истәлек җыентыгын әзерли (М.Җәлил исем. Татарстан комсомолы бүләге иясе). Повестьлар һәм хикәяләр авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Күңел көзгесе. К., 1975; Муса Джалиль. К., 1961; По завещанию Мусы Джалиля. К., 1984.

Әд.: Ахунжанов И. Остаз // Художник һәм аның сүзе. К., 1978; Юзиев Н. Фидакарьлек // Әдәбият хәзиналәре. К., 1978.

**КАЮМОВ** Гафур Шәкүр улы (2.3.1959, Арча р-ны Яна Сәрдә ав. туа), актёр, драматург. Казан театр уч-щесын тәмамлый (1983). 1983-90 да (өзеклек белән) Татар

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санында басылып килә.*

драма һәм комедия т-ры актёры, 1990-97 дә—Татар академия т-рында. 1997-99 да ТР Мәдәният министрлыгында театр сәнгате белгече. 1999 дан Татар академия т-рында сәхнәгә куючы режиссёр. 2000 нән «Татарстан» ДТРК нда әдәби тапшырулар мөхәррире. 2005 тән Әлмәт татар драма т-рының режиссёры. Аеруча әһәмиятле рольләре: театр сәхнәләрендә—Исмәгыйль (М.Фәйзинең «Галиябану» спектакле, 1991), месье Таккарель (Э.Лабишның «Тол ханымда тукталыш» спектакле, 1995), Сәйяр Ш.Хөсәеннең «Әни килде» спектакле, 2001); телевизион спектакльләрдә—Хәлил (М.Фәйзинең «Галиябану»ында, 1995), Сәлимҗан (Г.Исхакыйның «Зөләйха» сында, 2004). К.ның «Мирас» (1990), «Һинд кызы» (1993), «Әрнү» (1999), «Юбилей» (1992), «Соң инде...» (1998), «Сарык Арыслан» (1997) пьесалары буенча куелган спектакльләре Татар академия т-ры, Татар драма һәм комедия т-ры, Яр Чаллы, Минзәлә, Әлмәт татар драма т-рлары, «Нур» татар драма т-ры (Уфа шәһ.) сәхнәләрендә зур уңыш белән барды. «Упкын өстендә» (2003) пьесалар җыентыгы авторы.

**КӘЛИЛӘ ВӘ ДИМНӘ**, урта гасырлар фарсы һәм гарәп әдәбияты ядкәре. 6 гасырда фарсы теленә «К. вә Д.» исеме б-н (беренче 2 бүлек персонажлары—2 шакал исеме) тәрҗемә ителгән борынгы һинд фольклор китабы «Панчатантра»га нисбәтле. Әсәрнең бердәм тоташ сюжеты юк, ул аерым бүлек—гыйбрәтле хикәяләрдән (притча) тора. Әсәрнең үзәген Дабшалим патша б-н акыл иясе Бәйдаба арасында барган әңгәмә тәшкил итә. Башта һәр бүлек башында аның темасы билгеләнә, аннары патша үтенече б-н аның асылы аңлатыла. Һәр бүлек ахырында куелган мәсьәләләр буенча нәтиҗәләр ясала. Шулай итеп җыентыкның структурасын төгәл система тәшкил итә.

«К. вә Д.»дәге вакыйгалар һәм хәлләр төрле урыннарда бара: җирдә, су астында, һавада. Хикәяләрдә катнашучылар арасында: игенчеләр һәм һөнәрчеләр, акыл ияләре һәм руханиләр, ирләр һәм хатын-кызлар, балалар һәм олы яшьтәге кешеләр. Алар б-н беррәттән әсәрдә төрле җәнлекләр, кошлар, мифик затлар да очрый. Алар, кешеләр кебек, сөйләшәләр, уйланалар, эшлиләр, яраталар, канәгатьсезләнәләр. Алар язмышында кеше табигатенә хас булган сыйфатлар, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр чагылыш таба. Ул тереклек ияләре еш кына үзләрен кеше дип исәплиләр.

8 йөз уртасында Ибне әл-Мукаффа (723/724 тә туган) тарафыннан гарәп теленә тәрҗемә ителгән бу әсәр төрле версия һәм вариантларда мөселман Көнчыгышы дөньясына киң тарала. 13 йөздә гарәп версиясе испан һәм борынгы Европа телләренә, аннары латин (14 йөз), немец (1470), төрек (16 йөз), соңыннан француз, инглиз һәм рус телләренә тәрҗемә ителә. Әсәрнең төрки-татар теленә тәрҗемә ителгән 10 га якын тәрҗемәсе билгеле, иң борынгылары 15-16 йөзләргә карый. Татарлар арасында Г.Фаезханов тарафыннан тәрҗемә ителгән (Казанда 1889—91 дә басылып чыга) вариант аеруча киң таралган була. «К. вә Д.»нең мотив һәм сюжетлары татар әдәбиятында берничә тапкыр файдаланыла (Кол Гали, Мөхәммәдъяр һ.б. әсәрләрендә).

Чыг.: Ибн аль-Мукаффа. Калила и Димна / Пер. с араб. Б.Шидфар. М., 1986; Кәлилә вә Димнә: Хикәятләр / Төз. Ж.Зәйнуллин. К., 1996.

Әд.: Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и Восточная классика: Вопросы взаимосвязей и поэтики. К., 1993; Зәйнуллин Ж. Ибне Фазлан сәяхәтнамәсе һәм «Кәлилә вә Димнә» турында // Казан утлары. 1986. № 11.

*Г.Г.Зәйнуллин.*

**КӘРАМИ** (Кәрамиев) Рәфкать Кәрами улы (18.2.1942, Сарман р-ны Рангазар ав. туа), язучы, ТАССРның, РФның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989, 2005). Казан ун-тын (1970) һәм Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курслар тәмамлый (Мәскәү, 1979). 1979-93 елларда ТР Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросында әдәби консультант, уполномоченный, директор вазифаларын башкара. 1994-2001 дә Татар интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) директоры. 1967 елда үзенең «Дүрт кешелек каюта» исемле беренче детектив повестен яза, бераз соңрак байлык артыннан гына куучы тар карашлы кешеләрне тәнкыйть объекты итеп алган «Кичке уйлар» (1970) дигән повестен бастыра. «Капитан Хәкимов» (1974), «Сагышлы кояш» (1983), «Йөрәгемне ут алган» (1987), «Ындыр тулы кибән» (1992) повестьларында һәм «Өзелгән чәчәк» (2002) исемле хикәя җыентыкларында тормыштагы рухи һәм әхлакый проблемаларны үзәккә алып замандашларының тулы образларын чагылдыра. Өч кисәктән торган «Очар кошлар белән янәшә» (1999) романы яшь төзүчеләргә, «Каргышлы этаплар» (1995) романы репрессия елларында хаксызга рәнҗетелгән якташлары истәлегенә багышланган. «Яратуың чынмы?» пьесасын Минзәлә татар драма т-ры 1982 елда сәхнәләштерде. Күп әсәрләре рус, әзерб., кыргыз, мари телләренә тәрҗемә ителгән. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. премия лауреаты (1999).

Әд.: Бәдигый Х. Ындыр тулы кибән

// Мирас. 2002. №2; Вәлиев М. Чынлык көче // Казан утлары. 2002. №2.

**КӘРИМ** (Кәримев) Мостай (Мостафа) Сафа улы (20.10.1919, Уфа губ., Уфа өязе, Келәш а.—21.9.2005, Уфа ш.), язучы, Башкорт АССРның халык шагыйре (1963), Соц. Хезмәт Герое (1979), РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1982), Башкортстан ФАнең хакыйкый әгъзасы (1992). Башкорт телендә яза. Башкорт пед. ин-тын тәмамлый (1941). Беренче шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә 1935 тә күренә башлый. «Отряд кузгалды» (1938, автордаш), «Язгы тауыштар» (Уфа, 1941) җыентыкларына кергән шигырьләр тормышка гимн булып яңгырый. «Таныш булмаган кунак» (1940) поэмасында Гражданнар сугышы фаҗигале вакыйгалары тасвирлана. К. Бөек Ватан сугышында катнаша. Фронтка киткәндә язылган «Мин һугышка китәм, иптәштәр!» исемле шигыре ватанны яклаучы сугышчы анты булып яңгырады. «Минең атым» (Уфа, 1943), «Шигырьзар» (Уфа, 1945) җыентыкларына кергән шигырьләрендә, «Декабрь йыры» (1942), «Үлмәсбай» (1943) поэмаларында шагыйрь сугышның фаҗигалеген, сов. солдатының батырлыгын, аларның Гитлерга каршы алып барылган сугышта гуманлык миссиясен үтәвен күрсәтә. Яраланганнан соң (1942), «За честь Родины», «Советский воин» фронт газеталары хәбәрчесе булып эшли. «Кайтыу» (Уфа, 1947) җыентыгына кергән шигырьләрдә кичә сугыштан тыныч тормышка әйләнеп кайткан солдатларның хисләрен һәм өметләрен чагылдыра. Сугыштан соң үзен иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлеккә багышлый: 1951—62 ләрдә Башкортстан АССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе сәркәтибе. Сугыштан соңгы поэзиясе яңа төсмер ала: тематикасы киңәя, аналитиклыгы көчәя, тормыш турындагы фәлсәфи уйланулары тирәнәя; оптимизм б—н сугарылган пафос өстенә халыклар язмышы турында кайгырту өстәлә: «Европа—Азия» (1953), «Вьетнам язмалары» (1957), «Каштан сәскә аткан ерзә» (1959), «Болгар дәфтәре» (1960), «Кабардин-Балкар дәфтәреннән» (1962) цикллары; «Язгы ер» (Уфа, 1951), «Йылгалар һөйләшә» (Уфа, 1961), «Торналар кайтканда» (Уфа, 1964), «Мәхәббәттен дүрт мизгеле» (Уфа, 1978), «Заманалар» (Уфа, 1982) h.б. җыентыклар. 1950 нче еллардан К. үткән сугыш темасына кабат әйләнеп кайта. Аның фаҗигалелегенә, сов. кешеләренең бөек ватанпәрвәрлылыгы чагылышына төшенә: «Өс көн тоташ кар яуа» (1955) шигыре, «Кара һыузар» (1961) поэмасы h.б. Драматургия өлкәсендә актив эшли: сугыш башланып өзелгән тыныч тормыш турындагы «Туй дәуам итә» (1947), сугыштан соңгы авыл колхозы турындагы «Яңгыз кайын» (1950) пьесаларын яза. «Кыз урлау» (1958) лирик комедиядә, «Айгөл иле» (1968) романтик драмада авыл тормышының көлкеле һәм кайгылы яклары тасвирланган. «Йырланмаган йыр» (1961), «Йәйәүле Мәхмүт» (1986), «Киске табын» (1993) пьесалары кешенең халык һәм җәмгыять алдындагы җаваплылыгы турындагы фәлсәфи уйланулар б-н сугарылган. Риваятьләргә, тарихи фактларга нигезләнеп язган «Ай тотолган төндә» (1963), «Салауат» (1971), «Ташлама утты, Прометей!» (1975) трагедияләре ирекле кешенең бөеклеге, идея хакына корбан булырга әзерлеге темаларын күтәрәләр. «Озон-озон бала сак» (Уфа, 1976) повестенда кеше яшәү рәвешен фәлсәфи яктан яктыртырга тырыша. Әсәрнең логик дәвамы булып «Ауыл адвокаттары» (Уфа, 1989) һәм «Тормош мизгелдәре» (Уфа, 1997) китаплары языла. Сугышның кешелексез законнары турында «Ярлыкау» (Уфа, 1986) повестенда яза (язылa). Балалар һәм яшүсмерләр өчен язылган «Беззең өйзең йәме» (Уфа, 1951), «Өс таган» (Уфа, 1962) әсәрләрендә авыр сугыш һәм сугыштан соңгы елларда башкорт авылының тормышы балалар күзлегеннән чыгып яктыртыла; кешелеклелек, кешеләргә карата мәрхәмәтлелек, яхшылык кылуга омтылыш раслана. К. китаплары Россия һәм дөнья халыкларының телләренә тәрҗемә ителде. 1955—90 да РСФСР ЮС депутаты. Башкортстан АССРы Салават Юлаев исем. (1967), РСФСР Дәүләт К.С.Станиславский исем. (1967), СССР Дәүләт (1972), Ленин (1984) бүләкләре лауреаты. Ике Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗәле Ватан сугышы орденнары, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Әсәрзәр: 5 томда. Өфө, 1971—73; Әсәрзәр: 4 томда. Өфө, 1987—88; Собрание сочинений: В 3 т. М., 1983.

Әд.: Кильмухаметов Т. Драматургия Мустая Карима. Уфа, 1979; Хөсәйенов Г. Мостай Кәрим. Өфө, 1994.

*С.Г.Сафуанов.*

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ЗЫЯЛЫ УЛЫ

ФАТЫЙХ КӘРИМИНЕҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ

XIX йөзнең ахыры—XX гасырның тәүге елларында татар рухи тормышында башланган тирән үзгәрешләр, тәрәккый хәрәкәт—күпләгән зыялыларыбызның фидакарьләрчә эшчәнлеге, ижади яну-көюләренең нәтиҗәсе. Шунысы үзенчәлекле: татар Янарыш (Ренессанс) хәрәкәтенең төп көчләре, ничектер, бер үк елларда туалар: Р. Фәхреддин һәм Дәрдемәнд—1859, Г. Исхакый һәм Г. Камал—1878, М. Гафури һәм С. Рәмиев 1880, Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан—1886 елларда ... 1870 ел да дөньяга Ленинны гына түгел, татарның ике мәшһүр затын да бүләк итә: аның берсе күренекле прозаик Заһир Бигиев булса, икенчесе—мәгърифәтче, әдип, журналист, нашир, тәрҗемәче Фатыйх Кәрими. Чыгышы белән ул бераздан миллиардлаган тонна кара алтын бирәчәк атаклы Әлмәт якларыннан. Бу төбәк элек-электән үзенең Тайсугандагы һәм Түбән Чыршылыдагы мәдрәсәләре, Г. Исхакыйның бабаларын тудырган Елховойлары белән атаклы. Афзал Таһиров, Әхмәт Тимер, Хисам Камалов, бертуган Туйкиннар да Әлмәт тарафларыннан. Иң мөһиме—бу төбәк бөек Ризаэддин хәзрәтнең дә кече ватаны.

Мөхәммәдфатыйх Кәрими 1870 елның 30 мартында Әлмәттән 15 чакрым ераклыктагы Минлебайда дөньяга килә (Әлеге авылда язучы һәм драматург Шамил Бикчурин да туган). Мәгълүм ки, ата-ана, гаилә, мохит адәм баласының формалашуына зур йогынты ясый. Бу Ф. Кәрими мисалында аеруча калку чагыла. Әдипнең әнисе Мәгъсүмә абыстай—Р. Фәхреддиннең бертуган апасы—укымышлы, тәрбияле гаиләдән. Ризаэддин хәзрәт исә гомере буе Ф.Кәриминең остазы, фикердәше, таянычы булып тора. Әдипнең әтисе Гыйльман мулла (1.10.1841—2.06.1902)—үз чорының билгеле кешесе. Аның Габделмөэмин дигән бабасы улы Габделкәрим белән 1775 елларда Пенза тарафларыннан күчеп, Түбән Чыршылыда төпләнә. Гыйльман әүвәл шушы авылда, аннан Чистай шәһәрендәге атаклы шәех Мөхәммәдзакир хәзрәт Ваһапов мәдрәсәсендә белем ала, 1867 елда өйләнә һәм әнисенең туган авылы Минлебайда имам-хатыйп, бераздан ахун булып эшли; аның уку-укыту әсбаплары язуы да мәгълүм. Биредә аларның алты балалары туа (3 ир бала, 3есе кыз). Иң өлкәне—Мөхәммәдфатыйх. Шунысы мөһим: Гыйльман мулла үзе, балалары, кияү-киленнәре, оныклары татар дөньясында мөһим роль уйныйлар. Гариф Кәрими (улы; Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге якын көрәштәше), Тимерша Соловьев, Борһан Шәрәф, профессор Әлмира Әминова һ. б.—әнә шундыйлардан.

Ф. Кәриминең әтисе 1899 елда мулла-ахунлыгын калдырып, бөтен гаиләсе белән Оренбургка күчеп килә. Р. Фәхреддин киңәше, Гани бай Хөсәенов ярдәме белән басмаханә оештырып җибәрә. Улы Фатыйх Мәскәүгә һәм Петербургка барып, берничә ай буена наширлек, басмаханә һөнәрләрен үзләштерә. Эшләр көйләнеп кенә килгәндә, 1902 елның җәендә Гыйльман Кәрими фаҗигагә очрый. Аның үлеме кин җәмәгатьчелекне тетрәндерә. Һади Атласи, Гаяз Исхакый, Шакир Мөхәммәдов, Ильяс Бораганский, Галимҗан Баруди, Габдерәшит Ибраһимов, Ярулла Вәли һәм башка күп кенә билгеле затларның кайгынамәләрендә бу шәхеснең эшчәнлегенә югары бәя бирелә, «булдыклы һәм милләтпәрвәр» (Ш. Мөхәммәдов), «милләтнең бөек каһарманы» (Һ. Атласи) булуы искәртелә, аның вафаты зур югалту дип ассызыклана. Ризаэддин Фәхреддиннең Ф. Кәримигә җибәргән хатында мондый

юллар бар: «Сезнең кебек бала варис итеп калдырган ата һич вафат түгел, һәм, гомер дәвам иткәнчә, дөнья торганда, вафат булмас»[1]. Хәнифә бинте Гыйсмәтулла, Гыйльман Кәрими үлгәч, хәтта махсус мәрсия дә яза (69-72 б.). Гыйльман мулланың Исмәгыйль Гаспралы, Ольга Лебедева («Гөлнар ханым»). Әхмәд Мидхәд (төрек әдибе, мәгърифәтчесе. 1844—1913) кебек затлар белән хатлар алышуы, очрашып сөхбәт кылуы мәгълүм. 1881 елда ул хаҗга да бара.

Булачак әдип әүвәл Минлебайда үз әтисендә белем ала. 10 яше тулгач, аны Гыйльман мулла Чистайга, үзе укыган Мөхәммәдзакир мәдрәсәсенә илтә. Биредә Фатыйх 11 ел укый, ике еллап русча да белем ала. (Бу мәдрәсәдә Әхмәтҗан Тубыли, Г. Исхакый, Г. Чыгтай, Х. Фәйзи һәм кайбер бүтән билгеле шәхесләр дә укыган). Чистай мәдрәсәсен тәмамлагач, бераз вакыт Уфада торып ала, имамлыкка имтихан да тота. Әмма яшь егетнең алга таба да укыйсы килә. Әтисе һәм Ризаэддин хәзрәт аның бу теләген хуплыйлар. Шуның нәтиҗәсе буларак, Ф. Кәрими Истанбулга юнәлә. Биредә ул 1892-1896 елларда «Гали мәктәбе мөлкия»дә белем ала. Мәгълүм ки, дәүләт хезмәткәрләре хәзерли торган бу югары уку йорты университет дәрәҗәсендә була һәм бик абруйлы исәпләнә. Ф. Кәрими биредә бик тырышып белем ала. Монда кадәр дә татар, рус, гарәп, фарсы, төрек телләрен һәм әдәбиятларын белгән егет Аурупа рухи казанышларын да ныклап үзләштерә башлый. Әтисенең «күбрәк чит телләрне яхшы белеп кайт» диюен (79 б.) истә тотып, Минлебай егете бик камил рәвештә француз телен өйрәнә.

«Мөлкия»не тәгәлләгәч, Ф. Кәрими 1896—1898 елларда Ялта тирәсендәге бер мәктәптә мөгаллим булып эшли. [Биредә бер кыш аның Гариф һәм Закирә исемле туганнары да абыйларыннан белем ала]. Әтисенең «Кырым татарларының балаларын укытырлык кеше сиңнән башка да табылыр. Үз илендә наданлык бик көчле. Беренче ярдәмне монда бирергә кирәк» дигән хатын алгач, Ф. Кәрими туган авылына кайтып, берничә ай балалар укыта. 1899 елның июль аенда Гыйльман мулла бөтен гаиләсе белән Оренбургка күчеп килә. Ә инде шушы ук елның февраль-май айларында Ф. Кәрими Уралдагы алтын приискасы хуҗаларыннан берсе Шакир Рәмиевнең (Дәрдемәнднең туганы) юлдашы һәм тәрҗемәчесе сыйфатында Мәскәү-Петербург аркылы Аурупага сәяхәт кыла. Аларның сәфәре Берлин, Брюссель, Париж, Милан, Вена, Будапешт, Истанбул, Бакчасарай һәм кайбер башка шәһәрләр аша үтә. Бу сәфәрнең нәтиҗәсе буларак атаклы «Аурупа сәяхәтнамәсе» (1901) туа. Чит илләрдән йөреп кайткач, Ф. Кәрими Габделгани Хөсәенов тарафыннан Оренбург Каргалысында ачылган мөгаллимнәр хәзерләү курсларында укыта. Әтисе вафат булгач, басмаханә эшләре дә аның җилкәсенә төшә. 1903 елның маенда Бакчасарайда «Тәрҗеман» гәзитенең 20 еллык бәйрәм чараларында катнашып кайта һәм шундагы тәэсирләре хакында «Кырымга сәяхәт» исемле сәфәрнамәсен яза (1903).

1906—1917 елларда Ф. Кәрими—Рәмиевләр хисабына Оренбургта чыгарылган «Вакыт» гәҗитенең баш мөхәррире. Мәгълүм ки, бу басма, «Шура» журналы белән берлектә, Октябрьгә кадәр нәшер ителгән татар вакытлы матбугатының йөзек кашы булып тора. Ул халкыбыз арасында гына түгел, бөтен төрки, хәтта мөселман дөньясында да киң тарала. Андагы материалларның шактые баш мөхәррирнең үз каләме белән язылган. Бу елларда һәм гомумән Ф.Кәрими күп төрле җәмәгать эшләре дә алып бара. 1906 елда ул Дәүләт Думасы депутаты Закир Рәмиевнең ышанычлысы һәм ярдәмчесе вазифаларын башкара. Аның төрле иҗтимагый оешмаларда нәтиҗәле эшләве дә мәгълүм. 1917 елда Россия мөселманнар Шурасына да бертавыштан сайлана.

Октябрь инкыйлабыннан соң Ф.Кәрими «Яңа вакыт» (1918), «Эшчеләр дөньясы» (1919), «Юл» кебек гәзитләрдә, халык мәгарифе институтында, мөгаллимнәр хәзерләү курсларында һәм башка урыннарда эшли.

1925 елдан әдипнең Мәскәү тормышы башлана. Биредә ул СССР халыклары Үзәк нәшриятында эшли, тәрҗемәчелек белән дә шөгыльләнә, Көнчыгышны өйрәнү институтында төрек теле укыта. Әмма шуңа да карамастан, Ф. Кәрими башкалада

[1] Шәхесләребез: Фатыйх Кәрими. Фәнни-биографик җыентык (Татар һәм рус телләрендә) Фәнни мөхәррире—Миркасыйм Госманов—К.: Рухият, 200. —48 б. Алга таба бу басманың битләр саны җәяләр эчендә генә күрсәтеләчәк.

кыен шартларда яши. Анын 1902 елдан бирле бергә гомер кичергән, дүрт бала тудырып, икесен (Ибраһим һәм Фәритне) үстергән хатыны Сәйидә ханым 1936 елда үлеп китә. Бу хәлне әдип бик авыр кичерә. Патша чорында да, совет елларында да һәрчак тикшерү астында торган Ф. Кәрими өстендә шәхес культы болытлары тагын да куерып китә. 1937 елның 4 августында ул кулга алына һәм хөкем органнарының 1937 ел, 27 сентябрь карары белән пантюркизмда һәм Төркия разведкасына хезмәт итүдә гаепләнеп, атып үтерелә. СССР Югары суды Хәрби коллегиясенең 1959 ел, 21 декабрь карары нигезендә Ф. Кәрими гаепсез дип табыла һәм тулысынча аклана.

Кыскасы, татар Яңарыш хәрәкәтенен төп вәкилләреннән берсе булган Ф. Кәриминең тормыш юлы катлаулы һәм гыйбрәтле. Ул документаль һәм әдәби әсәрләр, кинофильмнар һәм сәхнә әсәрләре өчен менә дигән материал.

Бу эрудицияле, тирән белемле, талантлы, ораторлык сәләтенә ия затның күпкырлы әдәби, гыйльми, публицистик, тәрҗемәчелек һәм башка күп кенә тармаклардагы эшгамәлләре дә сокландырырлык. Милләткә хезмәт кылу, аны мәгърифәтле, әхлаклы, һөнәрле итү, алдынгы халыклар дәрәҗәсенә күтәрү—Ф. Кәрими эшчәнлегенең арка сөяге, төп рухы, җаны. Ул шушы олуг һәм игелекле максатларга төрле юллар, төрле ысуллар һәм чаралар белән бөтен гомере буе хезмәт итте.

Матур әдәбият Ф. Кәрими эшчәнлегендә мөһим урынны били. Дөрес, анын әдәби әсәрләре артык күп түгел: «Салих бабайның өйләнүе» (1897), «Бер шәкерт илә бер студент» (1899), «Нуреддин хәлфә» (1899), «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы» (1900), «Морза кызы Фатыйма» (1901), «Хыялмы, хакыйкатьме?» (1908) һ. б. Күрәсез: әдипнең хикәя-повестьлары, нигездә, ике гасыр аралыгына карый.

Ф. Кәриминең әдәби иҗаты М. Гайнуллин, М. Гайнетдинов кебек галимнәрнең мәкалә-хезмәтләрендә шактый тулы яктыртылган. Шуңа күрә без бу тема хакында аерым фикерләр әйтү белән чикләнәбез.

Әдипнең хикәя-повестьлары тормышчанлыгы, заманчалыгы белән сыйфатлана. Аларның үзәгендә төрле катлам, төрле холыклы кешеләр. Авторны аеруча халыкның артталыгы, наданлыгы борчый. Иске мәдрәсәләрне, мөгаллим-руханиларны тәнкыйтьләгәндә ул хәтта сатирага барып җитә. Әмма бу уңай белән шунысын да искә төшерик: татарга, гәрчә ул дәүләткә коточкыч күп салымнар түләсә дә, балаларын укытыр, мәктәп-мәдрәсәләрен тотар өчен хөкүмәт бер тиен дә акча бирми. Бар да халыкның үз хисабына эшләнгән. Шул төр уку йортларыннан Фәхреддиннәр, Тукайлар, Исхакыйлар, Кәримиләр тәрбияләнеп чыгуын да онытырга ярамый.

Ф. Кәриминең әдәби әсәрләре арасында һәм эчтәлеге, һәм төзелеше белән аеруча «Хыялмы, хакыйкатьме? бәяне (1908) игътибарга лаек. Анын үзәгендә Дәүләт Думасына сайланган татар депутаты һәм укымышлы, гүзәл татар кызы. Вакыйгахәлләр Петербургта бара. Яшь кыз билгеле бер дәрәҗәдә Р. Фәхреддиннең Сәлимәсен дә хәтерләтә. Ф. Кәрими карашынча, җәмгыятьне камилләштерү, милләтне алдынгы кавемнәр дәрәҗәсенә күтәрү иң беренче чиратта хатын-кызларның тәрбиялелегенә, белемлелегенә, иҗтимагый теләк-омтылышларына бәйле. Әсәрдәге героиня—автор күрергә теләгән хатын-кызларның күркәм бер мисалы. Әмма әле бу төр гүзәл затларның тормышта булуына әдип үзе дә ышанып җитми һәм, мөгаен, шуңадыр әсәрен дә, сорау куеп, хыялмы, хакыйкатьме дип исемли. Ф. Кәриминең узган гасыр башында иҗат ителгән «Морза кызы Фатыйма» бәяне дә үзенең романтик табигате, яшьләрнең олы мәхәббәтен гәүдәләндерүе, шигъри тел-стиле белән бүгенге укучыны да дулкынландырырлык. Бу әсәр алга таба татар әдәбиятында морзалар темасының киң таралуына да этәргеч бирде.

«Аурупа сәяхәтнамәсе» (1901), «Кырымга сәяхәт»/1903)—болар татар язма әдәбиятында кабатланмас (уникаль) ядкәрләр. Ф. Кәрими Исмәгыйль Бикмөхәммәд углы (XVIII йөз), Гали Чокрый, Шиһабеддин Мәрҗани, аеруча Заһир Бигиевнең сәяхәтнамә язу казанышларына таянып, бу жанрны яна баскычка күтәрде, һәр ике язма өчен дә, иң беренче чиратта, синкретизм хас. Бер яктан, алар матур әдәбиятның, сурәтле тел-стильнең күркәм бер үрнәге булсалар, икенче яктан, бу ядкәрләр тарихи, географик, этнографик, сәнгати һәм башка характердагы гаять төрле һәм бай материалларны туплаганнар. Алар киң катлам укучыга башка илләрне, халыкларны, мәдәниятне танып белергә ярдәм итә, дөнья, тормыш турындагы күзаллауларын

баета. Язмаларны укыганда авторнын эрудицияле, күзәтүчән, кызыксынучан булуын, тәрәккыйпәрвәрлеген күреп сокланасың. Бу сәяхәтнамәләр укучыга гыйбрәт, сабак бирә, яшәргә, эшләргә, халкына хезмәт итәргә дәрт өсти.

Авторның «Истанбул мәктүбләре» исемле язмасы да аның сәфәрнамәләре белән табигый керешеп китә. Әмма бу китапта публицистик башлангыч, тәнкыйди пафос көчле. Мәгълүм ки, Ф. Кәрими «Вакыт» гәзитенең һәм «Шура» журналының хәбәрчесе сыйфатында, Балкан сугышларын яктырту өчен, Төркиягә җибәрелә. Биредә аның 1912 елның ахыры—1913 елның башларында 4 ай булуы мәгълүм. Үзенең язмаларын ул очерк-мәкаләләр рәвешендә «Вакыт»ка җибәреп тора. (Барлыгы—70 «мәктүб»). 1913 елда автор аларны бергә туплап Оренбургта «Истанбул мәктүбләре» исеме белән аерым китап итеп бастыра. 453 биттән гыйбарәт булган бу китапта Балкан сугышы, Төркиянең эчке һәм тышкы хәле, халыкара вакыйгалар, аерым татар кешеләренең язмышы гаҗәеп оста итеп яктыртылган. «Истанбул мәктүбләре» хезмәте төрек, рус, венгр галимнәре тарафыннан да югары бәяләнә.

Ф. Кәрими—«Вакыт», «Шура» һәм кайбер башка басмаларда дөнья күргән күп санлы язмаларның, шул исәптән татар, урыс, төрек һ. б. әдәбиятлар хакындагы мәкаләләрнең авторы да. Алар өчен фикри тирәнлек, полемик рух хас. Мәсәлән, ул 1906 елда татар матбугатында башланып киткән «таңчылар» һәм «иттифакчылар» бәхәсендә актив катнаша. Әгәр дә боларның беренчеләре сыйнфый якны үзәктә тотса, иттифакчылар вәкиле Ф. Кәрими—милли бердәмлек тарафдары. Ул үзенең бу еллардагы оппоненты Г. Исхакый белән тигез дәрәҗәдә, кыю рәвештә бәхәсләшә. Ахыр чиктә, мәгълүм булганча, «Инкыйраз» авторы да милли бөтенлек сафына әйләнеп кайта.

Ф. Кәрими язмалары, бигрәк тә аның әдәби әсәрләре хакында сүз барганда, авторны госманлы теле элементларын мул куллануда тәнкыйтьлиләр. Биредә өлешчә хаклык та бар. Әмма мәсьәләнең икенче ягын да онытырга ярамый. XIX гасыр ахыры-XX йөз башы әдипләренең шактыенда (шул исәптән М. Акъегетзадә, Р. Фәхреддин, хәтта Г. Тукайда да) төрек теле алынмаларын күпләп очратырга мөмкин. Бу—бер. Икенчедән, Ф. Кәрими әдәбиятка нәкъ менә Истанбулда укуын тәгәлләгән елларда килеп керә. Аның әдип буларак формалашуында госманлы әдәбиятының һәм төрекчәгә күчерелгән Аурупа сүз сәнгатенең дә роле зур. Бу чор татар укучыларының күпчелеге госманлы, гарәп, фарсы телләреннән хәбәрдар булган. Ә инде гомумән тел-стиль мәсьәләсендә Ф. Кәрими—гаять оста әдип. Аның әсәрләрендә, шул исәптән сәяхәтнамәләрендә дә хикәяләү һәм тасвирлауның, сурәтлелекнең, хәтта шигърилекнең гаҗәеп матур үрнәкләрен күпләп очратырга була. Мәсәлән, автор Кулон шәһәр бакчасында ял итеп йөрүче алман кызларының гүзәллеген сурәтли дә, болай дип өсти: «Мәләк кеби, канатланып, һавага очып китмәсәләр ийе,—дия, калебләргә курку киләюр». («Морза кызы Фатыйма» китабы.—К., 1996.- 223 б.). «Нуреддин хәлфә» хикәясендә пейзажны тасвирлаган өлештә мондый юллар бар: «Яна ачылмалы чәчәкләрнең хуш исләре илә һәр якны хәтфә палас кеби каплаган ямь-яшел чирәмнәрнең күренеше фәүкыльгадә (гадәттән тыш.—Х. М.) ләтыйф вә гүзәл иде. Буйлә бер заманларда һәр кешенең табигате хөрләнеп, күнеле нечкәрә, кайгы вә хәсрәтләре онытылып, хыял вә өмидләре артадыр» («Морза кызы Фатыйма», 67 б.).

Татар Яңарыш хәрәкәтенең күп кенә вәкилләре кебек, Ф. Кәрими эшчәнлеге дә мәгариф, педагогик процесс белән тыгыз бәйләнешле. Әйткәнебезчә, ул туган авылында, Ялтада, Оренбургта, Мәскәүдә мөгаллим булып та эшли. Шулай ук бу мөхтәрәм зат, укытучы һәм укучыларның, мәгариф челтәренең ихтыяҗларын күздә тотып, төрле фәннәрдән дәреслек-әсбаплар да яза: «Мөхтәсаре җәгърәфия» (1899), «Мөгаллим вә мөрәббиләргә (тәрбиячеләргә. —Х. М.) рәһнамә (белешмәлек. Х. М.)» (1902), «Мөхтәсаре тарихе гомуми» (1911), «Мөхтәсаре тарихе ислам» (1913), «Тарихел-әнбия» (1913) һ. б. Болар күп мәртәбәләр кабат та басылып чыга. Нашир буларак, Ф. Кәрими чыгарган китапларның да күпчелеген уку-укыту әсбаплары, балалар әдәбияты тәшкил итә. Гомумән, ул язма истәлекләрне барлау, өйрәнү һәм бастырып чыгару юнәлешендә гаять нәтиҗәле гамәлләр кыла. Бу төр эшчәнлеген ул Октябрьдән соң да дәвам иттерә. Мәсәлән, Дәрдемәнднең 1929 елгы шигырьләр

жыентыгы Ф. Кәрими катнашында дөнья күрә. Шушы ук елларда ул Акмулла һәм Дәрдемәнд хакында махсус мәкаләләр дә яза.

XX йөз башы татар рухи тормышы үсешендә тәрҗемә әдәбиятның да роле зур. Бу төр басмалар халкыбызның күңел офыкларын киңәйтте, белем-мәгълүмати ягын тирәнәйтте һәм башка кавемнәрнең гыйльми-мәдәни казанышларын турыдан-туры үзләштерүгә юл ачты. Бу дәвер тәрҗемәчелек эшчәнлегенең үзәгендә дә Ф. Кәрими торды. Аның урыс, төрек, француз һәм кайбер башка телләрдән тәрҗемә ителгән гаять күп санлы һәм күп төрле язмалары, китаплары йөзәрләгән мең татар укучысының күңел хәзинәсенә әверелде. Ул, мәсәлән, поляк галиме Ф. Ф. Пуцековичның дөнья халыклары (гарәпләр, инглизләр, греклар, афганлылар, американлылар, итальяннар, кытайлылар, финнәр, төрекләр, японнар... барлыгы 26 төрле кавем) хакында язган брошюраларын татарчага тәрҗемә итеп, 1905-1912 еллар арасында Оренбургта нәшер итте. Ф. Кәрими татарчага күчергән ядкәрләр арасында В. Бартольдның «Төркестан тарихы», Сами бәк Шәмседдиннең «Хатыннар»ы кебек мәшһүр китаплар да бар.

Ф. Кәрими, агасы Ризаэддин хәзрәт кебек, куллаган каләм әһелләренең иҗади үсешендә дә мөһим роль уйнады. Ул җитәкләгән нәшриятта, «Вакыт» гәҗитендә басылган күп санлы әдәби әсәрләр—шуның күркәм бер гәүдәләнеше.

Кыскасы, Фатыйх Кәрими татар рухи тормышында тирән эз калдырган, халкыбызның алгарышына зур өлеш керткән мөхтәрәм зыялы. Аның шәхесе, эшчәнлеге хакында әйтелгән мөһим фикерләр бар. Шуларның кайберләрен китереп үтик:

*Дәрдемәнд (1911):*

«Фатыйхка тугры сүз, төпле фикер, хакыйкать, халыкка мәхәббәт, яшьләрне дөньяга тугры карашлы итеп үстерү, киләчәккә өмет белән карау ... [хас]... Бөек адәмнәрдә..., чын әдипләрдә генә була торган сыйфатлар Фатыйхта» («Фатыйх Кәрими» жыентыгы, 2000.—94 б.)

*Галимҗан Баруди (1902):*

Фатыйх «сабыр һәм сәбат (нык торучан, тотнаклы.—Х. М.) егет» (59 б.)

*А. Вамбери (1906, Будапешт):*

«Редактор «Times»—высокообразованный и культурный человек татарской национальности Мухаммедфатих, который поставил целью приобщить своих земляков к современной цивилизации, в особенности, подготовить татарскую общественность к понятиям свободы и конституционного права» (С. 176).

*Садрый Максуди (1911):*

«Фатыйх әфәнде–безнең милләт мәйданында хезмәт иткән каһарманнарның берсе» (182 б.).

*Шакир Мөхәммәдьяров (1956):*

«Бөтен-бөтенәнә Фатыйх әфәндене башкалардан аерып тора торган махсус хасиятләр бар иде. Бу «Фатыйх Кәримилек»—нәзер культура, һәркем тарафыннан сөекле нәзакәт белән бергә туры әйтүчәнлеге, эшкә реалистик карашы, ару-талуны белми торган эшчәнлеге, сөбатлыгы (ныклыгы.—Х. М.)... Фатыйх әфәнде турында никадәр генә язсак та—аз» (92-93 б.).

*Г.Сәгъди (1926):*

«... бу мөхәррир (ягъни Ф. Кәрими.—Х. М.) әдәбият һәм матбугат эшендә бик киң куллы, күп җимешле,үз заманы өчен күп файдалы һәм чиксез энергияле, зур хәзерлекле бер каләм булды» ( 180 б).

***

Әдипнең кече ватаны Миңлебай авылында узган гасыр ахырларында Ф. Кәрими музее да эшли башлады. Аны оештыруда, материал-экспонатлар белән баетуда мөгаллим Мөдәррис ага Ибраһимов фидакарьләрчә эш башкарды.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ**



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

Илдус
Хуҗин

## ЯҢА РОБИНЗОННАР

—Йә-йә! Нинди план туды башыңда?

—Безгә аларның су юлларын ябарга кирәк. Банданы утрауда бикләргә.

—Ничек итеп?—дип аптырадылар егетләр.

—Элементар рәвештә. Минем шартлаткыч пакетлар, динамит бар. Бик куәтлесе.

—Кайда ул?

—Көймәдә. Болай итәбез...

Кәефләре күтәрелгән эзтабарлар Расихка хәбәр иттеләр дә көймә янына ашыктылар. Ул аларны элекке урында көтә иде.

### Виктория!

Төнне «Виктория»дә уздырып, иртәнгә таба лагерь ягына таба юнәлделәр. Катерларның тарлавык буйлап диңгезгә чыга торган җиренә барып җиткәч тә, шәмсыман пакетларны бергә бәйләп,аңа бикфорд шнуры беркетеп һәм шнурның бер очына ут төртеп,бау белән кыя астына төшерделәр. Аннан соң ашыга-ашыга лагерьның үзе янына киттеләр. Әле иртәнге эңгер-меңгер,бөтен нәрсәнең соры булып күренә торган чагы иде.

—Биш минуттан җиде тула,—дип пышылдады Фәрит.—Ярый ла Расих вакытында эшне башкарса.

—Эшләр!—диде Идрис.—Менә күрерсез,нәкъ җидедә шартлатачак.

Сәгать җидегә җитте. Читлекләреннән чыгардай булып типкән йөрәкләрен көчкә генә тыеп яткан егетләр утрауның башта теге ягында, аннан соң лагерьдан ерак түгел бу читендә шартлау һәм таулар җимерелгәндәй дөбердәү ишеттеләр.

Аста пиратлар яшәгән мәгарәдән коралды кешеләр атылышып чыга башладылар. Колларны кире үз тау куышларына куалап керттеләр. Пиратларга кемдер боерыклар бирә башлады.

—Чен!—Хәсән белән Фәрит бер үк вакытта бер-беренең кабыргаларына төрттеләр.

Өч-дүрт кеше якындагы катер янына йөгерделәр һәм аңа утырып диңгез ягына ашыктылар. Кайдандыр озын-озын баскычлар китереп,кораллы кешеләр өскә үрмәли башладылар. Ул арада катер кире килде һәм аста тагын кычкырыш башланды. Өч дус елмаешып бер-берсенә караштылар: «Аңлашыла,янәсе,юл ябык».

Ул арада егермеләп кеше гаҗәеп тизлек белән өскә үрмәләп менеп, төркемләп-төркемләп төрле якка китеп югалдылар.

—Расих, саклан!—диде трубкага Фәрит.—Көймәңне төпкә батыр! Ун

*Дәвамы. Башы 1 нче санда.*

минуттан лагерь турысына кил һәм безне көт!

—Хәсән!—дип пышылдады Фәрит.—Лагерьда ничә кеше калды, дип уйлыйсың.

—Сакчыларны алып,өскә мендерделәр. Ченның үзе янында бер кеше күренә. Әнә алар мәгарәгә керделәр. Тоткыннар ишеге янында тагын берәү булырга тиеш. Ул аларның ишеген йозаклап маташа иде. «Егетләр! Йә баш, йә мал! Киттек!!»—дип, бауга ябышып Хәсән аска очты. Идрис белән Фәрит аңардан калышмадылар. Егетләрнең уч төпләре утта тоткан кебек янды,ләкин алар моңа әһәмият бирмәделәр. Менә алар төшеп җиттеләр һәм Чен керган тау куышы янына килделәр. Эчтә тавышлар ишетелә иде.

—Хәзер берсе чыга,—диде Хәсән тегеләрнең кытайча сөйләшүләрен аңлап.—Чыгуы белән тегенең башыга сугам да,икебез эчкә керәбез. Син,Идрис,аның коралын ал да монда тор.

Шул ук секундта пират атылып килеп чыкты һәм башына пистолет сабы эләгеп, җиргә ауды. Мондагы тавышны ишетеп, автоматын атарга әзерләгән тагын бер бандит күренде. Җирдә яткан иптәше өстенә иелгәч,яшеренеп торган егетләрдән анысы да «күчтәнәч» алды. Шул ук секундта Фәрит белән Хәсән мәгарәгә атылып керделәр. Ә анда!.. Арткы планда граната тоткан кулын югары күтәреп,Чен тора.

—Әһә! Алдыгызмы мине!—диде ул инглизчә һәм шаркылдап көлде. Шул ук вакытта бер яктарак яткан автомат янына елышырга тырышты. Хәсән тиз генә өстәл янына ташланды һәм автоматны кулына төшерде. Ике дус Чен гранатасын шартлатыр,дип көтте,ләкин ул янаудан узмады.

—Автомат сезгә ярдәм итмәс!—дип кычкырды бандит.—Барыбер сезгә үлем! Хәзер минем кешеләрем бары да монда киләчәк. Мине атсагыз,үзегез дә үләчәксез. Сез бит әле яшь башлыйсыз гына,миннән күпкә яшь әле сез. Сезгә котылу юк! Бирелегез мөмкинлек бар чакта. Шуннан карарбыз,бәлки,исән дә калдырырмын. Миңа нәрсә,мин инде яшәдем,шәп яшәдем...

—Ә без хәзер тикшереп карыйбыз,тормыштан туйдың микән!—дип,пистолет тоткан Фәрит ата бандитка таба бара башлады. Бу мизгел бөтен операциянең кульминациясе булды. Безнең егетләргә кызны да, үзләрен дә коткару өчен башка юл юк икәне яхшы аңлашыла иде. Вакыт алар файдасына эшләми иде шул. Әмма хәвеф-хәтәрнең масштабын белмәгән Чен моны аңламый иде ахрысы. Ул һаман боларны куркытмакчы була, үзенә таба елышучы Фәриткә: «Килмә! Килмә! Шартлатам!—дип акыра.

—Юк! Шартлатмыйсың! Синең кебек кеше канын кызганмаган җанвар бик куркучан була. Ә менә безнең сүзне тыңласаң,чыннан да исән каласың.

Фәрит Ченны таш кыяга постырды,Хәсән дә автоматын аның корсагына терәде.

—Сезгә ни кирәк!—дип хырылдады Чен.

—Менә монысы акыллы сүзләр!—дип, Фәрит аның кулына үрелде.—Бир гранатаңны,юкса ялгыштан шартлап куюы бар. Яхшылык белән килешик!

Фәрит Ченның кулыннан гранатаны алып,идәндә яткан чеканы кире урынына тыкты һәм куркынычсызландырылган коралны кесәсенә тыгып куйды.

Шуннан соң атаманга Алсуның фоторәсемен күрсәттеләр,һәм аңа катгый рәвештә әйтелде:

—Шушы кызны биреп,безне диңгез ярына озатып куйсаң,тере калачаксың! Чен өчен бу зур югалту түгел иде,шуңа күрә ул:

—Шул гынамы?—дип сорады.—Мин сезгә ышанмыйм. Сез китүгә полиция килеп төшмәсме? Гарантия бирәсезме?

—Ансы аларның үз эше,—диде Хәсән.—Син шуны аңла: синең бездән котылырга шансың—кызны биреп җибәрү,полициядән котылу—икенче планда.

—Сезгә дә котылу юк!—дип акырды бандит.

—Чен!—диде Хәсән тегенең чигәсенә пистолет терәп.—Безнең вакыт аз икәнне яхшы беләсең. Сине хәзер үк үтерсәк, безнең әле шанс кала. Өчкә чаклы саныйм,бер...

—Яхшы!—диде Чен.—Кызны монда ничек китерергә уйлыйсыз?

Фәрит кычкырып Идрисне чакырды һәм ишек алдында калган сакчының хәлен сорады.

—Аңына килде,ләкин кул-аягы бәйләнгән.

—Син аны чиш тә монда керт. Чен! Әйт үзеңнең бандитыңа: кызны монда китерсен! Кара аны! Андый-мондый хәл чыкса,беренче пуля үзеңә! Идрис! Син тышкы якта торчы,ул-бу булмагае.

Җиде-сигез минуттан мәгарәгә Алсу килеп керде. Йөрәге атылып чыгардай булып типкән Фәрит егылып китә язды. Ул кызның котычкыч ябыккан булуына да, битләрендәге кутырга да,мунчала рәвешенә кергән чәчләренә дә,өстендәге ертылып беткән сәләмәләргә дә игътибар итмәде: исән бит,менә ул каршыда аптыравыннан һәм дулкынлануыннан һушыннан язып,идәнгә ава башлады,аны Хәсән тотып калды.

—Фәрит!—диде кыз, ниһаять, зәгыйфь тавыш белән.—Син дә монда килеп эләктеңмени?

—Юк, Алсу! Мин сине алырга килдем. Синең атларга хәлең бармы?

—Бар. Кая барабыз соң?

—Өйгә кайтабыз, Алсу!

—Өйгә?!—кыз тагын аңын югалтты.

Хәсән Ченны катгый рәвештә кисәтә башлады:—Син хәзер үзең безне яр буена озатып куячаксың. Берәр ахмаклык эшләсәң,эре калибрлы пулялар синең эчеңдә булачак. Әгәр синең кешеләрең безгә ата башласа, иң беренче пуля синеке. Әйдә, атла!

Мәгарәдән иң алда Чен чыкты. Аның артыннан Хәсән һәм бераз тынычлана төшкән Алсу атлады. Идрис белән Фәрит тирә-якка карангалап, арттан бардылар.

Фәрит аппараттан Расихка дәште: тегесе аларны кирәкле урында көтә иде инде.

Процессия баскыч янына якынлашты. Ике коралы бандит Ченның боерыгы буенча коллар яшәгән мәгарәгә керделәр.

— Алар калган тоткыннарны үтерергә кермәделәр микән?—дип сорады Идрис Фәриттән татарчалатып.

—Юктыр, дип уйлыйм,—диде Фәрит.—Ул әле безнең бөтен планнарны белми бит.

—Әй-әй!—диде Чен,—ни сөйлисез анда, нинди телдә?

Баскычтан тоткарлыксыз гына менделәр дә,диңгез ягына юнәлделәр. Бу урында диңгез яры ерак түгел иде,менә инде алар аска төшә торган яшерен сукмакка да килеп җиттеләр. Шул вакытта утрау ягыннан ике төркем пиратлар килеп чыкты. Хәсән пистолеты белән Ченның аркасына төртте:—Әйт, килмәсеннәр!

Чен тегеләргә нәрсәдер әйтте һәм бер төркем каядыр йөгереп китте. Икенче төркем баскыч янына китте.

Чен кешеләренә иптәшләрен җыеп монда килергә кушты. Икенче төркемне яшерен катер алып килергә җибәрде.

Ул арада барысы да диңгез буена җиттеләр. Аларны инде яр буена ук килеп туктаган Расих көтә иде.

Алсуны арткы буш урынга утырткач, Хәсән иптәшләреннән:

—Бу ерткычны нишләтәбез?—дип сорады.

—Хәсән! Син бит безнең кан түгәргә теләмәгәнне беләсең,—диде Фәрит.

—Соң шундый канэчкечне тере калдырыйкмыни?

Чен үзе турында сүз барганны аңлап,җиргә тезләнде:

—Үтермәгез! Сез сүз бирдегез! Мин сүземдә тордым!

—Хәсән! Әйдә,утыр урыныңа,—диде Фәрит.—Әй,Чен! Утраудагы кешеләрне юк итсәң,сине беләсеңме нәрсә көтә?

Көйменең капкачы ябылгач ук, Чен кычкыра-кычкыра яр башына таба йөгерде:

—Килегез монда, хайваннар! Кайда йөрисез! Җибәрмәгез, атыгыз! Кайда ракета?

Тау башында автоматлар тоткан ун-унбиш пират күренде,ләкин «Виктория» иң зур тизлегендә Сингапурга таба юл алган иде инде. Ярдан очкан пулялар аның өчен берни түгел иде.

## Өйгә!

Соңгы сәгать эчендә булып үткән искиткеч вакыйгалардан соң әле чак тынычлана башлаган Алсу егетләр белән танышырга тотынды. Ул үзе алар белән сөйләшә,

үзе елый, үзе көлә. Кызның шатлыгы эченә сыймый, тышка бәреп чыга. Алсуга карап егетләрнең дә күзләре чыланып ала, ләкин алар күз яшьләрен яшерәләр.

Кыз бераз тынычлангач, Фәрит аңа бөтен нәрсәне бәйнә-бәйнә сөйләп бирде: ничек яңа шәһәргә күчкәнен, анда Расих һәм Идрис белән танышканын һәм Сингапурда Хәсәнне очратуын һәм ничек пиратларны җиңүләрен.

—Син инде икенче шәһәрдә торасыңмыни?

—Әйе! Мин анда көллияттә укыймын.

—Алай булгач, мин дә шунда керәчәкмен, минем шундый егетләр белән буласым килә.—Ә син, Хәсән, Сингапурга кайчан килеп урнаштың?

—Мин монда туып-үскәнмен, Алсу туташ!—диде Хәсән.

—Монда-а-а? Ә үзең туган телне шулай яхшы беләсең! Ә менә мин, күрәсеңме, ничек начар сөйләшәм? Миңа синең алда шундый оят. Әле бер ел эчендә азрак өйрәнә төштем. Аптырамагыз, чыннан да шулай. Юк, анда бер татар кешесе дә юк иде. Ләкин мин әти-әниемне сагынып, дусларым, өемне юксынып, үз-үзем белән гел татарча сөйләшеп йөрдем. Инде өемә кайтсам, әти-әниемә бер сүз дә русча эндәшмәм дип сүз бирдем. Әллә инде Алла шуны ишетте...

Шулай итеп өч-дүрт сәгать буе кызның күңелен күргәч, ул йоклап китте. Егетләр үзләрен борчыган темага күчтеләр.

—Йә, дуслар!—диде Фәрит.—Пиратларны нишләтәбез? Миңа калса, аларны тоттыру кирәк.

—Дөрес,—диде Идрис.—Һәм бу эш тиз дә, ышанычлы да башкарылсын. Хәсән, синең полициядә танышларың юкмы?

—Бар. Ул минем якын дустым. Ләкин ул кече офицер гына.

—Бу бик әйбәт ич!—дип шатланды Фәрит.—Шуның аша эш итәргә кирәк!

—Ул әлләни майтаралмас. Ә менә халыкара полиция белән бәйли алырга тиеш безне.

Егетләр бу турыда әле озак киңәшләштеләр.

Көн кичкә авышты. Озакламый Сингапур да күренергә тиеш иде.

—Хәсән!—диде Идрис.—Син безгә кунакка килерсеңме?

—Әлбәттә, дуслар! Ул турыда һич тә шикләнмәгез. Бабам белән икәүләп килербез.

—Ә яшәргә калыр идеңме бездә?

Хәсән бераз уйланып торды да:

—Хәзергә әйтә алмыйм,—диде. Шуннан соң ул дулкынланып, тагын кулына радиотелефонын алды. Ул аның йә дулкынын үзгәртә, аннан сон колагына куеп карый иде. Кинәт трубка шытырдап куйды һәм кемдер нәрсәдер әйтте. Аптырап калган Хәсән җавап бирде.

—Кем ул, нәрсә сөйли, нинди телдә?—дип сорады Фәрит.

—Сингапурның сигезенче округының полициясе. Ни җавап бирим?—дип сорады бер мәлгә аптырап калган Хәсән.

—Әйт, танышыңны тапсыннар!—диде Фәрит.—Инглиз телендә, мөмкин булса. Аппарат тагын сорау бирде.

—Тыңлагыз мине!—диде Хәсән нык тавыш белән.—Мине лейтенант Сурранга белән тоташтырыгыз! Бик мөһим хәбәрем бар. Аңа гына әйтергә тиешмен.

Өч-дүрт минуттан трубкадан ишетелде:

—Бу мин, Сурранга. Кем сорый мине.

—Сури! Бу мин, Хәсән. Хәерле кич!

—Хәерле кич, Хәсән! Син кайдан?

—Соңыннан, дус! Син «Меконг»ны талаганнарын ишеттеңме?

—Әлбәттә, ишеттем. Анда бит безнең ил кешеләре дә байтак булган. Бу җәһәттән бик зур тавыш кубып тора әле. Зур көчләр белән эзлиләр, ләкин әлегә нәтиҗәсез. Пиратлар турында берәр мәгълүмат биргән кешегә ишле генә бүләк тә вәгъдә ителде. Син ни өчен бу турыда сорыйсың?

—Алай булгач, дус, яздыр минем тавышны. Мин сиңа рәсми рәвештә хәбәр итәм. Син әзерме?

—Тукта. Хәзер роликны җибәрәбез. Булды, башла!

— Мин, Сингапурда даими яшәүче Хәсән Фәхри, шуны белдерәм: әле генә «Меконг» теплоходын талаган банда Анамбас утраулар төркеменең иң аргы кеше яшәми торганында качып ята. Пиратларның саны, якынча, егерме биш-утыз

кеше. Аларның башлыгы—Чен. Барысы да кораллы: автоматлар,пистолетлар,якын дистанциягә ата торган ракеталар. Пиратларның өч катеры бар,ләкин алар диңгезгә чыга алмый: юллары ябык. Хәер инде алар юлларын әрчеп маташалардыр.

Алардан башка янә ике бандит шуннан берерәк кечкенә утрауда көтеп утыралар. Пиратлар иллегә якын кешене тоткын итеп,үзләренә эшләтеп яткыралар. Алар төрле иллардән. Берсе,Россия гражданкасы,безнең тарафтан азат ителде. Утрауда СПИД бар,шуңа күрә Чен лагерьны юк итәргә җыена. Әлбәттә,кешеләре белән бергә. Тоткыннар торган мәгарәгә шартлаткыч салынган.

Соңгысы. Утрауның координатлары: төньяк киңлек буенча—дүрт градус уналты минут,озынлык буенча—йөз дә сигез градус ноль дүрт минут. Бетте!

—Ух си-и-н!..

—Сурранга!—диде Хәсән аны бүлдереп.—Без кайтуга,безне журналистлар каршы алмаслар,дип ышанам.

—Операция бик яшерен үткәреләчәк. Сау бул,Хәсән. Йөгердем түрәләрне сөендерергә.

—Сури! Миңа хәбәр итәргә онытма.

—О кей!

Бер сәгатьтән соң дуслар Таһир бабайның өендә иде инде. Аларны күргәч, Алсуның котылганын да белгәч,картның башы күккә тия язды.

—Унбиш яшемне алып ташладылармыни!—дип көлде ул тагын чәй янында.— Эчегез,эч! Аннан соң улым Хәсән белән берәгәйлерәк ризык җитештерербез. Сөйләгез инде,ничек булды?!

Аның өчен дә,кыскача гына итеп булса да,тагын бер мәртәбә булган хәлләрне бәян итеп чыгарга туры килде.

—Һай,егетләр икәнсез! Бик рәхмәт! Менә шулай! Менә шулай гына кирәк!— дип кинәнде бабай.—Һәр татар баласы өчен шулай көрәшегез,берсе дә юкка чыкмасын,югалмасын! Милләтебез артсын,күтәрелсен! Әйтегез анда,Казанда, дөньяда булган һәр татар кешесенә барып җитсеннәр,һәрберсен исәпкә алсыннар, һәркайсының мәнфәгате турында кайгыртсыннар! Шул чакта гына милләтебез сакланып калыр,ишәер. Әйтегез шуны хөрмәтле Минтимер әфәндегә...

—Ашагыз, балалар, эчегез! Оялма, кызым!—дип Алсуның аркасыннан сөйде карт. Кызның шундук күзләре яшь белән мөлдерәмә булды.

Кунакчыл бабайның өендә яшьләр рәхәтләнеп ял иттеләр,иркенләп йокладылар. Таһир бабай аларны тагын бер көнгә калырга күндерде. Үзләренең дә пиратларны тоту ничек үтәр икән,дигән сорауга җавап көтәселәре килә иде.

Кичкә таба телефоннан Хәсәнне сорадылар. Бу Сурранга иде.

—Котлыйм,Хәсән! Синең мәгълүматларың төгәл булды. Мине дә алдылар бит операциягә. Барысын да әләктердек,тоткыннар коткарылды. Калганын соңыннан сөйләрмен. Сүз уңаеннан әйтим,иртәгә сине полиция департаментына чакырырга тиешләр. Синнән сый!—дип трубканы куйды.

Таһир бабай өендә тагын шатлык булды. Төн уртасына кадәр йоклый алмадылар. Ә иртәнге сигездә Хәсәнне полиция участогына чакырдылар. Өйдә аны түземсезлек белән көттеләр. Ниһаять,авызы колагына җиткән Хәсән шаулап-гөрләп дуслары янына килеп керде. Иптәшләре шунда ук аңа ябырылдылар, нәрсәләр булганны сөйләргә куштылар.

—Бездән хәбәр алгач ук,—дип сөйләп китте Хәсән,—полиция Индонезия властьлары белән бәйләнешкә кереп, тиз генә берләшкән отряд оештырганнар. Махсус әзерләнгән кешеләрдән торган бу группа вертолетлардан утрауга төшкәннәр һәм артык кыенлык күрмичә генә барлык пиратларны да тотканнар. Үлүчеләр булмаган, тик берничә кеше җиңелчә яраланган. Бандитлар, качарга катерлары булмагач,бик тиз корал ташлаганнар. Тоткыннарга да тимәгәннәр. Әлбәттә,качып китү мөмкинлекләре табылса,ул мескен бәндәләрне юк иткән булырлар иде.

Утрауда берничә ел буе талап җыелган байлык табылган. Ул су юлы белән бара торган мәгарәдә булган. Корабларны талау белән алар күптән маташалар икән.

—Яхшы,Хәсән!—диде Фәрит.—Пиратларны тоттыручыга күпмедер бүләк тә вәгъдә ителгән,дип әйтте бит синең дустың?

—Әйе,дөрес! Моны таланган пассажирлар җәмгыяте бүлгән булган. Менә ул сумма, биш миллион доллар, һәм без моны бишкә бүләбез. Алыгыз! Сез моңа лаеклы.

Егетләр дә, Алсу да акчадан баш тартып караганнар иде, ләкин Хәсән авыз да ачтырмады, ә кызга болай диде:

—Ә сез, Алсу, миллиард бирсәләр дә, күргән газапларыгызны каплый алмас идегез.

Көннең калган өлеше шатлык эчендә узды. Ә кич белән Фәрит:

—Егетләр! Кызлар! Иртән таң белән юлга чыгарга кирәк бит, азрак ял итеп алыйк—диде.

—Сер булмаса, әйт, Фәрит,—дип сорады Хәсән,—сез кая җыенасыз? Һәм, гомумән, ничек Россиягә кайтырга уйлыйсыз?

—Сер түгел. Без туристлар буларак махсус төркем белән килдек бит. Аннан соң алардан качтык. Ә группа автобус белән Малайзияга күчәргә тиеш иде. Аннан соң тагын каядыр икенче илгә. Экскурсияне дәвам итәргәме, юкмы, без әлегә үзебез дә белмибез. Ләкин безнең анда әйберләребез, кирәкле нәрсәләребез калды. Безгә аларны куып җитәргә кирәк һәм безне китергән самолет белән бер атнадан илгә кайтырга. Алсуны, ничек булса да, үзебез белән алып кайтырга тырышырбыз.

—Минем бик яхшы тәкъдимем бар,—диде Хәсән.—Әйдәгез, Алсуны бимазалап йөртмик, Россиягә иртәгә ук самолет белән озатыйк. Ярты тәүлектә өенә кайтып җитсен.

—Акыллы сүзләр!—диде Фәрит.—Ләкин син бит беләсең: аның хәзер бер документы да юк.

—Ә паспорты булса, алдан кайтарырга күнәр идегезме?—дип сорады Хәсән, хәйләкәр елмаеп.

—Күнмиләрме соң!—дип бертавыштан кычкырдылар егетләр.

—Ә сез, Алсу туташ,—дип кызга карады Хәсән,—каршы килмәс идегезме?

—Егетләр ачуланмаса, мөмкинлек булса, хәзер үк очар идем.

—Бер! Ике! Өч!—дип, Хәсән эчке кесәсеннән кызның паспортын, круиз путевкасын һәм башка кәгазьләрен китереп чыгарды. Алсу тагын, күңеле тулып, балавыз сыгып алды.

—Әллә нишләдем соңгы вакытта,—диде ул күз яшьләре аша елмаеп,—бигрәк нечкә күңеллегә әйләндем...

Иптәшләренең соравына Хәсән болай җавап бирде:

—Чен яшәгән мәгарәдә бик күп тоткыннарның кәгазьләре сакланган булган. Пират аларны туганнарыннан акча таләп итү өчен файдаланган. Миңа Алсу туташныкын тиз генә кулга төшерергә Сурранга ярдәм итте.

Саубуллашу минутлары килеп җитте. Егетләргә Таһир бабай һәм Хәсән белән аерылышу бик тә авыр булды. Хәсәннең зур ярдәме тиган өчен генә түгел, кайдадыр еракта, җирнең читендә яшәгән милләттәшләр белән рухи бәйләнеш, хәтта ниндидер туганлык хисләренең күңелләрнең кай төшендәдер качып кәтеп кенә яткан сыман шундук пәйда булуы барысын да сөендерде һәм шул ук вакытта аерылышу газабына салды. Алар киләчәк очрашулар турында бер-берсеннән ныклы вәгъдәләр алып үз юлларына киттеләр: Алсу самолет белән Россиягә, егетләр турист иптәшләрен куып җитәргә.

## Соңгы сүз

Өч дус туган илгә бер атнадан кайтып төштеләр. Аэропортта лайнердан төшү белән үк берни көтмәгән егетләрне ниндидер кешеләр төркеме алкышлар, фото һәм телеаппаратлар белән каршы алды. Ләкин алларына шат йөзле Алсу килеп баскач, бар да аңлашылды.

—Алсу! Без болай сөйләшмәгән идек, нигә кирәк безгә мондый тавыш куптару!—дип шаяртты Фәрит.

—Тимә, тимә!—диде аңа каршы Идрис.—Әле кайчан тагын безне болай хөрмәтләрләр иде.

—Дөрес! Молодцы! Ура-а-а!—дип уч чаптылар Алсу артында торган егетләрнең ата-аналары, дуслары, классташлары һәм бик күп башка кешеләр. Без дә аларга кушылыйк, дуслар!

## *Кайтаваз*

### Әйтергә микән? (№ 1)

Арча Ләйсәненә Интернет җавапларын мин дә зарыгып көттем. Чөнки инде студент (студентка түгел!) булсам да (1курс), үзем дә Ләйсән хәлендәмен. Группабыздагы ...гә күзем төште. Җибегән малай булмасам да, әйтергә куркам, чөнки ул матур гына түгел, кыю кыз да. Киемнәре дә модный һәм кыю. Ул бөтен нәрсәне дә башкача аңлыйдыр кебек.

«Интернет апалар», сез ниләр генә язып бетермәгәнсез, ләкин анда «Әйтергәме?»гә җавап кына юк. Боларны укыгач, Ләйсән үзе дә, их, монысын да бозаудан гына сораган булсамчы, димәде микән? Сез матур әйберләр дә язгансыз, ләкин болар бүтән замандагылар бит. Мәхәббәт хәзер андый түгел бугай шул. Берәр атна гына булса да студент общежитиесендә яшәп карасагыз иде сез. Татарча «тулай торак» була бит инде. «Тулай ятак» түгел микән дип шикләнәм.

Мин кышкы семестрдан соң общежитиедән киттем. Туганнарымда яши башладым. Чөнки, анда калсам, минем хыялларым пыр итеп сүнәчәк иде...

Кыю мәхәббәт мәхәббәт була микән ул?

Мин ...не хәзер аудиториядә генә күрәм инде, һәм монда мина аның йөзе дә, тавышы да матуррак булып тоела...

Мин нәрсәнедер белмим, нәрсәнедер аңлап җиткермим бугай, ләкин мина безне киләчәккә алып барган көймәнең җилкәне ак түгелдер кебек тоела.

**Мансур.**

---

## *Интер-кайтаваз («WWW. matbugat. ru»дан)*

### «Әйтмәскә!» (№ 2)

Шамил Г. маладис, смайлик китми, бир бишне, диган. Чын җегет. Мәхәббәт турында вуз дипломы куенга кергәч кенә сөйләшә башларга кирәк. Тик бу кызларны пәрәнҗә белән каплаганда гына мөмкиндер. Шулай да дөрес, нык бул шулай. **Иркә**

«Мәхәббәт ул тилертә торган чир генә!»,—ди Шамил. Тик шушы чир белән чирләми калган берәү дә юк! Кирәк ул чир, тормышның мәгънәсе. Тик, закон подлости, димме инде, берәүгә мәхәббәт тотасың, ә икенче берәүгә кияүгә чыгасың (өйләнәсең), гел шулай. Бер-берен яраткан кешеләр сирәк бергә калалар... **Чипидейл**

Шәһәрдәге, тышкы яктан бик культурный булган кыяфәттә йөреп, чынлап карасаң бозык тормыш белән яшәүче кызларга караганда авылдагы сыер савучы эшчән кызларыбыз (укымасалар да) мең тапкырга өстен, беләсегез килсә. **Вәт**

Нәрсә, Шамил, синенчә, мәхәббәт шундый кирәксез, юньсез нәрсәмени? Шулай коры гына «ботаник» булып яшәвең хәерлерәкмени... Әгәр дә сина чын матур мәхәббәт килә икән, синнән сорап тормый ул.

Мәктәптә укыганда мин бик яхшы укымадым. Ә минем күз төшеп йөргән кыз бик әйбәт укый һәм бик тәртипле кыз иде. Мәхәббәт ул аллә нинди сихри көчкә сәләтле. Мин дә тырыштым. Без хәзер икебез бер җирдә укыйбыз, ләкин төрле факультетта. Мин бу «мәхәббәт чире» белән «авыруыма» рәхмәтлемен генә, чөнки минем көч-куәт өстәп торган яраткан кызым бар. Мин кешеләрне уңай якка үзгәртә алырлык мәхәббәт яклы. **Марат, Актаныш**

Маратка тәтегән «мәхәббәт заразасы» мина да эләксен иде әле. **Кызыктым**

*«Ак җилкән»дә яңа сәхифә ачарга булдык әле. Танылган шәхесләребез хәзер шундый да бит, ә менә бәләкәй һәм үсмер чакта нинди булдылар,ниләр кыландылар икән? Белербез!*

*Яңа сәхифәне «Казан утлары» егете Алмаз Хәмзиннән башлап җибәрик әле.*

# БӘЛӘКӘЙ АЛМАЗ

## Сагынам шул җәйләремне

Әй, ул без бәләкәй чаклардагы җәйнең матурлыклары!

Әтәчләрнең гайрәтләнеп кычкырган тавышыннан уянган таң офык читеннән зәңгәрсулана башлый. Шулчак йолдызларның ашыгып саубуллашкан җемелдәвен күреп каласың. Кояш та, мине көтәләр дигән сыман, кабаланыбрак күтәрелә, ахрысы, шул як кызыллана төшә. Әнә, бер чите тоемлана да бугай. Төне буе сайрап чыккан сандугач тавышына барлык кошлар чыркылдавы кушыла. Казлар каңгылдый, үрдәкләр бакылдый, сыерлар мөгри... Таң җанлана. Бу җиһанда көн саен кабатлана, янгырый торган гүзәл симфониянең увертюрасы!



Мин әле йоклыйм. Кичә арыганмын. Җәйнең көннәре озын булса да, уйнап туярга җитми. Төннәре кыска, йокы туймый. Төштә әллә нинди җен-пәриләр белән саташып, сугышып бетәм. Бабай бит әллә нинди куркыныч әкиятләр сөйли. Уянгач, мунчага керергә куркып йөрим. Әле бер төн өйдәге мич аралыгында шайтан лилипутлары белән бәргәләшеп алдык, хәзер аннан үтәргә дә шелләтә.

Көндез уйнап күрсәтәбез инде! Әни әйтмешли, дөньяны онытып уйныйбыз. Ашарга кайту да онытыла. Инештә балык тотабыз, «тәпәчле» (городки) уйныйбыз, ярамаса да, колхозның яшелчә бакчасыннан кыяр-помидор урлыйбыз, гөнаһ булса да, Сәүбәннәрнең алма бакчасына керәбез. Ай тәмле дә инде шуларның кытай алмалары! Әле беркөн кибет каршында үзен дә сыйладым. Башта ашады, карале, безнекенә ошаган тәме, ди, аннан сизеп: «Аһ, сез, караклар!»—диеп кычыткан йолкырга тотынды. Ыхы, тоттырды ди!..

Минем әби белән бабай ураза тоталар. Җәй көннәренә дә туры килә икән ул. Мин, ураза тотмасам да, ураза аен бик яратам. Кич белән вакытында ашарга кайтам. Анда әби авыз ачарга тәмле әйберләр пешерә. Табынга җимешләр дә куя. Шикәрне дә зуррак кисәкләргә вата. Бабай белән рәхәтләнеп күп итеп чәй эчәбез. Чү, туктагыз, ин бәхетле минутларымны сикертеп үткәнмен икән бит. Бабай миңа лапас түбәсенә менеп кояш баеганны карарга куша. Уразада кояш баегач кына ашарга ярый бит. Югыйсә уразаң кабул булмый. Мондый көннәрне ул хәтле биеккә—түбәгә менәргә рөхсәт итмиләр. Бабаем әйбәт минем, ул мине бик ярата, бар, улым, ди, кояшны кара әле, бату белән миңа кычкырырсың, ди. Мин атылып менеп китәм, ничек менәсен беләм инде, өйдәгеләр күрмәгәндә кырык тапкыр менгән бар. Әй андагы рәхәтлек, хозурлык—бөтен дөнья күренә. Мин әле Казан хәтле Казан да күренә дип уйлаган идем, ул күрше урыс авылының

чиркәве булып чыкты. Казан безгә ике йөз чакрым ераклыкта икән ул.

И рәхәтлек түбәдә! Чыпчыклар да синең биеклектә генә очып йөриләр. Ишек алдындагы әтәч тә миңа кырын карап әллә нинди тавыш белән кикереп куя. Көнләшә бугай. Менә алмыйсың шул!..

Кояш әле Сарсаз тавы артыннан хәйран күренеп тора. Әбием өстәлгә аш китереп утыртты. Миңа барысы да күренә. Алмагачы янындагы тәрәзә ачык. Тәмле аш исе түбәгә хәтле менә. Бабай кул-битләрен юып тастымалга сөртә-сөртә аш янына килә. Тәлинкәдән пар күтәрелеп сузыла-сузыла өскә тарала. Мин бер кулым белән түбә сыртына ябышып, икенче кулым белән ялан тәпиемнән черки куам. Аһ, явызлар, кояш баемаган килеш...

Бабай бераз тәрәзәгә иелә төшеп миңа карый.

—Ничек анда, улым, Кояш?

—Бабай, бер чирек бар әле баерга!

—Алай икән.

Бабай утырган урыныннан кубып бераз әйләнеп килә.

Мин кояшны күзәтәм. Әзрәк офыкка иелебрәк карасаң, кереп тә киткән кебек инде ул. Туры карасаң, бар икән шул әле, бар, батмаган икән. Бабай тагын аш артына утыра. Суынмаган әле, пары чыга.

—Улым, ну, ничек анда хәлләр?

Бабайны кызганып батты дип әйтер идем дә инде—гөнаһлы буласым килми. Ялганласам, Ходай Тәгалә түбәдән сугып төшерер. Ярамый. Юк, ярамый ялганларга!

—Бар шул әле, бабай, бер бармак калынлыгы.



Бабай тагын урыныннан кузгалып күрше бүлмәдән әйләнеп килә. Мин җәйге шәфәкънең шул кадәр матурлыгына сокланып онытылыбрак киткәнмен, ахрысы.

Бабайның тагын бер:

—Улым, булдымы инде?—дигәненә сискәнеп куйдым.

Кояш югалган иде бугай. Мин бабайның сүзләренә үк иярәп:

—Бабай, давай!—дип кул изәдем.

Әтәч көнләшерлек итеп түбәдән очып төштем дә, тавыкларны пыркытып өстәл артына кереп утырдым.

—Җәй рәхәт, әйеме, бабай?!

—Яшәүнең тәмен белеп яшәсәң, кышы да әйбәт аның, улым.

## Патриот

Минем кыш көне иң яраткан уеным «кых»лы, ягъни мәсәлән, сугышлы уйнау. Билгеле, бүтән уеннарны да рәхәтләнеп уйныйм. Мәсәлән, таудан чана, чаңгы шуу, кар көртләрен казып крепостьлар ясау, кәшәкәле... Бу уеннарны берүзең генә уйнамыйсың инде. Дуслар белән, әлбәттә.

Авылда элек кар урамның як-ягында эреп бетә торган иде. Урталагы юл карлы чана, ат эзләре белән тигезләнеп, соңгарак кала, житмәсә, анда салам, печән төшкәләп, ат тизәкләре белән буталып, ул эрү хәйранга сузыла. Койма кырыйларына сукмак төшә, ә теге юл тора.

Без «кых»лы уйныйбыз. Берәүләр—«немесләр», икенчеләр—«безнекеләр». Берәүнең дә немес буласы килми, барысының да безнекеләр булып, соныннан җиңеп каласы килә. Немес булмыйча да булмый, чөнки уен килеп чыкмый, оешмый. Ләкин бер бүленгәч китә ул уен кызып, «немесләр» дә шәп сугыша башлый. Мин—«безнекеләр» яклы. Инде «немесләр» безнекеләрне байтак

кырды. Әллә тагын берүзем генә калдым. Дошман төрле яктан ут ача. Шул агач мылтыклар белән инде, таяклар белән. Чүт баш калкыттың, беттең, аталар, үләсең—уең шарты шундый. Дошманнарның позициясе яхшы, алар безнекеләрнең окопларына төшеп аталар. Бөтенесенең уты миңа ява. Мин баш калкытырга куркып, әлеге дә баягы эреп бетмәгән тизәкле юлдан шуышам. Күз алларыма сөекле Ватаным килеп баса. Нишләр ул мин һәлак булсам?! Шул вакыт колхоз идарәсеннән әле генә клуб туфрагында ятып Ватан өчен «һәлак булган» дустым Разил Вәлиевның әтисе председатель Озын Исмәгыйль белән минем әтием—парторг Наил Хәмзин чыгып килә. Урам уртасыннан пычрак сөреп шуышып барган мине күрде дә, әти:

—Исмәгыйль абый, карале, кичә алган яңа пәлтә,—дип, протезлы аягы белән арт ягыма китереп типте. Мин:

—Чур, чур! Атарга ярамый!—диеп, клуб нигезендәге тузанга дөпелдәдем. «Дошман» белән аяусыз сугыш төнгә хәтле дәвам итте. Барыбер безнекеләр жиңде.

Ә менә өйдә мине...

## Әнием сабагы

Җәй буе иркенгә күнеккән күңел көзге мәшәкатьле көннәргә ияләшә алмый интегә. Инде укулар башланды. Дәрес хәзерләү өстенә бәрәңге алу, бакча казу, мал-туар карау өстәлә. Көтүдән кайтышлый уҗым басуына каерган мәнсез сыер шикелле гел уенга, урамга чыгуга хәйлә корам. Җитмәсә, бәрәңгесе дә алынып бетми. Әти көн-төн эштә, әни дә укытудан бушагач кына бакчага чыга ала. Тагын көннәре дә явымлы булып, җүнләп эш башларга ирек бирми. Әнә тагын куерып кара болыт килә. Әни белән икәү генә иртүк әти казып киткән бәрәңгеләрне ашыга-ашыга җыябыз. Ә мин мырлап урамга шылмакчы булам. Әни: «Ичмасам бирәрегез булса да кыз булып тумадыгыз бит»,—дип, тагын ике энекәшне дә күздә тотып җанны кыра. Инде яңгыр да сибәли башлады. Әти бераз кипшерсен, җилләсен дип калдырган җир өстендәге бәрәңгеләр юешләнеп бетте. Шулчак урам ягыннан, көтү кайтканны белдереп, сыерлар мөгрәве ишетелде. Каршыларга кирәк. Әни тагын да тизрәк кабалана башлады. «Уф, үтерәсез сез мине, бар, капканы гына ачып сыерны гына керт әле!» Турсайдым. Сыерны да каршыламыйм, уенга чыгармагач, бәрәңгене дә җыймыйм. Балчык кәнтәрләре белән казык башына кунган карганы куркытам. Шулчак әни бәгърем янәшәдә сабагы калган көнбагышны төбе-ние белән кубарып алды да, ун кило чамасы туфракны төйнәгән тамырын җилкәмә сылады. Җиргә сеңдем. Йөрәгем үк сызлап куйды хәтта, шунда аңладым әниемнең хәлләрен. Шуннан соң мин аңа беркайчан да сыкрау китермәдем.

Уенны аны уйнап бетереп булмый.

Каргалар да һаман карылдый.

## Шалапай

Миңа велосипед алдылар. Ул вакытта без аны «сәпид» дип кенә йөртә идек. Әби почтальон булып эшли. Гәжит-хатларны күрше авылга барып аласы. Үзәк почта шунда—Кызыл Чапчак авылында, аралар—җиде чакрым, урман аша. Әле яңа вельвет кәчтүм-чалбар да алып, сәпидтә дә әйбәт йөри башлагач, бабай мине шул күрше авылга почтага алып барырга булды. Әби урынына бу юлы ул бара. Нигә шулай ният кылгандыр инде?.. Үземә егет булып үскәнне сиздерер өчен микән? Киттек. Ул ат җигеп, тарантаста, мин яңа кәчтүм киеп, сәпидтә. Тарантас артыннан сәпид әйләндерәм. Менә урманга кердек. Урман куе, хәтта куркыныч. Яңгыр да явып киткән, чокырларда су. Мин җайлап кына иярәм, бабайдан калмыйм. Бабай гел сөйләштереп, мактап бара:

—Менә, улым, үсеп җиттең, бергәләп икәү урман кисәрбез әле.

Булышырсың бит!

—Әлбәттә, бабай!

—Икәү буралар бурарбыз, әйеме?

—Әйе, бабай!

—Яңа өй салырбыз!

—Салырбыз, бабай!

Инде урманны чыгып киләбез бугай. Еректарак ачыклык күренә. Бабай миңа:

—Улым, син турыга кит, әнә урман авызы. Ә минем юл әйләнгечрәк, син чыгачак сукмактан барып булмас,—диде.

Мин турыга бәрдем. Сукмак кына шул. Ике яклап тирән чокырларга су җыелган. Тар сукмактан боргаланмыйча барып та булмый, җитмәсә, анда-монда агач тамырлары сукмакка чыгып, бүлтәеп торалар. Берсендә минем сәпиднең алгы тәгәрмәче тамырны үтеп чыкты, ә арткысы үтә алмады. Алга-артка атынып тордым-тордым да сазлыкка чумдым. Көчкә сәпидемне өстерәп урман кырыена, бабай каршына килеп бастым. Бабай миңа карап шаккатып тора.

—Нәрсә булды, улым?

—Егылдым,—дип елап җибәрдем.

—Елама, улым, хәзер без аны,—диде дә, яңгыр суы җыелган чокырда кәчтүмне юарга тотынды.

Су болганып, кәчтүм көрән төстән җир төсенә керде.

—Булмады әле бу, улым, әйдә, Зәй буена төшкәч, әйбәтләп юарбыз, кайгырма!

Сәпидне тарантаска салып, үземне үз кәчтүмемә төреп, бабай мине Зәйгә алып төште. Су коендырып, кәчтүмне кабат юып, тарантас артына элде. Почтага кергәнче бабай мине кодаларында калдырып китте. Мине мунчада, кәчтүмне җылы суда сабынлап кабат юдылар. Кипкәнен дә көтмичә яхшылап үтүкләделәр. Киеп карасам, җиңнәр—беләктә, балаклар—балтырда. Кәчтүм утырган, кечерәйгән, җитмәсә, төсе дә качкан.

Шундый кыяфәттә бабай мине әтиләргә тапшырды. Әти сугып җибәрерме әллә дигән идем, ул матур итеп «Шалапай!» гына диде. Рәхмәт.

Ә шулай да үскәч без бабай белән урман да кистек, мең дигән өйләр дә салдык.

### Кышкы мунча

Кем шук булмаган инде ул бала чакта?! Синме, минме?

Кышкы зәһәр суык көннәр. Андый чакта мәктәптә укулар булмый. Безнең мәктәп тә бит әле күрше авылда, ике чакрым йөреп укыйбыз. Кайбер кышларны суыклар шул хәтле озак була!.. Укымыйча йөрүгә күнегелә. Күнегелгәч, мәктәпкә бару ирендерә, ялкауландыра башлый. Без суык дип алай кайгырмыйбыз, сөенәбез генә, чөнки мәктәпкә барасы булмагач, кәшәкәле уйнарга чыгабыз. Бөтен авыл баласы инеш буенда шар суга. Салкынлык бер дә комачауламый. Борын очлары, колаклар бераз агарып ала инде, өши диюем, әй, ул бала мени?! Уку туйдыра, ә менә уен беркайчан да туйдырмый!

Шулай бервакыт укый-укый тәмам арыгач (көннәре дә бит анын гел җылы тора, минус егерме биш, утызга җитми) Разил дустым белән егерме бер градус суыклыкта иртүк торып мәктәпкә киттек. Икәү яшерен сөйләшү буенча мәктәпкә барысыннан да алдан барып, кайтышлый каршы очраган укучыларга «Бүген уку булмый, бик суык, шулай әйтергә куштылар»,—дип әйтергә килештек. Һәм шулай иттек тә. Әлбәттә ул көнне уку булмады—рәхәтләнеп уйнадык.

Тик икенче көнне кичәге рәхәтләнеп уйнауларны кире чыгардылар. Барлык укучыларны һәм укытучыларны җыеп «мунча» керттеләр. «Чабындырдылар», «юындырдылар». Ай-яй эссе булды!

## ПАРЧАЛАР

### Бензин салдыңмы?

Казанның Карбышев урамындагы төбәгара клиник-диагностика үзәгендә ятканда күңелгә уелып кала торган хәлләр булгалады. Күршедәге палатага Дахау тоткыны кебек ябык, бик-бик өлкән яшьтәге урыс бабайны салдылар. Заманында халык «кукурузник» дип йөрткән самолетта очкан булса кирәк ул. Яшь вакытта чиксез күкләрне иңләгән каһарманның йөрәгенә генә түгел, баш миенә дә зыян килгән, ахры.

Бабайны саклаучы әби картын, коляскага утыртып, коридорга да алып чыккалый. Гөрләшәләр пар күгәрченнәр! Мин колак салып торам.

—Ты самолет заправила?

—Да, да, дед.

—А где стоит самолет?

—На стоянке.

—Ты точно заправила?'

—Да, да.Точно.

—Если обманешь, смотри!..

### Утны сүндереп чыгарсың

Галимулла ага Сафиуллин сугышның башыннан ахырына кадәр коточкыч газаплар күреп, туган авылы Эзмәгә сыңар аяк белән кайта. Фронт хатирәләрен бик тәфсилләп, тәэсирле итеп искә төшерә торган була ул. Сөйләрсең дә—миллионлаган кеше үлгәндә Ходай рәхмәте белән исән кал әле син. Агай күршеләре Нуретдиннәргә көн дә диярлек кич утырырга керә дә, истәлекләрен кат-кат яңартырга тотына икән. Берсендә, сәгать телләре төн уртасын күрсәтә башлагач, йорт хуҗасы йомшак түшәгенә чума да, болай ди:

—Галимулла абзый, сөйләп бетергәч, утны сүндерерсең дә, тышкы ишек белән капканы әйбәтләп ябып чыгарсың әле, яме!

### Куштырнаклары булмагач

Шагыйрь һәм публицист, сатира-юмор остасы Нәҗип Мадьяров белән булган хәлне якташы һәм хезмәттәше, озак еллар Балтач районының «Хезмәт» газетасы мөхәррире булып эшләп пенсиягә чыккан Әхәт абый Фазылҗанов (2009 елда вафат) сөйләгән иде. Илленче елларда Әтнәгә бер төркем язучылар—Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Атилла Расих, Зәки

Нури кебек могиканнар килеп төшә.Аларга яшь шагыйрь Нәжип Мадъяров та иярә.

Менә клубта кичке очрашу башлана. Әле генә чәйләп һәм бераз гына мәйләп килгән әдипләрнен кәефләре әйбәт икәне күренеп тора. Берсен-берсе уздыра-уздыра сөйли болар. Чират Нәжипкә җитә. Кечкенә генә буйлы яшь шагыйрь каушый-каушый сәхнәгә чыга да:

—Мин сезгә үземнен бер шигыремне укыйм әле салган баштан,—ди.

Халык дәррәү көлеп жибәрә. Баксан, шигырьнең исеме «Салган баштан» икән. Әйткән сүзгә куштырнаклар куеп булмый шул.

## Башка җитәчәк сөенеч

Жәүдәт Котдусов яшьтән үк шоферлыкка укыды һәм гомере буе үз һөнәренә тугры булды. «Родина» колхозынын ин алдынгы шоферы иде ул. Гадел хезмәте эзсез калмады, әлбәттә. «Хезмәт Даны» орденынын III һәм II дәрәжәсенә лаек булды. Коммунистлар үзен партиянен XVII съездына делегат итеп тә сайладылар. Олы форумга китәр алдыннан башкалабыздагы үзәк универмагнын махсус залында башыннан аягына каләр үз акчасына киендерделәр, дефицит өс киемнәрен гаилә әгъзаларына да сатып алырга рөхсәт иттеләр. Кыскасы, бу көннәрдә башы түшәмгә тиярдәй булды. Съездан сонра эшен дәвам итте. Әмма партиянен бетүен, СССРнын таркалуын авыр кичерде.

Пенсиягә киткәндә бер «УАЗ» машинасы сатып бирделәр үзенә. Ул вакытта да сөенгән иде Жәүдәт абый.

Еллар уза торды. 2000 елга кергәндә, шул «УАЗ»ына жәмәгате Саимә апа белән утырып, Казан читендәге авылда яшәүче кызларына дигән тере бозауны артка салып, юлга кузгала болар. Һәм, бәхетсезлекләренә каршы, юл фажигасенә дучар булалар. Әби белән бабай үлә, ә бозау ... исән кала. Анын гомере бетмәгән була...

## Аккан су юлны тапмаган

Совет заманында алдынгыларны туристлык путевкасы белән чит илгә алып чыккалый иделәр. Шулай бер елны Болгариягә баргач, ике хатын-кызны бер бүлмәгә урнаштырганнар. Аларнын берсе, «Октябрь» колхознын алдынгы савымчысы Маһижамал апа Гарипова, истәлекле жирләрне карап кайткач, изрәп йокыга китә. Ә икенчесе, терлекчелек белгече, душ кереп чыгарга була. Һәм Ходай биргән рәхәтлектән, бушка килгән жылы судан файдалана-файдалана сәгатьтән артык чистарына ул. Йомшак халатын киеп, чәй эчәргә дип бүлмәләренә чыкса, ул күзенә үзе ышанмый: бүлмә идәнен су баскан! Кирәген бирә инде шунда ел тәүлеге эшләп талчыккан Маһижамал апанын теге.

—Монда килеп йоклап ятмасан! Нәрсә карадын?! Артына су керә язган бит!!!

Баксан, душ керүче үзе гаепле икән. Ул аяк астына салына торган резин белән су тишеген каплаган икән.

## Тигезлек белән яшәү

Озак еллар пар күгәрченнәр кебек яшәп, бер көнне үк бакыйлыкка күчкән парлар сирәк була. Безнен Байлангар авылында (Кукмара районы). Сәмигулла абый белән анын жәмәгате Гарифа апа—берсе өйләгә каләр, икенчесе төштән сон мәнгелеккә китә. Бер-берсенен вафатын белмиләр дә...

## Дөнья киң ул

Бу дөньяны бервакытта да тар дияргә ярамый. Киң ул. Бөтен кешегә дә житә. Байтак еллар элек Караганда шәһәренә, төгәлрәге, аның янәшәсендәге Абайда яшәүче туганнарга кунакка бардык. Ярар, кунак булып, кайтыр вакыт житте. Аэропортка килдек һәм шунда Саба авыл Советының элеккеге рәисе Рафисә апа Рәхимованы очраттык. Ул да безнең рейс белән Казанга очарга тора икән.

## Асыл затлар мәкере

Турысын әйткәндә, алар белән бәхәскә кермәү хәерлерәк. Чөнки барыбер үзенекен итә ул хатын-кыз. Менә шуңа бер мисал.

—Уеннан уймак диләрме әле? Юктан гына бәхәсләшеп, зур үпкәләшүгә барып життек,—дип сүзен башлады бер танышым.—Шуннан соң хатыным бер атна эндәшми йөрде. Менә шул көннәрдә хәләлемнең туганнары кунакка чакырдылар. Бардык. Өстәл сый-ниләмәттән сыгылып тора. Гөр-гөр килеп утырабыз, мәзәкләр сөйлибез, шырык-шырык көлешәбез. Жәмәгатем миңа төрледән-төрле салатлар сала, башка тәм-том белән сыйлый, кабымлык алып бирә. Күңел сөенә инде, уртак туганнарга рәхмәт укыйм. Ярый әле чакырдылар, дим. Санаулы сәгатьләр тиз үтте, кайтыр минутлар житте. Хуҗалар озата чыкты. Саубуллашып, юлга кузгалдык. Һәм шул минуттан хатынымны алыштырып куйдылармыни? Яңадан эндәшмәс булды бу. Кыскасы, өйгә кайткач, тагын бер атна сөйләшмәдек әле.

**Тәлгат НӘҖМИЕВ**

***Редакциядән:***

*Танылган сатирик-юморист һәм публицист, журналның күптәнге дусты Тәлгат Нәҗмиевкә 60 яшь тулды.*

*Кукмара районының Байлангар авылында туган Т. Нәҗмиев гомеренең төп өлешен журналистикага багышлады: Сабада район радиотапшырулар үзәген җитәкләде, утыз еллап «Саба таңнары» газетасының баш мөхәррире булды. 2001 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Унлап китап авторы.*

## Мәгъсүм Гәрәевкә 75 яшь



Журналист, язучы-публицист Мәгъсүм Гәрәй улы Гәрәев 1935 елның 1 февралендә Татарстанның Питрәч районы Шәле авылында мөгаллимнәр гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе репрессияләнеп кулга алынуы сәбәпле, Мәгъсүм ишле туганнары белән бергә, әнисе тәрбиясендә үсә, тормыш авырлыкларын яшьли татый. Шулай да ул, тырышып укырга, кеше булырга, тормышта үз урынын табырга омтыла. 1953 елда Шәле урта мәктәбен тәмамлый. Сонрак ВЛКСМның Питрәч райкомында эшләп ала. 1956 елда ул Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетына укырга керә. Икенче курсны тәмамлаганда, аны Татарстан радиосына даими эшкә чакыралар.

Мәгъсүм Гәрәев—киң даирә җәмәгатьчелеккә үзен журналистика аша таныткан каләм иясе. Бу жанрга ул инде ярты гасырдан артык турылыклы хезмәт итә. Шушы дәвердә Татарстан китап нәшриятында заманның иҗтимагый-социаль мәсьәләләре, күренекле шәхесләре турында басылып чыккан дистәләрчә китап-җыентыкларның байтагында М. Гәрәевнең очеркларын, мәкаләләрен күрергә мөмкин.

2004-05 елларда язучы-публицистның сайланма мәкаләләре, хикәяләре, иҗат портретлары, юмор-сатира әсәрләре һәм автобиографик язмалары-истәлекләре тупланган «Мин, Чуен Гәрәй малае» һәм «Жаның кыйбатмы, малыңмы?» дигән күләмле ике китабы дөнья күрә.

Мәгъсүм Гәрәев 1967 елда «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасына эшкә күчә, 1991-95 елларда «Татарстан хәбәрләре» газетасында икътисад бүлеге редакторы булып эшли, 1995-98 елларда «Шәһри Казан» газетасында, 1998 елдан «Чаян» журналында әдәбият-сәнгать бүлеген житәкли. 2000 елдан, төп эше белән бергә, Казан дәүләт университетының журналистика һәм социология факультетында да укыта. 1999-2001 елларда М. Гәрәев җәмәгать тәртибендә Татарстанның Аксакал язучылар шурасын житәкли. Аңа 2005 елда «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

М. Гәрәев—1999 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.



*Шагыйрь Равил Фәйзуллинның Россия һәм Татарстан җитәкчеләреннән сорар сүзе бар. Президиум түрендә Б. Ельцин, М. Шәймиев, М. Сабиров. Казан. Язучыларның Г. Тукай клубы. 1990 ел.*



*Бер төркем язучылар Татарстан Язучылар союзы (берлеге) рәисенең эш бүлмәсендә. Сулдан уңга: Рөстәм Мингалимов, Шәукәт Галиев, Фәрваз Миңнуллин, Гәрәй Рәхим, Илдар Юзеев, Гариф Ахунов (рәис). 1981 ел.*



*«Казан утлары»нда Америкадан килгән милләттәшебез, галим Шамил Юлай белән очрашу истәлеге. Сулдан уңга: М. Харисов, Н. Акмал, И. Хәйруллина, Р. Туфитуллова, Ш. Маннапов, М. Вәлиев, М. Галиев, Җ. Миңнуллин, Р. Низамиев, Ш. Юлай, Р. Гаташ, Р. Харис, Ф. Латыйпов, Р. Фәйзуллин (Акъегет), Ф. Хәкимҗанов, Н. Шәйдуллина. 1989 ел.*



*Шагыйрь Камил Мостафин (1932-2009).*



*Якташ язучылар. Тәлгать Нәҗмиев һәм Рашат Низамиев «Казан утлары» журналы редакциясендә. 1994 ел.*

### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

### КАРАРЫ

**МИҢНЕХАНОВ РӨСТӘМ НУРГАЛИ УЛЫНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА**

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законның 5 һәм 18нче маддәләре, Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 һәм 91нче маддәләре нигезендә Миннеханов Рөстәм Нургали улына Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен бирү турында Россия Федерациясе Президенты Д. А. Медведев тәкъдимен карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карар бирә:

**1. Миңнеханов Рөстәм Нургали улына Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен бирергә.**

**2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Президентына җибәрергә.**

**3. Миңнеханов Рөстәм Нургали улының Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына керешү тантанасын 2010 елның 25 мартында үткәрергә.**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
Ф. МӨХӘММӘТШИН.

***

*Рөстәм Миңнеханов 1957 елның 1 мартында Балык Бистәсе районының Яңа Арыш авылында туган. Казан авыл хуҗалыгы институтын, аннары читтән торып Мәскәү совет сәүдәсе институтының Казан филиалын тәмамлаган. Хезмәт юлын «Сельхозтехника»ның Саба район берләшмәсендә инженер-диагностик буларак башлый. Саба урман хуҗалыгында, сәүдә оешмаларында тормыш тәҗрибәсе туплагач, Арча район Советы башкарма комитеты рәисе итеп сайлана. Аннары район хакимияте башлыгының беренче урынбасары, Биектау районы хакимияте башлыгы, ТР финанс министры, 1998 елның 10 июленнән—РТ Премьер-министры.*

### ПРЕЗИДЕНТКА РӘХМӘТ СҮЗЕ

РФ Президенты Дмитрий Медведев Мәскәүдә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев белән очрашты.

Дәүләт башлыгы әңгәмәне М. Шәймиевкә рәхмәт сүзләреннән башлады. «Татарстан белән озак еллар буе һәм төрле чорларда—болгавыр 90нчы елларда, икътисадыбыз асылда тулысынча таркалу чигенә житеп, федерация сынауларга дучар булган дәвердә дә, шулай ук житешрәк-иминрәк вакытларда да, бүгенгәчә житәкчелек итүегезгә зур рәхмәт», диде Д. Медведев.

Президент искәртеп үткәнчә, Татарстан бүген—илебезнең әйдәп баручы субъектларыннан берсе, чәчәк атучы төбәк. «Сезнең турыдан-туры казанышыгыз бу»,—диде дәүләт житәкчесе.

Очрашу вакытында Д. Медведев М. Шәймиевне III дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» ордены белән бүләкләү турында Указга кул куюы турында хәбәр итте. Ул Минтимер Шәрип улының әлеге орденның I һәм II дәрәҗәдәгеләренә инде ия булуын искә төшерде. «Дәрәҗәләрегездән (орден дәрәҗәләре) чыгып, монысы да Сезнең хезмәтегезне дөрес бәяләү булыр, дип уйлыйм»,—диде Д. Медведев.

### ПАЛЕСТИНА ЛИДЕРЫ ТАТАРСТАНДА

Соңгы дистә еллар эчендә Татарстанда чит ил житәкчеләре шактый еш була. 27 январьда башкалабызга Палестина милли администрациясе башлыгы Мәхмүд Аббас килде. Аның Татарстан Республикасына килүе Россия Федерациясендәге рәсми сәфәре кысаларында үтте. 26 январьда ул РФ Президенты Дмитрий Медведев белән сөйләшүләр уздырган иде.

Казанга килгәч Мәхмүд Аббас иң әүвәл «Кол Шәриф» мәчетендә намаз укыды һәм шуннан соң Россия ислам университеты студентлары һәм укытучылары белән очрашты.

—Ислам һәрвакытта да белем алырга өнди. Белем—җәмгыятьне алга этәрүче көч. Без дә ислам турында бөтен дөньяга белем таратырга тиеш. Казанны мин исламның бер бишеге дип саныйм. Ул Европа белән Азия кисешкән урында мәдәният, сәүдә үзәге булды һәм хәзер дә шулай дәвам

итә. Татарстан—толерантлыкның яхшы үрнәге. Күпсанлы мәчетләр, чиркәүләр һәм Татарстанда яшәүче төрле халыкларның дустанә мөнәсәбәттә булуы—сезнең горурлыгыгыз,—дип белдерде Мәхмүд Аббас.

Очрашу азагында дәрәҗәле кунакка «Татарстанда ислам» китабы бүләк ителде. Мәхмүд Аббас исә ислам дөньясында өченче изге мәчет булып саналган «Куббат әс-Сәхра» мәчете сурәтен бүләк итеп, Россия ислам университеты студентларын һәм укытучыларын Палестинага кунакка чакырды. «Казанның «Рубин»ы безнең җирле команда белән иптәшләрчә уен үткәрер дигән өметем дә бар»,—диде ул.

Мәхмүд Аббасның Казанга сәфәре ТР Милли музеена сәяхәт һәм Казан Кремлендә ТР Президенты Минтимер Шәймиевнең кабул итүе белән тәмамланды.

## ВИЗИТ ТӨГӘЛЛӘНДЕ

Быелгы елның гыйнвар ахырында Татарстан Республикасының парламент делегациясе АКШка тәүге рәсми визит ясады. Визит кысаларында Ф. Мөхәммәтшин АКШ Конгрессы һәм Сенатында, Ак йортта, Милли куркынычсызлык советында берничә очрашу үткәрде, Нью-Йорк штаты парламенты белән үзара аңлашу турындагы Меморандумга кул куйды. ТР Дәүләт Советы делегациясе РФнең БМО каршындагы даими вәкиле Виталий Чуркин белән очрашты. Әңгәмә барышында Казанда цивилизацияләр диалогы кысаларында БМО химаясендә зур Халыкара форум үткәрү теләге белдерелде. Федераль һәм төбәк хакимиятләре вәкилләре белән очрашу барышында исә Казанда Идел буе төбәгендә АКШ Генераль консуллыгын ачу мөмкинлеге турында фикер алышынды.

## ХЕЗМӘТТӘШЛЕК НЫГЫЙ

Татарстан белән Иран Ислам Республикасы арасында икътисадый-мәдәни бәйләнешләр елдан-ел ныгый бара. Февраль башында Иран революциясенең 31 еллыгы уңаеннан Иранның РФдәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Сәет Мәхмүт Реза Сәҗәди җитәкчелегендәге зур делегация Казанда булды. Делегацияне Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев кабул итте. Очрашу вакытында Татарстан һәм Иран арасында үзара мөнәсәбәтләрнең тарихы һәм булачак сәяси, икътисадый, мәдәни хезмәттәшлекне ныгыту юллары турында фикер алышынды. Илче М. Шәймиевне Иранга чакырды. «Без Шәймиев әфәндене Иранга чакырдык. Ул инде күптән чакыру алган иде, әмма эше тыгыз булу аркасында аннан файдалана алмады. Без визит 25 марттан соң булачак дип килештек»,—диде илче.

Сәет Мәхмүт Реза Сәҗәди, шулай ук, Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән дә очрашып әңгәмә үткәрде.

9 февраль көнне Казан дәүләт университетында «Иранда ислам революциясе: цивилизацияле феномен һәм перспективалар» дигән халыкара конференция дә уздырылды. Конференциягә Иранның мәдәни революциясе Югары Советы әгъзасы Хәсән Рәхимпур Әзһади җитәкчелегендәге галимнәр делегациясе килгән иде. Халыкара Конференциядә фарсы галимнәре белән бергә Казан һәм Мәскәүнең шәрекъ белгечләре дә актив катнашты.

Бу вакыйгалардан беркадәр элек—гыйнвар ахырында Иранның Казандагы Генераль Консуллыгында да бер төркем зыялыларның Генераль Консул Реза Багбан Кондори белән очрашуы булып узган иде. Анда уртак дини-мәдәни мәсьәләр буенча фикер алышынды. Очрашуда Татарстан ягыннан Татарстан мөфтие Госман Исхаков, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Татарстан министрлар кабинеты каршындагы дин эшләре советы рәисе Ренат Вәлиуллин һәм башка рәсми затлар, журналистлар катнашты.

## ДАВОСТА ИКЪТИСАДИ ҖЫЕН

Швейцариянең Давос шәһәрендә Бөтендөнья икътисади форумының 40нчы утырышы булып узды. Биш көн дәвам иткән җыенда дөньяның 90 иленнән хакимият структурасы, бизнес-элита һәм иҗтимагый оешма вәкилләре катнашты. Форумда Татарстанны Премьер-министр Рөстәм Миннеханов җитәкчелегендәге делегация тәкъдим итте. Форумның программасы икътисадны ничек көчәйтергә һәм социаль хәлне ничек яхшыртырга; тотрыклы үсешне ничек гарантияләргә; ышанычлылыкны ни рәвешле тәэмин итәргә; нәтиҗәле эшләүче институтларны ничек булдырырга дигән темаларны үз эченә алган иде.

## ТАРИХИ ГАМӘЛЛӘР БАШЫ

10 февральдә ТР Президенты Минтимер Шәймиев борынгы Болгар шәһәре һәм Свияжск утрау-каласы темасына киңәшмә уздырды. Анда мәдәният министры З. Вәлиева, Президент аппараты җитәкчесе Ю. Камалтдинов, әлеге тыюлыклар урнашкан Спас һәм Яшел Үзән районнары башлыклары һәм бу проектка катнашы булган бүтән җитәкчеләр катнашты.

«Болгар тыюлыгы һәм Свияжск утраукаласын торгызу илебез халыкларының мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертү булачак,—диде М. Шәймиев.—Тыюлыклар безнең республикабызда ике зур дин—ислам һәм православиенең үзара килешеп, тыныч яши алуына да ныклы мисал. Әлеге зур эшне башкарсак, без үзебезне тагын

да ныграк хөрмәт итә башлаячакбыз. Бу—цивилизациягә илтүче юл».

М. Шәймиев әйтүенчә, бүгенге көндә әлеге тыюлыкларны торгызу өчен федераль казнадан бүлеп бирелә торган акчалар аларны торгызуга түгел, хәтта җимерелү-таркалудан туктатуга да җитми икән. Шуна күрә ул Болгар һәм Свияжск турында Россия хөкүмәте рәисе Владимир Путин белән дә сөйләшкән һәм алар уртак фикергә килгәннәр. Хәзер Болгар тарихи тыюлыгын һәм Свияжск утрау-каласын торгызу өчен федераль казнадан Россиянең башка тыюлыкларына бүленгән кадәр үк акча биреләчәк.

Озакламый әлеге тыюлыкларны торгызыр өчен махсус фонд оештырылып, исәп-хисап счеты ачылачак. Димәк, һәркем теләгәнчә һәм кулыннан килгәнчә үз өлешен кертә алачак. Безнең республикада мондый тәҗрибә Кол Шәриф мәчетен төзегәндә булган һәм шактый уңышлы килеп чыккан иде.

«Без берничә ел эчендә бу тарих һәйкәлләрен үзебез дә карарлык, кешегә дә күрсәтерлек хәлгә китерергә тиешбез»,— диде Минтимер Шәймиев. Ул биредә эш күләменең бик күп булачагын һәм тыюлыклардагы ландшафтны бозмый гына кунаклар, туристлар өчен уңайлы шартлар тудыру, археологик тикшеренүләрне тагын да көчәйтү кирәклеген дә искәртте. Әлеге эшләр барысы берьюлы алып барылачак.

## АЛГАРЫШ ФӘННӘН БАШЛАНА

Россиядә Фән көне уңаеннан Татарстан Фәннәр академиясендә тантаналы җыелыш булды. Аны Академиянең президенты Әхмәт Мазгаров ачып җибәрде. Ул соңгы елдагы эш нәтиҗәләре белән таныштырып китте. Академия каршында төрле фәннитикшеренү институтлары, гыйльми үзәкләр эшләп килә. Экология институты, гаиләне өйрәтү үзәге, мәгълүматлаштыру үзәге, энергетика үзәге һ. б. шундый 80ләп эзләнү-өйрәнү үзәге бар.

Татарстан галимнәре шулай ук гуманитар белемнәрне үстерүгә дә зур әһәмият бирә. Тарихны яңача өйрәнү, төрле милләт халыклары арасында толерантлык булдыруга зур көч куела.

Хөкүмәтебез галимнәргә яшь алмаш тәрбияләүгә дә зур игътибар бирә. Мәсәлән, 2009 елда төрле фәнни бәйгеләрдә җиңгән өчен һәм фәндәге уңышларын бәяләп яшьләргә төрле грантлар булдыруга 28 млн. сум акча бүлеп бирелгән.

Татарстан Фәннәр академиясе Россиянең һәм төрле чит илләрнең фәнни даирәләре белән дә тыгыз элемтәләр урнаштыра. Болар—Казакъстан, Украина, Беларусь, Үзбәкстан, Башкортстан, Саха Фәннәр академияләре, Төркия, Франция, Германия, Иранның фәнни-эзләнү үзәкләре. Алар белән фәнни хезмәттәшлек турында 21 килешү төзелгән.

Утырышта Премьер-министрның беренче урынбасары Равил Моратов та катнашты. Ул узган ел Татарстан галимнәренең фәнне үстерүгә зур өлеш кертүен билгеләп үтте.

Равил Моратов үз чыгышында галимнәрнең яшь буынын тәрбияләү зарурлыгына зур игътибар бирде. «Бүгенге «Технопарк», «Бизнес инкубатор» һәм «Умник» программаларында катнашучы яшьләрне галимнәр үз карамагына алсын иде. 2010 елда Татарстанның икътисади үсешендә галимнәрнең роле зур булыр, дип ышанам,—диде Равил Моратов.

Утырышның икенче өлешендә Казанда быел ясалган кайбер ачышлар турында сүз барды. Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, медицина фәннәре докторы Андрей Киясов, мәсәлән, СПИДка каршы дару эшләү буенча кайбер эзләнүләре турында бәян итте.

Соныннан фәндә зур уңышларга ирешкән галимнәргә халыкара һәм Россия бүләкләре тапшырылды. «Татнефтехиминвестхолдинг» ачык акционерлар җәмгыяте директоры Рафинат Яруллин һәм ТФА президенты Әхмәт Мазгаров Россия Фәннәр академиясенең көмеш медаленә лаек булды. Дж. Гиббонс исемендәге халыкара фәнни премия Илдус Хәйбуллинга (вафатыннан соң) бирелде. Академик Миркасыйм Госмановка Американың алтаистика җәмгыятенең алтын медале тапшырылды.

Ел саен бәйрәм көнендә Татарстанда галимнәр династиясен зурлау да гадәткә кереп китте. Быел исә фәнгә өчәр буын галимнәр биргән Менделевич һәм тарихчы Фәхретдиновлар династияләренә дипломнар тапшырылды. Шулай ук «Елның иң яхшы галиме» һәм «Елның иң яхшы яшь галиме» конкурсларына йомгак ясалды. Лауреатларга премияләр тапшырылды. Фәннәр академиясенең махсус стипендиясен алып укучы студентларга да махсус дипломнар бирелде.

## ҖӘЛИЛ РУХЫН ЯД ИТҮ

Инде күп еллар дәвамында 15 февраль халкыбызның каһарман улы Муса Җәлилне искә алу көне буларак билгеләп үтелә. Шушы уңайдан быел да Татарстан Милли музеенда һәм шагыйрьнең Казандагы музей-фатирында Җәлил укулары уздырылды. Әлеге чараның темасы «Сугыш һәм батырлык: тарихи хәтерне саклау проблемалары» дип аталган иде. Иң әүвәл «Моабит дәфтәрләре»нең төп нөсхәсен тантаналы төстә тамашачылар хозурына алып чыктылар.

«Җәлил укуларын 1960 елдан бирле үткәреп киләбез,—диде Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният

министры Зилә Вәлиева Милли музейда үткәрелгән тантанада.—Җәмәгатьчелекне Җәлил һәм җәлилчеләрнең данлы көрәш юлы һәрдаим кызыксындыра. Шунысы сөенечле: аларның тиндәшсез батырлыгы хакында янадан-яна документлар табыла тора. Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулган көннәрдә без Берлинда да патриот-шагыйрь турында бик күп яналыклар белеп кайттык».

«Төп нөсхә көне» дип исемләнгән тантанада Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Муса Җәлилнең кызы Чулпан ханым, Милли музейның генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова, шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүче галим һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин һ. б.лар чыгыш ясады.

Аннары «Төп нөсхә көне»ндә катнашучылар Муса Җәлилнең Казан Кремле алдында—1 Май мәйданындагы һәйкәлгә чәчәкләр салды.

Җәлил укулары кысаларында Рафаэль Мостафинның «Репрессияләнгән татар әдипләре» исемле китабын тәкъдим итү дә булды, шулай ук әдәбият сөючеләргә «Без сайламаган юллар» дип аталган театраль-музыкаль композиция дә күрсәтелде. Музейда «Батыр үлә, үлмәс ат алып» дигән күргәзмә дә оештырылган иде. Икенче көнне Җәлил укулары шагыйрьнең музей-фатирында дәвам итте.

## «СӘЛӘТ»—МИЛЛӘТ КИЛӘЧӘГЕ

Балаларының киләчәген милләт язмышы белән бәйләргә ниятләгән һәр атаана «Сәләт» оешмасын яхшы белә. Быел «Сәләт»кә 15 ел тулды. Һәр зур эшнең башлангычы аерым шәхесләр белән бәйле. «Сәләт»кә нигез салучы, аны бүгенге көнгә кадәр яшәтүче, бик күп проектларны тормышка ашыручы кеше—Җәүдәт Шәүкәт улы Сөләйманов. Бүгенге көндә ул—Татарстан фәннәр Академиясе академигы, Казан дәүләт университеты профессоры, шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, фән һәм техника буенча Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты...

15 ел эчендә «Сәләт» укучы балалар өчен йөзләгән чаралар үткәрде. Зәй, Саба, Әлмәт, Балтач, Азнакай районнарында аның аланнары шул районнардагы укуда һәм спортта уңышка ирешкән сәләтле балаларны берләштерә. «Сәләт»—балаларга өстәмә белем бирү, сәламәтләндерү өлкәсендә дистәләгән конкурсларның җинүчесе дә.

«Сәләт»нең 15 еллыгы Республикада киң билгеләп үтелде. 5 февральдә Татарстан Фәннәр академиясендә бу уңайдан «Татарстанда сәләтле балаларны һәм яшьләрне барлау, туплау һәм үстерү үрнәге буларак «Сәләт» яшьләр оешмасы тәҗрибәсе» дип исемләнгән фәнни-гамәли конференция уздырылды. Аның эшендә республиканың мәртәбәле шәхесләре, министрлар, галимнәр, депутатлар катнашты. Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазгаров яшьләр оешмасының 15 еллык эш тәҗрибәсенә бәя биреп, болай диде: «Бу хәрәкәтнең бербөтен система булуы һәм фән белән тыгыз бәйләнеше кыйммәт безгә. «Сәләт» телләгәндә милли идея дәрәҗәсенә күтәрелә ала.

ТР яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министры Марат Бариев исә: «Сәләт»нең ирешкәннәре зур һәм кыйммәтле. Безнең максат—яйдаманнар үстерү, әлеге оешма бу вазыйфаны үз өстенә алды, дисәң дә була. Россиядә ел саен «XXI гасыр лидеры» дигән конкурс үткәрелә. Шунда ике ел рәттән «Сәләт» егетләре җиңеп чыкты. Быел «Республиканың иң яхшы студенты» да, «КДУның иң шәп студенты» да әлеге оешмада тәрбияләнгән яшьләр булды»,—дип билгеләп үтте.

Конференциядә шулай ук ТР мәгариф һәм фән министры Альберт Гыйльметдинов, РФ Дәүләт Думасы депутаты Валерия Черкисова, ТР Дәүләт Советы депутаты Разил Вәлиев, академик Индус Таһиров һәм башкалар катнашты һәм чыгыш ясады. Аннан соң, «Сәләт»нең җитәкчесе Җәүдәт Сөләйманов 15 еллык эш тәҗрибәсенә йомгак ясап болай диде:

«Төп максатыбыз—җәмгыятьтә интеллект дәрәҗәсен күтәрү, үсеп килүче буынның шәхси һәм иҗади йөзен формалаштыруда һәрьяклап ярдәм күрсәтү. Безне, икенче төрле, Татарстанның «Артек» лагере, диләр. Безгә ярдәм кулы сузучылар бихисап. Иң башлап Рөстәм Бикмуллинны искә алып китәргә кирәктер. Ул беренче сәлкешләрне Кара диңгез буенда ял иттерде. «Мәрҗани» фонды, «Таттелеком», «ТАИФ», «Камтент» оешмалары безнең бизнес-ярдәмчеләр. Бүген «Сәләт» аерым энтузиастларның тырышлыгы белән яшәп килә. Киләчәктә аны дәүләтнең яшьләр сәясәте карамагында итеп күрәсе килә».

Конференция ахырында «Сәләт» үсешенә күп көч куйган активистларга Рәхмәт хатлары тапшырылды. Шул ук көнне кичен УНИКС бинасында «Сәләт»тә катнашучылар көче белән зур бәйрәм концерты узды.

## ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ ОЕШУГА 200 ЕЛ

Россия мөселманнарының Диния нәзарәте оешуга 200 елдан артык вакыт узды. Халкыбыз тарихындагы әлеге мөһим вакыйга уңаеннан Татарстан Фәннәр Академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институтында семинар булды.

«XVIII гасырның соңгы чирегe—XX йөз башына кадәрге чорда Оренбург Диния нәзарәте һәм татар халкының рухи үсеше» дигән халыкара фәнни симпозиум эшендә, Казан тарихчылары белән бергә, Алмата, Уфа, Екатеринбург, Түбән Новгород һәм

Оренбург галимнәре катнашты. Семинарда ясалган докладлар Диния нәзарәте тарихына кагылышлы күп темаларны колачлады.

Аерым алганда, семинарда катнашучылар тарих фәннәре докторы, Казакъ милли университеты профессоры Гөлмирә Солтангалиеваның Оренбургның беренче мөфтие Мөхәммәтҗан Хөсәеновнын Казакъ Даласы күчмә ыру-кабиләләре белән мөнәсәбәтләрне җайлауга, четерекле хәлләрне тыныч юл белән хәл итүе турындагы докладны зур кызыксыну белән тыңлады.

Түбән Новгород галиме, сәясәт фәннәре кандидаты Дамир Мөхетдинов «Мәдинә» дини фәнни-мәдәни үзәге тарафыннан Ислам диненең Россия төбәкләрендә тамыр җәюенә багышланган энциклопедик сүзлекләр нәшер ителү турында бәян итте. Мондый басманың инде берничәсе дөнья күргән икән. Галим сүзләренә караганда, җыелма уникe томнан торачак һәм аның соңгы китабы 2013 елда басылып чыгачак.

## БЕЗНЕҢ КИТАПЛАР МИСЫРДА

Дөньяда халыкара китап ярминкәләре һәрдаим үткәрелеп тора. Аларның кайберләрендә Татарстан нәшриятлары да үзләре житештергән продукция белән катнаша. Әйтик, Германиядә, Кытайда, Һиндстанда, Төркмәнстанда үткән ярминкәләрдә татар китапларын да күрсәттеләр. Ә күптән түгел Мисырда ун көн дәвамында 42нче халыкара китап ярминкәсе булып узды. Анда шәрәфле кунак буларак катнашкан Россия нәшриятлары белән бергә Татарстанныкылар да зур экспозиция тәкъдим итте. Шушы унайдан Мисырга җөмһүриятебезнең әдәбият-сәнгать әһелләре, галимнәреннән торган зур делегация барды. Делегация составында Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров, Россия Хокук академиясе кафедрасы мөдире, фәлсәфә фәннәре докторы Айдар Юзеев, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре Резеда Сафиуллина, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты профессоры Фәрит Яхин, Татарстанның халык артисты Рөстәм Маликов, шулай ук «Татмедиа» вәкилләре бар иде. Күргәзмә кысаларында безнең делегация инициативасы белән «Габдулла Тукай һәм аның төрки дөньяга йогынтысы» дигән «Түгәрәк өстәл» утырышы да үткәрелде. Күргәзмәгә Татарстаннан 500дән артык китап алып барылган иде һәм соңрак алар Каһирәдәге Александрия китапханәсенә бүләк итеп калдырылды.

## БӨЕКЛЕКНЕ РАСЛАУ

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Илһам Шакировның 75 яшьлек юбилее уңаеннан концертлар булып узды. Тамашачы юбилярны аягүрә басып алкышлар белән каршы алды. Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева Президентның Рәхмәт хатын укыды. «Бүген татар халкы өчен зур бәйрәм. Шушы алкышлардан да Сез тамашачыга ничек кадерле икәнне аңларга мөмкин... Бу җырчының соңгы концерты түгел, ә юбилей тантанасының башлануы гына»,—диде ул.

Мәшһүр җырчыбызга Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Башкортстан Президенты М. Рәхимов котлау телеграммалары юллаган. И. Шакировны Үзбәкстаннан котларга килгән дусты Шамил Хәкимов ана келәм, алтын җепләр белән чигелгән чапан һәм баш киеме бүләк итте. Артистны экран аша Россия һәм чит илләрдән аның иҗатын яратучылар тәбрикләде. Концертта Ә. Авзалова, Ф. Гафаров, Г. Ибушев, З. Сөнгатуллина, Р. Маликов, В. Ганиева һ. б. күренекле җырчылар чыгыш ясады. Кичә ахырында тантана хуҗасы Илһам Шакиров: «Татар җыры яшәгәндә безнең халыкның киләчәге булыр»,—дип, үзенең ышанычын белдерде.

## ЯШЬ ТАЛАНТЛАР КӨЧ СЫНАША

Быел республикабызда «Татарстан» балалар һәм яшүсмерләр иҗаты фестивале бәйгесе узачак. Мәдәният министрлыгы аны ТАССР оешуның 90 еллыгына багышлап үткәрә. Конкурс мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә балаларга өстәмә һәм урта махсус һөнәри белем бирү системасын күтәрү, яшь башкаручыларга ярдәм итү, милли классик сәнгать традицияләрен дәвам итү максатыннан уздырыла. Анда 6 яшьтән алып 20гә хәтле талантлар катнаша. Алар музыка уен коралларында уйнау, рәсем сәнгате, хореография, театр кебек төрләрдә үз осталыкларын күрсәтә алачак. Конкурсның беренче этабы январь, февраль айларында уку йортларында үтте. Апрель аенда ике турда җыенган яшьләр көч сынашачак.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Аны берлек рәисе Илфак Ибраһимов алып барды. Утырышта әдәби елга йомгак ясау, шул чара кысаларында яшь язучыларның әсәрләренә бәя бирү, аларның иҗатындагы төп юнәлешләрне, үсеш тенденцияләрен билгеләү зарурлыгы турында сөйләшү булды. Аннары Язучылар берлеге идарәсе әгъзалары Татарстан Мәдәният министр-

лыгынын Һади Такташ исемендәге премиясенә кандидатларны күрсәтте. Бу әдәби бүләккә быел шагыйрьләр Салисә Гәрәева һәм Рим Идиятуллин тәкъдим ителде.

### С. ДАЛИ ӘСӘРЛӘРЕ КАЗАНДА

Февраль башында Казанның Милли музеенда XX гасырның бөек рәссамы (чыгышы белән ул католонияле—Испания) Сальвадор Дали эшләреннән торган күргәзмә ачылды. С. Дали әсәрләрен Казанга Екатеринбург эшмәкәре Александр Шадрин алып килгән. Рәссам иҗатына гашыйк бу кеше дөньяның төрле музейларыннан, шәхси кешеләрдән Далиның байтак әсәрләрен сатып алып үзендә уникаль коллекция булдырган. Күргәзмә ачылган көнне музейга килгән халык сабантуй җыенындагы кебек күп иде. Ачу тантанасында Татарстан Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева да катнашты. «Казан халкының Сальвадор Дали белән очрашуы—күптән көтелгән вакыйга. Моның өчен Александр Шадринга зур рәхмәт!»—диде ул.

Шунысын да әйтү зарур: С. Далиның хатыны Елена Дьяконова Казанда туып-үскән кеше. Бөек рәссам ана багышлап күп әсәрләр иҗат иткән. Исән чакта С. Дали үз әсәрләренең Казанда күрсәтелүен бик теләгән булган икән.

### РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА КИЧӘСЕ

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының Кече залында шигырь кичәләре уздыру гамәлгә керә башлады. Моннан берничә ай элек бу сәхнәдә татарның бүгенге яшь шагыйрьләре мәйдан тоткан иде. Январь уртасында шагыйрь, прозаик, драматург, Республиканың М. Җәлил премиясе лауреаты Ркаил Зәйдулланың иҗат кичәсе булып үтте. Бу кичә театрның директоры Шамил Закиров, баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев, яшь драматург Илгиз Зәйниевләрнең теләктәшлеге, булышлыгы белән булдырылды. Кичәдә фәкать әдәби әсәрләр яңгырады. Халык язмышы турында ачынып язылган шигырьләрне кешеләр күңеленә сеңдерерлек итеп автор үзе укыды. Чәчмә әсәрләрнең кайбер үрнәкләрен Татарстанның халык артисты Хәлим Җәләй яңгыратты. Кичәгә рәсми вәкилләр, әдипнең каләмдәшләре, дуслары җыелган иде.

### ФОТОРӘССАМ УҢЫШЫ

Бөтендөнья сәнгать музейларында фотокүргәзмәләр оештыру, фото сәнгате коллекцияләре булдыру традициясе яшәп килә. Моңа чаклы Россиядә зур фототупланмалар Мәскәү Фотография Йортында гына бар иде. Ниһаять, күптән түгел Санкт-Петербург шәһәрендә «Рус музеенда беренче фотобиеннале» дигән бик зур фотокүргәзмә ачылды һәм фоторәсемнәр коллекциясе туплана башлады. Экспозиция өчен конкурска куелган төрле жанрдагы 6000 эштән 500гә якын фотосурәт сайлап алынган. Үзенең югары традицияләре булган Казан фотомәктәбе бу күргәзмәдә лаеклы урынын алган. «Казаннан танылган фотограф Рөстәм Мөхәммәтҗанов эшләре аерым урын алып тора. Әлеге авторның 17 фоторәсеме жюри тарафыннан төрле номинацияләрдә билгеләнгән. Аның почеркын тану авыр түгел. Әгәр дә аның фотолары (1970-2009 еллар аралыгында иҗат ителгән) тагын да күбрәк булса, бу күргәзмәне Рөстәм Мөхәммәтҗанов бенефисы дип тә атарга булыр иде», дип яза «Российская газета».

Әлеге фотобиеннале нәтиҗәләре буенча Рөстәм Мөхәммәтҗановка «U-ART: Син һәм сәнгать» (скульптор Пата) уникаль призы тапшырылды.

Рөстәм Мөхәммәтҗанов—Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе. Ул күп еллар «Ялкын» журналында эшләгән фотожурналист, шулай ук байтак фотоальбомнар, китаплар бизәгән фоторәссам буларак та билгеле шәхес.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татар әдәбияты зур югалту кичерде: 2010 елның 16 февралендә 67нче яшендә язучы-прозаик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Флүс Латыйфи** (Флүс Фатих улы Латыйпов) вафат булды.

Флүс Латыйфи 1943 елның 3 июнендә Татарстанның Мөслим районы Мөслим авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Урта белемне туган авылы мәктәбендә алганнан соң, ул Алабуга педагогия институтының филология факультетына укырга керә, ләкин 2нче курска житкәч, хәрби хезмәткә алынуы сәбәпле укудан аерылып торырга мәжбүр була. Гаскәри хезмәттән кайткач Ф. Латыйфи 1964-69 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укуын дәвам иттерә. Студент елларында ук татар матбугаты белән хезмәттәшлек итә башлый. 1968 елдан ул—Татарстан радиосында репортер, мөхәррир, яшьләр өчен тапшырулар редакциясе житәкчесе. 1985 елның сентябреннән Ф. Латыйфи «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясенә күчә, тагын бер елдан «Казан утлары» журналында эшли башлый—бүлек мөхәррире һәм журналның җаваплы сәркәтибе була. 1991 елда латин имлясы белән «Дөнья» дигән халыкара татар газетасы чыга башлагач, аны шул газетаның баш мөхәррир урынбасары итеп эшкә чакыралар. Әмма бу газетаның гомере кыска була. Шуннан соң Ф. Латыйфи берникадәр вакыт республикада яна чыга башлаган «Татарстан хәбәрләре» газетасында әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булып эшләп ала, ә 1993 елның көзендә «Татарстан» журналына баш мөхәррир урынбасары итеп билгеләнә. 1997 елда Ф. Латыйфи янәдән «Казан утлары» журналы редакциясенә әйләнеп кайта һәм шул вакыттан 2005 елның ахырынача журналның баш мөхәррир урынбасары булып эшли.

Әдәби язмалары, шигырьләре, төрле темаларга язылган очерклары белән республика күләмендә матбугатында 70нче еллардан даими катнаша килгән Ф. Латыйфиның «Кырагай» исемле беренче хикәяләр җыентыгы 1988 елда басылып чыга. Шул ук елда аның очерк һәм публицистик мәкаләләре тупланган «Вөҗданыңнан сора» дигән икенче җыентыгы да дөнья күрә. Әлеге җыентыктагы әсәрләре өчен язучы 1989 елда Татарстан журналистларының Х. Ямашев исемендәге бүләгенә лаек була.

1993 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Хыянәт» романы язучыга аеруча киң популярлык китерә, аны татар прозаикларының алдынгы сафына бастыра.

Ф. Латыйфиның әдәби иҗаты актив җәмәгать эшләре белән тыгыз бәйләнгән иде. Ул татар яшьләренең «Сәләт» оешмасы белән хезмәттәшлек итте. Алар өчен туган тел, милләт, дәүләтчелегебез тарихына багышланган мәкаләләрен үз эченә алган «Уяну» исемле әдәби-публицистик китабын чыгарды.

Без гомере буена милли әдәбият гаме белән яшәгән тынгысыз җанлы, ихлас күңелле каләмдәшебезне югалттык. Ул безнең күңелләрдә дә шундый булып сакланыр.

**Татарстан Мәдәният министрлыгы,**
**Татарстан Язучылар берлеге,**
**«Казан утлары» журналы редакциясе.**

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* «В. И. Ленин ТАССР төзелү турындагы декретка кул куя». **Л. А. Фәттахов, Х. А. Якупов** картинасы. 1950 ел.

*Дүртенче биттә:* язучы **Камил Тангалычев**.

# Яңа китаплар




**Нурихан Фәттах.** Аклан: роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009.—399 бит. Тиражы—2000 данә.

«Аклан»—Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттахның тәмамланмый калган соңгы әсәре. Бик күп фәнни-популяр әдәбиятка нигезләнеп язылган бу романында автор әдәби образлар аша Атлантида язмышын сурәтли һәм халкыбызның үткәне һәм киләчәге турында житди уйлануларга этәрә. Әсәр китап булып чыкканчы «Казан утлары» журналында 2007 елны басылып чыккан иде.




**Лирон Хәмидуллин.** Кичке шәфәкъ: документаль повесть, эссе, очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009.—255 бит. Тиражы—1000 данә.

Бу китап авторның авылдашы, мәшһүр гармунчы, Татарстанның халык артисты Фәйзулла Туишевка багышланган документаль повесть белән ачыла. Китапта шулай ук татар халкының күренекле шәхесләре—шагыйрь Дәрдемәнд, Закир Рәмиев, драматург Мирхәйдәр Фәйзи, композитор Латыйф Хәмиди иҗатларына һәм биографияләренә багышланган очерклар да урын алган.

Китапка кереш сүзне Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин язган.



Камил Тангалычев

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)